ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2012



# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ ОЕШУГА 20 ЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Президенты Указы**

Гражданнарның күпсанлы мөрәҗәгатьләрен, татар халкының үз телен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен, мәдәниятен торгызу омтылышын искә алып, республикадан читтә яшәгән милләттәшләребез белән икътисади, мәдәни багланышларны үстерү һәм киңәйтү йөзеннән фәрман бирәм:

— 1992 елның июнендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессын уздырырга.

*Татарстан Республикасы*
*Президенты* *М.Ш.Шәймиев*

*1992 елның 20 гыйнвары*











# Казан утлары
# Qazan utlari

2012

# 12
**(1082)**

_ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:_
_«ТАТМЕДИА»_
_ачык акционерлык җәмгыяте_

татмедиа

_БАШ МӨХӘРРИР_
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

_ИДАРӘ:_

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
_(җаваплы сәркәтип)_
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
_(баш мөхәррир урынбасары)_

---

_Мөхәррирләр:_ **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

_Гамәли хезмәткәрләр:_ **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
_Исәп-хисап бүлеге:_ **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

_420066, Казан, Декабристлар урамы, 2._
_Баш мөхәррир — 562-10-62._
_Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38._
_Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28._
_Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53._
_Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53._
_Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28._
_Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80._
**Факс** — (843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Әрем балы. *Хикәя* ..... 5
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр. ..... 16
Фәрит ЯХИН. Умырзая. *Роман.* ..... 22
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Үзем өчен бер хакыйкать ачтым. *Шигырьләр.* ..... 56
Вера ХӘМИДУЛЛИНА. Сагыш моңлы жырын сузар... *Шигырьләр.* ..... 91
Дилә БУЛГАКОВА. Озын чәч. *Хикәяләр.* ..... 94

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Рәдиф СӘГЪДИ. Галиҗәнап Гатаулла хәзрәт. *Мелодрама-легенда.* ..... 60

**ЯҢА КОНСТИТУЦИЯГӘ 20 ЕЛ**

Минтимер ШӘЙМИЕВ. «Вәкаләтләребезгә тыкшыну ышанычны какшата». ..... 106
Әхмәт МАЗЬАРОВ. Татарстан Республикасы Конституциясе: тарих һәм бүгенге көн. ..... 108

**ТАРИХ**

Ф.НУРИЕВА, М.ПЕТРОВА, М.СӨНГАТУЛЛИНА. Беренче төрки басма китап. ..... 117
Фәйзелхак ИСЛАЕВ. Яңа керәшен кантуры. ..... 120
Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА. Имам һәм мөдәррис *(Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең тууына 150 ел).* ..... 130

**СӘНГАТЬ**

Милли моңнарыбыз илчесе *(Айрат ХӘМИТОВ, Венера ГӘРӘЕВА, Рәшит МОСТАФИН, Раилә ГАРИПОВА белән Гөлзадә БӘЙРӘМОВА әңгәмәсе).* ..... 134

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Муса МӨЛЕКОВ. Хунвэйбиннар заманы. ..... 138

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 148

**ОЧРАКЛЫКЛАР ОЧРАКЛЫМЫ?**

Алмаз ХӘМЗИН. Аккан сулар кире кайтмый. ..... 154

**ГАЗИЗ МӨХӘММӘТШИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Камил КӘРИМОВ. Ирләр кырыкта сынала. ..... 162

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Батулла мелла хикәяләре. ..... 172

2012 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ..... 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Ф.ЯХИНА «Подснежник (окон.);
рассказ А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Полынный мед»; рассказы Д.БУЛГАКОВОЙ;
стихи Р.ФАЙЗУЛЛИНА, Ф.ГАБДРАХИМА, В.ХАМИДУЛЛИНОЙ.
«Драматургия»: мелодрама-легенда Р.САГДИЕВА «Гатаулла хазрат».
«20 лет новой Конституции Татарстана»: выступление М.ШАЙМИЕВА,
доклад А.МАЗГАРОВА на международной научно-практической конференции.
«История»: Ф.НУРИЕВА, М.ПЕТРОВА, М.СУНГАТУЛЛИНА. «Первая
тюркская печатная книга»; Ф.ИСЛАЕВ. «Новокрещенская контора» (окон.);
статья А.СИБГАТУЛЛИНОЙ, посвященная 150-летию С.Мифтахутдина.
«Искусство»: беседа Г.БАЙРАМОВОЙ с А.ХАМИТОВЫМ, В.ГАРАЕВОЙ,
Р.МУСТАФИНЫМ и Р.ГАРИПОВОЙ, посвященная 75-летию Государственного
ансамбля песни и танца Республики Татарстан.
«Литературная критика»: М.МУЛЮКОВ. «Эпоха Хунвэйбинов».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Библиографический список произведений, опубликованных в 2012 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимнее утро»; писательница Вера ХАМИДУЛЛИНА.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and Poetry»: novel by F.YAHIN «Snowdrop» (ending);
story by A.AHMETGALIEVA «Wormwood honey», stories by D.BULGAKOVA;
poems by R.FAYZULLIN, F.GABDRAHIM, V.HAMIDULLINA.
«Dramatic art»: romance-legend by R.SAGDIEV «Gataulla hazrat».
«Journalism»: Speech by M.SHAIMIEV, report by A.MAZGAROV
in international scientific and practical conference dedicated to 20th anniversary of Constitution
of Republic of Tatarstan.
«History»: F.NURIEVA, M.PETROVA, M.SUNGATULLINA. «First
Turkish Printed Book»; F.ISLAEV. «Novokreschensk office» (ending);
article by A.SIBGATULLINA devoted to the 150th anniversary of S.Miftahutdin.
«Art»: Interlocution of G.BAYRAMOVA with A.Hametov, V.Garaeva, R.Mustafin and
R.Garipova dedicated to 75th anniversary of State Song and Dance Ensemble of Republic of
Tatarstan.
«Literary Criticism»: M.MULYUKOV. «Era of Red Guards».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages».
Bibliographical list of works published in 2012.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Winter Morning», the writer Vera KHAMIDULLINA.

*The magazine edits monthly*

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 03.12.2012, график буенча 03.12.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-1659. Тираж 4006.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча
Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Айгөл
Әхмәтгалиева

# ӘРЕМ БАЛЫ

ХИКӘЯ

Капкадан алып чыгып киткәндә, ишегалдына томырылыплар карады Йолдызы. Адәм акыллары бар диярсең үзендә: аерылышуны сизгән бахырның ике күзе дә мөлдерәмә яшь белән тулы иде. Шаһидәгә «бәхил бул» диюе булды микән, сузып-сузып мөгрәгәндәй итте дә, муенына тагылган бау тартылуга, ни чарадан бичара кыяфәттә яна хуҗасы артыннан атлады.

Гәүдәсенең җегәре киткән Шаһидә капка бигән төшерерлек хәл тапмады, хәлсезләнеп бакча коймасына сөялде. Каны качкан бармакларының туңуын да сизмичә, чит-читләре бәсәргән вәлен[1]* рәтләгәндәй итте. Җиң очлары сизрәгән иске сырмасына кунган карны сыпыргалады. Кизитегенә эләккән салам бөртекләрен кагарга иелгәч, сабыр савыты тулышып, нарасый баладай елап җибәрде.

И Ходаем, сыйлы көне — сыерлы көненнән аерылгач, ни белән генә көн үткәрер? Булганны бетерүкәйләр тиз, һай, бик тиз шул. Менәтрәк, балалары ничә кайтса, «нигә сыер асрап интегәсез, кибет тулы сөте, мае» дип авыз суы корыта иде, алар да тынычланыр инде. Парлы чакта ничек тә икәүләп теркелдәделәр әле, балалар сүзенә карап тормадылар анысы. Карты иртәрәк китеп барды шул, ашыкты, һич югы җәйне көтмәде. Гомер бакый үзе турында уйлый белми яшәде, соңгы сулышын да кеше өчен дип алды, мәрхүм. Күршеләрнең абзарына ут капкач, ашыга-кабалана су ташып йөргән иде, трактор астына килеп керүен дә абайламаган. Үлемнең кайсы гына үкенечле түгел...

И-и, хатын-кызкайлар... Без - муен, башны без борабыз дип күпме генә шапырынсак та, дөньяның тоткасы ирләр шул, ирләр...

— Әнкәй, йөрәгеңне бозып торма инде, әйдә, кер. Мин дә җыена башлармын. — Болдырга чыгып баскан төпчегенең тавышы Шаһидәне чынбарлыкка кайтарды. Ул, кул аркасы белән бит очларын сөрткәләде дә, гер аскандай авырайган аягын көчкә сөйрәп, баскычка таба атлады.

— Күрчәле, яланөс чыгып баскан, акыл кермәсә дә кермәс икән, агай...

[1] Вәл (диал.) – кәҗә мамыгыннан бәйләнгән мамык шәл.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА – *язучы; «Болытта җиләк үсә», «Синең өчен яшим» исемле китаплар авторы. ТР Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

– дип кызын орыша-орыша өйгә үтте. – Хәния дим, идәнгә ике банка сөт куйдым, сөт өсте белән катык халадильникта онытылып кала күрмәсен. Йолдызымның соңгы ризыкларын авыз итсеннәр дип күп итеп корт та әзерләгәнием, аны да алырсың.

– И, әнкәй, үзеңә үзең мәшәкать тудырмасаң инде. Корт ясыйм дип сөт кайнатып, сәгатьләр буе плитә саклаганчы… – Күзге каршында иннек сөртеп маташкан Хәния әле ишек төбендә тау булып өелеп торган кучтәнәчләргә, әле әнкәсенең кечерәеп, бөрешеп калган гәүдәсенә кызганулы караш ташлады. – Әнкәй, без ач ятмыйбыз лабаса, шулкадәр төямәле.

– Ярар, сөт-майны соңгы тапкыр апкитәсең, чәпчемә. Күз кайтуыгызда атагыз юк иде, бу кайтуында сыер юк, алдагысында мин булмам – Ходайныкын белмәссең.

– Теләсә нәрсә сөйләнмә әле, әнкәй. Саулыгың минекеннән ныграк, яшәргә дә яшәргә әле.

– Сигезенче дистәңне ваклаганда көнеңне түгел, сәгатеңне саныйсың, балам.

– Ярар-ярар, дөбердәтеп сыер сауганда яшеңне дә белмәдең, зарланма. Кызлар кебек әле син. – Хәния, күңеле йомшарганны сиздермәс өчен, юри дорфарак булырга тырыша иде.

Дөбердәтеп сауганда, ди, и бала-бала. Шаһиданең кәкрәеп каткан бармаклары сыер имчәген берәм-берәм тартканын, чиләгә тулганчы үзенең ун бүленеп, ун ял иткәнен каян белсен инде Хәниясе.

– Гәзиткә төреп күкәй әзерләп куйдым. Чүпрәк сумкада апаңнарга дигәне. Аларга дигән сөтне шешәгә тутырдым.

– Элегрәк көлә идең, әнкәй, хәтереңдәме? Киткән кыздан, мине дә апкитмәсә ярар иде дип, почмактагы пумала куркып тора, ди торган идең. – Хәния чәч-башын төзәткәләп бетерде дә, әнисенең ябык гәүдәсен кочаклап алды. Соңгы араларда бигрәк бирешә шул Шаһидә. Сынар канат дөнья көтеп маташканда, янәшәсендә бар куанычы булып җирән сыртлы Йолдызы калган иде, бүген менә аны да сатып җибәрде. Биш кызы, оныклары күпме генә чакырмасын, берсендә дә торырга ризалашмый шул. Шәһәрләрендә сулышы кысыла; күрше авылдагы олы кызы инде үзе каенана булып, улы-килене белән дөнья көтә – алар катына барып сыенмас бит инде… Мәшәкать димиләр тагын, рәхмәт төшкерләре, ике көннең берендә хәлен белеп, янына кайтып кына торалар. Суының салкыны, кайнары өйдә, газы кергән, үзе юа торган кер машинасы бер хикмәт – тәндә җан барында шушында яшәргә язсын берүк.

«Гомерем, җегәрем булганда балаларымны сөттән өзмәм» дигән сүзе бар иде Шаһиданең. Балачагында үзегенә үткән, бүген дә бәгыреннән кан саркыткан вакыйгалар әйттерде шулай дип. Таң алдыннан күргән татлы төш кебек, җәһәт кенә узды да китте шул ачлы-туклы балачагы, чабаталы яшьлеге… Бер генә көненнән булса да урап киләсе иде дә бит. Үрелеп кенә күз төшерәсе иде… Алайса, хәзерге заманның көзгесе күзгә дисеңме: гармун күреге кебек җыерчыкланып беткән йөздән элекке Шаһиданең чалымнарын эзләп-эзләп тә табарлык түгел. Күр инде: кайчандыр көлтә-көлтә ут бөркеп торган чая яшел күзләренең урыны гына утырып калган диярсең. Төсләр уңган, җуелган. Яулык астыннан күренмәсә дә, сүс шикелле юкарган, толым дисәң хәтер калырлык чәчкәйләр дә мамыкка охшап бетте инде. Әй үртәлә иде яшь Шаһидә шул толымнарының төсенә: көнбагыш чәчәге кебек җете сары да түгел ичмаса, көлсу дулкын булып, җилкәсенә тарала да төшә. Үреп куйса, инбашында кәҗә койрыгы кебек тырпая да кала… Кайчандыр мендәр чигүендәге гөләп таҗына охшап, турсаебрак торган алсу иреннәрнең дә күптән каны качкан; әйтелмичә, йөрәк түрендә

йомарланып калган сүзләр хәзер инде тирән-тирән буразналар булып ирен читенә күчкән.

Сыерын сатып җибәреп үз сүзенә хыянәт итмәде микән Шаһидә? Хәерле булсын... Бер җамаяк сөтнен түгел, кеше кадәр кешенен кадере калмаган заман диген. Алай дисән, кайсы чорда адәм баласынын кадере булды сон ул? Шулай да, шулай да...

***

— Инәкәй, әтекәй! — Шаһидәнен чатнап торган тавышы әллә каян ишетелә иде. Ялан тәпиен ялтыратып, ишегалдына чабып кергән шәйгә кыз гәрәбә төсенә кереп ялтыраган баскычны ике атлап бер генә сикерде дә бәрелә-сугыла өй эченә үтте. — Әтекәй! Төштән сон, тург ясарга дип, кәнсәләрдән безгә төшәчәкләр! Фәһимә апа әйтте, кулга тотардай әйберкараларын базга булса да күмсеннәр, диде. Он-мазарыгыз булса, анысын да яшерегез, диде. Уф! — Сулышы капкан кыз, мич аралыгына үтеп, чиләктән агач чүмеч белән су алып эчкәч, лып итеп инәкәе янына — сәкегә утырды. Утын пуләнен култык астына кыстырып, мич алдында пычак белән чыра телеп маташкан әткәсенен йөзеннән төс качты, ул, билендәге алъяпкычын сүтә-сүтә, артсыз урындыкка килеп чүмәште.

— Ала-ай... — диде, бердәнбер кулы белән ияген сыйпагандай итеп. — Ала-ай... Үтмәс балта белән юнган калхузлары безнен сырган юрганга калды микәнни сон... — Нигъмәт агай берара дәшми-тынмый башын иеп утырды. Аны күз карашыннан анларга өйрәнгән Мәрзиясе сүзгә кушылырга ашыкмады, иренең бер-бер фикергә килүен көтте. Ләкин тынлык озакка сузылгач, түзмәде:

— Болай да күзгә кырып салырлык әйбер калдырмадылар бит инде, тагын ни генә эзләп төшәләр икән, җир йоткырлары?! — дип рәнҗүле тавыш белән иренә текәлде. — Атасы дим, әйт инде берәр сүз!

— Калхузларына кермәгән өчен черки урынына канны эчкәннәр ие, хәзер кандала урынына ябышырга уйлаганнар инде, алайса...

— И Ходаем, шушы авылда яшәп, үзеннекеләр шулай мыскыл итсен инде... — Мәрзия, Шаһидәнен кош баласыдай авыз ачып әле әтисенен, әле үзенен сүзен тынлап утыруын күргәч, ана эндәште. — Бар, балам, Зәкия түтәнне эзләп тап, чишмәгә-мазар төшеп китмәде микән. Бирнә-сөлгеләрен булса да бакча артлатып кына әбиеннәргә илтеп кайтыгыз. Теге убыр авызларны белмәссен, җан күек күргән, төн утырып чиккән тастымалынны да тартып алырга күп сорамаслар.

Теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалган Шаһидә артыннан әтисе дә кыймылдады. Нигъмәт агай, ишегалдына чыккач, балтасы суга төшкән кешедәй бераз әйләнеп-тулганып йөрде дә, үз уйларынын очыкырыена чыга алмасын анлап, тагын өйгә кереп китте. Төртсән аварга торган дүртпочмаклы өйдән нинди зиннәт табарга уйлаганнардыр, нинәрсәне тамаша күрсәтеп сатарга җыеналардыр — һәрхәлдә, Нигъмәт үзе, күпме эзләнсә дә, хуҗалыгында кулга тотардай байлык күрмәде. Сәвит дигәннәре узган ел бар булганын — алты почмаклы зур өен дә, яна салган келәтен дә, ихатадагы мал-туарын да талап алды лабаса. Ястык-мендәргә чаклы алып чыгып киттеләр. Ярый инде үзләрен, мулла гаиләсен мыскыл иткән кебек, берәр кара мунчага күчермәделәр. Аргы урамдагы хамсамул Нәкыйпнен һәр ярыгыннан җил өреп торган өе — яна блачнын мәрхәмәте иде... Бүген килеп дүрт кешелек гаиләнен бар карап торганы — салам түбәле абзардагы Мәрүчкә. Бөтен болын-кырны әлеге дә баягы калхузлары үзенеке дип игълан иткәч, Нигъмәт кебек аерым хуҗалыкларга сыер көтәр урын да калмады. Узган ел капка төбендә үлән

чемченеп йөргән каз бибиләренә тиклем калхуз келәтенә илтеп яптылар бит, адәм гыйбрәте.

Кәнсәләрдә эшләүче чыбык очы туганнары Фәһимә дөрес әйткән икән, төш турысы узганны да көтмәделәр, өч-дүрт кеше – аларның берсе генә районнан килгән вәкил булып, калганнары үзләрен авыл активы дип йөрткән түбән очныкылар иде – Нигъмәтләрнең болай да кысан өенә бастырып килеп тә керделәр.

Шаһидә өйләренә нинди афәт кергәнне сабыйлыгы белән аңлап бетермәсә дә, бу ыгы-зыгының һич кенә дә кунак туе түгеллегенә төшенгән иде.

– Түтәй, – диде ул мич аралыгында яулык чите белән авызын каплап торган апасына пышылдап. – Толымындагы чулпыларны яшер инде, исәр, анавысы кыек танау көмеш дип белеп, тартып алырга да күп сорамас. Чәй савытын кисә-кисә, тикмәгә генә тырышканыбыз булыр.

Кыек танау дигәне – авыл халкы телендә Чүтчик дип йөртелгән счетовод Хәмит иде. Бераз шадра йөзендә уң якка авышыбрак торган борыны, болганчык су төсендәге йөгерек күзләре, авазларны йота-йота сөйләшүе аны җирәнгеч кыяфәттә күрсәтсә дә, кәнсәләр тирәсендәге кеше булганга, үзен Алланың кашка тәкәсе дип хис иткән, куштанлыгы, кансызлыгы хәттин ашкан бер бәндә иде ул.

Менә ул, мыскыллы елмаеп, балчык чүлмәктә утырган яран гөлнең башта бер, аннан икенче ботагын сындырып атты. Баланнар кызыллыгы белән балкып утырган гөл, кан таплары кебек таҗларын тәрәз төбенә коя-коя, идәнгә тәгәрәде. Чүлмәк янында яткан бәйләм җебе дә Чүтчик кулына күчте.

– Язығыз: бевсе кызыл, бевсе сары ике кәтүк!

Шаһидә, бу сүзләрне ишетеп, мич аралыгыннан атылып чыгуын сизми дә калды.

– Инәкәй, ул бит минем чигү җебе, аңа тимәсеннәр! – Кыз ике кулы белән чытырдап Чүтчик Хәмитнең җиңенә ябышты. – Кәтүк түгел ул, мин аны әбекәйнең иске тастымалларын сүтә-сүтә, үзем ясадым. Абзыкай, алма минем җепләремне, бир!

– Бу сытыгыгызны аяк астыннан алыгыз, кысылмасын! Ату тибеп очывывмын!

– Синнән булыр, кыз бала дип тә тормассың. Кызым, мин сиңа Пучы базарыннан яңаны апкайтырмын, бар, апаң янында гына тор! – Әткәсенең тыштан гаять тыныч тавышы Шаһидәнең үксүен баса алмады. Ул, исәр, исәр, дип авыз эченнән кабатлый-кабатлый, янә Зәкия түтәсенең кочагына сыенды. Ул арада Хәмит агач урындыкны сөйрәп китереп, мич башына үрмәләде. Алтын тапкандай ыржаеп, андагы җилпучны күтәреп төште.

– Ач таваканнав, шушымы бав оныгыз? Монда ике уч та юк бит! Явав, ул сезне бавыбев аяк сузудан коткава алмай бит! – Хәмит, ыржаеп көлгән җиреннән уртын чәйнәп басып торган Нигъмәтнең ут карашы белән очрашкач, тамагына кылчык кадалгандай тотлыгып калды. Аннан кискен хәрәкәт белән җилпучны идәнгә әйләндереп каплады.

– Аһ! – Мәрзиянең күкрәк авазы үзенә генә ишетелде бугай.

– Сез контвлавны йә ачка, йә салкынга катывып кына үтевевгә кивәк! Күзгә төтен җибәвмәкче буласыз, ә: имеш, хәервеләр, имеш, бев нәмәләве дә юк! Алтын-көмешегезне кая яшевгәнне бавыбев әйттевевбез! – Хәмит кырып юылган сап-сары идәнгә сибелгән он бөртекләрен күн итеге белән рәхәтләнеп таптады, үзе каны качкан иренен чәйни-чәйни, без карашы белән Мәрзиягә кадалды. – Бай кызы идең бит син ач бет Нигъмәткә

чыкканда, атаң сандык-сандык бивнә белән озатканны белмиләв дисенме әллә?

Яулык чите белән авызын каплаган Мәрзия кинәт дуамалланып китте:

— Иманыңны иблискә саткан нәрсә булдың тәки, башта әткәйләргә каныгып, аларның соңгы юрганнарына тиклем талап чыктың, хәзер безне тинтерәтәсең. Аласын узган юлы кырып-себереп алдыгыз бит инде. Адәм талаучы, жирбит! Каян килеп бездә алтын-көмеш булсын, мич артындагы тараканнар гына алтынга әйләнмәсә ...

— Анасы, телеңне әрәм итмә. Ходай барысын да үзе күреп тора. — Эчендә ут кайнаган Нигъмәт агай сабырлыгын җуймаска тырыша иде, ул, жилфердәп торган буш җиңен сәламәт кулы белән тотып, йодрыгын төйнәде.

Дүртесенең дә күзеннән яшь урынына кан агызганы — абзардагы Мәрүчкәне, Хәмит әйткәнчә, «тургка» куюлары булды. Аю биеткәнне карарга җыелгандай, жилкапка янына килеп өелгән халык берсен-берсе өзә-бүлә, Мәрзияләрнең күз текәп торган сыерын сатулашты.

Мәрүчкәне терәлеп торган күршеләре — жил иссә дә жилфердәрдәй ябык Касыйм алып чыгып китте. Нигъмәткә күз карашы белән нидер әйтергә теләгәндәй, тутырып карады, әмма бер сүз дә катмады. Сыгылып төшкән Мәрзиягә күтәрелеп тә карамыйча, өеннән алып чыккан бауны Мәрүчкәнең муенына салып, сыерны үз артыннан әйдәкләде.

Чынлап та затлырак мал табарына өметләнгән булды микән — Хәмит ишегалдын, базны, бакча-кура тирәләрен энә күзеннән үткәреп чыкты. Янәсе, янарак казылган урын шәйләнмиме... Ахыр чиктә, күзгә кырып салырлык да зиннәт-байлык тапмагач, җен ачуы белән котырып-кычкырып җибәрде:

— Әйттевевбез! Кая яшевгәнегезне бевзаман үзегез үк йөгевә-йөгевә килеп әйтевсез! Сәвит законы әйттевә ул!

Районнан килгән вәкил Нигъмәт һәм Мәрзияне үзе белән алып китте. Шаһидә белән Зәкияне исә, икесен тиң күз яшьләре белән елата-елата, кәнсә ишегалдындагы иске келәткә илтеп яптылар.

— Ата-анагызны исән күвәсегез килсә, байлыгыгызның кая качывылганын әйтегез. Аннавы дувт ягыгыз кыйбла!

***

Караңгы, юеш баз исе килеп торган шушы келәттә төн кунасыларын күзаллап, Шаһидәнең жаны үкчәсенә төште.

— Түтәй, монда тычкан юк микән, мин куркам! — диде ул апасының калтыранган гәүдәсенә сыенып.

Зәкиянең исә үз кайгысы кайгы иде. Ул жир идәнгә чүгәләп, бераз мышык-мышык килеп утырды да, тиен житезлеге белән сикереп торгач, күлмәк өстендәге чигүле алъяпкычын салып атты. Аны кулында бөтергәләде, ныклыгын тикшергәндәй, кат-кат тарткалап карады.

Шаһидә дә шыншуыннан туктап, шаккатып апасына төбәлде. Зәкиянең ниятен аңлап бетермәсә дә, нindидер ямьсез сизенүдән коты ачты. Апасының кулы белән кармалана-кармалана түшәм такталарын сыпыруын күреп, бөтенләй өнсез калды.

— Түтәй, син нишләмәкче буласың? — Кызның жан өшеткеч тавышы гына Зәкияне шөгыленнән туктатмады: ул келәтнең һәр тактасын, һәр бүрәнәсен барлап чыгарга җыенгандай ашыга-кабалана бер почмактан икенчесенә атылды. Аннан, кисәк хәле беткән кешедәй, бөгелеп төште дә, иңбашын дерелдәтә-дерелдәтә еларга тотынды.

— Адәм көлкесе, ындыр табагы чаклы келәттә тырпаеп торган бер кадак

кисәге булмасын инде... Яшим дисәң, яшәп, үлим дисәң, үлеп булмый дөньяларында.

Зәкиянең такмаклый-такмаклый елаганына Шаһидәнең куркулы пышылдавы кушылды.

– Түтәй, ычкындынмы әллә, минем үләсем килми, өйгә кайтасым килә. Тамагым ачты, әтекәйләрне сагындым!

Жир идәндә тезләрен кочаклап, бөрешеп утырган сеңлесенең бу сүзләрен ишеткәч, Зәкия такмаклавыннан туктады, яшь аралаш кызганыч елмаеп, Шаһидәгә карады. Сабый шул әле, кыз баланың язмышы кыл өстендә икәнен аңларлык яшьтә түгел.

– И апаем, син бәләкәй, сиңа тимәсләр. Менә теге жирбит Хәмит мине мәсхәрәләп ташласа, ни кылырмын? – Апасы, бер кулы белән Шаһидәнең инсәсеннән кочып, аның янәшәсенә сыенды.

Матур шул Шаһидәнең апасы, карап кына тормалы. Озын төз буен әйтәсеңме, уймак авызы, нигәдер гел моңсу итеп, өздереп караучы коңгырт күзләре, учка сыеп бетәрдәй нечкә биле дисеңме. Болай да кара кашларын, әнисе күрмәгәндә, корым белән каралтып, бит очларына кишер суы да тигезеп алсамы? Теләсә кем кызыгырлык.

– Кит, исәр, тумаган тайның билен сындырып утырма әле. – Шаһидә башта бик урынлы итеп әнкәсеннән откан сүзләрне кабатлады, аннан бала итәкле күлмәгенең кесәсеннән кечкенә саплы пәке чыгарды.

– Сиңа тиеп кенә карасын, шушының белән күзләрен чокып алырмын!

Апасының күзләре мангаена менгәнне күрмәсә дә, аның әйтергә өлгермәгән соравына җавап биргәндәй, батыраеп әйтеп куйды:

– Әухәт тәренеке ул, кичә шәпиле уйнаганда оттырды.

– Телеңә ничек тилчә чыкмыйдыр, кызый, әле тәре, әле исәр... Бир әле, хет шуның белән ишекне ачып булмасмы. – Зәкия сеңлесенең кулыннан пәкене алып, келәт ишеге янында кайнаша башлады. Тышкы яктан асылмалы йозакка бикләнгән ишек, кыз баланың чандыр кулларыннан үчекләп көлгәндәй, ыржайган аваз чыгарды.

– И Аллам, бөтен кеше пәке белән тимер кисәр ие аны...

Зәкиянең чарасызлыктан ачыргаланып әйткәне бу юлы Шаһидәне куркытмады, киресенчә, җен ачуын чыгарды.

– Түтәй, – диде ул, күпне күргән олы кеше кебек бик җитди итеп. – Исәр дими нәмә дисең инде сине. Кем инде шулай итеп тимер кисәргә маташсын. Анавысы йозакка туры китереп, тактаны җомрылатып чокып карале. Чокы да чокы инде, аннан каерып карарсын.

Зәкия беренче кат күргәндәй сеңлесенең арык гәүдәсенә текәлде. Сабый гына диген инде моны! Әткәсенең «Шаһидәгә малай булып кына туасы калган» дип көлгәне рас түгелме соң?..

– Синең пәкең безне төрмәдән коткарды дип сөйләсәм, теге капчык белән суккан ышанмас та әле, име, түтәй? – Инеш буендагы талларга ышыклана-ышыклана бакча артлатып кайтып килгән шәйгә Шаһидә пышылдап апасына эндәште.

– Кемгә сукканнар дисең, бер сүзеңне аңларлык түгел! – Зәкия як-ягына карана-карана атлавын дәвам итте.

– Суккан ди сиңа... Әухәтне әйтәм, сабын куыгы очырасың дигән булыр әле.

– Әухәт тә Әухәт телендә. Әтекәйләр ни хәлдә икән анда? Җибәрсәләр генә ярар инде үзләрен, и Ходаем!

Могҗиза димә инде – алар өйгә узуга, аякларын көчкә сөйрәп, ата белән ана да кайтып керде. Төн ката район үзәгеннән жәяү теркелдәгәннәр, тан атканны да көтеп тормаганнар.

— Сезнең бәхеткәдер инде, бәбекәйләрем, дөньясында мәрхәмәтле жаннар да калган икән әле. — Мәрзиянең жеп өзәрлек хәл-әхвәле булмаса да, кызларын исән-имин күрү шатлыгыннан күгәрчен урынына гөрләде. Мич кашагасыннан теленгән чыра үрелеп алгач, ут элдереп жибәрде. Өй эчендәге пыран-заран килгән дөньяга күз төшергәч кенә, йөзе тартылып, сулып калды.

— Балам, теге дәжжал таптаган онны канат белән ипләп кенә себереп ал әле, иләгәч, бер пычрагы да калмай аның, умач итәрбез, — дип Зәкиягә эндәште.

Бераздан, сүз берләшкәндәй, дүртәүләп как сәкегә тезелеп утырдылар.

— Бер изгелек мең бәладән коткара дигәннәре хак икән, агай. — Әнкәсе, үз-үзе белән сөйләшкәндәй генә әйтеп куйгач, Шаһидә, аның култык астына сыенып:

— Инәкәй, ә безне берәү дә коткармады, без үзебез качып кайттык, менәтрәк, вәт! — дип, күргән-кичергәннәрне иркенләп сөйләргә җыенган иде, түтәсе иплэп кенә беләген кысып куйды. Янәсе, тел белән тегермән тартуыннан туктап тор әле.

— Әтекәй, сөйлә инде, нәмәләр булды районда? — Буй житкергән Зәкия сеңлесенә караганда күпкә сабыррак, төплерәк шул — алҗыган, хәлсезләнгән Нигъмәт үзалдына көчсез генә елмаеп алды.

— Өченче ел буранда адашып, малае белән бер адәм кереп кунган ие бит, тикшерүче дигәннәре шул булып чыкты. Үзе танымаса, аны жүнләп карау да юк инде... «Сөт эчереп, сез генә исән калдырдыгыз безне», дип ике куллап күреште. Өтермәнгә тыгарлар дип барган жирендә шулай каршы алсыннар әле, Ходайның хикмәте.

Хәтерли, бик яхшы хәтерли кызлар ул кышны: юньле кеше этен урамга чыгармас давыллы, буранлы кич иде. Үзләренең алтыпочмаклы өйләрендә яшәгән чак иде. Әниләре тәрәзәләрне юрган-мендәр белән томалап бетерде, бусага төбенә иске сырманы түшәп куйды. Сызгырган-улаган авазлар белән бергә, тәрәзә шакыгандай тавышка башта игътибар итмәделәр, тик әлеге тавыш торган саен кабатлангач, Нигъмәт агай өстенә элеп, ишегалдына чыгып китте. Бераздан аның:

— Әйдәгез, әйдә. Анасы, кунакларны каршы ал, — дигән тавышына ияреп, бусагада ике жан иясе пәйда булды. Берсе, буена караганда, Шаһидә тирәсендәрәк — сигез-тугыз яшьләрдәге бала, икенчесе — озын буйлы, бишмәт якалары, мыегы бәсләнеп каткан урта яшьләрдәге ир иде. Чишенеп, сөйләшер хәлгә килгәч, шул ачыкланды: буранда юлларын адашып, бөтенләй кире якка килеп чыккан әти белән ул икән болар.

Икесе дә шактый гына туңарга өлгергәннәр иде. Нигъмәт селкенерлек тә хәле калмаган малайның кул-аякларын уарга кереште. Шаһидә белән Зәкия аш ягының чаршавын төшереп, шул якта кайнашырга тотынды. Мәрзия, башына яулыгын бәйләп алды да, «ярый әле кичке сөтне калдырганыем» дия-дия, казан астында жемелдәшкән күз өстенә калай табак белән сөт утыртты. Стенадагы шүрлектән чүпрәк капчыкка салынган мәтрүшкә эзләп алды. Кайнарга иткән сөткә мәтрүшкә ваклап салгач, табакның бер читен бияләй белән тотып, янә күз өстенә утыртты. Бераздан, хуш исләре борынны кытыклаган сөтне ике жамаякка бушатып, чакырылмаган кунакларга сузды. Мәтрүшкәле сөт, аннан мәтрүшкәле чәй эчкән юлчыларга әкрен генә төс керә башлады. Төн уздыргач, «Үзем өчен түгел, улым өчен бик курыккан идем, коткардыгыз, мең рәхмәт сезгә!» дип, бик жылы саубуллашып киткән кеше бүген менә Нигъмәт белән Мәрзияне коткарган, димәк. Өстәвенә, кызларыгызга жил-янгыр тимәс, дип тә ышандырган, рәхмәт төшкере.

Бүгенге борчулы көн шаукымын сөйләшә-сөйләшә, керфек какмый таң аттырды алар. Төн пәрдәсен ертып, тәрәзәдән шәфәкъ нурлары үрелеп карагач, Мәрзия, сыер саварга вакыт дип, чәчрәп дигәндәй сәкедән төште дә, корт чаккандай дертләп, үксеп еларга тотынды.

— Сыеркаем, сыеркаем...

— Ярар, анасы, баш исән бит әле... — Басынкы табигатьле, кешегә беркайчан күтәрелеп бәрелмәс Нигъмәт агай хатынын юатырдай артык сүз тапмады.

Бер-берсенә ялганып үткән көннәрнең иртәсе дә, киче дә һаман шул Мәрүчкәгә килеп тоташа башлады. Җаннан артык күргән малкаеның иртән күрше ихатадан чыгып китүе, кичен күрше ихатага кайтып керүе күзенә чалынмасын өчен Мәрзия үз-үзеннән качарга әзер иде. Ире күрше авылдан шактый мул сөтле кәҗә алып кайткач та, аны ишегалдында түгел, караңгы абзар эчендә саварга гадәтләнде. Үзе кәҗә имчәге тарта, үзе, күз яшьләренә буылып, Гөлсемнең күрше ишегалдында чажлатып сыер сауганын тыңлый. Анысы да, күзгә күренсә, Мәрзиянең ярасына тоз салырга теләгәндәй, теле-теле йокмый сыерны мактарга тотына.

Менә бүген дә Гөлсем, төртсәң аварга торган коймасына сөялеп:

— И сыерыңның сөтеннән ундык, Мәрзиякәем, бидрәм чүмәкәй булганчы савам бит. Иллә мәгәр холкы яман, койрыгы белән битемне кыйнап кына тора. Аптырагач, ботына бәйләп куйганыем, аягын күтәрә башлады, иблис токымы. Сезне әйтәм, кәҗә алгансыз, дигән иде Касыйм, саудырамы? Шулай инде, ишле өйдә сөтсез буламы соң, — дип чәте-чөте сөйләнде дә, Мәрзиянең авыз ачып сүз катканын да көтмичә, өенә кереп тә китте.

Шулай инде, ике карга талашса, бер козгынга җим төшәр, диләр бит. Күрче, кәнсәләрнең Нигъмәт дөньясын пыр туздыруы берәүләрне ничек бәхетле иткән.

Капка төбендә бер-берсе белән телләшә-телләшә бишташлы уйнаган балаларның сөйләшкәне дә әлеге дә баягы сыерга килеп тоташа иде. Әнисенең әле генә әйткәне батырлык өстәп җибәрдеме, Касыймның үзе кебек үк үтә күренмәле малае Әүхәт:

— Безнең сыер бар, без бәрәңгене сөт белән ашайбыз! — дип Шаһидәне үртәп, беләген чеметте.

— Сезнеке түгел, безнең сыер ул, исәр! Көтүдән кайтканда да инәң чыбык белән ярып кына алып керә ишегалдыгызга, ул туп-туры безгә кайта, менәтрәк, вәт! — Тамак төбенә төер утырса да, кыз шушы җиз баш алдында сер бирергә теләмәде, үзе дә Әүхәтнең бил буеннан борып чеметеп алды. — Как сөяк — тач май, как сөяк — тач май! — дип үртәп такмакларга да онытмады.

— Ә сез хәзер кәдә сөте эчәсез, фу-у!

Кәдә, кәдә, кәдәкәй,
Имиләрең бәләкәй.
Бер ыстакан сөт бирмисең,
Каһәр суккан нәмәкәй.

— Инәкәй әйтә, кәҗә сөте сыерныкына караганда да файдалырак, ди, беләсең килсә!

— Сасы бит ул, аны ничек эчәсез? Фу-у-у...

— Син үзең сасы! Безнең Әүхәдән мамык исе генә килеп тора!

— Диванадыр син, кем инде кәҗәгә шундый исем кушсын!

— Инәкәй әйтте, кышка аның бәкәйләре туачак, диде. Кәҗә тәкәсе туса, анысына бөтенләй Әүхәт диярмен әле, вәт!..

Көтү кайтыр вакыт җиткәч, әнкәсенең кырык сәбәп табып ишегалдыннан

өйгә кереп китүенә күнекте инде Шаһидә. Әнисе урамда көтү тузаны тынгач, тавыш-кара беткәч кенә чыгып, Әүхәне савып керә. Мәрзиянең нуры сүнгәндәй төссезләнеп калган күзләренә карагач, Зәкия белән Шаһидә кәҗә сөте салынган чәйне дә борын жыермый гына эчә. Белә ич алар: читән койма гына аерып торган күрше ишегалдында Гөлсем апалары дөбердәтеп сыер сауганда әнкәләре йөрәгенә урын таба алмый; Мәрүчкәнең мөгрәгәнен ишетсә дә, атылып чыгардай булып ишеккә талпына.

Беркөнне Шаһидә урамнан күз яшьләренә буылып кайтып керде.

— Инәкәй, Мәрүчкәне үгез сөзгән, жилене канга баткан!

Тәрәзә төбендәге гөл үсентесенә су сибеп маташкан Мәрзия дертләп китте, әмма эндәшмәде.

— Ишетмисеңме әллә, инәкәй, Мәрүчкәне сөзгәннәр, дим!

— Хуҗалары бар бит, карарлар. — Мәрзия, яралы кош кебек тыпырчынган йөрәген тыярга теләгәндәй, сул кулы белән күкрәген кысып тотты. Үзе, карашы белән тартып алырдай булып, тәрәз аша Касыймнар ишегалдына текәлде. Берара өй эчендә үле тынлык урнашты.

— Карга казга охшыйм дип ботын сындырган дигәннәре шушы була инде. Гөлсем бик хәтәр кыланып, сыер асрамакчы иде бит. Эт эченә сары май килешәме? — Мәрзиянең тавышында әрнү катыш ниндидер тантана ишетелгәндәй булды.

— Сина әйтәм, күршеләр белән әчелешле булып йөрмә тагын. — Нигъмәт, иске урындыкка аяк ясап маташкан жиреннән, башын күтәрми генә хатынына эндәште. — Гөлсем чәпчебрәк йөрсә дә, эчендәгесе тышында. Мал аркасында бозылышып ята күрмә. Әнә теге кабихләрне әйт син, кеше кулы белән утлы күмер тотмакчы булалар. Күз яше өстендә төзелгән блачларының гомере булыр микән, ай-һай...

Шаһидә белән Зәкия, юк сәбәпне бар итеп, тышта уралдылар. Күршеләр ишегалдында күз яше, ыгы-зыгы — мәет чыккан диярсең. Мәрүчкәнең канга баткан, актарылып чыккан жиленөнә карарлык түгел иде. Бичара сыер, үз хәлемне үзем генә беләм дигәндәй, вакыт-вакыт сузып кына мөгрәп куя. Аны кызганудан кызларның үзәкләре өзелде, икесе дә, йодрыкларын тешли-тешли, үзалдына үкседе. Әниләре ни йөрәге белән түзгәндер, тәки ишегалдына чыгып та карамады.

Икенче көнне кичкырын, һич көтмәгәндә, өйләренә жил-жил атлап Гөлсем килеп кергәч, Мәрзия башта сагаеп калды. Күрше хатыны, күнегелгән ордым-бәрдем гадәтен читкә куеп, балаларча елап жибәргәч, аптырауга ук төште.

— Каргагансыңдыр инде, Мәрзиякәем, рәхәтен күрмәсеннәр дигәнсеңдер. Синең сыерына тора салып кызыккан дисеңме? Кешегә сүләп җөрмәгәч ни... Касыймкаемның хәле хәл, үпкәсенең рәте юк бит. Кала брачлары көн саен сөт эчәргә кушып кайтарган булган. Каян алып эчерәем? Яз көне сыеркаемны үз кулыбыз белән житәкләп калхуз фермасына илтеп бирдек бит. Бозаулагач, бозавын үзегезгә алырсыз дигәннәр ие дә, бирделәр, тот... Бер атналык бозауны ачка тилмертеп үтерделәр, адәм тәганәсе. Мәрүчкәннең сөтенә тиендек дигән ием, бер бәхетең булмаса жук инде, Мәрзиякәем, жук. Әнә, өйалдына ярты чиләк сөт кертеп куйдым, тоташ кан, аны ничекләр эчерәем Касыймга? Җан талашып көчкә ике имчәген сава алам, жилене мендәр чаклы шеште инде, Мәрзиякәем, нәмә эшләргә дә белгән жук. — Алъяпкыч итәген кайтарып, мышык-мышык килгән борынына каплаган Гөлсем, ниндидер ярдәм өмет иткәндәй, ялварулы караш белән Мәрзиягә төбәлде.

— Кеше каргай торган гадәтем юк, йә үз башыңа төшәр, Алла сакласын... — Мәрзия, ни әйтергә белми бертын утыргач: — Калхузыгызның мал

духтыры бар түгелме соң, нигә эндәшеп карамайсың, бер-бер хәл кылыр ие, – дип өстәп куйды.

Юк шул, калхуз духтыры да, Нигъмәт белән Мәрзиянең үлән сулары сөртеп маташулары да ярдәм итмәде – бура хәтле сыер, биш-алты көн күзгә карап инәлеп ятты да, үлеп тә китте.

***

Күпереп торган ап-ак йонлы, бераз мут карашлы кәҗәкәйне Шаһидә якын итәргә дә өлгергән иде. Әүхә дип исем кушуына өйдәгеләр бер-берсенә карашып елмаеп ризалашкач, аерата сөенде. Кәҗәгә кушаматы белән эндәшкән саен, ни хикмәттер, күрше малаеның чандыр гәүдәсе, бакыр тәңкәдәй ялтыраган чәчләре, кешегә туп-туры карый торган зәңгәр күзләре исенә төшә дә, нигәдер авызы ерыла кызның. Әнкәсе тавыш-тынсыз гына кәҗә сауганда, Шаһидә бал корты урынына безелдәп аның тирәсендә бөтерелә. Мәрзия кечкенә әлүмин мискигә сауган сөтнең беразын стаканга бушатып, көн саен Шаһидәгә тоттыра.

– Бар, балам, Касыйм абыеңа кертеп чык. Аңа дару, безгә савап булыр. – Мәрзия, стаканның өстенә кечкенә ашъяулык каплап, кызына сузган шәйгә өстәп куярга да онытмый: – Аяк астыңа карап атла, әрәм итә күрмә!

Баштарак Шаһидә дә, Зәкия дә әнкәләренең бу гамәленә шаккаттылар.

– Инәкәй, алар безнең сыерны үтерде, нәмәгә син аларга сөт бирәсең? – дип Мәрзиянең желегенә төште кызлар.

– Атагыз дөрес әйтә, аларның бер гаебе дә юк, балалар... Заманасы шундый, ни хәл итәсең... Күрше хакы – Алла хакы, диләр, кителәсе дөнья бер жомры сөттән генә торып калмас.

– Бу дәжжаллар күрше белән күрше арасын гына түгел, дөньясын ук бутап бетерер әле. – Соңгы араларда сүзгә саранланган аталарының да сүзе бер. – Жан биргәнгә жүн бирер, малы да табылыр, иманыгызны гына сата күрмәгез...

Буталды шул, буталу гына түгел, асты өскә килде дөньяның. Сугышы да, ачлыгы да – Шаһидә өлешенә язылган көмеш арасында барысы да бар иде. Иң үкенечлесе – карап туймаслык чибәр, яшь Зәкия түтәсенең күз алдында шәм кебек сызуы, сусыз кипкән гөл шикелле сулып, мәңгелеккә китеп баруы булгандыр. Окоп казырга дип мәжбүри озатылган кызның ачлыктан күләгәсе генә торып калган гәүдәсе авылга кайтып егылганда, аны коткарыр бер уч он, бер жамаяк сөт табылмады өйдә. «Фронтка ит кирәк», дип, ак тунлы Әүхәне дә сөйрәп алып чыгып киткәннәр иде шул... Зәкиянең салкын гәүдәсенә карап, әнисе идәндә тәгәри-тәгәри елады, үзе өзми-куймый «бер жомры сөткәйләр булса» дип такмаклады. Күрше Гөлсем апасы да, шыткан бодай ашап жан биреп яткан Әүхәтен кочып, «сөт булса, исән каласы иде бит» дип илерә-илерә елады. Менә шул чагында әйтте дә инде сабый килеш вакытыннан алда олыгайган Шаһидә: мин үз балаларымны беркайчан да сөттән өзмәм, диде. Еллар узып, бер-бер артлы биш кызы дөньяга килгәч, әлеге сүзләргә «гомерем барында» дигәне дә өстәлде.

Бер жамаяк сөт... Кеше белән кеше, күрше белән күрше, ана белән бала арасын бәйләгән бер жамаяк сөт... Буталды шул, тагын килеп буталды дөньякайлар. Абзар тутырып сыер асраганнарның да күбесенә сөттән акча исе генә килә хәзер. Тора-салып хәл белергә керүчеләр дә, Шаһидәнең әнкәсе күк, үз авызыннан өзеп, күрше хакын хаклаучылар да кимеп бара, ни хәл итәсең. Яңа буын, яңа заман, яңа кешеләр – бернигә дә үпкәләрлек түгел.

Оныкларын гына күр – сөтле чәй ясап алларына куйсаң, борын жыерып иснәргә тотыналар, янәсе, үлән исә килә... Көтүдәге сыерның нинди үлән ашаганын сагалап йөреп буламыни, ачысы да, төчесе дә эләгәдер инде. Оныклары бер хәл, кызларына хәтле кайчагында: «Әнкәй, сөттән әрем тәме килә», – дип теңкәгә тия иде бит. Ашатырсың сыерга әремне, якын да бармый ул аңа.

Адәм баласы дөньяның ачысын-төчесен татып караганнан соң гына әремнән бал тәме килгәнен аңлый шул. Әрем ачысыннан күпкә ачырак сыйлары да бар язмышның, авыз иткәннәр үзләре генә белә...

«Гомерем барында балаларымны сөттән өзмәм» дигән иде Шаһидә, менәтрәк, үз сүзенә хилафлык китерә түгелме соң? Исән-сау бит әле ул, житезлеге кимесә дә, үз аягында ярыйсы гына теркелди ләбаса. Ходай язган гомере калгандыр әле, кул кушырып утырганчы...

Кызының машинасы борылышта күздән югалуга, Шаһидә карчык, үзенчә жил-жил атлап, күрше урамга юл алды. Кышкы көннең озынлыгы бер саплам, якты күздә өлгерергә кирәк. Берәүләрдә сатлык бозау бар дигән сүз колагына чалынган иде, кеше-кара житешкәнче белешеп кайтсын әле. Быел бозау булса, яренгә тана, аннан сыер дигән сүз бит ул, Алла боерса...

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнен юл», 1930-1932 елларда «Яналиф» һәм «Атака», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

90 ел элек (1922) **«Безнең юл»**да **Һади Такташның «Ил трагедиясе»** исемле әсәреннән «Нәләт» дигән пролог-өзеге;

80 ел элек (1932) **«Яңалиф»**тә **Муса Җәлилнең «Зәйнәп»** шигыре;

50 ел элек (1962) **«Совет әдәбияты»**нда **Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар»** романы;

45 ел элек (1967) **«Казан утлары»**нда **Атилла Расихның «Ямашев»** романы;

40 ел элек (1972) **«Казан утлары»**нда Гөлшәһидәнең **«Минем кала алуым»** повесте;

35 ел элек (1977) **«Казан утлары»**нда **Әхсән Баяновның «Тавыш – табигать бүләге»** повесте;

30 ел элек (1982 **«Казан утлары»**нда **Әмирхан Еникинең «Соңгы китап»** повесте;

25 ел элек (1987) **«Казан утлары»**нда **Мәгъсум Хуҗинның «Урак өсте болытлары»** повесте;

20 ел элек (1992) **«Казан утлары»**нда **Илдар Юзеевның «Ак калфагым төшердем кулдан»** драмасы дөнья күрә.



Равил
Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Рәнҗү

*Эх, бабайлар!..*

**Әйтмәкче булалар;**
**«Кошлар бит сезнеңчә сайрамый...**
**Агачлар сезнеңчә шауламый.**
**Төтен дә сезнеңчә аунамый...»**

**Сызланып, үртәлеп**
**эчемнән мин дә әйтәм:**
**яшьләрнең күбесе**
**телемнең асылын, аһәңен аңламый!..**

**Бу җиргә сөлектәй ябышкан**
**килмешәк турында әйткән юк...**

**«Ник алай? Ник болай?» дип уйлап,**
**әрнүгә сабышкан чакларда,**
**искән җил кистереп яңакка сыдырды –**
**«Җиңелмәскә иде!»**

**Күп җирләр йөрелә.**
**Күп илләр күрелә...**
**Чагыштырасың да күргәннәрне,**
**күпчак**
**читнекеннән безнең ким чыга...**
**Сәбәпләрен кем ди төпченсен!**
**...Чит күзләрдә горур өстенлек:**
**«Җиңелмәскә иде!»**

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) — *Татарстанның халык шагыйре; алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Төштә, имеш, бер йомгакны
әй сүтәм, әй сүтәм!..
Килеп чыкмасынмы бер мәлне,
гүяки сихерче төене эченнән,
кан белән тырналган бер язу —
«Җиңелмәскә иде!»

...Көч барда, акылга хаҗәт юк.
Беркемнең беркемгә әҗәт юк...
Күпме ул рәнҗелгән кавемнәр
хәмердә ысланган бу илдә!
Коллыкка тарылган өнеңдә...
Зарланма! Шыңшыма! —
Тел юк дип, рух юк дип...
«Җиңелмәскә иде!»

Ишетәм саңгырау өннәрне
Ерактан-ерактан:
урманнан,
даладан,
курганнан...
«Сезгә бик авырдыр,
авырдыр, оланнар!...»

...Сабантуй мәйданы ягына
баһадир бер егет ашкына урамнан.
«Җиңелмәскә иде бу юлы!
Җиңелмәскә иде!»

## Элек һәм хәзер

Укучылар күп иде элек,
язучы сирәк иде.
Әсәр — рухи азык булып,
гавамга кирәк иде.

Хәзер укып вакланмыйлар,
һәммәсе «иҗат» итә!..
Китап башын «китап» ашый
торган заманга җиттек.

Яшьләрдә — экран-китап.
Кызык та ул, яңа да.
...Кәгазь-китап охшап калды
рәнҗетелгән анага.

## Аккош күле урманында

Урманымда япа-ялгыз калып,
сабый кебек үксеп еладым.
Тома ятим хәзер... Ераклаша
эти-әни исән елларым.

Күпме дуслар китте соң елларда,
бу җирләрнең асыл уллары!
Сылу каеннарның шәүләсендә
күрәм сыман йөргән юлларын...

...Исәрләнеп йөрим әрле-бирле,
кәүсәләргә килеп сарылам.
Йөзләремә бәргән сагыш җиле
исә сыман кыйбла ягыннан.

Язлар-көзләр кабатланып тора.
Гомер фасыллары бер генә!
Яшьлек үткәч, шәфәкъ офыгында
Картлык дигәннәре күренә.

...Күпме югалтулар!.. Ә тапканнар?
Ачыкларга гомер бардырмы?..
Вакыт үтүләре кызган саен,
әкеренәя бара адымнар...

Агачлар да ава. Үсә яңалары.
Урман үзгә күренә эңгердә.
Кешеләрдән кешеләргә   күчкән
шатлык-кайгы гына мәңгедер.

Урманымда япа-ялгыз калып,
сабый кебек үксеп еладым.
...Бер юаныч: күрәм улларымның
күзләрендә килер елларым.

## Һәммәсе якыннар...

Яшәлгән гомерләр,
язылган китаплар,
күрелгән шәһәрләр,
яраткан хатыннар —
һәммәсе якыннар!

Кырдагы игеннәр,
иртәнге ак карлар,
судагы дулкыннар,
уттагы ялкыннар —
һәммәсе якыннар!

Ай-кояш, йолдызлар,
тургайлар, былбыллар,
дус-ишләр, көндәшләр,
җырчылар, акыннар —
һәммәсе якыннар!

...Үзем генә үз-үземә
чит-ят кебек карап торам.

## Замана

Күкне иңли көчле канат!
Җиргә сеңгән зәгыйфь каурый...

Биеклеккә карый–карый
кемдер үрли... Кемдер арый...

...Җирдә ята каты канат.
Күктә оча йомшак каурый...

## Пентатоника

Бер заман монгол илендә
булдык без кунакта.
(Моңарчы нигәдер юлым
төшмәгән бу якка).

Безгә дип концерт куйдылар
ерак бер аймакта.
Сәхнәдән агыла җанга
шундый якын көйләр!
әллә Сарманда утырам,
әллә, дим, Әлкидә!..

Идел шавын да ишетәм,
дала җилләрен дә...
Шул көйләрдә тибрәнә ди,
Кытай илләре дә!

...Җыр тәэсиреннән бер мәл
бу җир улы булдым.
Үзем сизмәстән, билләһи,
татар–монгол булдым.

## Ураза

Бүген кемгә ни яхшылык
эшлием? дип уянсам —
таң алды сәхәрем шул.

Азгын ләззәттән ваз кичеп,
яза–яза яна алсам —
вазифа уразам шул.

## Төшләр

*Хәерле төн! Тәмле төшләр!*

Йоклаганда һәммәбез дә тигез.
Ярымүлем халәт тигезли.
Төшләр юллап, Бөек илаһи Көч
күңелләребездән ни эзли?

Татлы төшләр Аның бүләге ул.
Тик алары кыска булучан.
Яман төшләр саташтыра, баса,
тән изелә, тыпырчына җан...

Ни булса да, төшләр насыйп безгә.
Яшәүнең бу үзгә хикмәте.
Вакытларны кире кайтарырга
тик төшләрнең җитә кодрәте.

Кайчак яшьлекләргә кайтып була.
Очратып була әткәң-әнкәңне.
Ишетергә мөмкин тәүге ярның
назлы, татлы сүзләр әйткәнен...

Төш юраулар, белмим, язык микән,
Язмыш синең белән уйнаса...
Ә уйласаң, безнең гомерләр дә
бер кыска төш кенә ләбаса.

## Кайтып төшә...

Туа бәндә.

Ята башта
биләвендә.
Тәпи йөргәч,
уйный аунап
идәнендә.
Исәйгәчтен
сабак ала
мәктәбендә,
ирешмәкче
максат куйган
дигәненә.
Балигъ булгач,
чыгып китә
дөнья буйлап
биләменә.

...Ә бер заман
түзалмыйча
сынауларның
иләвенә,
кайтып төшә
ләхеттәге
биләвенә...

Бер бәхете —
гомеренең
финал-ахырын
белмәвендә.

***

СССР чакта төзедек коммунизм.
Хәзер ни төзибез? — кем белә?..
Рәсәй милләтеннән димәкчеләр,
татар булып тугач, мин — бәла?

Үз телеңдә белем алу өчен
ялынырга, рөхсәт сорарга?
Мәҗит Гафурича сорау туа:
нәрсә карыйсың син, и Алла!..

## Саталар...

**Саталар һәм сатылалар...**
**Бар дөньясы сатуда!**
**Аерма шул: сату сүзен**
**кем ничек аңлатуда.**

**Саталар грам-мыскаллап,**
**саталар иләтә дә!**
**Кемнәрдер яшерен сата,**
**кемнәрдер — күрәләтә.**

**Саталар тәнен-гыйффәтен,**
**саталар урын-постын...**
**Сатасыңмы, сатыласыңмы —**
**син ни статуста, дустым?**

**... Һәммә кеше андый түгел**
**уеңда, дисең, хата.**
**Ышанмыйсың? Әнә чатта**
**кемдер гайбәтең, сата.**

***

**Томаннар эчендә югала еллар!..**
**Догасыз үтелгән шактые.**
**Уянса күңелдә үкенеч,**
**күзләргә яшь килә. Шат көе.**

**Офыклар артына күмелә еллар!..**
**Озата урманнар, үр-кырлар...**
**Яшь буын безнең чор турында**
**ни телдә, ни көйләр, ни җырлар?**

**Рәшәләр өстендә тибрәнә еллар!..**
**Хәтердә калмаган күп юллар...**
**Киләчәк түреннән безгә дип,**
**бер сыңар сәламне кем юллар?**

***

*Зарланырлык, үртәлерлек*
*Идел-Йортта хәлләр күп!..*

**Кара көчләр бассалар да,**
**барыбер түзәм! Кимсенмим!**
**Мондый чакта күпләр әйтер:**
**«Нишлием мин, нишлим мин?..»**

**Башны ияр чакларда да,**
**баш күтәреп эшлим мин!**
**... Җирдә ике татар калса,**
**шул икенең – берсе мин!**

Фәрит
Яхин

# УМЫРЗАЯ

РОМАН

## IV

Сабираның үзгәрүе Хәнифә Галиевнаның күңелен боза башлады. Ул юктан да Кәримәне яманлый торды. Эченә сыя алмый башлады. Әмма Газизчиккә карата мөнәсәбәте артыгы белән яхшы булу гына хуҗабикәне орылып бәрелүдән саклап калды. Хәнифә Галиевна ничек тә хәйләсенә керергә, җаен табарга тырышып карыйсы итте. Юк исә, Сабира бүген Кәримәгә ташланса, иртәгә Газизчиген алдарга яки пар күгәрченнәр кебек була барган кыз белән егетнең араларын бозып куярга да мөмкин иде. Шунда берәр яшь җилкенчәге дә кызыкмый бит үзенә!

Хәнифә Галиевна уйлавынча, Кәримә белән Газизчиге арасында Таһир һәм Зөһрәнеке кебек гүзәл бер мәхәббәт агачы үсеп, чәчәккә төренеп килә иде. Ул инде аңа кырау да төшерттермәс, салкын җилләрне дә тидертмәс. Берданбер улы Газизчик өчен бүген җанын фида кылса да кызганыч түгел!

Ә менә Сабира? Һай зәһәр дә инде теле. Әле кичә генә, университеттан кайтып та керде, Кәримәнең юклыгыннан файдаланып, шунда ук:

— Тагын бүген шагыйрь Фәхри Хисамига киткән ул! Аның белән мәхәббәт «крутит итә»! — дип, авызын алагаем ачып сөйләнеп торды, юньсез кыз!

Шагыйрь белән шагыйрә арасында әллә ниләр дә булырга мөмкин, анысы. Әмма шушы кадәр сабыр, шушы кадәр сагышлы, шушы кадәр бәлале, шушы да кадәр кешелекле Фәхри Хисами кебек, илле алты яшьлек карт әдип ул унтугызы да тулып җитмәгән кызга бәйләнмәс тә, аны бозып та йөрмәс! Монысын инде Сабира белмичә-аңламыйча сөйли, эт җан икәнлеген яшерә алмавыннан гына бу.

Инде дөньяның хикмәте ачыла да сыман иде. Шушы соңгы ай эчендә Хәнифә Галиевна үзгәрде дә куйды. Мона кадәр шәһәренне бер үзе яулап алырдай булып йөргән хатынның көтмәгәндә бөтенләй дә тынычланып, гамьле кешегә әверелеп калуы, җитмәсә кибеткә дип чыккан җиреннән берни дә алмыйча, күңеле югалгандай кайтып керүләре, уйлы һәм сабыр зат иясенә әйләнүе электән аны белгән танышларын хәйранга калдырды. Мондый галәмәтләрен берәүләр мәрхүм ирен сагынуына нисбәт итсәләр, икенчеләр аның иртә картая баруы белән бәйләделәр. Әмма ул үз улы

*Ахыры. Башы узган санда.*

хәсрәтендә иде. Кайсы ана асыл йөрәк җимешен бәхетле итеп күрергә теләмәс иде икән?

Газизчиге соңгы вакытларда бөтенләй дә сөйләшмәс булды. Ул елмаеп йөри бирә, көн дә скрипкәсен төрле сәер көйләр белән елата. Кәрименең дә аның мәхәббәтен инкарь итмәве әнкәсенә мәгълүм. Әмма тулы бәхет өчен кемдерме, нидерме комачаулый. Әллә Сабиранын күнелеме, әллә кызның яше бары тик унтугызга гына килеп җитеп маташумы — билгесез! Әгәр Газизчигенә кызның үсеп, өлгереп җитүен көтәргә туры килсә, ул мона да риза, югыйсә. Нинди комачаулык бар соң? Шул Сабиранын авыр күзе, ачулы теле генәме?

Хәнифә Галиевна мең кат үлчәде-үлчәде дә, бер фикергә килеп, ике туган сеңлесе Гөлшат Фаиковнага барырга кирәк икән, хәтта гозерләнеп сорарга кирәк дигән нияткә килде. Аларның аралары бер вакытта да салкын яки җылы булмады. Ә бу юлы Хәнифә Галиевнаның нечкә мәсьәлә белән анардан башка һичкемгә барасы килмәде. Хәер, аны аңларлык башка кеше табылыр идеме соң? Казанның зурлыгы, эче тулы халык булу — бер нәрсә, ә менә аның йомышын хәл итәрлеген көндез чыра яндырып эзләсән дә табып булмаячак.

Хәнифә Галиевнаның бәхетенә сеңлесе Гөлшат Фаиковна өендә, саусәламәт яшәп ята иде. Яшәп ята, димәктән — шушымы инде дөрес сүз? Гөлшат Фаиковна биш ир бала анасы, житмәсә өрлек кебек ире гомер буе баш бирә белмәде, каршында билен дә бөкмәде. Аңа хатыны кол иде. Малайлары да әткәләренә охшап, хатын-кызны санлый торганнардан түгелләр инде. Башкача була алмый. Шулай итеп, Гөлшат Фаиковна аларның колы булып, аш әзерләп, киемнәрен юу, йорт-җирне чиста тоту хафасында гомерен уздырырга хөкем ителгән иде. Өлкән уллары утызга житеп бара, ә өйләнәм дип әйтми. Энекәшләренә өлге инде ул. «Типсәләр — тимер өзәрлек» егетләр булып беткәннәр, кызларны бияләй урынына гына алыштырып торалар дип Хәнифә Галиевнаның ничә ишеткәне бар иде, хак ахрысы? Аталарына охшаганнар, аталарына, бер дә башкача түгел!

Хәнифә Галиевнаны сеңлесе аһ итеп:

— Абау, апам-җаным, мине дә исенә алыр көннәрең бар икән, — дип каршы алды. — Әллә безнең Газизчигебез өйләнәме? Туйга чакырырга килдегезме?

Вакыт иртәнге як иде. Ял көне. Алар яныннан әүвәле бер уллары, аннары икенчесе, өченчесе, һәммәсе дә берәмләп исәнләшеп, чалбар-майкачан гына узып-сүтеп алдылар. Аларның үзара охшашлыклары бер гаҗәп, әмма аналарын игътибарга алып, санга кертеп аптырамаулары — икенче.

— Безнең балалар шундый инде алар! Малайлар кебек чукынчык бала юктыр ул, — дип әнкәләре Гөлшат Фаиковна сөйләнгәләп тә өлгерде. — Бер кыз да алып кайта алмадым бит, кул янымда ярдәмче булыр иде!

Хәнифә Галиевна үзен тыныч тотты. Карашны югарыдан карауга көйләп куйган иде инде ул, эре кыяфәттә:

— Нәрсә, сеңлем-җаным, инде бу йортта мине түргә чакыру да юкмыни? — дип сорады. — Ярты сәгать ишек төбендә басып торам бугай?..

Гөлшат Фаиковна аның бу сүзләренә дә аһ итте. Көтелмәгәндә килеп кергән апасы алдында ул тәмам югалып калган иде. Зиһенен җыярга өлгерә алмыйча газапланды. Аннары гына, Хәнифә Галиевнаның күзләрендә сагыш һәм моң галәмәтләрен күреп йөрәге хафага төште.

— Апам-җаным, апам-җаным! — дип, аңа түргә, кухня ягына узарга юл күрсәтте. Бу вакытта җилкәсенә эленгән тастымалы төшеп китеп аптыратты, ни алга-ни артка атлый алмыйча гаҗизләде. — Аякларыннан салып торма! Шул көйгә генә кер, апам-җаным! Мондый үкчәле башмаклар белән шәһәрдә йөрүләре җайсыздыр бит?

— Бик җайлы, бик килешле!

— Минем мондыйларны кимәгәнемә дә бишбылтыр инде, — дип сеңлесе зар итеп маташса да апасының авыз читендә аз бер елмаю кисәге генә күренеп алды. Мыскыллау сүзләре буларак әйтелгән фикере шул йөз үзгәреше эчендә онытылып калды, ахрысы.

Икетуган сеңлесе Гөлшат Фаиковнаның торган җире төзек, кадагы да урынында, тактасы да яхшылап сырылган, идәннәре дә җеккә-җек тартылган иделәр. Йортта ир кулы барлыгы да сизелеп тора шул. Әмма хатын-кыз мәсьәләсе монда чыннан да чишелмәгән, табак-савытлар, өстәлләр юылган-сөртелгән исә дә, оны-бәрәңгесе-ите — башкасы тарау ята иде. Житмәсә өстәл янына беркетелеп куелган иттарткыч та эшен башлаган килеш ташлаган кебек тора.

— Апам-җаным, бик вакытлы әле килүең дә, менә бит, пәрәмәч пешерергә җыена идем. Малайлар тормый да тормый, итемне дә тартып бирмиләр.

Хәнифә Галиевна ваклыкларга бирелмәде. Тарттырырга дип кискәләп куелган табагы белән ит, ун-унбиш баш суган, ярты капчык өеме генә булмас — иләнгән он, тугылар өчен ватылган ничә дистә күкәй һәм аларның кабыклары, өч литрлы банка белән сөт — болар барысы да бер хатынга көне буена җитәчәк эш иде.

— Син, сеңлем, мине булышыр дип көтмә. Үземдә дә, улымны, аның янына ике кызны асрап, гомерем камыр-боламык эшеннән чыкмый! — Ул махсус шулай сөйләнде. Кызларны да сүз арасына юри китереп кыстырды. Кайчан да булса бер аларны теленә алырга һәм шуның өчен махсус килгәнлеген әйтеп аңлатырга тиеш иде ул. Менә бит, җае үзеннән-үзе ип килеп тора. Эшнең җебен акрынлап, очыннан башлап сүтә торуың хәерле шул.

— Кызларың булгач, синең яшәвең дә гөл бакчасында сандугач сайрату белән бер инде, апам-җаным, аны да сүз дип сөйләгәнче!.. Чәй куярга кирәктер?.. Кая соң чәйнегем?..

— Әйдә, чукынма әле, калдырып тор чәеңне! Мин озакка түгел! — диде Хәнифә Галиевна, буш урындыкка кулындагы авыр төргәген куеп, сумкасын эләргә урын эзләп. — Беләкләремне өзеп төшерә яздым. Хәсрәт. Чемоданга тутырып алып килсәм ни иде? Казан буйлап, адәм көлдереп, кәгазь капчык асып йөр инде, Арча хәерчесе кебек...

Аның бер башлаган сүз белән ярты дөньяны әйләндереп китереп сөйләшә белү куәте Гөлшат Фаиковнаны тагын ике кулсыз калдырды. Бүгенге көндә апасының олы хәсрәттә йөрүе, монда туйның да, башканың да катнашы булмавы акылына барып җитеп, шунда гына аңлады бугай? Туганың сине Казан читенә кадәр яхшы хәбәр белән эзләп килмәс, адәмне хәсрәт олы юлларга чыгара!

— Монда улымның бер-ике киеп калдырган киемнәре иде, — диде Хәнифә Галиевна, — ул кадәр ир гуртын киендерергә синдә Әндери казнасы юктыр? Шикләнмәсеннәр! Биби Шәрифәсенә биреп, өрфия яулык хисабына юдырттым. Бик тә чиста иткән, май аеның хуш исләре белән аңкыткан. Кайсы улыңа да төс булыр, киеп йөрсеннәр әле шуларны, дидем!

Әмма төргәкне ул чишеп маташмады, өстәл читендә торган чәйнекне күреп алды булса кирәк, тагын да йөзенә елмаю йөгерде. Аның күз карашына иярергә өлгергән Гөлшат Фаиковна исә шул якка борылып карады, майга пешкән пешкечедәй сикереп куйгандай булды һәм, ашкынуга күчеп, олы чуен керогаз янына килеп, аның филтәсен күтәрә төште, җылынып утырган майлы таба урынына чәйнекне утыртты:

— Гомергә бер килгәндә дә ашымнан-чәемнән өстен булып, мине кимхур итеп китмә инде, апа җаным! Менә хәзер пәрәмәчләрне дә булдырам.

Алар минем бик тәмле пешә. Атчы Хафизулладан май да алган идем, Арча хатыннарыннан каймак та китерттем. Нигә шушы кадәр сыйлы булдым әле, дисәм, синен, апам-жаным, кунакка төшәсен булган икән, — дип, кыска гына әйтелергә мөмкин сүзне озынга алып сөйләп ыргытты.

Әгәр дә пәрәмәчләрнен житешүен көтсән, монда кичкәчә гомере үтәчәген уйлагандыр инде. Хәнифә Галиевна чәйгә генә риза буласын белдереп:

— Өйгә кайтасым бар, сенлем, — диде, шулай да сумкасыннан кульяулык чыгарып, күз яннарын сөртеп алып. — Ял көннәре Газизчигемә үзем пирогмазар пешерерменме әллә дигән идем. Озаклый алмам. Эшләрем барып чыкса, йомышымны кире какмасан, сенлем-жаным, әле болай гына калмам, тиз арада йортыгызга тагын аяк басармын!

Кульяулык мәсьәләсенә килгәндә, монысы да алдан уйланылып, кайчандыр Гөлшат Фаиковна тарафыннан бүләк ителгән, сандыкнын ян тартмачыгында үз вакытын көтеп сакланып калган затлы истәлек иде. Исәптә хисап була, дигәндәй, анын да файдасы тиде. «Әллә апам елый инде?» — дип аһ итәргә жыенган Гөлшат Фаиковна үз бүләген танып өлгергәндер — йөзен нурга күмде. Хәер, анын күнеле үзгәрүгә апасынын зур хәсрәт белән түгел, йомыш артыннан гына йөрүен белүе дә тәэсир иткәндер әле?

— И апам-жаным, синен кебек зур кешенен сүзен тынларга туры килер инде, — дип, ашыгып сөйләп, алдан вәгъдәләп тә өлгерде.

— Ни бит әле, сенлем-жаным, Газизчигем, йөрәк парәм, фатирант кызларымнын берсенә, сөрмә күз, бөдрә чәч Кәримәсенә гашыйк булды да... Үзен харап итмәгәе дип куркам. Араларына сары көнбагыш Сабиранын көнчелек күләгәсе төшә бит, сенлем-жаным!

«Мин нәрсә эшли алырмын икән бу хәлләрдә?» — дип әйтергә теләгәндәй, Гөлшат Фаиковна бөтенләй дә эчсез-тышсыз калды. Ярый әле Ходайнын бирмеш бәрәкәте — чәйнек яна керогаз өстендә шаулап кайнап чыкты да, доньяны яулап алырдай куе пар ата башлады.

Әмма чәйгә керешкәнче, апанын сенелгә аталган йомышы хәл кылынырга тиеш иде.

## V

Атна да үтмәде, кич булды дигәндә, Хәнифә Галиевнаны аһ иттереп, ишек төбенә чәчәктән-чуктан, гөлдән-жимештән әле генә өзелеп төшкән ике затлы егет килеп тә басты. Болар Гөлшат Фаиковнанын әле яна егермесе генә тулган Шәрифе һәм Газизчиккә яшьтәш тиешлерәк улларыннан Гариф иделәр. Икесенен дә олы кара арыслан күзләре, бөдрәләнеп торган чәчләре, бит алсулыклары, житмәсә энәдән-жептән киенгән булулары, башларындагы Казан егетләрендә яратылып өлгерелгән кин кырлы фетр эшләпәләре, кара плашлары, галстуклы күтәренке ак якалы муеннары, алыптай гәүдәләре — һәммәсе-һәммәсе бергә аларнын доньяа йөзендә сирәк очрарга тиешле адәми зат иканлеге хакында сөйли иделәр. Болар янында сөекле Газизчик әлбәттә кәжә сыйрагын кимереп яткан көчек сыман гына тоелачак. Каш ясыйм дип күз чыгару галәмәте дигән нәрсә шушы буладыр инде ул?

— Исәнмесез, Хәнифә Галиевна! — диделәр болар, килеп керешкә үк, Берлинны алган егетләрчә күкрәкне кин тотып.

Хужабикә төшемме-өнемме дигәндәй артка чигенергә мәжбүр булды. Биби Шәрифәсеннән әрфия яулык бәрабәренә юдыртылган, улыннан калган киемнәре, ярты Казанны унымда, калганын сулымда тотам дигән олы өметтәге уйлары күз алдыннан берәм-берәм йөгерешеп үтте.

— Хәнифә апа, без Гөлшатнын уллары Гариф белән Шәриф булабыз! — дип, авызларын ерып ямь белән әйтеп алдылар. — Менә сезнен хәлләрегезне белергә кереп чыгасы иттек. Әнкәй сәламнәрен жибәрде!

Шунда энесенә кул аркасы белән генә Гариф төрткәләп алды да:

— Әнкәбез сезгә күчтәнәч тә җибәрде әле, — дип, тәмам тутырылган сары күн сумканы сузды. Аннан әле дә суынырга өлгермәгән пәрәмәчләр исе килә иде. Хәнифә Галиевна сумканы ирексездән кочагына алды.

Шунда, Ходаның рәхмәте, Газизчик тә кайтып керде. Егетләр үзара сөенешеп күрештеләр. Курыкканнан гына Гөлшат Фаиковнаның уллары әллә кемнәрдәй күренгән икән, әнә бит Газизчикнең дә алардан бер кайтыш җире юк. Тик менә җилкәләре генә таррак сыман әлегә!

— Әнием, нишләп минем братларымны ишек төбендә тотабыз? Түргә үтик, егетләр! — дип, Газизчик шунда аларга өске киемнәрен салырга булышты. Күренеп тора, бик тә куана иде ул.

— Әнием, әллә тәмле пәрәмәчләр пешергәнсең инде? Мең ел ашаганым юктыр сыман ачыктым! Сый янына кунакларыбыз да бар! — дип тә әйткәч кенә, Хәнифә Галиевна үз уйларыннан айнып, күчтәнәчле сумканы кочаклаган хәлендә кухня ягына ашыгып кереп китте. Шунда гына анның сулышы урынына утырды. Хәзер бөтен курыкканы фатирчы кызларның вакытсыз кайтып керүләре белән бәйле иде.

Әмма кирәкмәсне уйларга ярамый шул ул — алдыңа килә дә баса. Монда да нәкъ шулай булды: егетләр түргә узарга гына атлаганнар иде, Кәримә белән Сабира көлешә-көлешә көмеш кыңгыраудай чәрелдәшеп килеп тә керделәр. Өйдә чибәр егетләрне күргәч, дөрес ишектән узмадык ахрысы дигәндәй, як-якларына карангалап, ябылырга өлгергән җиңел йозак келәсенең «келт» итүеннән соң, шым булып, телсез калдылар. Күзләрендәге аптыраш, кызыл чия иреннәренең дерелдәп алуы, йөзләренең агарынып китүе — шушы кара һәм сары чәчле яшьлек гөлләренең балкышына тагын да күркәмлек һәм каләм язып бетәрә, адәм хис итәргә өлгерә алмаслык гүзәллек өсти иделәр.

Завод эшендә катыланырга өлгергән Гарифның зиһене тиз ачылды.

— Ну Газиз туган, син җәннәт хурилары белән яшисең икән шул, малай! — дип сокланып куйды.

Анның бу сүзләре арадагы тынлык пәрдәсен телде дә төшерде. Егетләр Газизчикнең бүлмәсенә юнәлделәр, кызлар, өске киемнәрен салып, үз бүлмәләренә мыштым гына чумдылар. Әмма аларга анда озак калтыранып-куркышып, мәхәббәттән котлары алынып утырырга насыйп түгел иде.

— Кызларым, сез кая? — дип, кухня ягыннан аваз салды Хәнифә Галиевна. Аңлашыла, кунаклар да булгач, кичке ашны хуҗабикә үзе яши торган зал ягында зур өстәлгә көйләячәк. Мондый катлаулы эшләрне ул бер башына гына башкарып чыгарга теләми, фатирчыларын электә дә йөгертә белә торган иде.

Сабира бүген өлгеррәк булып чыкты. Ничә көннәр авырганнан соң, Кәримәнең вакыт-вакыт хәле дә киткәләп алучан була башлады. Житмәсә затлы егетләрнең күз карашлары анның да йөрәген ук кебек үтәли тишеп, уттай яндырып үткән. Күнеле урынына утыра алмыйча гажизләде. Әмма, ни хикмәт, бу минутларда анның акылы ныклы иде, Фәхри абыйсы Хисамины да, Газизчик абыйсын да, теге ике затлы егет арысланнарын да намус бизмәнендә берәмләп үлчәргә булдыра алыр, әлбәттә. Шулай да андый исәп-хисапны уена кертергә анның башына килмәде. Хәтерендә бары тик сагыш тулы күзләре белән яктырып шагыйрь абыйсы гына йөренде. Бу аңа тынычлану өчен ныклы җирлек иде.

Кәримәнең булышырга килергә ашыкмавы Хәнифә Галиевна өчен кулай булып чыкты. Ул шунда ук Сабираны мәхәббәт тойгыларына ымсындырып куярга өлгерде.

— Әле бу атнада гына икетуган сеңлем Гөлшат Фаиковнаны күрергә

дип барган идем. Матур яшәп яталар. Аллаһыга мең шөкер! Сиңа да сөйләгәнем бар, беләсең инде, кызым! — дип башлап алып, сүзен махсус җайлап-җайлап китерә биреп, теләгендә саклаганын белдерде дә куйды: — Менә шунда, мин тиле, фатирчылар булып ике чибәр кызымның да бездә яшәүләре белән мактанып куйганмын. Бигрәкләр дә сине, Сабирам, сине инде, зурлап, дөресләп-матурлап, кадерлем итеп берничә кат телгә алдым. Әнә бит, мәлгуньнәр, килеп тә житкәннәр, әнкәләренә сөйләгәннәрне ишетеп торганнар инде болар! Аларның икесе дә ут кебек, тормышның терәге булырлык егетләр. Бигрәк тә өлкәнрәге, Гариф дигәне, заводта зур эштә, уч тутырып акча ала. Әллә сиңа яшьрәге ошыймы?

— Миңа да өлкәнрәге күбрәк ошады, Хәнифә Галиевна, — дип, шунда ук шушы сары чебеш әйтеп алсын әле! Хуҗабикәнең йөрәге валерьянка сорагандай тартылып куйды булса кирәк, кабаланган җирендә ул, тынын алыштыра алмыйча, хәрәкәтсез калгандай булды.

Бу Сабира дөньядан үзенә дигәнен алачак, Хәнифә Галиевна каршында көтелмәгәнчә борынын югары чөеп йөренә башлады, җитмәсә:

— Энесе дә начар кебек күренми, шук егеткә охшаган! — дип, үзалдына шаян елмаеп та алды.

Боларын ук көтмәгән хуҗабикә, тәмам сагаеп калып, сәясәт утын әлегә сүндереп торырга тиеш иде дә, яннарына Кәримә кереп җитте һәм:

— Өстәлне хәстәрләп тә бетергәнсез икән, шул ара эчендә... Һай өлгерләр! — дип, аларны мактап кына әйткән иде:

— Ялкау уянганчы көн үтә, төн җитә! — диярәк, Хәнифә Галиевна аңа битәрләү сүзен ташлады.

Хуҗабикәнең уенда әлбәттә сәясәт иде. Кәриманең егетләр күргәч тә йомшарып китмәвен теләүдән шулай әйтте ул. Әмма кыз алай кабул итмәде.

Кәриманең кадере белән бергә кәефе дә китте. Бу хәл аның йөзендәге гүзәллек нурларын бераз киметә төште. Әмма хуҗабикәнең сары әрсез фәрештәсе Сабира тагын да матуррак балкый алды. Бу хәл исә кунакларны һәм Газизчикне эсселәтми-суытмый өстәл янына китерү өчен иң кулай минутларның берсе иде.

## VI

Мәҗлес көтелгәннән дә яхшырак һәм күңеллерәк узды. Кунак егетләрнең икесенең дә күзе Сабирада иде. Кызларның күңелләрен көйләүдә маһирлыкның алтын медален алган бу егетләр үзләрен бик тә ипле, итагать ияләре, хөрмәт хуҗалары итеп тоттылар. Башкалар өчен ул хәлләр нинди дер театр уенын хәтерләтсә, Сабираның бәхет канатлары чиксез галәмнәрне инләп, күз күрмәгән, хыял ирешмәгән сәгадәт диңгезенә таба оча иде. Чак кына Шәриф тыелып калса, Гариф телгә күчеп, аннары кабат олысын кечесе, кечесен олысы алыштырып, кызның күңел кошын бер дә җиргә төшерми, болытларда кат-кат йөздерделәр. Шунда, бу уеннан хәбәрдар булмаган Газизчик, аларны бераз тынычландырырга теләп:

— Монда безнең Кәримә дә бар бит әле, егетләр! — дип әйтеп куйды. Аның бу сүзләрен ишетеп алган Хәнифә Галиевнаның әлбәттә җитмеш җиде җене берьюлы котырынгандыр? Әмма улын ул башкалар алдында: «Мокыт, алама тәре!» — дип битәрләргә базмады булса кирәк. Бары тик:

— Кәримә кызыбызга да бик күңелле, улым, — дип кенә әйтеп өлгерде. Әмма Шәриф, уенда могҗиза күрепме:

— И-и, монда, Хәнифә апа, тагын бер кызыгыз бар икән, аны онытып җибәргәнбез... Гафу итә күрегез, туташ! — дип, ят бер инкари караш белән Кәримәгә карап куйды.

Анын бу сүзләре Сабирага серле хикмәттәй ошадылар һәм ул, инде ике ел буена җыелып килгән ачуын чыгарыр хәлдә, көнчелек катыш мыскыллы күз карашын иптәш кызына юллап, рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Бусы ук артык иде. Шунда Кәримә өчен мөгаен дөньяны су баскан да, күкләр җимерелеп төшкән кебек тоелгандыр? Шагыйрә бит, күнеле мыскыллауны күтәрә алмый, урыныннан калкып:

— Хәнифә Галиевна, минем башым авыртып тора, — диде дә, шуның белән рөхсәт сорагандай өстәл артыннан кузгалып, үз бүлмәсенә таба йөгереп диярлек чыгып китте. Хәзер бу бала әлбәттә мендәргә капланачак, үксеп-үксеп елый инде!

Шунда ярты Казанны уң кулым белән туглыйм, ярты Казанны сулы белән бутыйм дип йөргән хуҗабикә дә аптырашка төште. Сенлесенең улларына хәйран иде ул. Бу егетләр адәм дигән затны ничекләр уйнатырга кирәк икәнлеген аңа күрсәтеп алдылар. Ул да кузгалды, җәһәтрәк кухня ягына чыгу юлына басты. Шунда авызын иләк ясап, Сабираның бәхетенә сокланып утырган мокытына төртеп аласы килде. «Бар, Газизчик, бу уен сиңа түгел, Кәримән янына кер!» — дип чак кына әйтеп ташламады. Ә мөмкин иде. Әмма шунда күзләре Сабираның беленнән алырга үрелгән Гарифның кулларын күреп калырга өлгерде. Барган адымнарын акрынайтып, беразга туктыйсы итте. Уймак чыгарган уенга шик төшерү килешмәс. Мәгәре бу егетләр таш йөрәкле Сабираны да эретүгә, анын күнел кошын канатландырып, үз ятьмәләренә кертергә ирешкәннәр икән, менә башка, хискә йомшак хатыннар-кызлар белән нәрсәләр эшлиләрдер бит әле? Ничәмә гүзәллек иясе аларның хәйләсеннән төпсез чиләккә утырып калмаган, дисен?

Хәнифә Галиевна кухня ягына ирешеп өлгермәде, Шәрифнең сүзләрен колагына алырга ашыкты. Ул:

— Әйдәгез, Газиз абый, онытып торамын икән, бер эш турында сезнең белән киңәшергә иткән идем бит, сезнең кабинетка? «Мужской разговор»! — дип әйтте.

Урыннан кузгалдылар. Хәнифә Галиевна Сабираны Гариф иркенә калдыруларын шунда ук аңлап, моңа хәтта бераз көенеп тә куйды. Аллаһ сакласын, Сабирага мондый да егетнең җиле тими үтмәс, көт тә тор, имеш. Ил алдында оят булмагае!

Шәриф белән Газизнең шәүләләре генә шәйләнеп калды. Угланнар шунда чагында хуҗабикә өч тынланып, биш караштырып, инде хихылдый башлаган Сабираның хәлләренә күз-колак сыйфатта зал ишеге янынннан узгалап йөрде. Ишекнең пыяла тәрәзәсе бүлмәдәге вакыйгаларны киноэкрандагы галәмәтләр итеп, бик тә матур ясап күрсәтә иде. Менә сөйкемле сөяк Гариф һәммә төрле саклыкның файдасын белеп, инде тәмам дәрт дәрманы мөлдерәмә тулган Сабирага таба үрелә. И сала сыйрагы, син дә үбешә беләсеңмени? Хәнифә Галиевнаны күрмиләр дә, белмиләр дә. Ул Гарифны әйтер идең инде, бер көн, бер сәгать эчендә мең кызны дәрт җилендә җилгәрсен инде?!

Хуҗабикә кулына әле уклау алды, әле табак тотып карады. Әгәр дә Гарифның чамадан узуын күрсә, ул шуларны коралы итеп, яшьләр янына кылычлы-калканлы каһарман сурәтендә бәреп керәчәк, ике гыйшыкчыны рисвай итәчәк иде. Шунда кабинеттан Шәриф белән Газизчик бер кулына табак, икенчесенә уклау тоткан Хәнифә Галиевнаны күреп алдылар. Бу хәлендә кеше көлкесенә калуы хуҗабикәнең үз күнеленә куш килерлек күренеш түгел иде. Ул шунда ук хәйләгә кереште һәм:

—Чоланга чыга идем, сандыктан онны алыйммы дигән идем... Улым, берәр тәмле ризык пешеримме соң? — дип, арылган кыяфәттә сүзләр тезде.

— Әнием, нинди ашыйсы килү инде ул? Гөлшат Фаиковнаның пәрәмәчләре дә ярты өстәл тулып тора!

Ханифә Галиевна арбадан төшеп калганнардан түгел, тойдырырлык итеп Шәрифкә дә карап алды. Егет шунда ук:

— Бик матур кунак булдык. Әлегә эшләребез бетте. Кайтасы юл да якын түгел. Рәхмәт сезгә жылы кабул иткәнегез өчен! Без китик инде! — диде. Ә аннары Гарифка эндәште: — Абый, шулаймы?

Зал ишеге ачылып, аннан егетләрнең солтаны үз мәртәбәсен саклаган, әле генә татлы ирен жиләкләрен тәмләп ашаган кыяфәттә килеп тә чыкты. Ул да бу йортка рәхмәтләрен белдерде. Шунда Гариф:

— Хәнифә апа, мин тагын иртәгәме, башка көндәме килсәм, ничек булыр икән? — дип сорады. Аның бу сүзләре әлбәттә Сабирага адресланган иделәр. Моны гына хужабикә дә жиңел аңларга тиеш иде, эсселәтмисыйтмый ул да:

— Килегез, кил, сез бит минем туганнарым! Юлны онытмагыз! — дип, әмер биргәндәй әйтеп өлгерде.

Сабираның куанычы жиденче күкләрдә иде. Йөзеннән шатлык нурлары сибелгәнен ул яшерә алмады. Хәер, моның кирәге дә юк иде.

— Хуш, чибәркәй! — диде, егетләр бераз үртәп һәм кызның күңелен тәмам ымсындырып. — Сау булыгыз!

Ишек ябылуга өч-дүрт минут үтмәгәндер, хужабикә кухня ягында олы аһ күтәрде.

— Сумка тотып килгәннәр иде, кире бирергә онытканмын! — диде Хәнифә Галиевна.

— Хәзер... Үзем... Артларыннан куып тотып, илтеп бирәм! — дип, Сабира чыгып йөгермәкче иде дә:

— Тукта, кызым! — дип хужабикә аны чак эләктереп калды. — Алар тагын киләләр әле. Күчтәнәчләр салып куярбыз! Буш сумка күтәреп йөрмәсләр бит инде!

Әле генә гөл кебек сулырга иткән Сабира кабат яктырып алды. Аның бар дөньясы тулы шатлык, сөенеч, сәгадәт һәм, иң хикмәтлесе, кайнар мәхәббәт иде. Ул, зал ягына чыгып, хәтта жырлап та жибәрде.

## VII

Сабира белән Гариф бик тә матур йөрешеп киттеләр. Шулай килеп чыгар дип Хәнифә Галиевна гына түгел, хәтта егет үзе дә әүвәле башына кертеп карамагандыр инде? Хәер, әлегә бу аларга заказлы уен гына кебек тоелгандыр бәлки? Чөнки бу тормыш театры уенының авторы Хәнифә Галиевна үзе, башкаручысы Гариф иде кебек.

Хикмәт шунда, икетуган сеңлесе Гөлшат Фаиковнага, теге вакытта олы йомыш белән килгәч, ахырда Хәнифә Галиевна нинди эш белән йөрүен төгәл генә әйтеп, аңлатып бирде. Шушы кадәр бер-берсенең күңеле килешеп китәр дип башына да кермәгән иде.

— Сеңлем-жаным, Газизчигемне өйләндерәсе идем. Нәкъ күңеленә ятып торган кыз да бар. Менә шул. Әмма араларына Сабира дигәне керә бит. Бер дә ирек бирми. Газизчигемне беләсең, әрсезлеге юк, — дип сөйләп китте...

Көннәрнең берендә ике асыл коштай кыз баланың үзләрендә фатирда яши башлауларын, әүвәле ул-бу сизелмәвен, ахырда Кәримәгә Газизчикнең гыйшкын бик оста сизенүен, тормышка дәрте күренә башлавын чәй янына чәйне өстәтә-өстәтә, инде китәргә тиешле жиреннән тагын да ике сәгатькә соңарып кала-кала, кабат-кабат сөйләп бирде.

Апасының юк эш белән йөрүен Гөлшат Фаиковна әүвәле яшермичәрәк

әйтә торды, үзенең кулыннан килмәячәкне, фатирга да ул Сабираны кертергә мөмкинчелеге юклыгын, кешенең бәхетенә катнаша алмауларын, тагын әллә нәрсәләрне кузгатып бетерде. Ә Хәнифә Галиевна үз туксанына тугры булды:

— Алай түгел шул, акылыңны да сатар идем инде... Моны мин дә, син дә түгел, затлы улларыңның берсе башкарып чыкса гына!.. Зиһеннәрендә камилләрдер бит? Кызлар белән йөрү һөнәрен үзләштергәннәре бер дә сизелмиме?

— Кая ди ул, апам-җаным, нинди кызлар турында уйлау ди ул, һичкемгә күтәрелеп тә карый белмәделәр! — диде Гөлшат Фаиковна, тәмам утлар йоткан хәлендә. — Иремә охшаганнар, адәм затына күз ташларга да куркалар.

— Сөйләдең сүз, — диде, ачу кайнарлыгында акыл казаны кайный башлаган Хәнифә Галиевна, халык телендәге сүзләрне хәтерендә айкап. — Иреңне фәрештә бит ул дип әйтсәң, егылып үләрмен! Маржалар итәгендә җил уйнатудан әле кайчан гына арына башлады соң?

— Юк сүз! Сөйләмә дә! Булмаганны! Шушы кадәр ыштан тутырып бала алып кайта алыр идеммени, әгәр ул читтә талпынып-кагынып йөресә?

Әмма бераздан, күңеленә шик төшеп, апасына сынаулы карашын төбәде дә, ышанып яшәгән диварлары артында ышанычсыз, мәкерле җан яшеренеп ятуы мөмкин икәнлеген сизенеп, йөрәген тотырып аһ орды:

— Әллә сүзләрең дөресме, апа-җаным?

— Юк ла инде, болай гына әйтелде, — диярәк, Хәнифә Галиевна шунда ук сүз басымын киметеп өлгерде. — Иреңнән бәхетле булдың, сине дан итеп, дөньяда иң затлы, яраткан хатыны бәрабәренә күреп яшәде. Дәлилен үзең дә әйтеп бирдең, якты дөнья йөзенә ыштан тутырып балалар ташыдың, кайнар кочагында йокладың, җәбер-җәфа күрмәдең!

— Бик алай ук булмады шул, — дип, Гөлшат Фаиковна, каралып калган күңелен юарга теләде. — Гомере буе коры усал булды. Мин бит аның күз карашыннан да котым очып яшәдем. Өскә килсә, элекләрне, күлмәк итәгем юешләнеп киткәндәй тоя идем үземне. Дөрес әйтәсең, җаным, көндезләрен колы урынына күрә иде, кичләрен сөякләремә кадәр җебетеп куя иде. Гомерем буена ут белән су арасында яшәдем. Ярый әле соңгы елларда, улларым үсеп җиткәч, алардан куркамы-ояламы шунда, көндезләрен йомшарды, кичләрдә бушап калды.

Әлегә һичкемгә энҗедәй серләрен чишкәне юк иде, шунамы йөзе агарынды, йөрәгенең бу кадәрле батыр гамәлне башкарып чыга алуыннан хәтта хәтере җинеләеп калгандай тоелды. Хәер, сөйләмәсә дә була иде. Хәнифә Галиевна аның гаилә хәле нәкъ шушындый икәнлекне электән сизенеп яшәде. Араларына кермәскә, тормышларына катнашмаска тырышты. Йомышы төшмәсә, әле бүген дә бусагасыннан атлыйсы, чәй янына узасы түгел иде.

— Әйтәм бит, бәхетле яшәдең ирең белән!

Бераз тынлыктан соң, сәгате барудан хафага төшкән Хәнифә Галиевна бөтенләй дә башка төрле сүзләрне әйтте дә куйды:

— Менә шул Сабираны улларыңның берәрсе ымсындырып, үзенә каратып, Кәримә белән Газизчигем арасына керүеннән коткарып калса иде! Улларың гомерләрен бер кыз да күрмичә, ялгызлык хәсрәтендә уздырмасын өчен генә әйтәм боларны. Әллә ни авыр эш түгел ул аларга!

Ана, ниндидер өмет белән кайнап, хәсрәтләр чигеп утырган җиреннән шунда «Ильич лампасы» сыман яктырып алды. Ак йөзенә кызыллык йөгерү бер хәл, авызы ерылды. «Инде әллә, Ходаем, мине киленле итәме?» — дигәнрәк уй аңа нур өсти иде.

Әйтәсе — әйтелгән, сәясәт ятьмәсе тормыш дәрьясына салынган, бу кадәр олы эшне башкарып чыгуыннан Хәнифә Галиевнаның күнеле тынычланып өлгергән. Үз өметенең барып чыгасына ышанган хәлендә ул:

— Улың миңа килсен. Аңа үзең аңлатып бир. Карасы — Кәримә, сарысы — Сабира булыр! Әгәр күңелен үз ягына аудара алса — миннән зур бүләк! Шуны башкарып чыгыйк! — диде, инде гүяки карар биргән төпле түрә кебек җитди тонда сүз беркетеп. Гөлшат Фаиковна аның бу сүзләреннән соң артка чигенер хәлдә түгел иде инде.

Һәм менә, Хәнифә Галиевнаның җентекләп корган сәясәте, Гөлшат Фаиковнаның олы улы Гариф, кечесе Шәрифнең ярдәме белән — син күр дә мин күр — бик оста иттереп тормыш мәйданына китерелеп чыгарылды. Инде алдагы бер ай эчендә Кәримә белән Газизчикне тәмам пар күгәрченнәр кебек гөрләтеп, мәхәббәтне түргә келәм итеп җәеп, ахырында туй уздырасы гына калды.

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Кәримә артка таба чигенә-чигенә килде дә почмакка сеңде. Хәзер аның качар җире юк иде. «Абау матур бала, әйдә тотып карыйк әле!» — дип, кулларын сузып, бармак җәмкиләренә аны эләктерергә маташкан юләрләр ажгырып куйдылар. Берсенең кулы аның җилкәсенә тиеп узды. Ул чәрелдәп кычкырып җибәрде, ә Кәримәнең аһы да чыкмады. Менә соңгы ике-өч сәгать эчендә кыз әллә нинди сәер дөньяда яши башлады. Үзенең кайда һәм ни өчен монда икәнлеген башы җитеп аңлаудан ерак иде. Әмма шунысы ачык — аның тирәсендә һәммә кем бар, барысы да сәерләр, бөтенесе дә юләрләр! Чәчләре кырылган, хатынмы-ирме икәнлекләре битләрендәге төкләреннән генә ачык аңлашыла.

— Тимәгез минем гөлемә, ул минем чәчәгем!

Шунда кыйшайган авызлы, селәгәйләре агып төшеп идәнгә тамган берәү почмакка сеңгән Кәримәне яклап, теге җәмкидәй кулларын сузып гаҗизләгән кешеләрне читкә тибәрде, арысландай сугышырга теләп, аларга ташланып-ташланып ыжгырынды. Кәримә аның артына сыенды. Әмма бу вакытта ул үзен яклаучы арысланның азыгына әвереләсен күз алдына китерә алмый иде бугай? Егет, шунда кинәт борылып:

— И минем гөл чәчәгем! — дип, селәгәйле авызы белән Кәримәне үбәргә, кәкре гәүдәсенә кысарга маташты. Бер бәладән котылдым, икенчесенә каптым диярәк уйларга тиешле булган кыз, тагын да куркынып, читкә йөгерде. Ярый әле шунда бүлмә эче тынып калды, чөнки анда бер ир кеше килеп кергән иде. Ак төсе күптәннән уңып, саргая барган халатлы, олы гәүдәле булуыннан кем икәнлеге аңлашылды. Кәримә аның дөрес акыллы кеше икәнлеген шунда ук тоеп, кочагына ташланды:

— Абый, яшерегез мине, абый! Яшерегез! — дип гозерләнеп, йөрәк авазлары белән тилмереп үтенде. — Мин бит юләр түгел!

Ир кеше үзен тыныч тотты. Йөзендә бер генә чалым да үзгәрмәде. Әмма борчак бөртеге хәтлек күзләрендә генә нindидер үзгәрешләр булып алды һәм ул:

— Монда бер кеше дә юләр түгел, һәммәсе дә акыллы! — диде. — Әле танышмадыгыз дамыни? Ярар, өлгерерсез әле... Әйдә, сине чакыралар. Чәчләреңне йолкып бетермәсеннәр дип анда бер абыең килде. Син дә матураеп китәрсең! — дип, Кәримәне бүлмәдән алып чыкты һәм ярым караңгы коридорның аргы башына таба, җилкәсеннән кочкан хәлендә, карыштырмый алып килә башлады. Кыз шунда үзен мыскыл итәргә алып баралармы диярәк уйлапмы, кинәт бәргәләнә, бу ирнең каты кулларыннан

ычкынырга маташып карады. Әмма атасы хөкеменә тапшырылган сабый бала кебек ул үз теләгәненчә берни дә эшли алмый, бары хурланып еларга мәҗбүр иде.

— Абый, тимәгез инде миңа?

Кәримәнең уенда ниләр барлыгы бу адәмне кызыксындырмый булса кирәк. Аның исе дә китмәде. Шулай да:

— Тыпырчынма әле! — дип, каты итеп әйтүе өстенә, кочак эскәнҗәләрен дә ныгытты. Кәримәнең тыны кысылды, авыз читләренә күбекләре килде, инде һәммә эчке әгъзалары да тышка әйләнеп чыгар сыман тоелды. Ярый әле бер бүлмәнең ишеге төртелүгә ачылып китеп, якты тәрәзә каршысындагы урындыкка аны китереп утырттылар.

— Тыпырчынма! — дип тагын да әмер бирде китерүче адәм.

Шунда башка бер кеше күренде. Монысы инде чиста ак халатлы иде. Кулындагы тарагы белән Кәримәгә үрелеп, тыныч кына чәчен тарый башлап, туктап калды һәм, сулышын алыштырып:

— Мондый толымнарны кисәргә дә кызганыч инде, — диде. — Нигә кирәк икән юләрләргә мондый калын яхшы чәч, акыллы башлар такыр йөргәндә?

Кәримә аның бу сүзләренә бик тә гаҗәпләнде, шунда университет профессурасының күбесе ярым пеләш булуы, ә берсенең бөтенләй дә такыр икәнлеге исенә төшеп, һаман да хәйранлыкта калды. Аның уйлары хәтер буйлап йөгереп йөреп, кызның әле генә студент булганлыгын искәртеп торды. Бу хәл аны тагын да шомландырды. Шунда чәч алучы агай толымнарының әле берсен, әле икенчесен кайчы белән шырт та шырт итеп кисеп тә чыкты. Кәримә аңа монсу гына эндәште:

— Абый, мин кайда? Монда ничек килеп эләктем?

Агай тимер өстәлгә аның озын кара бөдрә чәч толымнарын сузып салды. Шунда кайдадыр шаулашкан, кычкырышкан тавышлар ишетелде. Сакта торган котсыз адәм ашыгып чыгып китте. Чәч кисүче агай, үзенең яһүди борынлы карт йөзенә күтәрелеп карап торган кызга иренеп кенә җавап бирде.

— Шуны да белмисеңмени әле, сеңлем, — һәм, ишеккә карап алып, анда һичкем дә юклыгын белгәч, — Сары йортта, — дип өстәп куйды.

Кәримә «Сары йорт» дигәннәренең ни икәнен аңлап өлгерде. Аның бу хакта ничәмә әсәрдән укыганы бар, юләрләр йортын шулай дип аталганын белә. Җәһәт кенә талпынып китеп, тәрәзәгә таба ташланды, аны ачарга итте. Әмма яһүди борынлы агай кызның янына килеп җиткән иде инде. Кәримәнең кулларына сак хәрәкәт белән үзенең җылы учын салды да:

— Сеңлем, алай итмә! Ашыкма әле! Син беренче һәм соңгысы түгел. Мин синең хәлеңне аңлыйм! — диде, тыныч тавыш белән генә, йөрәккә үтешле итеп: — Моннан чыгып та, качып китеп тә булмый, тәкъдиреңнән котыла алмаган кебек!

Кәримәнең кинәт хәле китте. Юк, ул инде сикерә дә, кача да алмый иде, хәтта тәрәзә ачык торса да, бу эшне җиңел генә башкарырга мөмкин исә дә.

Агай аны, шул хәлендә житәкләп китереп, урындыкка кабат утыртты. Аннары, сөйләнә-сөйләнә, кызның күңелен тынычландыра-тынычландыра, чәчен машинка белән ала башлады.

— Монда тәртип шулайрак инде. Чәчеңне алмасак, башкалар сиңа бер дә тынгы бирмәсләр. Чәч ул — сәясәт корбаннары шикелле, башны саклап калыр өчен коелып котыла, — дип, бик тә катлаулы итеп сөйләп алды, тагын дәвам итеп: — Менә шулай ничек матур була! Чәч яхшырсынга электән бер-бер кырдыргалап алуны дөрес гамәлгә санаганнар. Сиңа да

килешә башлар, сеңлем! Бары сабыр бул, кинәшем шул! Сабыр булсаң, пәкем дә яхшы кырыр, машинкам да йөгерек булыр, — диярәк, сүзләрен такмаклап сөйли торды.

Кәримә анардан баш исәнлеге турында бик күп ишетте, монда күңел тынычлыгына өйрәнү генә зарури икән. Берәр мәгънәле уйга чума алмыйча интегү халәте дә интектерә. Үзе белән нәрсә булганлыгын, бу йортка ничек килеп эләгүен белә алмыйча мең кат борчылды, хәтерен кайтара алмыйча гаҗизләнде. Аны һаман да күңеле алдый иде. Бу хәлдә дә кала алмый бит инде!

— Абый, мина нәрсә булды икән? Нигә монда яптылар? Кеше үтермәгәнмендер бит? — диде кыз, һаман да куркынып.

Аның бу сораулары чәч алучыга түгел, асылда үзенә, үз хәтеренә адресланган иде.

— Һе, кызым, юләр түгелмен, дисең, ә үзең ахмак сүзләр сөйлисең! Кеше үтерүчене «Сары йорт»ка китермиләр, төрмәгә илтәләр, — диде яһүди борынлы абзый, эшен бетерә барып.

Шунда ишек ачылган тавыш белән бергә алар янына кемдер керде. Теге саргайган халатлы адәм икән, сүзләреннән үк танылды:

— Нәрсә, гел шулай тыныч кына утырдымы бу?

— Селкенмәде дә! — диде чәч алу эшен инде бетереп өлгергән агай. — Мондый пациентларыгыз булганда, эшегез бер дә авырга килмәс.

— Белмим, — диде теге адәм, — мондыйларның ни гаебе бардыр? Аңламыйм. Әллә дөнья үзгәреп, анда, тышта, ил «дурдом»га әйләнеп бара инде?

— Сәясәт һаман да искечә кала, кешеләре генә үзгәрә, дисезме?

— Мин андый ук дәрәҗәдә әйтмәдем! Болай гына... Мондыйларны да китерә башлагач, дидем...

— Гаепсез кеше булмый... Димәк ул, кайдадыр хата ясаган, агымга каршы йөзгән... Йә ярый, минем эшем бетте, юк сүз белән гомеребез үтәр дә китәр, ашыгырга кирәк. Эш кала күрмәсен! — диде ул, кечкенә чемоданына һәммә әйберләрен өстәлдән җыеп алып. Аның сәясәт, ан, дөнья, ил турындагы сүзләре Кәримәнең колагына адресланган булуын кыз әлегә аңламады. Шулай да ул аларны ачык ишетеп, бераз ачыла алган хәтеренә сендереп калды.

— Кара әле, дустым кем! — диде шунда ул агай. — Син бер үтенечемне башкарырга булышмассыңмы?

— Нәрсә соң ул?

— Нәрсә дип... Ярар, башлагач, әйтим инде... Үтенеп сорыйм! Харап итмәсеннәр. Бәлки шушы үтенечем өчен Ходай Тәгалә мине дә Кыямәт көнендә ярлыкар? — дип, йөрәкләргә шом салырлык итеп әйтеп куйды. — Ул бит бер дә юләргә охшамаган!

Каты тавышлы теге авыр адәм тамак кырды һәм, ярым пышылдап:

— Юләр түгел әлегә! Әмма аны шул хәлгә төшерәчәкләр. Башка барыр юлы юк! — диде.

Агайлар шунда ук кычкырып сөйләшүгә күчте. Хушлашкан кебек белдереп, бер-берсенә матур сүзләр әйттеләр. Кыз да үзенең аларны тыңлап торуын сиздереп елмайды. Алга таба да сары халатлы каты абзыйның авыр холкы белән котларны алачагын уйлады. Әмма:

— Сеңлем, әйдәгез, палатага! Авыруыгыз узганчы шунда ятып сихәтләнерсез! — дигән, күңелгә җиңел кабул ителерлек сүзләрен ишеткәч, тәмам буйсынды да куйды.

Кәримә аңа ышанды һәм башын иеп артыннан иярде. Ул хәзер үзенең яки тәкъдир белән, яисә башкача шушы хәлләргә хөкем ителгәнлеген сизенгән читлектәге кош иде.

Кәримәне абзый кеше башка бер палатага кертеп, чиста урынны күрсәткәч, аңа шунда ятып торырга кушты. Монда инде башкалар йоклый иде. Кесәсеннән ике төймә дару чыгарып, аны йотарга кушты, өсте ак чүпрәк белән ябулы өстәлдән бер стакан су алып бирде. Кәримә ул кушканнарны һичбер каршылыксыз төгәл үтәгәч, агай стаканны кире алды, ятарга, өстенә ябынырга булышты һәм теге кечкенә, ак япмалы өстәлен, андагы яртысы эчелгән сулы стаканны һәм башка җиһазлары белән бергә күтәреп алып чыгып китте.

Кәримә нииндидер сәер, әмма инде таныш кебек тоелган халәткә керде. Йокысы килеп, башы авырттырып әйләнеп китте. Тагын да су сорамакчы итте. Әмма тавышы чыкмаганын тойды. Гүяки күз алмалары әйләнәдер сыман иде, шул сәбәпле күнелендә авырлык тойды. Тагын укшыгандай булды. Күзләре авыр йомылгач кына, ничектер тынычрак хәлгә кергәнен хис итте. Янынннан гына җылы җил исеп узгандай тоелды. Киң далада бишек эленеп тора, Кәримәне шунда тибрәтә иделәр. Юк ла, табут икән бит бу, кара табут! Әмма һичкем юк. Кәримә шунда, дала белән күк арасында эленеп торган табутта ята. Җил тагын исеп куя, табут-бишек тибрәнә, такталарының шыгырдаган тавышы да ишетелеп ала.

## II

Кәриманең тынычлана баруы күңелен дә урынына утырткандай булды. Инде хәтере дә тәртипкә килә башлады сыман. Менә ул Сабира белән лекцияләргә йөгерә торган иде. Ә бүген аның янында иптәш кызы юк. Әйе, аларның, Гариф белән Сабираның, шушы язда мәхәббәтләре купшыланып чәчәк атты. Ул хәтта бер генә минут та егетен исенә төшермичә яши алмый башлады. Әле беркөнне шигырь дә язган, Кәримәгә шуны укыды. Беренче тәҗрибәсеннән көләргә ярамый иде. Шунлыктан Кәримә аңарга:

— Бик матур чыккан! Гарифка укыгач, хәйран калачак әле! — дигән булды.

Сабира әүвәле аңа ышанган да, бүлмәләрендә шатлык чәчә-чәчә сөйләнеп йөренә дә башлаган иде, аннары:

— Бу урынны болай итсәк, анысын алай үзгәртсәк, — дия-дия, Кәримә аның язмасын бөтенләй дә төзәтеп бетергәч, телсез калды. Кабат укып карадылар һәм хәйран иттеләр: шигырь йөрәк серләренең шундый да тирән кылларына тиеп үтүче җырга әверелгән иде.

— Моны мин яздыммы? — диде Сабира. — Дустым, мондый әсәрне гомеремдә дә укыганым юк! Шушы кадәрле үткен талантым бар икәнлеген электән үк белгән булсам, әллә кайчан Габдулла Тукай белән ярышырлыгымны күрсәтеп, дөньяны шаккаттырыр идем!

Кәримә аңа каршы һичбер сүз әйтмәде. Бары сонынннан гына:

— Тагын да язып кара әле! — диде.

Шушы рәвешле Сабира шигырьгә бирелеп китте. Болай әйтсәм ничек була, алай язган идем, матур килеп чыкканмы, дигән сораулары белән Кәримәне аптыратып бетерде. Әмма аңа киредән сүз әйтү барыбер ярамый иде. Бу шигырен дә Кәримә, сыерлары мөгрәгән, сарыклары бәэлдәгән Сабираның күңел абзарыннан якты дөньяга чыгарып, зәңгәр күкләрдә канатларын иркен җәеп аккош кебек оча торган җыр итеп ясап бирде. Сөенечләре чиксез иде. Шигырен Сабира акка күчерде. Янадан укып чыкты һәм, иптәш кызын кочаклап алып, сөенеч-шатлыгы белән бетмәс-төкәнмәс хисләр ташкынын кубарды.

Беренче тәҗрибәләрен өченчесе алыштырды. Әмма бу юлы Кәримә аңа башкачарак киңәш бирергә булды:

— Сабира, Тукайны кабат укып чык әле, ничегрәк аны аңлыйсың икән?

Менә шушы хакта уйланып, дикъкатенне бер юнәлештә тотсаң, тәҗрибәң дә артыр! — диде.

— Юк, мин шигырьләр укырга бер дә яратмыйм. Аларны аңламыйм. Анализлап сөйләтеп, профессорларыбызның аптыратулары да җитмәгәнмени? — дип, Сабира каршы төште.

— Алай түгел шул, — диде аңа тагын да Кәримә. — Шигырь ул — әдәбиятның нигезе!

— Ә ул вакытта проза нәрсә? Ул әдәбиятның атасы түгелмени? — дип, Сабира тагын да аңа каршы төште. — Укыйсың, аңлашылып тора!

— Ә үзең шигырьләр язасың!

Кәримәнең бу сүзе Сабирага тәэсир итте булса кирәк. Кулына ул Тукай томын тотып утырды. Ярты көнен диярлек шушы халәтендә уздырды. Тәмам арып-талып, томлыкның уртасына барып җитә алмыйча, ереп йокыга китте. Икенче көнне башы авыртудан зарланды. Әмма Гарифы белән очрашасын исенә төшереп, янадан кабынып китте дә:

— Кара әле, Кәримә, мин Тукайны аңлый башладым бугай! Моңа кадәр сүзләрен генә укыганмын, матур килеп чыккан рифмаларына сокланганмын, вакыйгаларына... Ә хәзер... Ә хәзер... Беләсеңме «Пар ат» шигыре нәрсә турында?.. Үзем әйтәм! Ул — яшәгән җирне, андагы кешеләрне кайда барсаң да сагынып искә алачагың турында!.. Син дә мине, укып бетереп таралышкач, шулай сагынырсыңмы икән?.. Ә мин сагынырмын сыман! — дип тезеп-тезеп сөйли башлады. — Ул бит Казанга чибәр ярымны очратам, аның белән җәннәттә яшәгән кебек гомер кичерәчәкмен дип шагыйранә ышанып килгән! Аңлыйсыңмы? Шуңа күрә Казан белән дә горурланган, аңа сокланган!

Сабираның бу хисләре иптәш кызының күңеле өчен бер генә дә яңалык түгел иде. Шулай да сүзләрен тагын-тагын куәтләндерергә теләп, аңа:

— Син, дустым, табышмак! Дөньяның серләрен үтә күрә башлагансың, — диде. Әмма шул ук вакытта боларны да әйтте: — «Пар ат»та Тукай абыебыз үзе хакында язмый бит. Аның лирик герое — шәкерт. Ул аның хисләрен сурәтли. Әсәре шуның белән кызыклы да! — диде.

Сабирага аның бу сүзләре ошамады. Ялганында тотылган баланыкы кебек йөзе кызарды һәм ул:

— Син генә беләсең инде бөтенесен, син генә аңлыйсың! — дип, ачуын да яшерми белдерде. — Университетта да шулай, семинарларда үзең генә җаваплар биреп барасың да, профессорларыбыз, лекцияләрендә безнең барлыкны онытып, синең белән генә дәрес алып баруга күчә!

Сабира бу сүзләре белән хаклы да, мәгънәсезлегендә хаксыз да иде. Хикмәт шунда: башка студентлар күпчелек очракларда авызларына су кабып, бик олы акыл ияләре кебек утыралар-утыралар да, үзләренә атап сорау бирелә калганда, җавапка күчәсе урынга, ыкы-мыкы килеп, аптырашта калалар. Аларга Кәримә ярдәмгә килә. Сорауларга туры һәм төгәл җавап бирә. Шушымы икән инде аның башкаларга укырга, белем алырга комачау итүләре?

Ә беркөнне ул, Гариф белән кич буе йөреп, аның бәхетле кочакларыннан канатланып кайткач, үзе Кәримәдән имтихан алды. Әле бер шигырь хакында әйтте, әле икенчесен сөйләде. Һәм, шуларга өстәп:

— Ул нәрсә турында? — диде. — Бусы нинди?

Иптәш кызының дикъкате укый торган китабында булганга, анардан гел «белмим», — дигән җавап ала торгач, бу хәлгә бик тә куанды һәм ул әсәрләрнең мәгънәләрен ачык итеп, төгәл итеп үзе әйтеп бирде. Китабыннан Кәримә тәмам аерылды. Сабираның күңелендәге үзгәрешләргә сокланам гына дигән иде, ә ул:

— Боларны миңа Гарифчик әйтте, бик беләсең килсә! Күрәсеңме,

ул нинди башлы, син аңламаганнарны да җиңел генә төшенә! — дип, көтмәгәндә егете белән мактанып, очсызлы сафсата сатып ташлады. Кәримә анда да тантана иткән кызның кайнар хисләренә салкын сүз суларын сибеп, арада гауга парын чыгарасы килмәде.

— Әйе, Гариф акыллы егет шул! — дип әйтүдән узмады.

— Син дә шулай уйлыйсыңмы, дустым? — дип, Сабира тәмам канатланып, өстәл артында укып-язып утырган Кәримәнең өстенә үк ташлангандай аны ике куллап кочып алып, үзенең күкрәгенә кысты. Мондый галәмәтләр әле бер ай гына элек анарда юк иде. Менә бит мәхәббәт нишләтә! Салкын таш бәгырьле Сабирабыз да кешечә икән, балавыз кебек эрегән!

— Әйе, Гариф акыллы егет! — дип тагын кабатлый Кәримә.

— Син нәрсә, минем бәхетемнән көнләшәсеңме әллә?

Билгеле, һәммә кеше дә башкаларга үз күзлеге аша карый. Ә ул күзлек — аларның йөрәге. Әгәр дә безгә шикләнүчән, игътибарыбызга саф мөнәсәбәт күрсәтмәүче кем дә булса очрый икән, ул адәмнең кем икәнлеген таныдыгыз инде!

Сабиранын көнче күбәләк булуын элгәрерәк күрсәткән әче-төче кыланышларыннан ук белгәненә күрә, аның бу яктан һаман да үзгәрешсез калуына игътибар иткән Кәримә бу юлы да елмаеп куярга гына мәҗбүр. Шулай шул, берәүләрне табигать бала чагыннан зиһенле, күркәм, акыллы итә, икенчеләрне таш бәгырьле килеш тормыш мәйданына чыгарып җибәрә.

— Бик көнләшер идем дә, Гарифчигең мина кырын күзен дә салмады шул! Беренче көннән, беренче күрешкән минутыгыздан яныңнан китмәде! — дип, Кәримә шунда үпкәләү кыяфәте чыгара. Сабира тагын тантана итә башлый. Аннары, кабат зиһене җыелып:

— Ә ул, безнең очрашулар саен, һаман да сине сорый, сине мактый! Мина яманларга да бирми! — дип әйтеп ташлый. Шушы рәвешле хисләре кабарып, тагын холыксызланасы итә. Әмма Кәримә:

— Соң, нишләсен инде? — ди. — Без бит бергә, бер бүлмәдә яшибез! Мине сораган булып, синең хәлләреңне беләсе килә инде аның, үзең дә сизенәсеңдер!

Әгәр дә ике ел гына элек бик житди тоелган Сабираны һәм күбәләктәй очынган Кәримәне күреп калган кешеләр бүген аларның шушы сөйләшүләренә колак салсалар, кыз баланың егермегә кадәр кырыкка төрләнеп өлгерүенә хәйран итәрләр иде.

— Гариф абый бүген миннән, безнең профессорларыбыз Муса Җәлилнең шигырьләрен халыкка кире кайтару белән бәйле нәрсәләр сөйли, белик әле, дип сорады?

Сабиранын бик оста рәвештә сөйләшү темасын үзгәртергә маташуын Кәримә аңламый калды. Хәзер ул ни укыган китабыннан күңеле белән аерылган, ни иптәш кызына гаҗәпләнүеннән туктаган, әллә нинди сәер сагышка-гамьгә кереп чумган иде. Фәхри абыйсы Хисами исенә төште. Аның бүген Кәримәне эзләп университетта йөрүе хакында әйткәннәр иде, моны кыз ничек аңларга да белмәде. Шушы хакта сүз кузгаткан укытучы ханым, бик тә житди итеп:

— Кара аны, кызый! Аң бул! — дип кисәткән иде бит!

Ә Кәримә аның ник шулай ачуланганын төшенми калган булган!

## III

Ул көнне Сабира иртән университет китапханәсенең уку залына киткән иде. Өченче дәрескә докладын житештерәсе бар. Анысын да, Кәримәсе әйтеп исенә төшермәсә, игътибарыннан бөтенләй читтә калдырасы икән. Иртәрәк уянып, очты гына кыз, юньләп ашап та тормады. Гариф белән

йөрүе аны бөтенләй бәхетле итеп куйган, дөньясын тәмам оныттырып бетерткән икән.

Укулары бу елда төштән сонга, кичке яккарак күчеп, расписаниеләре икенче сменага төзелгән иде. Университетка Кәримә дә ялгызы гына китте. Әмма барып җитәрәк, уку бинасы төбендә аны бер яшь әфәнде туктатты. Алар танышлар иде. Кәримәнең аны ничәмә күргәне, журналдан әсәрләрен дә укыганы булды. Тик нигәдер ул аларны кабул итә генә алмады. Ясалма купшы җөмләләрдән, очерк тибындагы нәрсәләрдән гыйбарәт иде алар. Хәтта олы гына повесте дә элгәрерәк басылып чыгып, хәзер бу әфәнденең Язучылар союзында шактый җаваплы постка күтәрелгәнлеге дә, акрын-акрын гына, бөртекләп диярлек дөньяны үз учларына җыя барганлыгы хакында да сүзләрнең ишетелгәне бар иде. Арча якларыннан булуы теленә үк чыккан, йөз-кыяфәттә дә марига тартым икән.

— Кәримә, сезне көтә идем, бик җитди сөйләшү өчен! — дип, кызны ул бик җиңел туктатты. — Лекциядән кереп алып чыгарга иткән идем дә, дәресләрегез башланмаган икән. Сүзебез кыска булыр. Аңлашсак, уртак фикергә килсәк, сезне озак тоткарлап тормам.

Кыз нәрсә хакында сөйләшәселәрен башына да китермәде. Мондый кешеләрнең юк белән йөрмәүләрен ул аңлый иде. Кәримәгә яки берәр эш урыны тәкъдим итәчәк инде, әнә бит, югары курслар хәзердән үк төрле газета-журналларда эшлиләр, яки дә, белмәссең, Мәскәүгә, язучыларны әзерләүче институтка укырга җибәрерләр бәлки? Монысын кыз бик теләи, әмма ничек булдырып чыгарырга белмичә, Фәхри Хисами абыйсына да сөйләгән иде. Ә ул ашыкмаска киңәш итте. Бәлки Язучылар союзына хәбәр салгандыр да, менә бу иптәш шуның өчен аны эзләп килгәндер?

— Син безнең нiләр хакында сөйләшәчәгебезне беләсеңдер инде? Фәхри Хисами... — дип сүз башлап, үзенә ияртеп: — Әйдәгез әле, Лобачевский бакчасына! Анда тыныч урын, шунда сөйләшеп бетерербез, — дип, кызны алып китте.

Кәримә һаман да үз уйларына батып, Мәскәүгә ничек китәсе турында хыяллана, бергә укыган иптәшләрен ташлыйсы булуы хакында сагышлана да башлады. Әгәр дә мөмкин икән, монда гына укуын дәвам итсә дә ярыйдыр сыман тоелды. Әмма Мәскәүгә бару, анда белем алу теләге кыз баланың күңелен, бөек хыял рәвешен ала барып, көчлерәк ымсындыра иде. Шушы уйлары аны әле сагышка, әле шатлыкка салды. Бакчага җитеп, андагы эскәмияләрнең түрдәге бушында урын алгач та хәтерен болгатып тотты ул өметләре.

Әдип иптәш озын кара чәчләрен бер янга таба, аннары артка куллары белән чөеп үк ташлады. Җитдиләгән яшермәде.

— Безнең нәрсә хакында сөйләшкәнебезне төшенәсездер? Моны беркем дә белергә тиеш түгел. Хәтта минем белән очрашуыгызны да! — диде ул. — Болар сер булып калсын. Мин дәүләт органнары белән бәйләнештә торучы кеше. Әгәр дә сүз ишетелсә, сезгә якты көн калмаячак!

Кәримә, тәмам аптырашка төшеп, ни әйтергә дә белмәде. Яна гына «беләм» дип баш каккан, унтугызы тулып кына җиткән кыз баланың күңелен шом басты. Аның бу хәлдә йөрәге сыкрап алды.

— Безгә сезнең Фәхри Хисами белән барлык мөнәсәбәтләрегез дә билгеле. Ул күпне күргән, авыр язмышлы кеше. Башкаларга карата изге карашларын саклап калуы гына аны яшәтә. Хатынын югалткан, картлык көнендә ялгызы калган. Ә сез аның хисләре белән уйныйсыз. Бу сезнең кебек «бишле»гә генә укучы комсомолка кызга килешә торган нәрсә түгел! Мәхәббәт аша әдәбият мәйданын яулап алырга омтылуыгыз — монысы инде бернинди киртәләргә дә сыймый!..

Бу әдип иптәш язган әсәрендәге кебек, бик тә гаделсез сөйли иде. Кәримәнең йөрәгендәге шомы зурая, бөтен эчке-тышкы дөньясын басып ала барды. Аның бу минутларда колаклары дөрес ишетә идеме — ул боларын ук анларлык хәлдә түгел сыман. Нинди мәхәббәт уены ди инде ул тагын? Нәрсә сөйли бу абый? Әллә юри, сынар өчен генә әйтәме боларны?

Кыз бала ансызлана баруын да төшенмәде, шушы кадәр гаделсезлек аның йөрәген изде, шом тагын да зураеп китеп, аның күзләрен һәм сулышын каплады. Бу халәте әдип абыйга өстәмә көч бирде булса кирәк, ул инде чебешкә ташланган явыз кара козгын кебек иде, Кәримәнең бәгырен изеп сөйләвен дәвам иттерде, сездән сингә күчте:

— Карт кешене аздырып йөрмәсән, яшьләр беткәндер? Чакыр гына, сенлем, әллә мин каршы килер идемме?.. Әмма Фәхри Хисамины мәхәббәт кочагына алдап кертүең — бусы инде ай-һай, бер дә юньле эш түгел! Чарасын күрүне көтәсеңме?

Әдип арттырып җибәргәнен дә, кабих булуын да сизмәде. Аңа боларны анлау бирелмәгән иде. Ул әле бөек премияләр алыр, исемнәр!..

Кәримә елый ук башлады. Ялынган тавыш белән:

— Абый, ни сөйлисез сез? Нигә мине болай пычратасыз? — дип әйтеп алды. Аның йөрәге бозылган, хәзер аңын да югалтыр сыман тоелды. Әмма, бу хәленә дә карамастан, әдип абый, аңа комсыз карашын юнәлткән килеш, сүзләренең басымын көчәйтүне кирәк тапты. Кызның елавы, куркып калуы белән генә канәгать түгел иде, ахрысы. Әмма көтмәгәндә ул кабат сезгә күчте:

— Шигырьләрегез бер тиенгә дә тормый! Сезгә моннан соң әдәбият ишеге бикләнәчәк! Фәхри Хисамины үзегезгә ялчы иткәнсез. Моның нәрсә хисабына эшләнгәнлеген анламаска, безне юләргә саныйсызмы әллә? Җитмәсә елап утырган буласыз! Комсомолдан да, университеттан да колак кагарсыз!

Шунда Кәримә кабат үзгәрде, барлык зиһенен, соңгы көчләрен җыеп өлгерде һәм:

— Боларны сезгә Фәхри абый Хисами үзе әйттеме әллә? — дип сорады. Аның туры һәм көчле карашы әдиптән дөресен сөйләвен таләп итә иде.

— Сез нәрсә, безне тинтәккә дә саныйсызмы әллә? Аны нинди газапларга салганыгызны, җанын-йөрәген үртәп аптыратуларыгызны белмибез-күрмибезгә нисбәт итәсезме? Әнә, сезгә атап ничәмә шигырь язган инде! — дип, ачу белән әйтеп, әдип иптәш шунда кызның йөзенә таба кулы белән гүяки сугардай булып хәрәкәт ясады, әмма озайта алмады. Моңа намусы җитмәдеме, әллә кеше күзе күреп калыр дип өректеме?

— Ул үзе әйтмәгәч, ничек инде шушы сүзләрне миңа сөйлисез? — диде рәнҗетелгән кыз, яшь аралаш йөзен тагын да югары күтәреп. — Ул бит мәхәббәт шигырьләрен хатынына атап, аны сагынудан яза! Аларда минем ни катнашым бар?

Кәримәнең кирелеге әдипнең акыл шөрепләрен бушандырып алдымы, әллә әйткән сүзләрендә хаклык барлыгы да сизелдеме — арада тынлык урнашты. Әмма ул адәм китәргә, гафу үтенергә уйламады да. Шулай да уйга бирелеп алуы яхшыга сыман тоелды.

Бераздан зиһенен җыеп өлгереп, әдип катгый тонда болай диде:

— Беренчедән, Фәхри Хисамиларга баруыңны бөтенләй туктатасың! Әйе... Икенчедән...

— Минем инде күптән аларга барганым юк! — диде шунда Кәримә, йөрәгенә барлык батырлыгы җыелганын тоеп. Әмма сүзләре әдипнең кабат ачуын гына китерде. Ул тагын да каралып-бүртенеп чыкты:

— Нишләп ул сине эзләп университетка килә? Аудиторияләргә керә? Кафедра укытучыларыннан сине сорый?!

— Белмим! Күргәнем юк!

Әдип шунда ук, аның сүзләрен эләктереп алып:

— Беләбез, без барысын да беләбез! Аңлап, күреп торабыз! Безгә барысы да ачык! Аны юри үртәп, аңардан качып йөрисез! Монысы да җинаять, монысы да — икенчедән!..

Кәримә бу ике шартның кайсысын үтәргә тиеш иде икән — аңлашылмады.

— Юк! Очрашмыйсыз, бетте-китте! Күзенә күренмисез! Әгәр дә бу хакта, күрешкәнегез, сөйләшкәнегез беленсә — башыгызны кайда черетергә белербез!

Һәм ул ашкынып китеп барды. Кәримә, учларына капланып, үксеп-үксеп елады. Шулай күпме утыргандыр, белә алмады. Инде лекцияләре башланып киткән, ә ул университетка барып керергә батырчылык итмәде. Зиһенен-йөрәген баскан шом колакларында дингез давылы булып күтәрелде, күз аллары караңгыланып, кояш та тотылгандай булып алды. Аның башына гүяки утта кып-кызыл итеп кыздырылган кыршау кидерттеләр һәм кыз, аңсыз калып, яны белән эскәмиягә сеңде.

Аны бу халәтендә һичкем күрмәде, әллә күреп тә борчырга теләмәде? Ул шушылай ярты сәгатьләп һушсыз ятты, аннары гына кемнеңдер сызгыру авазыннан уянып китте, күзләрен ачты. Сызгыру авазы кабатланган кебек тоелды. Ул шул тавыш килгән якка карады.

Университет ишегалдындагы тәбәнәк йортларның түбәсендә өч малай күгәрченнәр очырып утыра иде. Алар тагын да сызгырынып алды. Кәримә дә зәңгәр күккә төбәлде. Анда ак күгәрченнәр төркеме шаулап оча иделәр. Араларыннан берсе читкә каерылып, нәкъ кыз утырган бакча уртасындагы мәйданчыкка төште, гу-гу килеп йөренә башлады.

Менә аларның күзләре очрашты. Ана күгәрчен башын ия-ия сәлам бирде, тагын да гу-гу килеп, гүяки тынычлануын үтенде.

Малайлар тагын сызгырды. Аларның теләкләренә буйсынып, күгәрчен, ак канатларын җилпеп, күккә күтәрелде, очып килгән төркем аны, үз кочагына алып, югарыга таба аштырып менеп китте. Алар ерагайдылар, нокталарга, пыяла өстенә сибелгән дөге ярмаларына охшап калдылар. Шунда берәү:

— Кәримә! Нишләп монда утырасың? Лекцияне хәзер кемнән күчерәм инде? — дип, ачулы һәм канәгатьсез тавыш белән эндәште. Кыз аңа таба борылырга мәҗбүр булды. Китапханәдән уку бинасына таба йөгергәнендә булыр, Сабираның, туктап, әрсез күзләре белән карап торуын күрде. Үзенә дә ашыгырга кирәк икәнлеген аңлады. Аларның уку урыны «Химкорпус» дип аталган, университетның әле яңа төзелгәнгә саналган колонналы биналарының берсе иде. Лобачевский бакчасына каршы якта гына урнашкан.

Кәримә дә Сабира артыннан шунда таба йөгерде. Әмма тукталып калырга мәҗбүр иде. Ишектән Фәхри Хисаминың факультет деканы белән сөйләшеп чыгып килгәнен шәйләп өлгерде, юан колонналарның берәрсе артына тизрәк качарга итте. Чабып-йөгереп килеп, йөзгә-йөз декан абыйсы белән бәрелешә язып калган Сабирадан Фәхри абыйсы нидер сорады. Кыз, артына борылып, әле яңа монда иде дигәндәй, эзләгән кешесен таба алмыйча, бакча ягына таба күрсәтеп, нәрсәләрдер аңлатып алды да ишеккә кереп чумды. Декан белән хушлашып, Фәхри Хисами Лобачевский бакчасына таба атлады. Кәримә аның кемне эзләвен шунда ук аңлап өлгерде. Деканның үз юлы белән китеп баруы да аңа кулай булды. Хәзер Кәримә, Сабира артыннан ашкынып, куып тотарга теләп, ишеккә таба ашыкты. Әмма аннан студентлар төркеме чыга башлап, аны гаҗизлектә калдырып, керергә мөмкинлек бирмичә аптыраттылар. Кәримәнең бер күзе Фәхри абыйсы Хисаминың аркасында, икенчесе — ашыкмыйча чыга барган студентларда иде. Ахырда түзмәде, кысыла-төртелә эчкә таба ташланды.

Плащ итәгеН кемдер тарттымы, күкрәк турындагы төймәсе өзелеп төште. Әмма аны эзләп торырга вакыты юк иде. Барча балалардан бары тик кеше күзеннән качып китеп кенә котылып була дип уйладымы — ул үз иптәшләре янына, лекция аудиториясенә таба йөгерә бирде.

IV

Мостафа мөгаллим кара бәрхет түбәтәен урамда да киеп йөри, аудиторияләрдә дә салмый һәм моны шулай кирәк дип белә торган шәхес иде. Кәримәләргә ул беренче курста ук гарәп хәрефләре белән язулы татар текстларын уку дәресләрен алып барды. Хәзер Каюм Насыйриның грамматикаларына бәйле махсус курсны җитәкли. Бу киң мәгълүматлы, югары зәвыклы, эчке мәдәни куәтле кеше лекцияләрен бик җитди тонда, һәр мәсьәләнең төбенә төшеп аңлатып алып бара. Уку аудиторияләре һәм кафедралары химия факультеты белән бергә булганлыктан, монда кәләпүшле яһүди профессураны күрү дә сәер тойгылар уятмый иде. Коридорда алар татар түбәтәйле Мостафа мөгаллимне очратсалар, аңа иркен колач җәеп, хәтта яңакка-яңак китереп исәнләшәләр. Бу хәлләр студентлар күз алдында бара, әмма кайбер укытучыларның җенен чыгара — нәрсә инде ул, милләтчеләр, искелек тарафдарлары, имеш. Әмма бу күрә алмауларының асылында наданлык һәм көнчелек ятканлыгын да аңлау кыен түгел.

Бигрәк тә быел гына тел гыйлеменнән кандидатлык диссертациясе яклап өлгергән ханым, үзенең лекцияләрендә иркенәеп китеп, «Кәләпүш» кушаматы белән атап, Мостафа мөгаллимнән төрлечә көлгәли, хәтта студентларга мондый укытучыдан гыйлем эстәп йөрүләренең хаҗәте юклыгы хакында искәрткәли торды. Аның ул әйткәннәре Кәримәнең бавырына ябыша. Алар нигәдер дөрес сүзләр түгелдер сыман тоела. Соңгы вакытларда үзе белән булып узган хәлләр дә моңа этәргеч ясый булса кирәк? Шунлыктан, сабыры бетеп:

— Лекцияләр темасы башкачарак бугай, апа, — дигән иде, хәтерен калдырырлык сүзләр ишетте:

— Әнә Кәримә Дулатова кебек комсомолкалар үзләренең нәрсә хакында сөйләүләрен дә онытып җибәрәләр. Тел гыйлемендә һәммә нәрсәнең әһәмияте бар, шуны да аңламагач, университетта укып йөрүнең нинди кирәген табасыз?

Кәримә партасына сеңәргә мәҗбүр ителде. Моңа кадәр һаман да «бишле»гә генә укып йөргән кыз бу ханымның фәннәреннән күзгә күренеп түбән тәгәри башлады. Мөгаллимә хатын һәр практик дәрестә аны такта янына чыгара торды. Хәер, Кәримәнең җавап бирү өчен алга чыгарылуы электән гадәти күренеш иде. Әмма аларында бүтән студентлар эшли, сөйли, чишә алмаган, аңлата белмәгән очракларда гына шулай була иде. Хәзер барысын да төшендереп бирәчәк үзегезгә дип, аны мактап, чираттагы «бишле» билгесен куяр өчен такта янына махсус чыгаралар сыман иделәр. Ә бу ханым, киресенчә, мыскыллап, җитмәсә юри, менә белдекле кызны чыгарыйк әле дип әйтеп, мәкер белән эшли.

Кәримә чынлыкта һәммә яңа теманы белеп, өйрәнеп барырга тырыша. Аның зиһене камил, тиз үзләштерүчән. Тик ханымның лекцияләренә кереп китә алмый. Аларда аңа нидер җитми. Һәм менә шул нидерне Кәримә китап-дәреслекләрдән таба. Ә мөгаллимәсе:

— Юк, алай түгел, дөрес эшләмисез, җөмлә болай анализланмый, тел гыйлемендә шагыйрә кызларга «ничу делать»! — дип, хаталарын табып тормыйча, мыскыллауга керешә. Студентлар аптырашка төшә, зиһеннәре бутала. «Бу апага ни кирәк икән?» — дип, аңа сораулы карашларын төбиләр. Болай булса, берсе дә имтиханнарын уңай билгегә бирә алмаячакларын төшенәләр.

Университет гыйлеме дигән сүзнең шундый хикмәте бар: ул үзенә үткән-бүгенге-киләчәк фәнни карашларны, фикерләрне бергә берләштерү көченә ия, хакыйкатьне ачыклап, аның чиксез булуын төшендерә. Анда һәммә белем алу тәртибе анализлау һәм синтезлау мантыйгына корылган. Сөйләп бирү түгел, бәлки аңлату — белем бирүнең асылында ята. Мостафа мөгаллим нәкъ менә шундый шәхес тә бит инде! Ә бу яшь мөгаллимә ханым аның ул якларын таный алмый. Дөрестер инде, башкаларның хаклыгын күрә алмаган кешеләр үзләре хаталы буладыр! Таный белергә кирәк, таный! Ә бәлки Кәримә ялгышадыр?

Вакыйгалар үз тәртибендә бара торды. Ә беркөнне Кәримәне коридорда Фәхри абыйсы Хисами көтеп алды. Аның анда барлыгын кыз сизмичә-күрмичә калган иде. Лекцияләре бетүгә, Сабира белән тизрәк кайтып китәбез дигәннәрендә, Фәхри Хисманиның нәкъ каршысына килеп чыктылар. Исәнләштеләр. Кәримә үзенең каушавын тойды. Ул әлегә бернинди дә хисләр кичермидер сыман иде. Беренче күрүеннән бирле Фәхри абыйсына кыз хөрмәт белән карады, әмма аны сөю-ярату тойгылары анарда бар иделәрме — әйтә алмастыр сыман. Газизчик абыйсы да кызга шушылай ук кадерле, әмма аңа да йөрәге ялганып житә алмый. Әйе, аңа да! Юк-юк, монысы дөрес түгел, аның йөрәге, хисләре аша, шушы Фәхри Хисамига тоташкан түгелме соң? Йа Ходай? Бу нинди аяныч хәл?

«Әгәр дә күрешсәгез, сөйләшсәгез... Фәхри Хисамины тынычлыкта калдырмасагыз, без сезне нишләтергә белербез!» — Болар бит теге кара эчле әдип абыйның сүзләре. Ул монда гынадыр, карап-күреп торадыр!

— Кәримә Дулатова, сез әле китмәдегезмени?

Ә боларын теге мөгаллимә хатын әйтте. Кәримә аның тавышы килгән якка күтәрелеп карады. Баскычтан алар янына «ай-яй!» дип чекрәеп шул ханым төшеп житеп килә иде. Кызга бик тә оят булып, газиз башын кайларга куярга да белмәде.

— Ачуланмагыз, Альбина Халиковна, гаеп — миндә! — диде шунда сабыр һәм итагатьле тавышы белән Фәхри Хисами. — Кәримәне мин туктаттым, сүзем бар иде аңарга. Ачуланмагыз? Үтенәм!

Калын бәдәнле һәм мәгърур буйлы, бик тә килешле сыйфатлар иясе, чәчләрен матур итеп артка каратып тарап, заманча итеп өеп куйган мөгаллимә ханым:

— Укуы начарланды Кәримә Дулатованың, Фәхри абыйсы! Дәресләремдә «өчле»гә төшеп бетте! — диде.

Бу сүзләре күрәләтә мыскыллау өчен әйтелгән иделәр әлбәттә. Дөрес, Альбина Халиковнаның алай дип уйларга, мондый сүзләрне дә кычкырып әйтергә хакы бар кебек:

— Сез бер-берегезне яхшы беләсез бугай? Абыйлы-сеңелле дип әйтимме? Башкачамы?.. Фәхри абыйсы, аңлатыгыз әле үзенә, тәртибе дә йомшарды кызның!

Альбина Халиковна горур кыяфәтендә шушыларны әйтә-әйтә алар яныннан узып китте дә:

— Сабира, Сабира! Сабира сеңлем, туктагыз, мине көтегез әле! — дип, ишек янындагы дүрт рәтле баскычтан төшеп, Кәримәнең иптәш кызын култыклап алып чыгып китте.

Кәримә, шул ук көнне белде: Сабирага Альбина Халиковна аспирантурада калырга, фән белән шөгыльләнергә куша икән, гыйлемгә сәләтен зурлаган. Кызның түбәсе күкләргә тигән!

Альбина Халиковнаның махсус мыскыллауларына да үч итеп, ул кичне Кәримә Фәхри абыйсы Хисами белән Ленин исемендәге урам буйлап Кремль ягына таба атлады. Монда кешеләр дә күзгә карап үтми, тәрбиялеләр, йөрергә дә уңайлы, якты. Һәммә таш, койма, тәрәзә, ишек — тарихи. Менә

анда элек «Татгосиздат» урнашкан булган. Ул ишектән Һади Такташ узып йөргән. Ә монысы — ашханә. Анда да легендар шәхесләрнең эзләре. Болар Фәхри абыйсы Хисаминың үз тормышына бәйле, ә Кәримәгә — тарих.

Һе, кызык икән, менә алар икәү — Фәхри Хисами һәм Кәримә Дулатова, икесе ике чор кешесе, берсе — олы шагыйрь, ә икенчесе — әлегә каләм тибрәтүче. Тарих һәм заман бергә атлап баралар. Сөйләшәләр.

— Кәримә сеңлем, соңгы айларда күренмәдегез! Мин монда, университетка, студентлар белән очрашу кичәләренә ничәмә тапкырлар килдем. Араларында сезне күрмәдем, кадерлем! Авырдыгызмы әллә? Юктыр ла инде! Булмас! Сезнең кебек гүзәллек иясенә сырхау кагылып китәргә оялыр!..

Фәхри абыйсы шагыйранә сөйли иде. Аны Кәримә үзен эзләп килгән дип тора, ә ул әнә химия факультеты студентлары белән очрашуга чакырылган икән. Мәхәббәт, Ил, Ватан, Дөнья, Галәм турында шигырьләремне укыдым, яратып тыңладылар, ди. Әле беркөнне генә рус филологиясе төркемендә укучы студентлар белән очрашуда булган. Аңа ак гвардиячел Бунин, Ахматова, Гумилев кебек, Кәримәнең колагына-зиһененә әле генә керә башлаган шәхесләрнең иҗатларына бәйле сораулар биргәннәр. Пушкинның хикәяләрендә эчке гармония турында сөйләгән идем, ди. Студентларның моңа бик тә күңелләре булган. Аларның әдәбият белән кызыксынулары аны чиксез сөендергән. Муса Җәлил хакында истәлекләремне сөйләргә үтенгәч, аңа карата нинди яхшы караштa торуымнан башлап китеп, Һади Такташка кучкәнмен, ялгышымны әллә сизми калдылар, әллә инде аңладылар, бары әйтергә кирәк тапмадылар, ди. Декан үзе алып барган очрашуны. Аннары, кабинетына чакырып, сөйләшеп тә утырганнар. Сезнең хакта да аңа әйткән идем: «Безнең бик яхшы студентыбыз ул!» — дип мактады үзегезне, ә мин шагыйрә икәнлегегезне дә искәрткәч, сезне чакыртып, эзләткән дә иделәр әле, лекциягә килмәгән булгансыз икән.

Кәримә әле уттай янгандай хәлгә төшә, әле суыкка эләккәндәй куырылып китә. Фәхри абыйсы сөйли дә сөйли, бәйрәмнән бәйрәмгә, туйдан туйга гына йөргән кебек китереп чыгара. Менә бүген Кәримәне очратуына бик шат икән. Күптәннән күрешмәгәч, кешеләр сагындыра, имеш!

— Сеңлем, безгә килегез, кил! Мин күп вакытымны өйдә уздырам. Барыбыз да сезне сагынабыз, хәтта тәрәзә төбендәге гөлләр дә!

Кәримәнең күптән инде мондый сүзләрне ишеткәне юк. Күңеле шатлык һәм бәхет хисләре белән тула. Алар Кремль янына барып җиттеләр. Язгы кичнең салкын һавасы Фәхри абыйсын да туңдырып ала. Университет ягына китәргә дип борылдылар. Умырзаялар баш калкыттымы икән әле? Кәримә аларны бик ярата. Бу хакта Фәхри Хисамига да әйтте.

— Мин сезне аларны сөясездер дип белми идем, — ди шагыйрь абыйсы.

Кәримәне әүвәле ромашкалар белән тиңләгән булган ул. Инде менә хәзер генә аңлаган. Умырзаялар турында искә алынса шигыремдә, ул сезнең хакта булыр, сеңлем, ди. Умырзая чәчәкләре ритмга да, гомернең үтүенә бәйле фәлсәфәгә дә килеп-килешеп тора икән бит. Бу ачышка этәрүе өчен Кәримәгә аерым рәхмәтләр әйтә барды.

Фәхри абыйсы белән шушылай сөйләшеп йөрүләре рәхәт тә бит. Менә алар үзара ничек аңлашып, җиңел, күңелле итеп баралар. Әнә университет. Тәрәзәләреннән яктылык нур чәчә. Утлар кабынган. Кичке укудадыр инде студентлар? Көндез дә, читтән торып та, башкача да халык белем ала-ала, һәммәсе дә бик акыллы булып бетәрләр инде. Менә бәхет, менә күрелмәгән хәл — һәркем югары белемле! Мондый акыллы илдә яшәве дә күңелле булыр!

— Сезнең фатирыгыз кайда әле, Кәримә сеңлем?

— Монда гына! Университет урамы буйлап төшәм дә, Болакның аргы ягындагы, сул кулдагы йортта торам. Ерак түгел!

— Әйдәгез, яшь вакытларым хәтеремә кайтсын әле! Хәзер караңгы да ирешеп килә аннары! Кеше-кара кимсетмәсен, сезне озатып куям!

Кәримә әлегә бер сүз дә әйтми. Алар Университет урамы буйлап Бауманга таба төшә баралар. Фәхри абыйсы борынгы хан заманнарындагы тарихларны сөйләүгә күчә. Шунда шаулы студентлар төркеме аларны аралап уза. Берберсеннән ераклашып калалар.

Ул да түгел, анда Бауман урамы буйлап кайтып килүче Газизчик абыйсы күренә. Кәримә, куанып:

— Әнә ул абый, бире таба килә бит әле, урам уты эленгән багана төбенә житте, эшләпәле! Ул безнең фатир хужабикәбезнең улы. Анаияреп китәрмен, Фәхри абый, сезне аптыратып йөртмәскә яхшы булыр!

Килеп житеп, танып өлгергәч, яшь кеше мул елмаеп исәнләшә:

— Ә, безнең Кәримәбез! Кайтып килүегезме?

— Менә сезне көтеп алып торабыз! — дип куана кыз. — Таныш булыгыз, бу — Фәхри абыем Хисами, шагыйрь һәм сез дә таныш булыгыз, данлыклы инженер — Газиз абый!

— Сез нәрсә инде, Кәримә! Кешене ышандырырсыз тагын, мин нинди данлыклы инженер булыйм,ди? Фәхри абый, исәнмесез тагын бер кат, сезнең белән очрашуыма, танышу форсатына бик шатмын!

Алар кул кысышып күрештеләр. Үзара хәлләрен сораштылар. Утның сүрәнлеге икесенең дә йөзен ачык күрергә, йөз чалымнарын барлап калырга мөмкинлек бирми. Ә менә тавышлары тигез һәм ягымлы, матур итеп сөйләшәләр дә инде!

— Сезнең кебек егеткә, житмәсә фатир хужасына Кәримә кебек чибәр кызны ышанып тапшыра алам, — ди шунда Фәхри Хисами, әйткән сүзләренә күп төрле мәгънәләр салып. Аны Кәримә аңлый, Газиз абыйсы да кабул итә. Әмма үртәлми һәм үртәргә дә теләми.

— Фәхри абый, сез бик дөрес әйтәсез, мона кадәр, бездә яшәгән чорында Кәримәгә жил дә тидермәдек. Түбәбездән яңгыр да үтмәде. Бүлмәсе дә салкын булмады бугай? Моннан соң да шулай була күрсенгә тырышабыз, — диде Газизчик. Әмма аның шушы кадәр күп итеп сөйләп куюлары үзенә дә гажәп бер хәл иде булса кирәк, инде хәзер ни әйтергә белми, кинәт шым калды.

Фәхри абыйсы да берни өсти алмады. Ул үзенең яки шат булуын, яисә башкача бер-бер фикергә килгәнлеген белдерергә тиеш иде. Әмма жаен югалткан бала сыман, бераз читкә тайпылды.

— Газиз абый, мин сезгә тагылып кайтсам, ачуланмассыздыр бит? — диде шунда Кәримә, бу сүзләрендә һичбер башка төрле уй күрмичә, үзен тыныч тотып.

— Бик яхшы булыр, әйдәгез әле, киң урамнарны тар итеп, егет белән кыз булып узаек! — дип, Газизчик шунда Кәримәне култыклап алды. Аларның бер-берсенә килешеп торуларын Фәхри Хисами да күрми-аңламый калалмый иде. Әмма ул бөтенләй дә башка төрле сүз әйтте:

— Сезгә Кәримәне ышанып тапшырасым да килми башлады әле! Әллә үзем генә озатып куяргамы соң? — диде.

Боларны ишеткәч, кыз каушап, калтыранып алды. Әмма Газизчик бик тә матур сүзләр табып өлгерде:

— Моңа кадәр Кәримә бездә фатирда яшәде! Әтисе дә бик ышанып тапшырып киткәнне, сез, Фәхри абый, алай әйтмәгез инде! — диде.

Алар шул сүзләрдән соң бераз көлешеп алдылар да хушлашып аерылыштылар. Газизчик абыйсының беләгенә ябышкан хәлдә Кәримә, анардан калышмый, Болакка таба ашыкты. Адымнары шактый жылы иде. Фәхри Хисами трамвай тукталышыннан ерак калмаган иде. Ул шуннан кайтып китәр.

## V

Соңгы атналарында Сабира лекцияләрен еш калдыра башлады. Гарифы белән, мөмкинлек чыкканда, бергәләп кибетләргә йөриләр. Нәрсәдер буласы, туйгамы җыеналар? Әмма моны һичкемгә әлегә белдермиләр. Кәримәнең дә үз хәсрәте үзенә житкән, артыгын кызыксынмый. Аның күз алдыннан теге кара чәчле әдип абыйның кыяфәте, хәтерендә исә усал итеп куркытып әйткән сүзләре иде булса кирәк? Житмәсә Фәхри абыйсы белән булган очрашуны яна пешкән фән кандидаты мөгаллимә ханым күреп калды бит. Хәзер гайбәтен ил беләдер инде? Казанның үзәк урамыннан шагыйрь абыйсы белән узулары да күзләргә чалынмый калгандыр дисеңме? Ничек хаталанды Кәримә, нигә кирәк иде бу кадәр кылану?

Лекциягә килеп кергән Мостафа мөгаллим гадәтенчә кара бәрхет түбәтәеннән һәм ягымлы елмайган йөз белән иде. Көне дә матур килде бит әле аның. Бөтен дөньяны тутырып яз яме йөри. Ә менә аудиториядә Кәримә үзе генә иде.

— Башкаларыгыз кайда? — дип сорады, аптырашка бирелеп Мостафа мөгаллим. Ул әлбәттә бер студент өчен генә дәрес башлый алмый инде.

— Алар коридорда иделәр. Шунда булырлар. Дәрес башлануын онытып жибәргәннәрдер? Чакырыйммы үзләрен? — диде Кәримә, урыныннан кузгала башлап.

— Юк-юк, сеңлем! — диде Мостафа абыйсы, ана кулы белән күрсәтеп, ишарәләп утырырга өндәде. — Монда гына икәннәр, хәзер, чыгып, үзем дәшәм. Ничек алай тугарылып китүләре аңлашыла. Яз галәмәте бит, сеңлем!

Һәм ул Кәримәнең группадашларын аудиториягә чакырырга дип ишектән чыкты. Аның әйткән сүзләре ачык ишетелде:

— Кызлар-егетләр, кадерле шәкертләрем, мөмкин, әйдәгез, аудиториягә узыгыз, лекциябез башланып китте!

Студентлар белән болай жайга китереп университетта яһүди профессорлар гына сөйләшә торган иделәр. Башка доцент-мөгаллимнәр исә аларны көтү урынына куып йөртергә ярата.

Мостафа мөгаллим тыныч кына әйләнеп тә керде. Кафедра артына басып, лекцияләр итеп туплап куйган язмаларын ачты һәм:

— Бүген безнең тема... — дип, сузыбрак сүз башлаган иде, ишектән Сабира күренде. Нигәдер ул Кәримә янына килмичә, дәшми-тынмый, мыштым песи сыман, иң арткы рәтләрнең берсенә барып утырды. Мостафа мөгаллим ана игътибар итмәде булса кирәк:

— Яздыгызмы, Кәримә сеңлем? — дип сорады һәм лекциясен җиңел сулыш белән башлап китте. Ул арада икенче, өченче, дүртенче студент та кереп утырды. Лекция дәвам итә торды. Бер Кәримәдән башка әлегә бүтәннәр дәфтәрләрен ачмаган, яза да башламаган иделәр.

— Каюм Насыйри фәндә һәрдаим халыкчан булды. Тарих, тел, әдәбият, химия, тыйбба-медицина кебек гыйлемнәргә дә халыкчан якын килеп, без фольклор дип аталган халык иҗаты ягыннан фикерләрен үстерә барып...

Аудиториягә калган студентлар да кереп тулды. Кәримә үзе утырган беренче рәткә кемнең дә якын килмәвен күргәч, монда нииндидер мәкер барлыгын сизгер күңеле белән тоярга тиеш иде югыйсә. Әмма дикъкате лектор абыйсының сүзләрендә булганлыктан, башка нәрсәләр турында уйламады. Лекциясен Мостафа мөгаллим өзмәде, жиңел агымда дәвам иттерде, халык иҗаты дигән сүзләренә аеруча басым ясый барды:

— Аның шушы нигездә фикерләрен үстерә баруы татарда гыйлемнең чыннан да халыкчан нигезләргә корылганлыгы хакында сөйләмиме? — дигән кызыктыргыч сорау куеп, студентларга башын күтәреп карады.

— Әйе, — диде аңа Кәримә, гадәттә ул профессорларына лекцияләрендә шулай ярдәм итеп алгалый иде.

Әмма шунда группадаш егетләреннән берсе каты һәм ачулы итеп:

— Юк! — дип әйтеп куйды.

Лекциясен дәвам итүдә булган Мостафа мөгаллим, шунда аудиториягә башын кабат күтәреп карап, нигәдер сүзсез калды. Аптырабрак торды да:

— Ни өчен юк дип уйлыйсыз, кадерле шәкертем иптәш Хизамов? — дип, ярым мәсхәрәле тонда сорады.

— Юк булганга юк! — диде теге, аягына торып басып.

— Анысын ишеттек инде. Әмма аңлашылмый, ни өчен юк!

— Бик тә аңлашыла! — диде Хизамов, мишәрлеге белән кайнап чыгып: — Без кәләпүшле мулладан комган хәрефләре турында хорафи лекцияләр тыңларга университетка кермәдек! Без сезгә протест белдерәбез!

Аның болай кистереп әйтүләре хафага төшерми калдырмады. Мостафа мөгаллим хәтерсез адәмгә әверелгән төс алды. Әгәр ул шушы шәкертенең киләчәктә татарның гарәп хәрефле китаплары буенча үзен белгеч дип танытасыннан хәбәр алалган булса, бәлки аның сүзләреннән көлеп кенә куйган һәм: «Сез ялгышасыз, әфәндем!» — дип, аны урынына утыртуны мәслихәт күрер иде. Әмма шушы мең дә тугыз йөз дә илле тугызынчы елда шул ук егерменче гасырның ахырында дөнья йөзе нинди төсләр алачагын кайдан күзалларга мөмкин? Ашыгып, тамырсыз утыртылган коммунизмның кибә барган агачы иртәгә шаулатып чәчәк атачагына дәгъва белән кабат җаннарны кузгатырга алынган мең тугыз йөз алтмыш беренче ел да ул вакыт өчен ерак бер киләчәк вакыйгасы кебек иде.

— Илебез галәм киңлекләрен яуларга җыенган чорда без иске кәләпүшләрдән гыйлем алырга теләмибез! Кемнәр комсомол, әйдәгез, минем арттан! — дип, шунда Хизамов аудиториядән чыгып китте. Башкалар да берәмләп-икәүләп-өчәүләп аңа иярде. Сабира да күренде. Ул әллә Мостафа мөгаллимнең, әллә Кәримәнең күзенә чалынырга теләмичә, алдан барган группадашы Бәриянең артына кача-кача чыкты. Бу хәлләр котчыккысыз вакыйга иде.

Аудиториядә тынлык урнашты. Бераздан Мостафа мөгаллим телгә килеп сорады:

— Сез берәр нәрсә аңладыгызмы?

Кәримә җавап бирә алмады, ул үзе дә укытучысыннан артыграк таңгаҗәптә иде.

— Комган хәрефләре, имеш! Дураклар! Шушы комган хәрефләре безне мең ел буена яшәтеп, җаннарыбызны гыйлем суы белән юындырып, зиһеннәребезне агартып килгән!..

Ул һушын алыштырырга дип өстәл артындагы урындыкка утырды. Студентларның протестыннан бигрәк, аны аларның аңсызлыгы, томана булулары шаккатырган иде. Әгәр дә халык чыннан да сарык икән, ул бары тик чыбыркы телен генә аңлый. Әгәр дә халык мәдәниятле, алга омтылучы булса, аңа гыйлем, мәдәният, әдәбият, сәнгать кирәк һәм ул аларның югары дәрәҗә алуын тели, аларны үстерүгә бар тырышлыгын куя. Хикмәт бит акчаң булмаудан җырлап йөрүдә түгел, бәлки синең җырлавыңның халыкка кирәкле, теләп һәм сорап алынуыннан! Әдәбият, сәнгать, мәдәният, фән бары тик шушындый очракларда гына кешелеккә хезмәт итә ала.

— Ә син, сеңлем, нигә аларга иярмәдең? — диде шунда Мостафа мөгаллим, сабырлыгын күңеленә кабат кайтарып.

Кәримә аның нигә бу сорауны бирүен аңламады.

— Мин бит сине, сеңлем, саклап калалмаячакмын. Хәзер мин үзем яклауга мохтаҗ, — диде мөгаллиме. — Синең тирәңдә, Кәримә сеңлем, болытларны бик тә куерталар. Инде чират миңа да житкән икән. Берүк сак була күр!.. Йа Ходай, тагын шул заманнар башланды микәнни? Инде дә үзгәрде, үзгәрә бара дип тора идек!..

Мостафа мөгаллим әллә үзенә, әллә Кәримәгә сөйли иде. Сулышын алыштырырга итеп, тәрәзә янына барып басты, аннары аны ачып җибәрде. Салкынча язгы һава аудитория буйлап узды. Шунда ишек ачылып китеп, олы гәүдәле, ат кыяфәтле йөрешендә Альбина Халиковна килеп керде һәм:

— Кая студентларыгыз? Алар миңа кирәк иде. Дәрес булмыймы әллә, Мостафа ага? Кәримә, ә син монда нишләп утырасың? — дип, ялагайлык һәм ялган төсмердә сорауларын яудыра башлады. Бигрәк тә соңгы җөмләсе нәрсә өчен, нишләп йөргән аңлы кешенең күңеленә ирешелерлек ителеп әйтелде. Әмма моңа Мостафа мөгаллим игътибар бирмәде, Кәримә чыгып китәргә инде соң булуын сизенде. Ана хәзер шушы аудитория бүлмәсе ныклы сыену каласы сыман тоелды.

— Алар яна гына чыгып киттеләр, — диде Мостафа мөгаллим, тәрәзә яныннан китеп, шунда кулындагы дәфтәрен өстәлгә куярга җайлана алмыйча, анда нәрсәләрдер яза,ниндидер билгеләр тезә башлаган Альбина Халиковнага.

Ханым ашыкмыйча гына маташкан җиреннән кинәт үзгәреп, артыннан янып килгәндәй кабалана башлап, әмма озаклап эшен төгәлләде, аннары:

— Кая? Ни өчен чыкканнарын әйтмәделәрмени? Мостафа ага? — дип хафаланып сорады.

— Мин үзем төшенеп житә алмадым, Кәримә дә белми калгандыр... Алар коридорда түгелмени? Үзләреннән сорасагыз? — диде Мостафа мөгаллим, үзен тыштан һаман да тыныч тотарга тырышып.

— Очрамадылар, күрмәдем әлегә! — диде ханым, эшен бетереп, язган дәфтәрен күкрәгенә кысып. Ә аннары шылт итеп тагын да әйтеп куйды: — Кәримә, дәрес бетүгә — комсомол комитеты бүлмәсенә керерсең! Анда сине көтәләр!

Аның бу сүзләреннән соң кыз бөтенләй дә коелып төште, Альбина Халиковна михахайлаган ат сыман ашкынып чыгып китте. Лекция сөйләүгә дәрте беткән Мостафа ага кабат урындыгына утырган һәм өстәл өстенә таба сыгылып төшкән иде.

— Хәзер бит яшьләр җиңел юлны сайлыйлар. Рус гыйлемендәге казанышларны әләктереп алалар да бөркеткә әвереләләр. Әмма татар фәне, татар теле гыйлеме үз казанышлары нигезендә үсәргә тиешле, бу хакта уйлап та карамыйлар! — диде ул шунда.

Кәримә аның нәрсә өчен, кемгә боларны әйткәнлеген анламады. Ул әлегә бу кадәр үк төгәл, һәм гомуми, һәм конкрет юнәлештә фикерли белми иде.

— Диссертациясен тикшергәндә шуларны әйтеп алган идем, яратмады. Менә нәтиҗәсе дә күренде, җимеше озак көттермәде, өзелеп килеп төште, — диде Мостафа мөгаллим тагын да үчекләнеп. Һәм шунда аның башы югары чөелде: — Лекциябезне дәвам итик!

Кәримә язарга җыенды. Вакыт әле күптер сыман иде. Әмма дәрес үтеп тә киткән, тәнәфескә чыгарга хәбәр биреп кыңгырау шалтырады. Мостафа ага лекция материалларын җыйнады, портфеленә тутырды да: «Нык бул, сеңлем!» — дип авыр адымнар белән чыгып китте. Кәримә аның артыннан кызганып карап калды. Әлегә хәсрәте бары тик Мостафа абыйсы турында гына иде. Аны кафедра утырышына куеп тикшерерләр инде, түбәтәен дә салдырырлар. Нигә кия инде ул аны? Эшеннән дә куарлар. Кая барыр?

Шушы уйлары эчендә Кәримә комсомол комитеты бүлмәсенә юнәлде. Саклык белән генә ишек какты. Ачтылар. Керде. Түрдә, кызыл постаулы өстәл артында комсомол комитеты секретаре, аның янында гына теге кара

эчле әдип абый, тагын да өч-дүрт студент активисты. Кәримәнен группа старостасы, комсоргы, аннары Хизамов утыра иделәр. Ашкынып диярлек Альбина Халиковна да килеп керде. Йөзе бик тә канәгать, ана эчке горурлык белән тулы елмаю йөгертелгән иде.

— Барыбыз да монда бугай? Башларга кирәктер! — дип, комсомол комитеты секретаре белдерү ясады: — Бүген без комсомолка Кәримә Дулатованың тәртибен тикшерергә жыелдык. Материаллар тиешенчә тупланган. Бу мәсьәлә күптәннән безне кызыксындырып килде. Бүген тагын да бер ЧП булды, күз алдыгызда! Инде әйдәгез, сүзне башладык. Беренче булып кем әйтә? Сезме, староста? Комсорг Бәдриева? Әзерсездер бит?

Бәдриева дигәннәре какча йөзле, озын торыклы, ямьсез чалымнарга бай кыз иде. Ул:

— Ни инде, ни... — дип, бераз каушабрак, алдындагы язулы дәфтәргә карый-карый, сүзләрен тезеп чыкты: — Кәримә безнең «бишле»гә генә укучы кызыбыз инде, ни...

— Анысын без үзебез дә беләбез, иптәш Бәдриева! Мәсьәләгә якынрак килик! Тәртип ягына, үз-үзен тотышына, дәресләрдә материалларны үзләштерүдә комачаулык тудыруларына!.. — Комсомол комитеты секретаре бу сүзләрен ышаныч белән әйтте, Бәдриеваның пешмәгәнлегенә ризасызлык белдерде. Аның ачуы кайнарлана барды.

Кәримә үзен тәртипле, дәресне үзләштерү ягыннан һәрвакыт өлгемен дип саный иде, аптырабрак калды.

Шунда Хизамов:

— Менә бүген без комган хәрефләренә ябышып ятучы, артталыгы белән студентларны надан калдырырга маташучы кәләпүшле лекторыбызга протест белдердек! Саф, намуслы кызыл комсомол протесты! Бөтен группабыз бу мероприятиедә катнашты. Әмма Кәримә Дулатова милләтче мөгаллимне яклап чыкты, барчабыз каршысында! — дип тезде дә салды. Аның болай ашыгып әйтүләре, житмәсә университет укытучысына милләтчелек ярлыгын тагуы көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты, ахрысы, барысы да шым калдылар.

— Сез утырыгыз әле, утыр, Хизамов! — дип әмер бирде шунда ана кулларын күкрәгенә урап, урындыгында төптәй утырган Альбина Халиковна. — Сезгә чират житмәгән!

Кәримә алар каршында басып тора иде. Аның күз аллары бераз караңгыланып калды. Сүзне һаман да Бәдриевадан көттеләр. Ул сөйләп алып китә алмыйча аптырады. Аннары, үз хәлен аңлап, дәфтәрендә язылганнарны укый башлады:

— Безнең Дулатова үзсүзле, иптәшләренә өстән генә караучы кыз. Үз максатларына ирешү өчен өлкәннәр белән шаярудан да чирканмый, бүлмәдәш кызы Сабира белән дә тарткалашып, аны мыскыллап, аннан өстен булып яши, пычрак хыяллары турында шигырьләр яз... яз... яза-а...

Ул шунда укуыннан тукталып калды һәм, нигәдер күзләре акаеп, әле комсомол секретарена таба, әле кара эчле әдипкә, әле Альбина Халиковнага карады. Кәримәгә таба күзләрен күтәрергә көче житмәде. Тагын да укымакчы булды, әмма:

— Бетте, — диде.

— Анда алар гына түгел бугай бит?! — Кара эчле әдип, комсоргның үз янында утыруыннан файдаланып, язылган дәфтәр битенә ташланып карап алды. — Укы, укы!

Бәдриева шунда Кәримәгә гафу сорагандай күтәрелеп карады. Аларның карашлары очрашырга тиеш иделәр. Әмма Кәримә инде дөньяның якты йөзен күрерлек хәлдә түгел иде. Төсе китеп, тезләре бөгелә барып, идәнгә һушсыз хәлендә ишелеп төште. Берсе дә болай булыр дип көтмәгән иделәр, ахрысы. Беренче булып кара эчле әдип өлгерде:

— Су бирегез, су!

Комитет секретаре өстәлдәге саргаеп-күгәреп беткән графиннан чисталыгына зур шиге булган стаканга су агызды, чайкалдырып, эш кәгазьләренә дә түгеп бетерде. Кәримә ул арада күзләрен ачкандай булды. Әдип абыйсының кочагында һушына килүенә гаҗәпләндеме, күзләре шардай кабара барды. Бу вакыйгада тамашачы хәлендә калган һәммә кеше аптырашта, берни эшли алмас хәлдә иделәр. Кара эчле әдип кесәсеннән ниндидер тартмачык чыгарды, аннан ак төймә кадәрле ике түгәрәк дару тапты, аларны әүвәле учына салды, аннары Кәримәгә каптырды. Стакан сузып торган комсомол комитеты секретареннан «монда бир» диярәк суны алды һәм кызга эчеп җибәрергә кушты.

— Аңа хәзер бер-ике сәгать утырып торырга кирәк! — диде ул аннары, күтәрешергә булышуларын сорап.

Комитет утырышы шуның белән тәмамланган иде. Кәримә «Юләрләр йорты» дип аталган шифаханәдә генә аңына килде. Тәнендә-җанында авырлык сизү аны изә иде.

## VI

Июнь аеның эссе көннәреннән берсендә Казан шәһәренә ике гамьле кешенең иртәнге поезд белән килеп җитүе, вокзал алды мәйданында инде кая барырга икән дип аптырап торулары, шушы мең тугыз йөз илле тугызынчы елда кемне дә булса гаҗәпләндерде микән? Юктыр. Чөнки кала кадәр калага эчке-тышкы хәсрәт белән, юл йөрү газапларын кичеп, ничәмә-ничә кеше генә керми дә урамнарында югалып калмый, эреми? Әмма бу юлчыларыбыз «Юләрләр йорты»н табарга тиеш иделәр. Адресын да төгәл генә белмиләр, кешедән дә сорарга оялалар. Авылдан килгән шушы ага белән абый үз якларында олы кешеләрдән, хөрмәт белән телгә алынучы укытучылардан булсалар да, Казан өчен беркем дә түгел иделәр.

— Гарифулла, әллә соң, авырыксынмый, әнә теге милиционер егеттән сорыйсынмы? — диде апа кеше, чүпрәктән затлап тегелгән сумкасын эскәмиягә куеп. — Ул белә дә белә инде аны. Китер, синекен дә шушында!

Гарифулла абый дөньяда күпне күргәнгә охшаган, кулындагы ике тоткалы күн сыман сумкасын хатыны кулына тапшырып, борын өстенә күзлеген җайлап киеп, костюм кесәсеннән блокнот чыгарып, аннан «Телеграмма» дигән язулы кәгазьне алып, милиционер егет янына таба китте. Тегесе, аны күзәтеп торган җирдән, әллә юри, әллә кирәк булганга, арты белән борылып басты. Ярый әле урынында калды.

— Улым, кем, — дип мөрәҗәгать итте аңа Гарифулла абый, — сорыйммы-юкмы икән?

— Исәнмесез! — диде милиционер егет. — Сез кем буласыз? Монда нишләп йөрисез?

Андый сораулар алырын башына да кертмәгән агай бераз зиһенен чуалтып торды. Аның арыганлыгы, язмыш кадерсезләвеннән изалануы күренеп тора иде. Шулай да милиционер егеткә кулындагы телеграммасын сузды. Теге аны алды, укыды, аптырап күтәрелеп карады һәм:

— Вокзал эчендә «Справочное бюро» язулы урын бар. Шуны табып, алардан сорагыз. Юләрләрнең кайда икәнлеген мин белмим! — диде.

Гарифулла абый аның бу сүзләреннән соң күнелендә зур авыр хисләр кичерде. Әмма тормышны һәм андагы кешеләрне азмы-күпме белүе исенә килергә ярдәм итте. Рәхмәтен әйтеп, вокзал эченә таба юнәлде. Ярый әле ажгырып килгән машина, көч белән тукталып, аңа үтәргә юл бирде. Гарифулла абый шуны да абайламый барып, вокзал бинасы эченә кереп

китте. Анда ун минутлап торганнан соң гына кире чыкты. Бу юлы аның йөзендә бераз яктылык пәйда булган иде. Хатыны янына житеп, кайсы маршрут белән китәселәре турында сөйләп алды.

— Шулай бик еракмы? — дигән сүзләрне ишеткәч:

— Бара-бара якынаер әле... Казан зур шәһәр түгел ул! — диде. Аның сүзләрендәге сагыш һәм гамь куелыгы ят адәм колагы өчен дә авыр тоелачак иде. Апа кеше күзләреннән яшьме сөртеп матаашты, әллә юл тузанынмы?

Бер трамвайдан икенчесенә күчеп, шәһәр читенә таба гына түгел, дөнья артына кадәр барган кебек иялэнеп, тыныч кына килделәр дә килделәр. Аннары, урамны сорап белешеп, тыкрык кебек бер жиргә барып керделәр. Анда авыр капкалы, биек коймалы больница сыман бина бар иде.

— Шушыдыр инде ул! — дип, Гарифулла абый капканы барып какты. Анда бер күз ачылды. Башы эшләп өлгереп, Гарифулла абый алдан ук әзерләп куйган телеграмманы күрсәтте.

Көтәргә куштылар. Кайда да утырып торырлык урын юк иде.

Аннары кече капка ачылды, аннан бер агай чыкты. Ул яһүди борынлы кеше алар яныннан тыныч кына үтеп бара иде, нигәдер күтәрелеп карап, кемнедер таныгандай аптырап тукталып калды. Кулындагы яхшы көн кечкенә чемоданы, башындагы тар кырлы эшләпәсе ана бик килешле иде. Йөз кыяфәтләре бер дә татарныкы кебек тоелмаса да, ул аларга татарча эндәште:

— Кемне эзли идегез? Берәрсен көтәсезме әллә?

Гарифулла абый аңа кулындагы «Телеграмма» язулы кәгазьне шикләнеп кенә бирде. Ул аны укып чыкты да:

— Моны мин суккан идем... Килгәнсез икән, — диде. Тавышы бу юлы бик зәгыйфь чыкты.

— Сез бу хастаханәнең баш врачымыни? — диде Гарифулла абый, шунда тагын йөзе яктырып алып. — Сезмени инде ул иптәш Спиранский?

— Юк, мин үзем Рәхмәтулла дигән кеше булам. Гүзәл туташ Кәримәнең башын кырыккан идем. Ул көн уникенче апрель иде, шушындый ук иртәнге вакыт. Кызыгыз акылында иде әле... Менә шуннан соң айнымады инде. Үлгәненә бүген өченче көн. Спиранский белән танышлыгым яхшы булу аркасында сезгә аның исеменнән телеграмма суга алдым. Югыйсә белми дә каласы идегез. Аны бүген жирләргә әзерләп, табутка салдылар инде, — дип сөйләп, әйдәгез әле диярәк үзенә ияртеп, хастаханә коймасы яныннан уза торган сукмактан ары таба алып китте.

— Сез аны барыбер дә үз авылыгызга алып кайта алмас идегез. Ничек адресыгызны таптым, дисезме? Монысы да үзе бер вакыйга. Әйдәгез. Анда, бүлнис каршында торып, кызыгызны алып киткәннәрен күрми дә калыр идегез. Монда морг арткы якта...

Алар, Кәримәнең әтисе һәм әнисе, яһүди борынлы адәм артыннан ниңәрсә уйларга да белми аптыраш хәлдә бара бирделәр. Бераздан койма бетеп, уңга таба киттеләр. Анда ачык һавалы жир икән.

— Шул уникенче апрель көненнән кызыгызның монда ни өчен килеп эләгүен белешеп, укыган жиренә барып, сораштыргалап йөрдем. Төгәл генә аңларлык һичбер хәбәр булмады. Шуннан, Мостафа мөгаллим дигән әдипне беләсездер инде?..

— Әйе, әйе, укыйбыз шигырьләрен! — диде апа кеше. — Беләбез! Беләбез! Ник белмик?

Ана кешенең, мондый игелекле жанны очратудан һушы яхшырып, моңа кадәр бәгыренә утырып житкән ташлары бераз эрергә маташып алган чагы иде бу. Гарифулла абый да дикъкатен югалтмады.

— Менә шул кеше әйтә, гел «биш»кә генә укучы бик чибәр бер кызыбыз бар иде, Кәримә Дулатова, ди... Шуны югалттык бит әле, ди... Мин аннан

сораштырып, кызның төс-кыяфәтен белештем. Дөнья йөзендә үзара охшаш кешеләр була түгелме? Кайбер әйткәннәре дөреслеккә туры килеп җитми бит. Шулай да әти-әнисенең адресын сорадым, ягъни сезнекен инде. «Бу сиңа нәрсәгә кирәк?» — ди ул миңа. Электән танышлыгыбыз бар аның белән, шиккә саласым килмәде үзен. Мин әйтәм, бәлки авылына кайтып киткәндер, дим. Ул да аптырап калды. Адресын табыйм, хат языйм әле эзләп, ди. Күрәм, нәрсәдәндерме, кемнәрдәндерме курка үзе. Ярармы икән, ди. Нәрсә киңәш итәргә белми аптырап уйлап, булмый болай, сөйләп бирим әле, дим. Әмма мин дә икеләнеп калдым. Ул аның, сезнең кызның... Ә бәлки сезнең кыз да түгелдер? Танымыйм бит мин аны, исемен дә белмим. Монда да әйтмәделәр. Менә карарсыз, бәлки кызыгыз түгелдер? Чыннан да...

Алар арткы капкага килеп җиттеләр. Анда олагаем гәүдәле бер адәм ат җигеп маташа иде. Яһүди борынлы кешене күргәч, ул аңа сәлам юллады да:

— Ә болары кемнәр? — дип, кертмәскә маташты. — Ярамый! Монда исән кеше йөри торган җир түгел! — диде, юлларына аркылы төшеп.

Яһүди борынлы аңа кесәсеннән кәгазь акча чыгарып бирде дә:

— Аларның Спиранскийдан рөхсәт документы бар! — диде.

Ат җигүен ташлап торган агай, Гарифулла абыйның кулында «Телеграмма» кәгазьен күреп:

— Ә алай булса — ярый, — диде дә акчаны кесәсенә салып куйды. — Ялгыз табут бар, өстен какмаган идем әле!

Эчтә салкынча һәм караңгы иде. Озын өстәл кебек урында табутка ут яктысы төшеп тора, анда чебеннәр, һәртөрле талпаннар бәргәләнә иде.

Яһүди борынлы агай саклык белән генә табут капкачын ачты да кырыйгарак шудырды. Баласын танып алган ана кеше аһ итте. Бәлки кызым түгелдер дип өметләнергә өлгергән Гарифулла абыйның йөрәге кыелып төшкәндәй булды. Ир белән хатын бер-берсенә капланып елап җибәрделәр. Табутта башы уралган, бит яңаклары коры сөяктәй ябыккан, дөньяның беренче гүзәле, иң зур акыл ияләреннән берсе, татарның киләчәктә бөек шагыйрәсе булачак затлыдан-затлы Кәримәсе тыныч кына, кузгалмас булып ята иде. Шунда күкләр ярылып китеп, гүяки Газраил үзе елагандай ишетелеп алды. Ә юк икән шул. Бу — теге ат җигүче дәү гәүдәле агай ишекләрне киңрәк ачып җибәргән. Инде алар янына килде дә:

— Бу бала сезнекеме? — дип сорады.

— Әйе, безнеке! — диде дөньяның бәхетсез әтисе.

— Зиратка илтеп, җирләргә кушылды! Гүре кәтә баланы! — дигән җавапны ишетте.

Эшләгән урыны «Юләрләр йорты»нда үлем-китемне, башка хәлләрне күп күрүдән бәгыре тупасланып беткән ул агай дөнья хәлләренә исе дә китмәстән һаман сөйли бирде:

— Мөслимә кыз булганга дип, аны шлангадан су агызып өч кат юдым. Матур бала булган. Күз тигән. Дүрт катка төрдем. Менә йөзен генә капларга күнелем тартмады. Табут капкачын какканда тагын бер карармын дигән идем. Бигрәк матур бала бит! — диде.

— Башын да яулыклагансыз икән, — диде шунда ана, тагын да баласына күз нурын күчерердәй бага торып.

— Анысын духтырлар эшләде. Баш капкачын ачып, анда нәрсәләр барын эзләгәннәрдер инде... — диде теге адәм, һаман да үзен салкын тотып.

Мәрхүмәнең анасына авыр була башлагач, табутның капкачын ябып, теге кеше кадаклар санады. Әмма шунда ул, эшен башламыйча калдырып:

— Рәхмәтулла, син укый беләсең, әллә җеназасын башкарасыңмы? — дип сорады.

— Чиста урын мәслихәт андый гамәлгә, — диде яһүди борынлы зат

агай. — Зиратка кергәнче, алгы якта туктап, женаза намазын башкарып алырбыз. Бездә шулайрак инде ул, күргәнен бар...

Намазны тәмам иткәч, тагын киттеләр. Сулда тезмә-тезмә тәреле каберләр калды. Аннары бер алан күренде, аны да уздылар. Калын һәм биек тирәк агачы янына килеп туктадылар. Аның калку ягында авызын ачкан кабер иде.

Тынлык. Кайдадыр сандугач сайрый. Әнә икән, баш очларында гына, тирәк ботагында бер кошның йөренгәне-сикеренгәләгәне күренә. Үзе чут-чут килә.

Зират тынлыгына кушылып бераз тынып торганнан соң сандугач, тирәкләрнең ботакларыннан йөгерә-ашкына иң түбәнгә кадәр диярлек төшеп житеп, аларның баш очларында сузып-сузып, өздереп-өздереп, шаулы итеп сайрап жибәрде. Ана тәлкыйн авазлары кушылды.

## VII

Фатир ишеген Газизчик килеп ачты. Ул киенеп алган, каядыр чыгып китәргә әзерләнеп житкән иде. Гарифулла абыйга бераз карап торгач, танып алды.

— Сез Кәримәнең әтисе бит, әйеме?

— Әйе, әнкәсе белән килгән идек әле менә...

— Бик яхшы булган, бик яхшы... Түрдән үтегез! — диде аннары Газизчик, ни әйткәнен дә аңламас хәлдә каушап.

— Без озакка түгел, әйберләрен алырбыз да, фатиры өчен түләрбез дә китәрбез, — диде ата кеше, адымга авырайган хатынын ияртә кереп.

— Әйе, әйе... — диде Газизчик, һаман да каушап төшүен яшерергә куәте житмичә.

— Өйдә кеше юкмыни? — диде шунда Гарифулла абый. — Безгә әле бит, хужабикәне дә күрергә кирәк иде. Аннары, ни, кызым белән яшәгән Сабираны да... Сорарбызмы дигән идек. Ни, ничек икәнлеген...

— Сабира безнең туганыбыз Гарифка кияүгә чыкты бит. Туйга әзерләнәләр, бүген булачак! Әнием дә шунда, табын әзерләшермен дип киткән иде...

Егет мул елмаюга, шатлануга күчте. Анардан мондый сүзләрне ата белән ана ишетсәләр дә, нәрсә хакында әйткәнен аңламыйлар төсле иде. Аларның аптырашлы хәлләрен күреп, Газизчик тынычландырырга ашыкты:

— Кәримәнең чемоданын әнием тутырып куйган иде. Менә ул! Монда гына! Бар әйберләрен салдымы икән? — дип ул, житез хәрәкәтләр белән йөреп, алар алдына аны китереп тә куйды. Шунда гына башы эшләп өлгерде. — Карагыз әле, нишлим соң әле мин? Сез бит яшь кешеләр түгел, ишек төбендә торасыз! Узыгыз әле, менә монда, түргә, утырыгыз, урыннар житәрлек! — дип, бүлмәгә чакыра башлады.

— Ярар, бераз хәл алыйк та, вокзалга төшик без, улым... Бүген китәсебез дә бар...

Газизчик аларны Кәримә яшәгән бүлмәгә кертеп утыртты, өстендәге кәчтүмен салды, муенындагы галстугын чишеп ташлап, кухня ягына ашыкты.

— Хәзер чәй куям!

Ул әллә сөенә, әллә көенә иде, белмәссең. Хәер, яраткан кешеңнең якыннарын күрсәң дә үзе белән очрашкан кебек буласың шул!

Монда һава тыныч һәм Кәримәнең рухы да бардыр сыман тоела. Ана кеше әкренләп үз хәленә кайткандай булды.

— Сәгать ничә әле, атасы? — диде.

Гарифулла абый коридор ягындагы ишеккә каршы диварда эленеп торган сәгатькә урыныннан кузгалмыйча гына үрелеп карап алды.

— Дүртенчегә китеп бара.

— Сонга калмыйк поездга. Билет аласыбыз да бар!

— Хәзер китәрбез, анасы!

Шул вакытта ишектән шаулап Хәнифә Галиевна килеп керде.

— Газизчик, син нәрсә эшлисең? Туйга барасың бар бит! Нишләп өстәл әзерләп йөрисең? Анда министр үзе буласы, сөйкемле кызы Эльзасы белән! Сиңа дип, махсус атап чакыралар бит, юләр баш! Ике-өч елда завод директоры ясыйм кияүне, безгә Газиз бик төс инде, мин аны яхшы беләм дип әйтә икән! Ә син монда өстәл ясап маташасың! Шәриф машинага утырган. Министрның үзен йортта, бик беләсең килсә! Синең туганың булуын белеп эшкә алган ул аны. Кара жимешләре бетеп китте. Базарга чаптырдылар. Менә сине алырга дип кенә кердем. Белдем мин аны, качып ятасыңны! Киен, тизрәк бул! — дия-дия, кубарыла ук башлады.

Аның бу сүзләрен ишеткән ата белән ана, бер-берсенә тотынышып, коридорга килеп чыктылар. Аларны күреп алган Хәнифә Галиевна аһ итте, шунда ук тавышы үзгәрде дә:

— Абау, кунаклар бар икән! — диде. — Кәримәне эзләп килдегезме?Минем улым да, отпускалар ала-ала, бер ай эзләде аны!

— Без таптык инде! — диде шунда ата кеше, рәнжегән тавыш белән.

Бусы ук көтелмәгән сүз иде. Йорт эчендә шомлы тынлык урнашты. Кухня ягыннан Газизчик нәрсәнедер идәнгә төшереп ватты. Әмма ул балкып йөгереп чыкты да:

— Ул кайда? Кайдан таптыгыз? — дип сорый башлады.

Гарифулла абыйның аңсызлыгын, хатынының күңеле тулып, елап жибәрүен күреп, егет кабат аптырап калды. Авыр, хәтта котчыккысыз вакыйга булганлыгын Хәнифә Галиевна да төшенеп өлгерде.

Гарифулла абый, иелеп, бер кулына Кәримәнең чемоданын, икенчесенә үзенен һәм хатынының сумкасын алып, чыгарга атлады. Әмма хәлсезлеге сизелде. Ул бирешмәскә итте. Хатыны, аның бер кулын бушатырга үрелеп, сумкаларына тотынды. Ире кирәкми дигән ишарә ясады.

— Туктагыз әле, туктагыз! — дип, Газизчик шунда ук үз бүлмәсенә ашкынып кереп китте һәм аннан калын гына дәфтәр күтәреп килеп тә чыкты. — Бу — Кәримәнеке икән! Анда барысы да язылган бугай? Сабираны кияүгә озаткан көндә, әйберләрен жыештырганда табылды. Укырга өлгермәдем. Аннары, рөхсәтсез ярамас, дидем. Андагы шигырьләргә генә күз салдым. Аларын укырга ярыйдыр, дидем. Шигырьләр бит алар укыр өчен языла. Ачуланмагыз инде! Монысына кадәр тагын бер дәфтәре булган. Анысын тапмадык. Бусының башына «Икенче тупланма» дип язып куелган. Тулы да түгел. Кайбер битләре күпләп-күпләп ертылып алынган. Әйттем бугай инде: беренчесен таба алмадык. Бусын сезгә кайтарып бирәм! — диде, күп сөйләде, ашыкты, тагын даниләрдер әйтергә теләде.

Гарифулла абый мона әллә ни исе китмәгәндәй итте. Әмма хатыны тәмам куанды, дәфтәрне алып, күкрәгенә кысты. Рәхмәтен әйтте.

Шунда Гарифулласы да, чемодан һәм сумкаларны кулыннан төшереп:

— Гафу итә күрегез без исәрләрне, — дип, кесәсеннән акча чыгарды, — без күпме тиеш әле? Алыгыз! — диярәк, аларга сузды.

— Сез нәрсә? — диде шунда тагын да Газизчик. — Сез нәрсә? Кәримәнен безгә тиеше юк, фатирда торган өчен дә ул айныкын-айга алдан бирep бара иде, шулай бит, әнием? — диде. Әмма аның Кәримә хакында бәйнә-бәйнә сөйләтәсе килә икәнлеге дә сизелә иде.

Гадәтенчә Хәнифә Галиевна акчага таба үрелә башлады, аннары, улының сүзләреннән соң оялыпмы, әллә ике бичарадан күнеле чирканыпмы:

— Юк-юк, сез нәрсә, бер генә дә бирәсегез калмады! Кәримә ул яктан бик тәртипле кыз иде, — дигән булды.

Ата кеше акчаларын кесәсенә кире тыкты, чемодан һәм сумкаларын кабат

алып, зур рәхмәтен әйтеп, ишектән чыкты, баскычтан хатыны белән сак атлап төшеп китте. Ярым ябылырга да өлгермәгән ишек артында Хәнифә Галиевна улын ашыктыра башлады:

— Әйдә, так галстугыңны! Ки кәчтүменне! Туйга министрның машинасы көтә. Әнә, урамда гына тора! — дип каты-каты әйтте.

Казан эчендә тормыш кайнавы дәвам итә иде.

Урамга чыккач, ата кеше арбалы бер атлыны туктатты. Дилбегәләр егет кеше кулында иде. Ул, арбасыннан җинел генә сикереп төшеп, Гарифулла абыйның кулындагы чемоданын арбага күтәрешеп куярга булышты. Хатынының аяклары буталыбрак торуын күргәч, аңа да ярдәм итте. Аннары атын ашыктырыбрак, Париж Коммунасы урамы буйлап алып китте дә Наримановка борылды. Моннан вокзалга якынрак сыман иде.

Анда кадәр тыныч төштеләр. Егет кеше игелекле булып чыкты, Гарифулла абыйга тагын чемоданын күтәрешеп, вокзал эченә кертергә булышты, хатынын буш эскәмиягә китертеп утыртышты. Ул гына да түгел, кассалар янына йөгереп барып, билет хакында белешеп килде.

— Минем монда апам эшли! Алтынчы кассага барырсыз. Бөгелмәгә кадәр ике билет дигән идегез бит. Табып бирергә, булышырга вәгъдә итте. Онытмагыз, исеме — Әминә, без — Кәримнән, диярсез! Онытмагыз! Табып бирер! Вәгъдә итте!.. Ярый, мин ашыгам! — дип китеп тә барды.

— Тукта әле, энем, акча бирергә онытканмын! — дип, артыннан Гарифулла абый чыгып та караган иде, егеттән җилләр искән. Казан каласының игелекле кешеләр белән дә тулы икәнлеген ул әлегә сизенмичәрәк калды.

Бераздан кассага барып, Әминәне сорады, Кәрим дигән исемне ялгышлык белән Кәримә диде, әмма моны да төшенмәде. Кыз аңа ике билет әзерләп куйган икән, акчасын тиешле кадәр генә алып, калганын кире кайтарып бирде. Моны да Гарифулла абый шулай тиеш буларак аңлады.

Вакытлары бераз бар икән әле, анысы. Буфеттан, икешәр-өчәр рәт барып, стакан белән чәй алып эчтеләр. Бусы яхшы булды. Тәннәренә хәл кереп китте. Кәримә хәсрәте дә артка чигенеп торды. Дәртләнеп китеп, Гарифулла абый киоскка барды, бәлки укылып кайтылыр дигән уйда берничә төрле татар газеталарын да сатып алды. Авыллары Ләшәүгә әле болар кайчан килеп җитә? Гарифулла, алардан укып, барысын да алдан белешеп өлгерер!

Шунда поездга утырту башлануы хакында хәбәр бирделәр. Инде хатыны да хәлләнгән иде. Сумкаларны кулына ул алды. Гарифулла абый чемодан белән мәш килде.

Вагонга бик вакытлы барып утырдылар. Алар янына Буа хатыннары тулырга өлгерде. Кайсылары югарыгы урыннарга ук менеп кунакладылар. Һаваның бөркүлеге аларга итәк күтәреп җилләнергә дә комачауламады. Ярый әле, кузгалып китүләренә, вагон эчендә һава йөри башлады.

Казан буйлап шактый озак чыктылар. Аннары поезд тизлекне арттыра барды. Хатынына кысталуын әйтеп, Гарифулла абый кирәкле бүлмәне эзләп китте. Аңа кеше, укытучы буларак, сала хатыннары белән аралашып торуны сөймәгәндәй тотты үзен. Бу вакытта аның да күңеленнән хәсрәте китеп торган, Кәримәсе уеннан чыккан, поездда өйгә кайтып бару шатлыгы гына иде, югыйсә.

Менә ул газеталарның берсен алды, аны, укыр алдыннан, әүвәле карап чыгасы итте. Анда Сабира Хаирова дигән шагыйрәнең күп итеп бастырылган шигырьләрен күрде. Сурәтенә карап, бу кыз матур икән дип уйлады һәм укый башлады. Шунда Кәримәсе кабат исенә төште һәм аңа аһ итеп сикереп торды да идәнгә һушсыз егылды. Аңа карап барган бер бала чәрелдәп кычкырып җибәрде. Халык җыелуына сәерсенеп, ирә Гарифулла абый да йөгереп килде. Вагон вожатыен дәштеләр. Ул, ашыгып, нашатырь алып килеп иснәтте. Аңа кеше аңына кайтты.

Бу егылу вакыйгасы анын белән гомерендә беренче тапкыр булды. Әмма соңгысы түгел иде. Моңа кадәр андый хәлгә очрамаган ире хәйранлыкта калды. Хатынын кочагына алып утырды. Шунда ана:

— Ирем, укы әле шуларны! Нәкъ Кәримәбез шигырьләре сыман! — диде.

Ата кеше дә укыды. Йөрәген салкынлыкта тотты. Сурәттәге Сабира Хаированың кем икәнлеген таныды, әмма:

— Юк! Аныкылар кебек түгелләр! — диде.

Әмма ул алдый иде. Ана бит әле хатынын исән-имин алып кайтып җиткерәсе дә бар!

Бу — Кәриманең җеназасы көне генә түгел, бәлки бөек шагыйрә булырга дөньяга туган Кәримә Дулатованың үлгән, анын урынын шигырьдән ерак шагыйрә Сабира Хаирова алган көн дә иде.

## ЭПИЛОГ

1990 нчы елның июнь ахырына кадәр миңа Тимер-бетон конструкцияләр заводында гади эшче булып эшләргә туры килде. Ул вакытта, югыйсә, яшь галим, фәннәр кандидаты идем. Заводтан тыш, калган бөтен вакытым Яшьләр торак комплексын төзүдә, Казан шәһәренең яңа-яңа йортларын салуда үтә торды. Төзүче һөнәре минем кулларым өчен һич тә яналык түгел иде. Барлык тырышлыгым — гаиләмне фатирлы итү теләгеп тормышка ашыру мөмкинлегеннән файдаланып калырга омтылышка бәйле булды.

Ахырдан фәнни эшемә әйләнеп кайттым. Мин төзелешкә киткәндә кып-кызыл хәлендә калган дөнья хәзер сары-яшел-ак төсләргә кереп беткән иде. Гүяки яна бер илгә килеп эләктем, бер кыйтгадан чыгып китеп, төрле утларга, вәхшият белән мәдәният арасында үсеш кичергән илләргә тукталып-тукталып, олы бәлаләр аша уза-уза, бөтенләй башка материкка барып чыкканмындыр кебек иде.

Язмыш мине үзенең куәтле җилләренең иркендә ул елларда менә шулай айкалдырып-чайкалдырып йөртте. Фатир дигәнем дә алай ук җиңел генә, тиз генә булмады...

Фән, мәдәният, әдәбият, сәнгать кебек өлкәләр тәрәккыятнең бинасын хасил итсәләр дә, тормыш-яшәеш барыбер дә икътисади нигезгә корыла, анысы. Яңа төзелеп килгән җәмгыятьтә дә, искесендәге кебек үк, тәрәккыять файдасы алга чыгарылмады. Хәер, тормыш-яшәешнең нигезләре дә тиздән кабат умырылып-ватылып ташланды.

Ул елны көз көннәре мине үземнең туган якларыма — Әлмәт-Сарман төбәгенә, гыйльми-гамәли командировкага җибәрделәр. Эшем авылдан-авылга, каладан-калага йөреп, татарның борынгы китапларын барлап, өйрәнеп чыгудан гыйбарәт иде. Аягымда күн итек, өстемдә поход киеме, аркамда биштәр булды. Әүвәле көннәр кояшлы торды, аннары яңгырга китте, суытты, изаландырды. Күп юлларны үтәргә, гыйбрәтле язмышлар белән очрашырга, бала чагымда дөнья чигендәдер кебек тоелган караңгы, мескен, фәкыйрь авылларга да, заманаы артта калдырып, үзләре алга ашкынучы салаларга һәм шәһәрләргә дә барып чыгарга туры килде. Бөгелмә якларын да күп таптадым. Юлым унды, кызыклы, мәдәни, фәнебез өчен аерым әһәмияткә ия кулъязмалар да табылды. Сөенечтән күңелем, өметләрем дә акланып, тынычланып өлгерде.

Әлмәт шәһәренә бәйле бер адрес биргән иделәр. Әүвәле аны, кирәкми дип уйлап, инде ахырда, ярар, миннән калмасын диярәк, бернинди кызыксынусыз гына, шунын буенча барып, хәлләрен белешеп чыгарга кирәктер, дидем. Була бит андый чаклар да: күңелем бик тә тыныч көн иде бу!

Барысы да уңышлы гына иде. Юлда машинасы да җиңел генә утыртып

алып китте, адреста язылган йорты, фатиры да һичбер кыенлыксыз, жайлы гына табылды. Өйләрендә кешесе дә бар иде.

Үземнен кем, кайдан, нинди эшләр белән йөрүемне гадәттәгечә аңлатып бирдем. Таныштык. Түргә үтүемне сорадылар. Өстәл артына утырдым. Заллары иркен һәм затлы җиһазлы иде. Мине каршы алган ханым өстәлнең икенче ягына утырды. Бүлмәдә бераз ярым карангырак халәт иде. Өлкән яшьтәге, кап-кара бөдрә чәчле, яхшы йөн, бераз укалары да булган караңгы-көрән төстәге затлы күлмәктән иде ул. Бизәнгән, ясанган.

Барасы җирләре, ашыгасы урыннары юкмы икәнлеген сорадым. Әле берәр сәгать сөйләшеп утырырга мөмкин икән. Әмма шунысы аптыраштa калдырды, ханым, дөресрәге, әби кеше инде ул, мине күптәннән көтеп алганы сыманрак кабул итте. Иске китаплар, кульязмалар турында сорадым. Алар аңарда юк икәннәр. Әйе, күренеп тора шул, бу апа бер дә яулыклы, абыстай булып йөрүче татар әбиләренә охшамаган.

Ул минем алдыма калын гына бер дәфтәр, папкалар белән хатлар-язмалар китереп куйды. Ачтым. Карыйм. Кемнеңдер көндәлеге иде бугай, шигырьләре дә күп икән дип уйлыйм. Укыйм. Бераз таныш та кебекләр. Әмма шунда ул ханым:

— Мин боларны сезгә бирә алмыйм, изге истәлекләрдән алар! — диде дә, күзләреннән яшьләрен сыгып кына елап алды. Аннары гафу үтенде.
— Йа Ходаем, әллә ничек булды әле бу! — диде.

Кешеләрне сабыр гына тыңлап утыра торган гадәтем бала чагымнан бар иде. Хәзер ул сабырлык, романнар укудагы кебек хикмәтле бер халәт сыман тойгылар уятып, күңелемне рәхәтлеккә чумдыра торганга ук әверелде.

Мин бу ханымнан, моннан егерме ел элек инде, шушы әсәрем сөйләп чыккан вакыйгаларны, ягъни бүгенге көнемнән илле еллар элгәре булып узган тарихларны ишеттем. Бик тәэсирләнгән идем. Каләмем бу кадәр сагышларны үзенең күзеннән тамызып язып та житкерә һәм бетерә алмады. Хәзер дә осталыгым хилафлырак булды, ахрысы, гафу итәрсез!

Чыгып киткәнемдә мин ул апаның йөзенә кабат бактым. Кара чәч дигәннәрем — калын итеп буялган иде, йөзендәге җыерчыкларының күплеген һәм тирәнлеген һичбер төрле кершән каплап, яшереп бетерә алмаган.

Анда, Казанда, Арча кыры зиратында, түбәнге якта, мәгърур тирәк төбендә «Шагыйрә Дулатова Кәримә» дигән язулы таш куелган кабер әле дә бардыр дигән уй күңелгә керде. Ел саен, өстен тутырып, сары-ак-зәңгәр умырзаялар чәчәк ата икән анда дип күзаллап куйгалау да гадәтемә әверелеп алды.

Әлмәткә ничә барылды, әмма ул ханым белән кабат очрашып, алар хакында сөйләшергә туры килмәде. Дәфтәре дә, папкалар да үзендә калды. Ә күз алдымда шул көннән башлап мондый сурәт сакланды да сакланды: зират, биек, күккә ашкан тирәк, хуш исле умырзаялар һәм... Менә алар, чәчәк тажлары коелалар, кабер өсте яшелләнә, анда башка чәчәкләр шытып чыга... Өздереп-өздереп сайраган сандугачлы май ае иртәсе...

Казанда, вакытым табылуга, шунда барырга, үзем күреп, мәсьәләне ачыкларга иттем. Эзләдем. Андый каберне тапмадым. Кызганыч. Вакыйгада катнашкан шәхесләр дә исән түгелләр иде инде, берничәсеннән кала. Хәер, аларын ук барлап, ерак тарихларны кузгатып, борчып йөрисем килмәде.

Менә шул!

*2009 – 2010.*



Фәрит
Габдерәхим

# ҮЗЕМ ӨЧЕН БЕР ХАКЫЙКАТЬ АЧТЫМ

## Милләт хәтере

**Дәверләрне имин кичсеннәр дип,
Бөек сүзләр ташка уелган.
Аямаган вакыт — гали сүзләр
Бер дә булмагандай җуелган.**

**Гарасатлар...
Әманәтләр кайда?
Табалмассың хәтта эзләрен.
Җуелмыйдыр милләт хәтеренә
Уелганы гына сүзләрнең.**

## Иблис ялчысы

**Учак яна. Иблис яккан учак.
Сүзем бүген шуның хакында.
Татарымның киләчәге яна,
Шул учакта яна ялкынлап.**

**Күрмисеңме?! Якында ул — түгел
Әллә кая эзләп барасы.
Карама син маңгай күзең белән,
Күңел күзең белән кара син.**

**Матур сүзләр сөйли «бөек» Иблис,
Кулында юк никтер камчысы.
Камчысыз да, әнә, өтәләнә
Кавемдәшем — Иблис ялчысы.**

**Һай, сәләтле ялчы! Күрмәп алып
Бинийһая олы кочакка,
Милли ядкярләрне, телебезне —
Киләчәкне сала учакка.**

---

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) – *Башкортстанда (Уфа) яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә чыккан дистәдән артык китап авторы.*

Үзем өчен бер хакыйкать ачтым,
Ул хакыйкать чыкмас һич истән:
Әгәр ялчы бик сәләтле булса,
Хәтәррәк икән Иблистән.

Иблис куя ялчы кавемдәшне
Башлык итеп үзе юк чакта.
Нишләргә соң?! Гөнаһ булмас, шаять,
Шул ялчыны салсак учакка.
Бәлки, янар?!

## Тукай шәкерте

Алда — портретың.
Мин бит, Тукай,
Шәкертең күк тоям үземне.
Шигырь сырлаганда сизеп торам:
Син укыйсың һәрбер сүземне.

Карашларың кайчак серле була,
Һәм үз итеп кайчак карыйсың.
Юанамын: «Язган сүзләремне
Тукай кабул итте, ахрысы».

Ләкин кайчак шелтәлисең сыман:
«Шигыреңдә минем Ишмиләр...»
Нишләргә соң?!
Синең чордан күчкән
Шул Ишмиләр бигрәк ишлеләр,
Синекеннән ныграк тешлиләр...

## Ишәйткәннән соң

*(Башкортстанда җанисәпкә бәйле хәлләр)*

Күз дә йоммый: «Һед — башкорттар!» — диләр
Халык санын алган чакларда.
Кардәш милләтне ишәйткәннән соң
Күчерәләр кабат татарга.
Әйләнәбез янә батракларга —
Йөк ташучы чыдам атларга.

## Уйдырма–ялганнарым

Чын–дөресен язып, бик еш
Булды шелтә алганым.
Ә бу юлы языйм әле
Шау уйдырма–ялганны.

Бу ил иртән баш төзәтә,
Кичен — кабат исерек.
Канны эчкән Сәмруг кошны
Гафу иттек — кичердек.

Мәхкәмәче зерә оста:
Ак дип раслый караны.
Урлашалар — каракларга
Хәләл ни дә харәм ни.

**Менә тагын чеп–чи ялган:**
**Ана сата баласын.**
**Авыл бетә — татар бетә,**
**Бетми кая барасың...**

**Ялганнарга ышанмаган**
**Берәр кеше бардырмы.**
**Әгәр була калса, үзен**
**Кочаклап ук алырмын.**

## Иске зиратта

**Иске зират. Бакый уйга талган**
**Мәрхүмнәрнең соңгы аймагы.**
**Таныш түгел кабер. Ташы ауган.**
**Әрем баскан. Шайтан таягы...**

**Сүзләр җуелганнар. Кем кабере?**
**Исеме дә юк бит, ичмасам.**
**Бик тырыша торгач укый алдым:**
**«... онытмабыз сине һичкайчан.**

## Гомер чиге

**Спортчы булып, ахрысы,**
**Туа адәм баласы.**
**Килә беренче буласы,**
**Килми артта каласы.**

**Килә иде үземнең дә**
**Барсын узып китәсе.**
**Максатларга көндәшләрдән**
**Алда барып җитәсе.**

**Гарьләндерә җир сөргәндә**
**Буразнаң булса кыек.**
**«Җебегән!» дип көләчәкләр,**
**Буының булса сыек.**

**Бәла килсә берәрсенә, —**
**Танышмы ул, түгелме, —**
**Бәлки, ярдәм итеп булыр:**
**Барып җитәм йөгереп.**

**Алда финиш — гомер чиге,**
**Сугачак соңгы сәгать.**
**Бик озак килә барасы,**
**Табып мең төрле сәбәп.**

## Имеш, охшаган...

**Әйтә иде өлкән яшьтәгеләр:**
**— Бабасына суеп каплаган!**
**— Төп нигездә яши: бабасының**
**Олуг өметләрен аклаган.**

**Бабасыдай киң күкрәкле, чая,**
**Бабасыдай балта остасы.**
**Нидер кора, нидер сүтеп ташлый,**
**Тач бабасы инде, кыскасы.**

**Шул бабасы мәчет манарасын**
**Заманында кисеп төшергән.**
**Ә оныгы, әнә, мәчет сала,**
**Көч бир, Ходай, изге эшендә!**

**Бабасына, имеш, охшаган...**

## Ахириләр гәпләшә

Ике ахири гәпләшә,
Берсе зарлана бигрәк:
— Атлаган саен кемгәдер
Акча төртергә кирәк.

Рәтсез килеш булмый ачып
Институт ишеген.
Майлап тормасаң түрәне,
Көе булмас эшеңнең.

Чирләп китсәң, бара күрмә
Буш кул белән врачка.
Ясактан башка берни дә
Кирәкми бу влачка.

Икенчесе ахиринең
Әйтте:
— Чәпчемә, дускай!
Газлы булса да, һаваны
Сулыйбыз әле бушлай.

Түләмичә бер тиен дә
(Шуңа рәхмәт укырлык!),
Кояш тирәли очабыз,
Җир шарына утырып.

Бертуктаусыз зарланасың:
«Түләргә дә түләргә!»
Шөкер итик: әлегә бит
Бушлай мөмкин үләргә.

## Шигъри сүзләр

Ә нигә соң,
Ә кайчан соң
Шигъри сүзләр ярала?

Тугры дустың бердәнбер көн
Тоз сипкәндә ярага;
Баласын җуйган кыр казы
Кычкырганда илереп;
Мәхәббәт өчпочмагында
Торып калсаң җиңелеп;
Җир өстендәге тәмугтан
Исән чыга алалсаң;
Илеңнән колак каккач та
Татар булып калалсаң;
Исемеңне түбән җаннар
Манчыганда карага
Кала алсаң ак-пакь килеш,
Шигъри сүзләр ярала.

Яраламы шигъри сүзләр
Әҗәл килгән чагында?
Анысын әйтермен,
Әҗәл
Килеп баскач алдыма.



Рәдиф Сәгъди

# ГАЛИҖӘНАП ГАТАУЛЛА ХӘЗРӘТ

МЕЛОДРАМА-ЛЕГЕНДА

**Катнашалар:**

Гатаулла — Уфа, Пермь, Барда төбәкләрендә мәктәп-мәдрәсәләр ачып, шәкертләр укыткан, шәхесләр тәрбияләгән, ятим балаларга хәтле ярдәм кулы сузган легендар шәхес, 35 яшьләрдә.

Андрей — Әнвәр — ятим калган урыс баласы, Гатаулла мөгаллимнең хөрмәт иткән шәкертләреннән берсе.

Коля – Камил — ятим, Андрейның җан дусты, соңыннан ак армиядә офицер.

Зөбәрҗәт — махсус музыка белеме булган чибәр туташ, 20 яшьләрдә.

Галимулла — Гатаулланың хезмәттәше, ярдәмчесе, 50 яшьләрдә.

Иван атакай — Федоровка селосының побы; нәсел чыгышы Тутай морзалардан, 45 яшьләрдә.

Фәттах — консерватив карашлы дин әһеле, 35-40 яшьләрдә.

Гриша — урыс малае, соңыннан кызыл армия солдаты.

Полицейский.

Канбаев — кызыл комиссар, 28 яшьләрдә.

Заһидә — Зөбәрҗәтнен сенлесе, 17-18 яшьләрдә.

Луиза — Солтанай мәктәбе директоры.

Рәшит Ягъфәр — язучы.

Ләбиб Лерон — язучы.

Фәнзаман Әтнинский — артист.

1 нче француз — мөгаллим.

2 нче француз — мөгаллим.

Мәктәп балалары, халык, хәрбиләр һ.б.

---

Рәдиф СӘГЪДИ (1957) – *язучы, драматург; «Сынган беләзек», «Яз галәмәте», «Финляндиядә рәхәт ди» кебек драма әсәрләре, берничә китап авторы. Казанда яши.*

# I ПӘРДӘ

## I күренеш

*Пермь өлкәсенең Барда районы. Солтанай урта мәктәбе. Музыка яңгырый. Казаннан кунакка килгән язучыларны каршы алу мизгелләре. Авыл өйләре күренә. Мәктәпкә үк терәлеп зират тора.*

Л у и з а. Исәнмесез-саумысез, кадерле Казан кунаклары! *(Бер ир кеше фотога төшереп йөри).* Без сезнең белән очрашуга бик шат, рәхим итегез Солтанай мәктәбенә! Кызлар, яле үзебезнең кырларыбызда үскән икмәктән пешерелгән чәкчәктән абыйларыгызны авыз иттерегез!

I к ы з. Рәхим итегез, Рәшит абый!

II к ы з. Рәхим итегез, Ләбиб абый!

Р ә ш и т. Бик зур рәхмәт, сеңлем!

Л ә б и б. Рәхмәт, матурым. Бигрәк нәфис чакка туры килдек. Яз көне ап-ак чәчәктә икән сездә тирәяк.

Л у и з а. Урман тулы шомырт, миләш бездә. Әллә сезнең Барда якларына беренче генә килүегезме?

Л ә б и б. Әйе. Тик беренче килүемдә үк ак чәчәкләр иленә гашыйк та булдым инде!

Р ә ш и т. Бездә кызлар да бик чибәр, алып калмасыннар тагын үзеңне.

Л у и з а. Шулай-шулай, Рәшит абый. Уйлап та тормыйбыз, мондый пәһлевандай егетне алып та калырбыз! Ике кызын гына ятим итәсебез килми.

Л ә б и б. Менә сиңа! Егет булып кына йөрмәкче идем, ике кызым барлыгын белгәннәр.

Л у и з а. Әле улыгыз барлыгын да ачыкладык.

Л ә б и б. Әстәгъфирулла! Бетте минем егет булып йөргән чаклар!

Р ә ш и т. Борчылма, Ләбиб энекәш, ир кеше алтмышта да егет ул. Әйтик, менә мин!

Л ә б и б. Алайса, мин үсмер генә икән әле! *(Көлешәләр).*

Л у и з а. Хәзер, хөрмәтле кунаклар, сезнең хөрмәткә кызларыбыз башкаруында «Яшьлегем тугае» дигән җыр яңгырый. Әйдәгез әле, балалар! *(Фотограф баянда уйный).*

*Җыр.*

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.
Күзләрең сагышлы,
Дип әйтте бер тургай,
Нишлим соң, тургаем, сагындым.

*Музыка әкренәя бара.*

Л у и з а. Хәзер, ерактан килгән кадерле кунакларыбызны мәктәбебез белән таныштырыйк! Бүгенге көндә уку йортында 121 бала белем ала. Кызганыч ки, ул сан елдан-ел кими. Тик без төшенкелеккә бирелмибез. Кичләрен төрле түгәрәкләр эшли. Җыр-бию, театр сәнгатен бик яратабыз. Китапханәбез, Аллага шөкер, бик бай. Җыйнак кына музеебыз да бар. Гади генә күргәзмә түгел ул, легендар шәхесебез Гатаулла хәзрәткә багышланган музей!

Л ә б и б. Рәшит абый килгәндә сөйләгән иде.

Л у и з а. Рәшит абый, үзебезнең якныкы булгач, бик еш кайта. Сөйләү бер әйбер, үз күзләрең белән күрү бөтенләй башка ул!

Р ә ш и т. Кайткан саен сагынып кайтам бит мин сезне!

Л у и з а. Сагынмыйча соң, мондый гүзәл яклар тагын кайда бар?!

Л ә б и б. Мөслимдә!

Л у и з а. Мөслимдә?

Р ә ш и т. Туган ягы ул аның!

Л у и з а. Шулаймыни!

Рәшит. Искитмәле җирләр! Ләбиб анда тумаса да, үскән төбәге. Шулай бит, ник дәшмисең?

Л ә б и б. Аны сөйләргә түгел, үз күзләрең белән күрергә кирәк!

Л у и з а. Шулай-шулай, Ләбиб

дустым! Әйдәгез, безнең музеебызны да кереп күрик әле! Рәхим итегез! *(Мәктәпнен икенче катына күтәреләләр. Музей бүлмәсе).* Менә безнең экспонатлар. Гатаулла мулланың эш бүлмәсендә торган диваны, кәнәфие, китап шкафы, чәй сервизы. Менә стена сәгате.

Ләбиб. Бу китаплар да шул чорныкымы?

Луиза. Әйе, шәхсән үзенеке! Аның бар мөлкәтен 1918 елда конфисковать иткәннәр. Бик күбесе юкка чыккан, урланган. Без эзләп тапкан хәтлесе генә бирелә. Менә Тукай, Дәрдемәнд, Гомәр Хәйям, Пушкин, Лермонтов, Толстой Коръәне! Французларның тел белеме...

Ләбиб. Әллә французча да өйрәнгәнме?

Луиза. Өйрәнгән генә түгел, чиста белгән. Шәкертләренә дә өйрәткән.

Ләбиб. Ничек алай?!

Луиза. Шулай. Ул Сорбоннада фәлсәфә бүлегендә укып, алтын медальгә тәмамлаган.

Рәшит. Луиза Солтановна, сәгате турында да сөйләгез әле!

Луиза. Белмим инде, гөнаһысы булмас микән?!

Рәшит. Нишләп гөнаһысы булсын ди! Үзебезнең легендар шәхесебезне сагынып искә алу гына бит!

Луиза. Аллага тапшырдык алайса. Бисмиллахир-рахман-иррахим! Бабабыз гына рәнҗемәсен.

Ләбиб. Вафат булган кеше ничек рәнҗи алсын, ди!

Луиза. Зинһар, андый сүзләр сөйләмәгез!

Рәшит. Луиза ханым дөрес әйтә, монда шаярыр урын түгел.

Ләбиб. Гафу итегез!

Луиза. Менә үзегез күрәсез, эчен дә ачып күрсәтәм. Эчке детальләре сүтеп алынган, тулысынча ватык сәгать ул! Ләкин, йә Ходаем, үзен кичерә күр! Вакыт-вакыт бөтен мәктәпне яңгыратып суга ул!

Ләбиб. Шушы сәгать сугамы?!

Луиза. Үткән елны кабинетымда вак-төяк эшләремне караштырып утыра идем, бала-чага шаярта микән әллә диеп, коридорга чыксам, идән юучы Маһинур апа, чүпрәген күкрәгенә кысып, коты очып басып тора. Нәрсә булды, дим. Ул музей ишегенә төртеп күрсәтә. Якынрак килеп тыңласак, музей эчендә суга бит ватык сәгатебез! Ачып керсәк, бүлмәдә беркем дә юк!

Ләбиб. Булмас ла!

Луиза. Ант менә! Миңа ышанмасагыз, Маһинур апаның үзеннән сорарга була. Ул шул сәер хәлләрдән соң эшен ташлады. Чиратлашып, мәктәп эчен хәзер укучылар үзләре юа!

Ләбиб. Чынлап сөйлисезме соң сез, Луиза Солтановна?

Луиза. Әле ул гына да түгел! Кич белән идән юган балалар Гатаулла хәзрәтнең өрәген дә күргәннәр. Хәерлегә генә була күрсен инде!

Ләбиб. Бәрәкалла, әкият бит бу!

Рәшит. Син тыңлап бетер, тыңлап!

Луиза. Юк, бүтән берни дә сөйләмим, болай да сулышым кысыла башлады. *(Кыз-кыркын тавышы ишетелә).*

Рәшит. Әллә берәр хәл булган инде. Чәрелдәшәләр.

Луиза. Әйтеп торам бит, яхшыга түгел бу! Әйдәгез, ни булган икән. *(Музей бүлмәсеннән чыгалар. Коридор буйлап ике кыз чабып килә).*

I кыз. Анда, Луиза Солтановна, анда Гатаулла бабай өрәге!

Луиза. Кайда?

II кыз. Коридор буйлап, зират ягына таба китте.

Луиза. Менә сез ышанмаган идегез!

Ләбиб. Әйдә, барып карыйк әле!

Луиза. Куркам мин!

Ләбиб. Сәер хәл!

Луиза. Бик сәер шул! Шом бар безнең мәктәптә!

Рәшит. Әйдәгез әле, кызлар, күрсәтегез, кая китте ул? *(Коридор буйлап сак кына баралар).*

I кыз *(туктап кала. Шыпырт*

*кына).* Менә шушы як стенага кереп югалды.

Л ә б и б. Дөрес хәлме соң бу?

Л у и з а. Дөрес булмаган кая. Котым очып тора инде шушы мәктәпкә килергә!

Р ә ш и т. Үзе алай-болай зыян итмидер ич?

Л у и з а. Анысы, Аллага шөкер, зыянсыз!

Р ә ш и т. Мулла чакыртып укытып карамадыгызмы соң?

Л у и з а. Укытмаган кая, файдасы гына булмады!

Л ә б и б. Нишләп алай икән?!

Л у и з а. Мәктәп салганда... *(Шул чак сәгать суга башлый).* Юк, юк, сөйли алмыйм. Сулышым кысыла. Әнә ничек стена сәгате суга. Ул бит ватык, тик суга!

Р ә ш и т. Әйдәгез, чыннан да, урамга чыгыйк әле!

Л у и з а. Ашханәдә чәй эчеп алырбыз, халык белән очрашу вакыты да житеп килә! Әйдәгез! Уф!!!

Л ә б и б. Сез мина Гатаулла мулла турында, үтенеп сорыйм, сөйләгез әле, Луиза ханым!

Л у и з а. Гатаулла хәзрәт, үзебезнен авылныкы — Солтанайда туган. Йә Ходаем, шушы кадерле бабабызнын рухы бер тынычлык тапсын, урыны жәннәтнен түрендә булсын иде!

Л ә б и б. Нәшләп нәкъ менә мәктәптә йөри икән соң ул? Бәлкем, шушы диван-шкафларын юксынып киләдер.

Л у и з а. Юк, юк, анда гына түгел эш! Анын сәбәбе, мина калса, бөтенләй башкада. Әйдәгез, кайта-кайта урамда сөйләрмен!

*Музыка. Стена сәгате суга. Бераздан азан тавышы ишетелә. Вакыйга XX гасыр башына күчә.*

**II күренеш**

*Монсу гына көй агыла. Пермь өлкәсенен Барда бистәсе. Музейдагы кәнәфи-диван, китап шкафы, стена сәгате, урындыклар, зур өстәл, өстендә китаплар өеме.*

Г а т а *(нидер язып утыра. Сәгать суга).* Кичке намазга да вакыт житеп килә икән. *(Ишек шакыйлар).* Әйе, керегез!

Г а л и м у л л а. Гатаулла хәзрәт, анда Федоровка авылыннан Иван атакай килгән.

Г а т а. Иван атакай?!

Г а л и м у л л а. Әйе! Тиздән намаз вакыты житә диеп, әйтеп тә карадым. Бик нык тузына! Почему так та, почеме так, ди. Кяфер!

Г а т а. Нигә шулай усаллана икән соң ул?

Г а л и м у л л а. Шул балалар аркасында инде. Бәлкем мина?..

Г а т а. Бернинди бәлкемнәр дә кирәкми. Керсен әйдә!

Г а л и м у л л а. Анлашылды. Чәй дә кертергәме?

Г а т а. Әлбәттә, Галимулла туган. *(Галимулла китә. Хәзрәт тиз генә көзгегә күз салып ала, түбәтәен төзәткәли).*

Г а л и м у л л а *(керәләр).* Әйдәгез, әйдәгез, Иван атакай, рәхим итегез! Прошу!

П о п. Извините за грубость, конечно! Гата хазрат, что за безобразие? Узигизнын мадрасаларда безнен христиан балаларын да көчләп укытып ятасыз икән. Бу ике дин, ике халык арасына, татарлар әйтмешли, чөй кагу түгелме?

Г а т а. Исәнмесез, Иван атакай?

П о п. Прошу прощение, кызган баштан исәнләшергә дә онытып жибәргәнмен! Здравствуй, Гатаулла хазрат! *(Ике куллап күрешәләр).*

Г а т а. Рәхим итеп түрдән узыгыз, Иван Генадьевич! Утырыгыз!

П о п. Утырырсын монда, бөтен Федоровка колак итен чәйни. Нишләп урыс балалары окоянный татарларда белем ала, диләр.

Г а т а. Соравыгыз бик урынлы, Иван Генадьевич! Әйе, дөресен

әйтергә кирәк, безнең мәдрәсәләрдә биш урыс, сигез удмурт, тагын берничә мордва, мари малайлары да тәрбияләнә.

П о п. Во-во! Мин бит юкка гына килмәдем!

Г а т а. Шул балаларны чын күнелдән кайгыртып йөргәнегез өчен бик зур рәхмәт сезгә!

П о п. Кайгыртмассың бар. Син шуны безнең село халкына төшендереп кара! Губернаторга, патшага жалобу написать надо, диләр.

Г а т а. Сез үзегез, минем урында булсагыз, әйтик, урамда кеше талап, урлашып йөргән татар балаларына ярдәм кулы сузмас идегезме?

П о п. Хем! Айта алмыйм, Гатаулла хазрат! Минем бу турыда уйлап караганым булмады.

Г а т а. Хәзер күз алдына китерегез! Шул ятим балалар җинаять кылып, йә кеше үтереп төрмәгә элгәләр, ди. Зинданнан кем булып чыга инде алар? Бозылып кайтачаклар. Тагын җинаять кыла, йә үзен кыйнап үтерәләр.

П о п. Ну, конечно, куркыныч хәл бу! Это понятно!

Г а т а. Шулай булгач! Безне яраткан көч Аллаһы Тәгалә, сез Бог дисез, бер үк бөек иҗатчы инде, барыбызга да тигез карый.

П о п. Дурус, дурус, бик дурус айтасыз Гатаулла туган! Тик, понимаете, безнең село халкын икенче айбер борчый. Ул балалар үз ирекләре белән сезгә килделәрме икән?! Вот в чем вопрос?

Г а т а. Аны бик җиңел ачыклап була. Галимулла туган, Андрей белән Коляны чакыртып кертегез әле!

Г а л и м у л л а. Яхшы, Гатаулла хәзрәт! *(Өстәл әзерләп йөргән Галимулла чыгып китә).*

П о п. Без бит село белән шуннан шикләнәбез, бәлкем сез аларны насильственно мусульманлыкка кертеп ятасыздыр. Теге ничек әле, обрезание ясатасыздыр?!

Г а т а. Сөннәткә утырту үзләреннән тора. Ходай Тәгалә үзе шаһит... Без аларга белем генә бирәбез. Ислам фәне, исәп-хисап, астрономия, тарих кебек фәннәр белән бер рәттән француз телен дә өйрәнәләр.

П о п. Француз телен дә?!

Г а т а. Әйе, мөхтәрәм Иван атакай! Инде мөселманлыкка керү-кермәү, сөннәтле булу-булмау аларның шәхси эше. Без биредә шәхесләр әзерлибез!

П о п. Похвально, похвально, Гатаулла хазрат! Шулай да үзләрен күреп суйляшеп карыйк әле!

Г а т а. Әлбәттә! Хәзер килеп житәрләр. Сез, Иван Генадьевич, юл килгән кеше. Берәр чынаяк чәй комачау итмәс!

П о п. Рахмат.

Г а т а *(пыялаларга чәй сала, чәкчәкне кисә, бал савытын ача).* Әйдәгез, әйдә Иван туган, чәкчәкләп чәй эчик әле! Ул арада малайлар да килеп житәрләр.

П о п. Да, да, да! Бер күрәсе иде үзлярин.

Г а т а. Иван атакай, чәегез суына бит!

П о п. Юк, юк! Бик зур рахмат! Безнең урус халкы әйтмешли: «Чаен гына күргәнем бар». *(Авыр сулап куя).*

Г а т а. Бәлкем сезгә...

П о п *(канатланып китә).* Әлля бармы?

Г а т а. Сезнең хөрмәткә табарбыз как-нибудь. *(Көлә).*

П о п. Подожди-ка, подожди, дорогой! У вас же это «харам» считается.

Г а т а *(көлә).* Шулай Иван атакай! Әгәр дә мин хәмер эчсәм, нинди үрнәк булырмын икән? Чәй — кымыз!

П о п. Молодец, Гатаулла туган. *(Авыр сулап куя)* Уф!!! Ярыймы үзем белән алып килгәнен?

Г а т а. Тик хәлегезне анлап кына, Иван Генадьевич.

П о п *(коньяк чыгара).* Может со мной үзегез дә.

Г а т а. Мин бит беләсең ич инде, чыннан да эчмим, Иван Генадьевич.

П о п. Ну инде... Французлар килгәндә дә кулланмыйсызмы?!

Гата. Бары тик чәй, кофе, кымыз гына!

Поп. Молодец! Үзем дә күптән кулланган юк иде. Кичә боярин Митрофанны озаттык бит! Поминкасы бик нык булды!

Гата. Ишеттем, ишеттем. Бик таза кеше иде бит. Нидән?

Поп. Нидән булсын инде?! Рус чәённән. Бавыры таркалып, саргаеп үлде. Урыны җаннатта булгырый!

Гата. Әйбәт сәүдәгәр иде.

Поп. Әле ул миңа туган тиешле дә. Ярый, Митрофанның изге рухы өчен! *(Эчә).*

Гата. Менә пәрәмәчләреннән авыз итегез! Казылык та бар! Хотя сез рус халкы ат ите ашамыйсыз бугай!

Поп. Ничек ашамаган! Шап, затлы ризык!

Гата. Шулай, Иван атакай, сезнең әче су сәламәтлекне җимерә инде ул. Боярин Митрофан да бит, типсә тимер өзәрдәй ир иде. Аракыны җинә алмадымы?

Поп. Үзем дә бик яхшы аңлыйм. Ташлап булмый шул, туган! «Бог даст, не помрем еще» диярга гына кала инде.

Гата. Авыл халкы ни уйлар, сез бит дин әһеле, атакайлары?

Поп. Наоборот, Гатаулла! Эчмәсам, үз итми, санга сукмый, безне диячаклар. Син безнең халыкның психологиясен белеп бетермисен шул! Кеше туса да халык белән, кеше үлсә дә халык белән... бергә чумырабыз.

Гата. Аңладым. Тагын теләгегез бармы?

Поп. Тагын берне и все. Бог нам судья, Гатаулла туган! *(Эчә).* Сез Казан мадрасасен бетергән идегезме, или Уфанымы?

Гата. Оренбургта укыдым мин. Соңыннан Франциядә Сарбонна университетын тәмамладым.

Поп. Вот оно что! Вот как! Үзеңне күптән белә идем, дөнья күргән кеше икәнлегеңне, молодец Гатаулла.

Гата. Үзем белгән хәтлесен генә шәкертләргә дә өйрәтәм.

Поп. Бир әле бишне! Рахмат сый-хурматыңа, друг мой! Ну үзең дә бер Федоровкага әйләнеп чык әле! Мунча кереп бер рахатланып сөйләшеп утырырбыз. Мамык кебек йомшак себерке белән чабынырбыз. Кирәк дисәң, чәчбикәләрне дә табарбыз.

Гата. Рәхмәт, Иван дустым, килермен. Тик син әйткән тузган чәчләр генә кирәкмәс, яме.

Поп. Как скажешь, Гатаулла, так и будет. Шулай дөресрәк тә булыр. Минем үзенә генә ачасы килгән серем да бар.

Гата. Кемнен генә юк икән инде андый серләре?

Поп. Минекенә житә торган серляр түгел алар. Кайчагында шундый төшләр күрәм. Белсәң, исенакылың китярлек.

Гата. Сер булмаса, сөйләрсез.

Поп. Только между нами, Гата.

Гата. Әлбәттә!

Поп. Вот слушай. *(Шыпыртка куча).* Имеш, мин гаскәрем белән каядыр чабучы татар морзасы икән. Урман-сулар кичәбез. Тирә-юнь гел сазлык, баткаклык. Мине үзенә суыра икән. Карчыгым Варвара әйтә: «Эченә жениәр оялаган, саташып татарча кычкырасың», — ди.

Гата. Татарча! Ничек алай?

Поп. Вот в том то и дело! Хатын да нык аптыраган инде шуна. Минем бит әле татарчам да ипи белән коньяклык кына.

Гата. Кызык!

Поп. Мин белям аның сабябен, Гатаулла туган, белям!

Гата. Нидән шулай диеп уйлыйсыз?

Поп. Менә бая сина айта башлаган серем шул инде минем. Я только тебе доверяю, хазрат. Только тебе.

Гата. Ышанычыгызны акларьмын, Иван Генадьевич.

Поп. Белясезме, Гатаулла хазрат... Мин бит... *(Ишек шакыйлар).* Кемдер керә, соңыннан!

Гата. Хорошо. Әйе, керегез! *(Мәзингә ияреп, ике үсмер керә).*

Николай. Әссәламәгаләйкум!

Андрей. Әссәламәгаләйкум!

Гата. Вәгаләйкүмәссәлам! Бирегә узыгыз, балалар, утырыгыз!

Поп *(бик җентекләп карап чыга).* Йә, братцы, хәлләр ничек?

Андрей. Бик айбат. Укыталар, ашаталар.

Поп. Нигә селога кайтмыйсыз? Сез бит рус малайлары.

Николай. Безгә монда яхши.

Поп. Ничек инде алай, яхшы?! Сезне кучляп ислам диненә кертәлярмы? Говорите, не бойтесь! Иван атакаегыз сезне беркемнән дә рәнжеттермәячәк! Ник дәшмисез? Почему?

Николай. Сездән аракы исе килә. Минем әнием эчеп юлдан язды, әтием дунгыз урлап төрмәгә эләкте. Ике сенлем ач-ялангач.

Поп. Ике сенлең дә монастырьда!

Андрей. Эчкән кешеләрне мин дә ненавижу! Ненавижу!

Гата. Андрей, тынычлан, улым. Үзегез теләмәсәгез, сезне беркем дә көчләп алып китә алмый.

Коля. Мин беркая да бармыйм.

Андрей. Мин дә. Иван атакай, кайтып китегез!

Поп. Кара син бу шайтан малайларга. Бәлкем, сезне суннатка утырткannардыр?

Коля. Юк, утыртмадылар.

Поп. Не верю! Яле, брюки снимите!

Андрей. Не будем. Үзеннекен кара.

Гата. Коля, алай ямьсез сөйләшмә олы кеше белән.

Коля. Нәрсә соң ул безнең галәмәтләрне тикшерә!

Андрей. Олы кеше булгач, үзенекен карасын!

Гата. Барыбер итагатьле булырга кирәк. Иван атакай сезнең өчен борчылып йөри бит.

Поп. Мине үзебезнең селодан халык җибәрде. «Татарлар урус балаларын кучляп тоталар икән, бар, алып кайт», диеп юлладылар.

Андрей. Мин селога кайтмыйм. Укуны да мәдрәсәдә бетерәм. Соңыннан поеду в Казань, там закончу мадрасу имени Марджани. Бәлки әле Парижда да укырмын.

Поп. Синме Парижда?! Дай Бог!

Андрей. Татарча өйрәндем бит әле. Гарәпчә дә чамалыйм. Вот увидите, французча да беләчәкмен.

Коля. Мин дә!

Поп. Нарся диляр әле, булырга язсын!

Гата. Нигә исегез китә?! Егетләрдә тырышлык зур. Дөнья әдәбияты тарихы белән дә кызыксыналар.

Поп. Дай Бог!

Гата. Гаҗәпләнергә кирәкми, атакай. Андрей кайбер фәннәрне татар малайларыннан да яхшырак үзләштерә. Коляга килгәндә, ул исәп-хисап дәресләрен ярата. Вакыт җитәр, менә дигән сәүдәгәр килеп чыгар әле үзеннән. *(Каяндыр кычкырган тавыш ишетелә).*

Гриша тавышы. Помогите, помогите!

Поп. Туктагыз әле, тукта. Анда кемдер кычкыра. Помогите, ди.

Гриша *(атылып керә).* Где Иван атакай? Иван атакай, коткар мине, забери меня отсюда! Забери меня! *(Тезләнә).*

Поп. Говори, сынок, что случилось?

Гриша. Атакаем, алар мине кыйныйлар. Издеваться итәләр. Я домой в Федоровку хочу. Прошу вас, заберите меня.

Поп. Йә, что скажете, Гатаулла хазрат?

Гата. Үзем дә аптыраган әле.

Гриша. Если не заберете, сам убегу.

Поп. Сине кыйнап ислам диненә кертялярмы?

Гриша. Юк! Миңа иртә-кич тынычлык юк.

Гата. Гриша улым, кемнәр рәнжетте соң сине?

Гриша. Если скажу, мне еще хуже будет.

Поп. Не бойся пока я здесь.

Гриша. А вы меня заберете?

**Поп.** Если правду скажешь, заберу!

**Гриша.** Менә бу предатели, своих бьют!

**Гата.** Андрей белән Колямы?

**Гриша.** Да, это они сволочи. Батюшка, забери меня. Не хочу я здесь учиться. Я их ненавижу. Я их когда-нибудь сам убью.

**Поп.** За что ты своих братьев убьешь?

**Гриша.** За все.

**Гата.** Андрей, Коля, нәрсә булды?

**Андрей.** Гафу итегез. Гатаулла хазрат! Аны тукмамыйча мөмкин түгел.

**Гата.** Сездән ике яшькә кечерәк бит ул.

**Андрей.** Жулик ул!

**Гриша.** Ты сам жулик.

**Коля.** Бермәлне безгә татар малайлары кырын карый башладылар. Дус булып йөргәннәре дә читләште.

**Андрей.** Сәбәбен дә әйтмиләр.

**Коля.** Соңыннан ачыкланды, әлбәттә. Шәкертләрнең әйберләре югала башлаган. Гриша да үзен бик сәер тота. Караватыннан сирәк тора. Эше төшеп урамга чыкса да, букчасын калдырмый. Без аны күзәтә башладык.

**Поп.** А что дальше?

**Андрей.** Төнлә юрганы астында нәрсәдер мәтәштерә. Тартып ачсам, билле прәннек сыпыртып ята. Оказывается, Батталның биш тиенен урлаган да, шуңа лавкадан тәм-томнар алып, төнлә генә тыгынып ята икән.

**Гриша.** Врут они, врут. Не крал я!

**Поп.** Шуннан?

**Коля.** Безнең тавышка бүтән шәкертләр дә уянды. Лампа кабызып, урын-җирен тикшереп карасак, бөтен югалган әйберләр килеп чыкты.

**Андрей.** Габделәхәтнең пәкесе, Мөнирнең тәсбигы, Хәлимнең уенчык аты Гриша букчасында иде.

**Гриша** *(елый).* Вы сволочи! Предатели. Я вас ненавижу. Ненавижу. Вы не русские. Атакай, жаным, алып кит мине биредән.

**Поп.** Ну атаң кылый Петрга ошасаң да, ошарсың икән, гаденыш! Ул да бурлыкта йөреп каторгага олакты. Инде хәзер син житлегеп киләсең, күз көеге! Бар, жыен, монда бөтен рус халкын мыскылга калдырып ятма!

**Гриша.** Яхшы, яхшы, атакай! Их, вы, из-за вас все! Вы не русские!

**Гата.** Галимулла хәзрәт, сез бу хәлне белдегезме?

**Галимулла.** Әйе.

**Гата.** Нишләп мина хәбәр итмәдегез?

**Галимулла.** Беренчедән, сезне борчыйсым килмәде, икенчедән, калганын мин үзем жайладым.

**Гата.** Ничек жайлагансыздыр, анысын белмим. Баланы кыйнаганнар бит әле.

**Коля.** Без аны бер генә мәртәбә. Галимулла хәзрәт анлаткач, бүтән чәпәләмәдек.

**Гриша.** Если бы Галимулла хазрат, они бы меня точно изуродовали бы.

**Гата.** Эшне жайлаганың өчен рәхмәт. Ләкин икенче юлы мина хәбәр итүенне сорыйм.

**Галимулла.** Аңладым, Гатаулла хәзрәт.

**Гата.** Хәзер Гришаны кайтарып жибәргәнгә протокол тутыр. Иван атакай кулын куеп үз өстенә алсын.

**Галимулла.** Яхшы.

**Гата.** Сез балалар икенче юлы гауга чыгарып йөрмәгез, килеп минем белән киңәшегез. Сез бит булачак белем иясе.

**Андрей.** Яхшы.

**Коля.** Гафу итегез.

**Гата.** Хәзер барыгыз, дәресләрегезне карагыз!

**Коля.** Гатаулла хазрат. Мин сыбызгы ясарга өйрәндем, тиздән курай да эшләп карыйм. Бусы сезгә бүләгем булсын. *(Сызгырып ала да, бирә).*

Гата. Рәхмәт. Булдыргансың.

Коля. Курай ясасаммы, Миңнулла кебек көйләр чыгарачакмын.

Гата. Уйнарга өйрәнәсең киләме?

Коля. Бик килә.

Гата *(шкафтан курай ала)*. Менә бүләгем булсын. Өйрән.

Коля. Рәхмәт, Гатаулла хазрат.

Гата. Бәхетле бул, Коля олан.

Гриша. Я с ними не пойду. Они меня...

Гата. Андрей, Коля, барыгыз.

Коля. *(Кураен сызгыртып Гришаны котыртып ала)*. Дуй, давай дуй! Урлашсаң, сине Федоровкада да дөмбәслиләр.

Поп. Ну Гришенок, чертенок, селога кайткач урлашмассыңмы? Кәҗә маенны чыгарам мин синең.

Гриша. Урлашмыйм, урлашмыйм, Иван атакай, клянусь!

Поп. Чиркәүдә утын ватарсың, су ташырсың, эшләп ашарсың. Айда жыен, адам актыгы.

Гриша. Яхшы, атакай. *(Йөгерә)*.

Гата. Бу балага төпле тәрбия кирәк. Үзегез күрәсез, начар гадәткә өйрәнгән.

Поп. Үземнең тирәдә йөртеп өйрәтеп карармын инде аны. Нәселдән аларда угрылык чире.

Гата. Укып белем дә алса...

Поп. Үзеннән тора. Ана бит Андрей белән Коля ничек тырышып белем алалар дисең. Коранны да үзляштерялярме?

Гата. Коръәнне ашыктырырга ярамый. Аңлап сеңдерүләре кирәк.

Поп. Точно. Библияне дә шулай. Да! Күпме малайны татарчукка айляндырып бетергәнчең икән. Молодец.

Гата. Наполеон нәрсә дигән?

Поп. Нәрсә дигән соң?

Гата. Поскреби любого русского, там найдешь татарина, дигән. Малайлар да әллә кая китмәделәр, үзләренең кан-кардәшләре янында гына.

Поп. Бик дөрес сөйлисең. Минем дә бит бая айта башлаган серем шул тирәдәрак. Хәзер, бер генә минут. *(Коньяк шешәсен ала)*. Мөмкинме?

Гата. Үзенә кара.

Поп. Рахмат *(күтәреп эчә)*. Минем дә бит предкаларым татарлар булган. Чукынган Тутай кнәз нәселеннән мин. Бабамның бабасы Ильяс атлы булган.

Гата. Чынлапмы?!

Поп. Вот Богом, Аллахом клянусь! Шуңа күрә килеп чык, яшереп кенә саклаган нәсел китабымны күрсятам. Карчыгым Варвара да белми бу турыда.

Гата. Әйбәт булыр иде.

Поп. Нәсел чыгышыгыз Казан ханлыгыннан, Кайбыч тубагеннән диелгән анда. Бирегә бабам жир күп итеп бирелгәч, күчеп кенә килгән. Вот так брат.

Гата. Нинди язмыш. Син затлы нәселдән икән бит, Иван туган. Ул китапны, әлбәттә, килеп күрәчәкмен.

Поп. Чын сүзме?

Гата. Ант менә. Киләм.

Поп. Анда гел по арабски. Укып, таржыма ясарсың алы!

Гата. Рәхәтләнеп, Тутай углы.

Поп. Жан тартмаса да, кан тарта икән бит, брат. Син Тутай углы дигәч, шундый рахат булып китте. Ярый, кузгалыйм але мин.

Гата. Рәхмәт, килеп хәл белүеңә.

Поп. Малайлар мәсьәләсендә борчылма. Укысыннар, үзләренә ошый икән. Бер жирләре дә киселмәгән дә, тәртипләре дә яхшырак диеп халыкка үзем аңлатырмын.

Гата. Ышанырлармы икән соң?

Поп. Ышанмасалар, үзляре килеп малайларның галәмәтләрен карап китсенняр. Миңа күргән хатлиси дә бик житте.

Гата. Исән-сау йөр, Тутай морза оныгы.

Поп. Спасибо, мой дорогой! *(Кочаклашалар)*. Их, күңелем тулды, китим әле мин бередән. *(Күз яшьләрен сөртеп чыгып китә)*.

Гата. Шәп кеше. Шундыйлары күбрәк булсын иде. Әчкерсез, мәрхәмәтле. Аңлый белә торган адәм! Хәерле юл сиңа, Тутай туган! Галимулла хәзрәт!

Галимулла. Әйе.

Гата. Иртәгә юлга чыгу ничегрәк инде?

Галимулла. Сезне Чернушка тимер юлына, ике ат җигеп, Галимҗан озатачак. Төн куну Фазылҗан хәзрәтләр авылы — Чыршылыда.

Гата. Минем белән барасы шәкертләрне җылырак киендер. Юл озын, көннәр суык хәзер. Аллага тапшырдык, Галимулла туган, уңышлы сәфәр булуын теләп, әйдәгез бер дога. *(Укый).* Бисмилләһиррахманир-рахим. Әл-хәмдү лилләһи раббил-гааләмин. Әррахмәәнир-рахим. Мәәлики-йәүмиддин. Иййәәкә нәгъбүдү үә иййәәкә нәстәгыйн. Сыраталь-лэзиинә әкгантә галәйһим үәләддааллиин. Әмин. Йә раббым, догамны кабул ит!

Галимулла. Юлга дүрт күмәч, ит, чәй, казылык, пәрәмәчләр төенләттем. Җитәргә тиеш.

Гата. Рәхмәт. Әгәр дә Уфада, заманча мәктәп-мәдрәсәләр ача алсакмы! Безнең уку йортларыннан чыккан шәкертләр татар милләтен дөньяга танытырга тиешләр. Ул шулай булачак та, тырышырга гына кирәк. Татарның Европа югарылыгындагы мәктәпләре, театрлары, профессиональ артистлары булырга тиеш!

Галимулла. Амин, шулай гына була күрсен, Гатаулла хәзрәт.

Гата. Хәзер кичке намазга, Галимулла дустым. Иртән юлга чыгасым да бар. Ял итеп алырга да кирәк.

Галимулла. Иван атакай бик үпкәләп китмәдеме?

Гата. Шәп кеше ул. Кайвакытта мин аның татар булмавына үпкәләп тә куям.

Галимулла. Чынлап сөйлисезме соң сез?!

Гата. Әлбәттә. Син миңа хәерле юл телә, Галимулла кардәш.

Галимулла. Ак юл сиңа, хәзрәт.

*Музыка.*

**III күренеш**

*Музыка. Уфа. Рус драма театрының залы. Шактый гына татар алдынгылары җыелган.*

Урамда тавыш. Әфәнделәр, ханымнар! Шәкертләр һәм мөгаллимнәр! Бүген рус драма театры сәхнәсендә Казан артистлары чыгыш ясый. Концерт бик күңелле булачак. Килегез, күрегез, рәхәтләнеп ял итегез. Уфада бер генә тапкыр Казан артистлары!

*Тавыш ерагая. Тарантас тавышлары, ат кешнәшкән, кешеләр шаулашкан авазлар яңгырый.*

Тавыш: *(яңадан якыная).* Сәхнәдә Казан артистлары. Танылган сүз остасы, җырчы, музыкант Фәнзаман Әтнинский, җырчы сандугачыбыз Зөбәрҗәт Талгинскаялар. Рәхим итегез! *(Пәрдә ачыла. Сәхнәдә Фәнзаман әфәнде).*

Фәнзаман. Хөрмәтле милләттәшләр, концертыбызны дәвам итәбез. Хәзер халкыбызның мәхәббәтен казанган җырчы, музыкант Зөбәрҗәт Талгинская «Зөләйха» җырын башкарачак. Курайда мин үзем — Фәнзаман Әтнинский.

*Музыка башлана, Зөбәрҗәт скрипкада уйнап җыр башкара.*

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә,
Айга менеп, түбән карап,
Сине күрәсем килә.

Кызарып кояш чыкканда
Нурлар төшә түтәлгә,

Күзем төшсә, күңлем төшми,
Синнән башка бутәнгә.

Ф ә т т а х *(акырып-бакырып полиция белән килеп керә).* Яле, туктатыгыз әле бу мөртәт эшегезне! Туктатыгыз! Уфа каласы уртасында кяфер эшләр кылып ятарга ирек бирмәбез! *(Бар да аптырап кала).*

Ф ә н з а м а н. Киемнәрегезгә караганда хәзрәткә охшагансыз. Ни булса да аңлатыгыз әле, хөрмәтлем!

Ф ә т т а х. Булырмын мин сиңа хөрмәтлең! Халыкны аздырып ятасыз, зиначылар, житте! Куып төшерегез кара йөзләрне! Полицай, нәрсә карап торасың?

П о л и ц а й. Бу тамашаның житәкчесе кем?

Ф ә н з а м а н. Мин оештырдым.

П о л и ц а й. Шәһәр житәкчеләренең рөхсәте бармы?

Ф ә н з а м а н. Әлбәттә, полицай әфәнде. Менә ул!

П о л и ц а й. Монда барысы да шәһәр житәкчеләренең рөхсәте белән бит, Фәттах хәзрәт. Сез миңа өелешеп зина кылып яталар дип ялганладыгыз.

Ф ә т т а х. Авыз күтәреп, өрән салып улап яту халыкны аздыру, рухи зина түгелме? Жәмәгать, таралышыгыз! Гөнаһ жыймагыз күнелегезгә. Ходайның ачы каһәре төшмәсен үзегезгә!

I к е ш е. Без акча түләп кердек! Карап бетерәчәкбез! Хакыгыз юк!

II к е ш е. Башка халыкларга яраган, нишләп әле безгә хәрәм?! Дин үзенә, сәнгать үзенә бер тәрбия!

Ф ә т т а х. Жәмәгать, үзеңнең чыраенны, тәнеңне күрсәтеп, халык каршында боргалану, үзе зур гөнаһ инде, кяферләр кыланмышы. Халык аздыру, бозыклык юлына керту түгелме бу эшегез?!

Ф ә н з а м а н. Без халкыбызның карашын киңәйтәбез. Йомылып яшәүдән чыгарырга тырышабыз.

Ф ә т т а х. Сез алып барган эш — хәрәм эш. Таралыгыз, жәмәгать! Иманыгызга килегез! *(Кешеләрне сөйрәп торгызмакчы булып рәт араларында йөри).* Син? Син нишләп утырасың, Әһлиулла мөәзин? Әстәгъфирулла! Шәкертләр дә монда. Муеныгыз астына килгереләре.

I к е ш е. Үз каргышың үзеңә төшсен, Фәттах ишан!

Ф ә т т а х. Тукта, тукта! Син Әсрар мулла кызы Өммегөлсем түгелме соң? Мөхәммәт купец малае Мозаффар! Коткы бу! Сез шайтан фәлсәфәсенә бирелгәнсез! Тор, бар өеңә кайт, Мозаффар. *(Якасыннан сөйри).* Тор дим, муеның астыңа килгере!

М о з а ф ф а р. Алыгыз кулыгызны! Хакыгыз юк. *(Кешеләр арасыннан Гатаулла күтәрелә, Фәттах мулланың кулларын каерып алып, буш урындыкка утырта).*

Г а т а. Житте, кеше көлдермә, Фәттах. Халык ул һәрвакытта яктылыкка омтылган. Нәрсә, татар халкының башкаларныкы кебек мәдәниятен, сәнгатен үстерергә хакы юкмы?!

Ф ә т т а х. Без бит мөселман өммәтеннән.

Г а т а. Мөселман өммәтеннән булган төрекләр, гарәпләр, фарсылар ни өчен төрле уен коралларында уйныйлар, жыр-биюдә осталыкларын арттыралар. Бернинди зиначылык та юк ниятләрендә.

Ф ә т т а х. Мөмкин хәл түгел бу.

Г а т а. Мин ул илләрдә йөреп кайттым. Күрдем.

Ф ә т т а х. Сез үзегез кем буласыз соң әле, мелла кем?

Г а т а. Танымыйсызмы, Фәттах белемдәш. Оренбург мәдрәсәсен искә төшерегез?..

Ф ә т т а х. Гатаулла! Әллә сез дә шушы кяферләргә иярдегезме?

Г а т а. Мин монда татар алдынгыларынннан гайре бер генә кяфер дә күрмим. Үземә килгәндә, дөрес, ара ерак булса да, үзебезнең халык жәүһәрләрен күрергә, моңлы көйләребезне тыңларга диеп, Пермь якларыннан ук юл үттем.

Ф ә т т а х. Син дә алар белән, димәк?

Гата. Казан артистларын күрү бәхете көн дә тәтеми ул, Фәттахетдин.

Фәттах. Сез ни сөйлисез? Акылыгызга килегез, Гатаулла хәзрәт?

Гата. Ни өчен әле, җәмәгать, безнең халкыбыз Европа, Азия, Россия кебек үзенең концерт залларын ачмаска тиеш. Үзебезнең Моцартлар, Бетховеннар, Шаляпиннар кая? *(Халык аның сүзен хуплап күтәреп ала. «Булырга тиеш! Егерменче гасыр башында яшибез! Балетыбыз да, театрыбыз да, концерт залларыбыз да юк»).*

Фәттах. Коткыга бирелмәгез, мөселман кардәшләр. Әле сез беләсезме соң бу кешенең кемлеген?

Гата. Әйе, әйтегез кемлегемне, үзем дә белмим әле.

Фәттах. Бу җәмәгать кяфер балаларын җыеп, Коръән укытып ятучы, зур гөнаһ җыючы Барда мулласы Гатаулла хәзрәт.

Гата. Әйе, туганнар! Мин, милләте кем булуына карамастан, ятим балалар җинаять кылып йөрмәсеннәр дип тәрбиягә алам, иман юлына бастырырга тырышам. Алар ислам дине буенча гына түгел, дөньяви фәннәрдән дә белем эстиләр. Французча да өйрәнәләр. Тиздән Парижның үзеннән дә мөгаллимнәр килеп тел буенча дәресләр бирәчәкләр.

Фәттах. Мөселман татар баласына нәрсәгә кирәк ул француз теле?

Гата. Аралашу, сәүдә өчен, илнең икътисадын күтәрү өчен дә кирәк. Шунсыз алга китеш юк. Чит милләт вәкилләренең ислам динендә белем алырга теләкләре бар икән, киләчәктә алар да рәхим итсеннәр, тәрбия кылачакбыз. Хәзер, рөхсәт итегез, үземнең шәкертләрем башкаруында «Сак белән Сок» мөнәҗәтен тыңлап карыйк.

Фәттах. Мөнәҗәткә мин үзем дә каршы түгел.

Гата. Менә монысы чын ирләр сүзе. Утырыгыз бирегә, Фәттах туган.

Фәнзаман. Рәхим итегез, егетләр.

*Андрей белән Коля чыгып утыра. Музыка башлана.*

Сак - Сок бәете.
Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.
Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.

Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.
Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.
Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә өзелә үзәкләр.
Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.
Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй елама, үзең каргагач.

Халык *(җыр беткәч)*. Афәрин, шәкертләр. Булдырдыгыз! Искиткеч! Афәрин! Сөбханалла!

Фәттах. Менә монысы үзебезчә ичмасам, менә монысы ихлас.

Гата. Инде Фәттах хәзрәткә дә җырымыз ошаган икән, әйдәгез әле, егетләр, «Якты дөньяны күреп туймадым» мөнәҗәтен дә җиткерегез.

*Егетләр җырлый.*

Әҗәл ширбәтен бер көн эчәрмен,
Якты дөньядан бер көн күчәрмен.

Әҗәлем җитәр, тыннарым бетәр,
Ясин укырга вакытлар җитәр.

Укый алмамын, бетәр сулышым,
Артымнан калсын дога укучым.

Караңгы гүрдә калыр бу башым,
Ак фәрештәләр булсын юлдашым.

Мөшкел хәл икән җанны бирүе,
Авыр хәл икән гүргә керүе.

Зәгыйфь тәнемне каты тотмагыз.
Кире кайталмасам, ашыктырмагыз.

Йорттан чыкканда ашыгып
чыкмагыз,
Бик елашмагыз, зинһар, чыдагыз.

Тордым дөньяда бераз вакытлар,
Салкын туфрактыр безгә ястыклар.

Каберләремне киңрәк казыгыз.
Ак таш утыртып исемем язгыгыз.

Халык. Гомерегез озын булсын, балакайлар.

Фәттах. Менә ул ничек, илаһыдан булгач, ничек күнелләргә үтеп керә, уйландыра.

Гата. Рәхмәт сезгә, балалар. Бу ике мөнәҗәтне башкаручылар рус өммәтеннән булган Андрей белән Николай. Әйдәгез, кул чабып олуг рәхмәтебезне белдерик. *(Кул чабалар).*

Фәттах. Булмас ла!

Гата. Яле, балалар, Фәттах туганны русча сәламләгез әле!

Андрей. Ой мороз, мороз, не морозь меня.

Коля. Не морозь меня, моего коня.

Фәттах *(халык көлә-көлә кул чаба).* Булмас ла?!

Гата. Дөресе шулай, Фәттах туган. Ислам дине кануннарын хөрмәт итүләре, өйрәнүләре белән безне зурлыйлар.

Фәттах. Ата-аналары каршы түгелме соң?

Гата. Кызганыч ки, әти-әниләре юк инде аларның. Бик зур рәхмәт сезгә. Икегез дә менә дигән җегетләр.

Андрей. Татар җегетләре.

Гата. Әлбәттә, сез чын татар җегетләре. Менә шушы чигүле түбәтәйләр бүләгем булсын.

Коля. Гатаулла хәзрәт, мөмкинме мин Коръән Кәримнән бер өзек сөйләп күрсәтсәм.

Гата. Фәттах туган, сез каршы түгелме?

Фәттах. Андый иманлы эшкә ничек каршы булыйм ди инде.

Гата. Рәхим ит, Коля.

Коля *(кунут догасы).* Аллаһүмә иннә нәстәгынүкү үә настәгъфирукә үә йүәминү бикә үә нәтәвәккәлү галәйкә үә нүсни гәләйкәлхайра нәшкүрүкә үә лә нәкфүрүкә үә нәхләгу үә нәтрукү мәй-йөфҗүрүк. Аллаһүммә иийәкә нәгъбүдү үә ләкә нүсалли үә нәсҗүду үә иләйкә нәсга үә нәхфиду нәрнү рахмәтәкә үә нәхшә гәзәәбәкә иннә гәззәбәкә бил- күффәри мүлхикъ.

Фәттах. Бәрәкалла, бәрәкалла. Бу балаларның кайсы җире урыс соң?

Гата. Рәхмәт, Коля.

Фәттах. Могҗизадыр бу. Менә бит ничек, Ходай Тәгаләнең кодрәте киң булгач. Афәрин, наныйларым! Бик савaплы эш кылдыгыз. Кунут догасын ничек укыды!

Гата. Фәттах ишан, сез бит үзегез дә, Ходайның биргәненә шөкер, Оренбургта укыгында бик үткен, бик җор телле шәкерт идегез.

Фәттах. Ул чагында бәлки шулай булганмындыр да бит, мелла кем Гатаулла. Дөнья мәшәкатьләре бер китереп баса икән ул!

Гата. Менә шул дөнья мәшәкатьләрен онытып тору өчен, бөтенләй акылдан шашмас өчен тыңлап карыйк әле без бая өзелгән җырыбызны.

Фәттах. Алланың биргәненә шөкер, акылдан шашканым юк әле.

Гата. Әйдәгез, шулай да Зөбәрҗәт былбылыбызны тыңлап карыйк. Ошамаса, кайтып китәрсез.

Фәттах. Иртәгә бөтен Уфа минем гайбәтемне чәйнәячәк бит. Аллам сакласын! *(Тора).*

Гата. Киресенчә, халык алдында ихтирамыгыз гына күбәячәк. Үзең генә түгел, мин дә бар бит әле биредә.

Фәттах. Шулай дисенме? Тик берне генә тыңлыйм да, соңыннан китәрмен инде... *(Утыра).*

Фәнзаман *(елмаеп).* Хәзер концертыбызны дәвам итәбез! Сезнен каршыгызда сайрар сандугачыбыз Зөбәрҗәт туташ Талгинская! *(Кул чабалар).*

Зөбәрҗәт. Халкыбызның яраткан җырларыннан берсе «Зиләйлүк». *(Җыр янгырый).*

Фәттах. Бәрәкалла-машаллa! Җәннәт кошчыгыдыр бу! *(Күз яшьләрен сөртә).* Бала чагымда әнкәй җырлый иде бит аны. Искиткеч моң!

Гата. Халык күнеле кин, тирән бит ул дигән Габдулла Тукай.

Полицай. Мин мондый гүзәл тамашаны гомеремдә дә күргәнем юк иде. Рәхмәт сезгә, Гатаулла әфәнде. Сез генә ул, Фәттах абзый, куарга, таратырга кирәк, анда яп-ялангач хатын-кызлар арт саннарын күрсәтеп бииләр, соныннан зина кылалар дип коткы таратасыз.

Фәттах. Минем бит үземә дә шулай дип аңлаттылар.

Полицай. Ул Зөбәрҗәт дигән кызның тавышыннан гына түгел, күз карашыннан да иман нуры агыла.

Фәттах. Белмәдем бит!

Фәнзаман. Хөрмәтле концерт карауучылар, кызганыч, безнең театр житәкчеләре белән килешенгән вакытыбыз чыкты. Төнлә аларның үзләренең ниндидер кичәләре башланачак. Гафу итегез!

Гата. Мөмкин булса, бер генә сүз житкерим әле. Хөрмәтле милләттәшләр, туганнар! Без әле Габдулла Тукай шигырьләрен дә, халкыбыз биюләрен дә карый алмадык. Мондый затлы бәйрәм көн саен булмый. Моннан ерак түгел ашханә бар. Хуҗасы белән көндез сөйләшеп куйган идем. Шунда барып тәмләп чәй эчә-эчә концертның дәвамын карыйсыгыз киләме? Бар чыгымнарны да үз өстемә алам.

Халык. Барабыз, барабыз! Шундый концертны карамаска!

Полицай. Мина да барсам ярыймы?

Гата. Әлбәттә, кем, әфәнде.

Полицай. Бакир мин.

Гата. Бергәләшеп карыйк, Бакир әфәнде. *(Полицай китә).*

Фәттах (икеләнеп тора). Ярый, Гатаулла сабакташ, мин әкрен генә тәпилим инде.

Гата. Ашыкмагыз әле, Фәттах! Сезнең белән киңәшәсе сүзләрем дә бар иде. Минем бит Уфага килүем тиктомалга түгел. Биредә мәктәпмәдрәсәләр ачып, балаларга төрле яклап белем бирергә ният.

Фәттах. Бик изге эш белән йөрисең икән, Гатаулла туган. Бик афәрин. Ишетеп белә идем, бу кадәресен үк көтмәгән идем.

Гата. Бик саваплы, бик җаваплы эш, Фәттах туган. Тик минем бер үземә генә кыенга туры киләчәк. Бергәләшеп башласак!

Фәттах. Чынлап әйтәсезме соң?

Гата. Уйнап сөйләшергә вакытым аз минем, Фәттахулла. Уфада ике кибетем, бер чәйханәм бар. Алардан кергән табышны мәктәпмәдрәсәләр ачарга тотачакмын.

Фәттах. Аннан кергән керем генә житәр дисенме?

Гата. Житеп бетмәс, әлбәттә. Пермьда, Бардада, Чернушкадагы сәүдә нокталарым да үз өлешләрен кертерләр.

Фәттах. Алай булгач, Ходайның «Амин» дигән сәгатенә туры килсен, барып чыгар дип уйлыйм ниятең.

Гата. Өстәвенә алтын приискасында бер бик якын дустым эшли, мәчет салганда ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

Фәттах. Иншалла, Гатаулла туган, бик хуплыйм бу эшенне!

Гата. Инде, сүземне түгәрәкләп синнән шуны гына сорыйм. Шушы дин йортларыбызның имам хатыйбы бул әле.

Фәттах. Минме?! Бәрәкалла, бәрәкалла! Көчем житеп бетәр микән соң?

Гата. Әрсезлегең, кирәк хәтле усаллыгың да бар, житәр көчең!

Фәттах. Аллага тапшырып эшләп карарга була ул, Гатаулла дустым.

Гата. Хәерле сәгатьтә, Фәттах туган. Син хәзер ашханәгә барып чәй, хәлвә, шикәр, гөбәдияләргә заказ бирә тор. Ничә кеше килгәнен барла. Һәрберсенә пылаудан да өлеш чыгар. Мин артистлар белән килермен инде.

Фәттах. Яхшы, Гатаулла хәзрәт. *(Китә).*

Гата. Нинди моңлы тавыш, нинди нурлы күзләр бу Зөбәрҗәт туташта. Ул чәч толымнары, сихри елмаюлары! Кем бәхетенә тугансын

икән мәркәзебез Казанның гүзәле, Зөбәрҗәт туташ?! *(Ике чемодан күтәргән Фәнзаман чыга).*

Фәнзаман. Зөбәрҗәт туташ дисезме? Хәзер чыга ул. Әнә үзе дә.

Зөбәрҗәт. Мин әзер, әфәнделәр!

Гата. Бик яхшы.

Фәнзаман. Ярый әле сез булдыгыз. Югыйсә, теге Фәттах дигәннәре әллә нәрсә эшләп бетергән булыр иде.

Гата. Борчылмагыз. Андый гына хәлләр булгалый ул татар дөньясында. Үз илең, үз патшаларыңның булмавы да комачау ясый. Тик иманым камил, тагын бер егерме-утыз елдан татарымызның театрлары, профессиональ артистлары да үсеп чыгачак. Без ачкан мәктәп-мәдрәсәләр үз эшен эшли. Тиздән Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Габдулла Кариев салган сукмактан яшьләребез атлап китәчәк.

Зөбәрҗәт. Шулай гына була күрсен инде, Гатаулла әфәнде.

Гата. Булыр, Алла боерса. Дин җанны тәрбия кылса, сәнгать рухыбызны тагы да баетыр! Сезгә аерым рәхмәтебезне җиткерәм! Сихерләндем җыр-моннарыгыз белән. Рәхмәт сезгә! *(Букет суза).* Аннан тагын бер бүләгем, истәлегем бар иде... менә бу затлы беләзекләрне Уфада гына коялар.

Зөбәрҗәт. Әй, жанкисәгем, шуның хәтле кыйммәтле бүләк алмасаң! Якыннарыгыз ни әйтер!

Гата. Якыннарым сүз әйтмәс. сөйгән ярым да юк минем. Беркем дә рәнжемәс... Чын күңелдән...

Зөбәрҗәт. Гафу итегез... Минем дә кем бүләк итте дип бәйләнерлек кешем юк!

Гата. Мин бүген... *(Фәнзаман белән карашып алалар. Ул эшне аңлап читкә кагыла).* Мин бүген шуның хәтле бәхетле, Зөбәрҗәт туташ, чөнки сезне очраттым. Әгәр дә сезнең нурлы йөзегезне, матур тавышыгызны күрәсем килеп, бер тапкыр Казанга барып чыксам?

Зөбәрҗәт. Нигә бер генә тапкыр? Мин сезгә Болак, Кабан күле, Кремль буйларын күрсәтермен.

Гата. Ихластан әйтәсезме?

Зөбәрҗәт. Мин сезне көтәчәкмен!

Гата. Рәхмәт, сайрар сандугач!

Зөбәрҗәт. Үзегезгә бик рәхмәтлемен. *(Күзләрен сөртә).*

Гата. Нишләп җылыйсың, Зөбәрҗәт туташ?

Зөбәрҗәт. Нинди татлы сүзләр... Миңа сезнең кебек җан җылыткыч сүзләрне беркем дә әйткәне юк иде.

Гата. Мин ул сүзләрне гомерем буе сезгә генә әйтер идем! Фәнзаман әфәнде!

Фәнзаман. Әйе.

Гата. Сезгә кечкенә генә үтенечем бар.

Фәнзаман. Игътибар белән тыңлыйм, Гатаулла әфәнде.

Гата. Тиздән сез шәһри Казанга кайтып китәсез. Әгәр Габдулла әфәндегә дәваланырга 20 сум акчаны сезнең аша тапшырсам?

Фәнзаман. Андый изге әманәтне тапшыруым белән бик бәхетле булачакмын.

Гата. Аннан... Зинһар... Зөбәрҗәт туташ, безне гафу итегез. *(Читкәрәк алып китә).* Менә сезнең үзегезгә 10 сум гонорар. Зөбәрҗәткә, үзенә затлы кием-салым алырсыз. Юл йөргәндә яхшырак номерларга урнаштырырсың.

Фәнзаман. Сезгә нинди генә рәхмәтләр әйтим икән соң шушы ярдәмегез өчен, Гатаулла туган.

Гата. Иң мөһиме, исән-сау йөрегез!

Фәнзаман. Бу бик зур сумма бит. Калганына бер яхшы тальян гармун юнәтсәм, гаеп итмәссезме?

Гата. Киресенчә, чиксез шат булачакмын. Сез бит халыкта хезмәттә. Истәлегем, бүләгем булсын.

Фәнзаман. Сезгә Ходай Тәгалә меңе белән кайтарсын!

Гата. Шулай булсын! Әйдәгез, Зөбәрҗәт туташ! Сез, Фәнзаман әфәнде, бер чемоданыгызны миңа бирегез.

Фәнзаман. Рәхмәт. *(Бирә. Полицай керә, борчулы).*

Полицай. Хөрмәтле әфәнделәр! Кәефегезне төшерәсем килми дә, житкермичә дә булмый!

Гата. Ни булды?

Полицай. Бүген төнлә Казанда Габдулла әфәнде Тукаев вафат булган.

Гата. Авыр туфрагы жинел, урыны җәннәтнең түрендә булсын. *(Тезләнеп дога укый).*

Зөбәрҗәт. Бу хәл мөмкин түгел!

Гата. Ни кызганыч, исән килеш күреп кенә дә калып булмады бит. Белгән булсам...

Фәнзаман. Халкыбыз өчен зур югалту! Татарның шигъри моңы китте. *(«Әллүки»не жырлый башлый, аңа башкалар да кушыла).*

Ишеттем мин кичә берәү җырлый,
Чын безнеңчә, матур милли көй.
Башка килә уйлар төрле-төрле,
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.
Әллүки-бәллүки,
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Гата. Әйдәгез, туганнар, ашханәгә. Габдуллабыз рухына төне буе дога кылып чыгарбыз. Шигырьләре аша искә алырбыз.

Фәнзаман. Гатаулла әфәнде, Тукайга дигән акчалар. *(Суза).*

Гата. Син, Фәнзаман әфәнде, ул акчаларга Тукай, Дәрдемәнд, Утыз Имәни һәм башка язучыларның китапларын сатып ал да, Россиянең төрле төбәкләрендә йөрисез, халыкка бүләк итеп тарат, зинһар!

Фәнзаман. Сез нинди изге, бөек кеше, Гатаулла әфәнде.

Гата. Мин Тукаебыз янында бер нур гына. Ул халкыбызның кояшы иде. Нинди зур мирас калдырып китте. Рәхмәт аңа. Татарларыбыз укысыннар, белсеннәр аны!

Зөбәрҗәт. Гатаулла абый, җанкисәгем, инде Тукаебызсыз нишләрбез?! *(Кычкырып елап җибәрә).*

Гата. Аны гомеребез буе сагынып яшәрбез, Зөбәрҗәт туташ! Нык бул! Мин сезнең белән Казанга китәрмен, ахры.

*Музыка. Күренеш тәмам.*

**IV күренеш**

*Гатаулла хәзрәтнең эш бүлмәсе. Тукай, Пушкин рәсемнәре эленгән. Зөбәрҗәт тузан сөртеп, гөлләргә су сибеп йөри. Үзе герман көен көйли.*

Зөбәрҗәт.
Без авылны чыккан чакта,
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар.

Бу сугышы бетеп житмәде, икенче афәте башланды. Кайчан булса да бер тынычлык килерме икән бу илгә?! Йә Ходаем, үзең генә саклый күр инде.

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз
Сау булыгыз, туганнар.

Заһидә *(керә).* Әссәламәгаләйкүм, Зөбәрҗәт апам.

Зөбәрҗәт. Вәгаләйкүмәссәлам, наныем. Ярты көн буена кайларда йөрдең инде, тамак ялгарга да кайтмыйча?

Заһидә. Андрей Бардым елгаларын күрсәтте. Табигать белән хозурландык. *(Кулындагы чәчәкләрен исни).*

Зөбәрҗәт. Казанга, әти-әниләр янына бик монсуланып кайтып китәсең түгелме соң, матурым?

Заһидә. Сезнең белән аерылышу кәефемне төшерә. Биредәге табигатьне, сез кадерлеләремне сагынып тилмерермен инде мин.

Зөбәрҗәт. Шулай булгач, ашыкма, яшә безнең белән рәхәтләнеп. Андрейның да үзеңне җибәрәсе килми.

Заһидә. Апаем, бәгърем, инде минем синнән яшерен серем юк.

Анын миңа булган мөнәсәбәтеннән куркам да инде мин.

Зөбәрҗәт. Сина анын мөнәсәбәте начармы?

Заһидә. Киресенчә! Ул китмәвемне үтенә!

Зөбәрҗәт. Шулай булгач! Әти-әнигә хат язып хәбәр бирербез дә, син булганда миңа да җинел. Өй эшләренә дә булышасың.

Заһидә. Китәргә кирәк мина, Зөбәрҗәт апам, ике ут арасында мин.

Зөбәрҗәт. Ничек ике ут арасында?

Заһидә. Апа, дөресен сөйләсәм, гаеп итмәссезме? Андрей миннән кайтып китмәвемне тезләнеп сорады. Синсез миңа тормыш юк, ди. Күзләреннән яшьләре коелды. Нишлим соң, апам?

Зөбәрҗәт. Шулай булгач!

Заһидә. Куркам мин, апам, берәр ялгышлык эшләп ташлармын дип куркам.

Зөбәрҗәт. Юкны сөйләмә әле, Заһидә сенлем. Нинди ялгышлык эшлисең ди, акылың да, белемен дә җитәрлек.

Заһидә. Моңа белем дә, акыл да ярдәм итми икән шул! Ниндидер дулкыннар бөтереп ала да, үземне жылы томанга эләккәндәй тоям, котылмакчы булам, көчем җитми.

Зөбәрҗәт. Әй бәләкәчем минем, гашыйк булгансың бит син! *(Кочаклап ала).*

Заһидә. Беттем мин апа!

Зөбәрҗәт. Нишләп алай дисен, аппагым?

Заһидә. Андрей бит бүтән милләт кешесе. Әткәй-әнкәй, аннан Гатаулла җизнәм ни дияр? Туган-тумача ни уйлар?

Зөбәрҗәт. Әйтүчеләр булыр анысы. Тик шуны онытма: Андрей инде күптән ислам дине кабул итте. Исеме дә Әнвәр анын, җизнәнңнең иң яраткан, үз иткән шәкертләреннән берсе.

Заһидә. Әнвәр дигән исем алгач, нишләп алайса Андрей дисез?

Зөбәрҗәт. Аны тудырган, аңа исем биргән әти-әнисенә хөрмәт йөзеннән.

Заһидә. Миңа үзен Әнвәр дип атаганымны теләи.

Зөбәрҗәт. Эш исемдә түгел, сенлем, җисемдә. Бик уңган, бик булган егет ул. Төс-бите дә Аллага шөкер. Менә җизнән кайтсын да, анын белән дә киңәшербез.

Заһидә. Апа җаным, зинһар аңа әйтә күрмә! Оятымнан үләм бит.

Зөбәрҗәт. Борчылма, Заһидә. Хәзрәт Пермьнән кайтсын да, ни булса да хәл кылырбыз.

Заһидә. Әнвәр үзе дә Гатаулла җизнинең кайтуын урамда көтеп калды.

Зөбәрҗәт. Бигрәк тә яхшы. Егет кеше бит, сүзне дә үзе башласын. Казанга кайтып китәргә дә ашыкма, күрмисеңмени, дөньянын асты өскә килгән чагы!

Заһидә. Ярый әле апам җизнәм белән сез бар. Сез булмасагыз, нишләп беткән булыр идем! *(Күз яшьләрен сөртә).*

Зөбәрҗәт. Матурым минем, оныттыңмы инде, мин Гатаулла хәзрәткә кияүгә чыга башлагач, «ничек инде үзеңнән егерме яшькә олырак кешегә гашыйк булырга мөмкин» дип аптыраткан иден.

Заһидә. Кичер мине, апам, булды шул андый хәл.

Зөбәрҗәт. Шуңа күрә мәхәббәт ул яшькә дә, картка да карамый, исемгә дә карамый. Эләктереп ала да, үзенне сагыш утларына сала. Әйдә, Ходай Тәгаләдән барысы да игелекле булуын сорыйк. *(Дога укый).*

«Бисмилләһир рахмәәнир-рахим! Әлхәмдү лилләһи рабил гәләмин. Әррахманирахим. Мәлики йәүмиддин, ииийкә нәгъбу дү вә ииийкәнәстәгыйм. Иһдинәс-сыйраталә мүстәкыйм. Сыйраталь-ләзинә әнгамтә галәйһим гайрил мәгъдууби галәйһим вәләддааллиин». Аллага тапшырдык, Заһидә сенлем.

Заһидә. Аллага тапшырдык, апам. *(Тояк тавышлары. Тр-р! дигән авазлар).* Гатаулла хәзрәт түгел микән? *(Тәрәзә янына бара).*

Зөбәрҗәт. Үзе, Гатаулла жизнәң! Галимулла абый, сез кая?

Галимулла. *(Керә).* Әйе, Зөбәрҗәт абыстай.

Зөбәрҗәт. Галимулла абый, хәзрәт кайтып житте. Чәйне ашханәдә эчәрбез. Әзерләшергә үзем дә булышырмын.

Галимулла. Яхшы, Зөбәрҗәт абыстай. *(Китә).*

Заһидә. Әбәү, апай, алар минем тәрәзәдән карап торуымны күрделәр, керәләр, апам. Әллә миңа йокы бүлмәсенә кереп качаргамы?

Зөбәрҗәт. Юк, юк, сенлем, алай килешмәс. Әле бит янында мин дә бар. Тынычлан. Шыпырт, керәләр.

Гата *(керә. Чемодан күтәргән Андрей аның артыннан күренә).* Әссәламегаләйкүм, кадерлеләрем!

Зөбәрҗәт. Вәгаләйкүмәссәлам, хәзрәт!

Гата. Нихәл, Зөбәрҗәтем! *(Битеннән үбеп ала).*

Зөбәрҗәт. Бусын да! *(Икенче битен куя).*

Заһидә. Нихәл, жизнәй!

Гата. Аллага шөкер, Заһидә сенлем. Әйдәгез, олы юлдан соң бер дога. *(Укый).* Менә шулай, ялгыз башына, бик күнелсез булмадымы сон?

Зөбәрҗәт. Әллә ни кыен булмады, әтисе. Серләшергә сенлем янымда. Балалар гына «әти кайчан кайта» дип сагыныштылар.

Гата. Үзем дә бик юксындым үзләрен. Йоклыйлармы?

Зөбәрҗәт. Әйе. Әти кайткач, уятырсың диделәр.

Гата. Жанкисәкләрем! Йә, Андрей, синең хәлләр ничек?

Андрей. Аллага шөкер, Гатаулла абый, үзегезнең юллар уңдымы сон?

Гатаулла. Төрле хәлләр булды инде. Ярый әле үзем белән Иван атакайны алганмын...

Андрей. Иван атакайны?!

Гата. Әйе. Карагрухчылар безнең бистәдә бернинди дә мәчет салмыйсыз дип халыкны күтәрделәр.

Андрей. Кабахәтлек бит бу!

Гата. Шуннан Иван атакай уртага чыкты да: «Ходай бәндәләре, акылыгызга килегез! Сез бит гөнаһ жыясыз! Уфа, Казан, Оренбург кебек татар шәһәрләрендә йөзләгән чиркәү салынган. Шулай ук рус дәүләтен саклап батырларча сугышкан татарларга хөрмәт йөзеннән хәтта Мәскәү белән Питерда да мәчетләр төзергә рөхсәт ителгән» диеп тегеләргә анлатты.

Андрей. Молодец, Иван атакай!

Гата. Гажәеп шәхес! Шуннан берсе «шул житкән аларга, Казаннарына кайтып салсыннар» дип кычкыра. Иван атакай тегене үз янына тартып чыгарды да «монда әле без килгәнче татарлар яшәгән, иген иккән, урман кискән. Соңыннан дошман килсә, ингә-ин куеп илне саклаган, кан койган. Инде иң якын терәгебез, ышанычлы татарларыбызга мәчет салдырырга каршы чыгабызмы? Алайса, безне миллионлап кырган немецлар килеп чиркәү салсыннар! Акылыгызга килегез, диннәр төрле булса да, Ходай Тәгалә бер генә, аның һәм минем каргышымнан куркыгыз» диеп кычкырды. Ул да түгел, фронттан кайткан солдатлар күтәреп алды. Шуның белән эш хәл ителде.

Зөбәрҗәт. Әстәгъфирулла, ничек шулай курыкмыйча йөрисен?!

Андрей. Ант итеп әйтәм, әгәр дә Иван аткайны күрсәм, рәхмәт йөзеннән бер кочаклап үбәр идем.

Гата. Заслужил ул аны, бик кыю кеше.

Зөбәрҗәт. Гатаулла хәзрәт, юлдан кайтканнан бирле чәй дә эчкәнегез юк. Тамагын кипкәндер.

Гата. Эчәбез аны, кадерлем! Ин мөһиме, эш барып чыкты. Мәчет урыны бик матур. Якында гына урман, жыйнак кына күле дә бар. Син, Заһидә балдызым, нишләп күнелсез әле? Әти-әниенне, Казанны сагынгансыңдыр инде.

Заһидә. Әйе, Гатаулла жизни. Сездән дә аерылуы бик авыр.

Гата. Минем үземнең дә сине кайтарып җибәрәсем килми. Аннан мин генә микән?!

Андрей. Мин дә, хәзрәт.

Гата. Әгәр дә, Заһидә сеңлем, чыннан да Әнвәрне сөясең икән, үзеңне дә аны да көйдермә!

Заһидә. Ләкин бит...

Гата. Әнвәр — үзебезнең чын татар егете инде. Мәдрәсәдә алган белеме белән дә күпләрне шаккатырды. Сарбоннага китәргә йөргәндә генә, дөньялары болганып китте бит әле!

Андрей. Заһидә, үтенеп сорыйм, ташлап китмә безне! Өстәвенә сугышы бетеп житмәде, чуалышлары башланды.

Заһидә. Әткәй-әнкәй бар бит әле. Алар ни дияр?!

Гата. Әби-бабай да фатихаларын бирерләр Әнвәр кебек егеткә. Үзем дә, апаң да риза бәхил. Әнвәр миңа бер туган энем кебек.

Андрей. Рәхмәт, Гатаулла абый.

Заһидә. Ничек яшәрбез соң без?!

Гата. Укытырсың. Музыка белеме бирерсең шәкертләргә.

Андрей. Тору мәсьәләсен мин инде хәл иттем. Фатир таптым, кыйммәт тә сорамыйлар. Мәдрәсәгә дә якын.

Гата. Әнвәр энем, син беркайчан да алдашмадың. Ни кушсам, җиренә житкереп үтәдең. Сине мин фатирда яшәтәмме инде?! Иртәгә үк Барданың бер матур җирендә сиңа йорт сала башлыйбыз!

Андрей. Йорт?! Безгәме, Гатаулла хәзрәт?

Гата. Әлбәттә! Иртәгә үк урманчылыкка барып, Уразбаевны күр. Йорт һәм мунча бурасыннар. Акчасын Галимулла мөәзиннән алырсың.

Андрей. Рәхмәт, Гатаулла хәзрәт.

Гата. Ләкин шуны да белеп тор, дөньялар тынычлану белән Парижга китәсең. Укырга кирәк! Укырга!

Андрей. Минем өчен иң мөһиме, яраткан кешем белән гаилә кору.

Гата. Гаилә корасыз икән, бергә китәсез! Миннән сезгә, балалар, хәер-фатиха.

Зөбәрҗәт. Миннән дә, сеңлем.

Гата. Бәхетле булыгыз, кадерләрем. Әйдәгез, шуның өчен бер дога. Әлхәмдү лиллаһи күлли хәлин фә-иннәһү мухәүүилүл-әхүәл, раббәнә әәтинә фид-дунйә хәсәнәтән үә филәәхирати хәсәнәтән үә кыйнә газәәбәнәәр. Бирахмәтикә йә әрхәмнәррахимин.

Зөбәрҗәт. Иманлы гомер кичерегез, сеңлем!

Заһидә. Рәхмәт апам. Тик әнкәйләр?!

Зөбәрҗәт. Аларга мин үзем аңлатырмын. Әнвәр энем, матур итеп яшәгез. Заһидә сеңлем шуңа бик лаек.

Андрей. Йөзегезгә кызыллык китермәбез, Зөбәрҗәт апам.

Зөбәрҗәт *(күз яшьләрен сөртә, икесен дә үбеп чыга).* Бәхетле булыгыз!

Галимулла *(керә).* Гатаулла хәзрәт, анда Иван атакай.

Гата. Керсен, әлбәттә, *(Галимулла чыга, атакай керә).* Здравствуй, дорогой Иван Генадьевич!

Поп. Ассалямагалейкум, Гатаулла дустым! Исанмысыз, кызлар! Салям, Андрей авылдаш!

Андрей *(хатын-кызлар башларын иеп исәнләшәләр).* Аллага шөкер, Иван атакай, карендәшем!

Поп. Гатаулла туган, мин кайтып киткач, килеп байлянеп йөрүчеләр табылмадымы?

Гата. Киресенчә, әле килеп чәй эчеп китегез дип, чакыручылар булды.

Поп. Болай, безнең рус халкы гади ул, кунакчыл да. Ну барыбер котыртып торучылары табыла. Халык тиз ышанучан.

Гата. Менә сез килгәнче әле, Андрей рәхмәт йөзеннән сезне бер...

Поп. Сыйламакчы булдымы?

Андрей *(якын килә дә, кочаклап үбә).* Рәхмәт сезгә!

Поп. Ты что, ты что делаешь? Неужели, мин хатын-кызга ошаган?

Андрей *(көлә).* Әйткән сүз — аткан ук, Иван атакай! *(Хатын-кызлар да рәхәтләнеп шыркылдыйлар).*

Поп. Вот ты даешь! Шундый чибәр Заһидә туташ булганда, самогон исе килеп торган Иван атакайны үпмәсиян?!

Гата. Сүз — иман, диләр бездә.

Андрей. Рәхмәт сезгә, Иван атакай. Ходай Тәгалә сәламәтлегегездән аермасын!

Поп. Рәхмәт, улым. *(Кочаклашалар).* Үзебезнеке бит! Настоящий парень! *(Күзен сөртә).* Рус малай!

Гата. Үзегезнеке дә, безнеке дә!

Поп. Иманы, намусы булган кеше ярдәм итәргә тиеш! Шуңа күрәдер инде, мин үземне рус халкым арасында да, татарларым арасында да бәхитле хис итәм.

Гата. Мәңге шулай булсын! Тагын бер шатлыгыбыз бар бит әле, Иван дустым! Андрей белән Заһидә кавышырга вәгъдә бирделәр.

Поп. Боже мой! Нинди шатлык, искиткеч хабар бит бу! Маман Наталья, җан кисәгем, исән булса, шатлыгыннан биер иде. Бахытлы булыгыз, детки мои. Туйга чакырырсыз, Варвара түтиегезне ияртеп точно киләм. Бу хабарны ул да белсәме, шатлыгыннан үрле-кырлы сикерячак.

Гата. Урын иң түрдән булачак!

Поп. Шап булачак! Туктале, тукта, оят булса да сорыйм әле. А то, теге вакытта... Синең хәзер суннатың бармы соң?

Андрей. Иван атакай, сез мине уңайсыз хәлгә куясыз!

Гата. Барысы да тәртиптә, Иван дустым. Яшьләрне оялтасыз бит. Ярый, кызлар, барыгыз ашханәгә төшә торыгыз, тиздән без дә күренербез.

Зөбәрҗәт. Яхшы, Гатаулла хәзрәт. *(Китәләр).*

Поп. Син әле нишләп авызыңны салындырдың?

Андрей. Сез мине Заһидә туташ алдында оятка калдырдыгыз.

Поп. Шаярттым гына бит, Андрей улым. Заһидә сеңлем дә акыллы, юк-барга үпкәләмәс.

Андрей. Күрсәтимме соң сөннәтле галәмәтемне?! *(Көлә).*

Поп. Юк, кирәкмәс, ышанам!

Гата. Иван атакай, сине Андрей үз итә. Әйдәгез, дусларым, төшеп тәмле коймак белән чәй эчик әле.

Поп. Ты, Андрей сынок, не волнуйся! Я тебя как родного люблю. На свадьбе, Алла боерса, мы с женой тетей Варварой со стороны твоих родителей будем. Только миңа, Гатаулла туган, берәр кеше күрмәс җиргә самогон әзерләп куй. Хәтта Варвара жена да күрерлек булмасын. Өйдә колак ите ашаган да бик житкян!

Гата. Самогоның әйтә алмыйм. Әмма дә ләкин, сезгә дигән, затлы француз коньягы саклана!

Поп. Рахмат сезгә, чукынган Тутай оныгын үз иткән өчен, большое спасибо. Яратам мин сезнең икегезне дә.

Гата. Мин дә, Иван, сине үз туганымдай якын итәм.

Андрей. Мин дә, Иван атакай.

Поп *(килеп һәрберсен кочып чыга).* Рахмат бик зур, рахмат сезгә.

Гата. Иван туган, килгәндә йөзегез бик борчулы иде. Берәр хәл булмагандыр ич?

Поп. Сизгәнсең икән, Гатаулла! Хатын-кызлар янында не хотел об этом! Тревожные вести идут от Петрограда. Минем побым кочкә әйләнеп кайтты. Керенскийны Кышкы сарайдан бәреп төшергәннәр. Чуалышлар хәзер Россиянең үзгенә тарала башлаган, ди.

Гата. Шулайрак буласын сиземләгән идем мин аның. Бер кирәкмәгән сугышлар, патша даирәләренең болай да бөлгенлеккә төшкән,

ачлы-туклы халык җилкәсендә типтереп яшәүләре шушы хәлгә китереп житкерде дә!

Поп. Ул гына түгел, Гатаулла туган. Кайбер төбәкләрдә, халык күтәрелешеп, бояр-алпавытларның мал-мулкатләрен талап, үзләрен кыйнап үтерә башлаганнар. Хатын-кызларны кучләү очраклары да бар, ди.

Гата. Фетнәнең иң куркыныч ягы шушы инде аның. Бирегә укытырга дип килүче француз мөгаллимнәре дә юкка чыкты бит.

Поп. Димәк, каядыр шушы ташкынга эләккән алар, Андрей улым, после женитьбы тебе надо уехать за границу. С такой головой тебе не место здесь.

Гата. Дөрес әйтәсез, Иван атакай. Аннан Коля да юнкерлар мәктәбен тәмамлап кайтырга тиеш иде. Чуалышлар тоткарлагандыр аны да!

Поп. Гатаулла, озат син аны чит илгә. Хотя бы они по человечески жили. Кеше булсын, дальше укысын! Акча мәсьәләсендә по возможности и сам помогу.

Гата. Рәхмәт, атакай! Изге Иван туган!

Поп. Минме изге?! Эчәм, гулять итәм! Одни грехи! Одни грехи! Ну барыбер рахмат, Гатаулла!

Гата. Сез бик мәрхәмәтле, ярдәмчел кеше.

Поп. Син ул изге кеше, Гатаулла. Йөзләгән ятимнәрне укыттың, аякка бастырдың. Халемнән килсә, синең сурәтенне чиркәүнең түренә, изгеляр рәтенә элдерер идем мин.

Гата *(көлә)*. Мин аның хәтлесенә лаек түгел әле, Иван Генадьевич! *(Ишек шакыйлар, Заһидә керә).*

Заһидә. Гатаулла жизни, Иван атакай, Андрей әфәнде, апай сезне кичке ашка чакырды. Рәхим итегез.

Гата. Рәхмәт, Заһидә. Хәзер төшәбез! Әйдәгез, хөрмәтлем Иван Генадьевич!

Поп. Как там татары говорять: «Аштан большой булмас» что ли.

Гата. Аштан олы булып булмас!

Поп. Шап айтылган. С удовольствием!

*Гата белән Иван чыгалар. Андрей ашыкмый.*

Заһидә. Сез нишләп төшмисез, Андрей әфәнде?

Андрей. Заһидә, сез диеп, зинһар, читләтмәгез мине!

Заһидә. Миңа унайсыз бит, Андрей әфәнде!

Андрей. Алайса, Әнвәр генә диегез!

Заһидә. Яхшы, Әнвәр әфәнде! Әйдәгез, өлкәннәр янына төшик, әллә ни уйламасыннар.

Андрей. Уйламаслар. Алар безне шуның хәтле үз итәләр. Хәтта Иван атакай да.

Заһидә. Шундый кызык кеше ул! *(Көлеп җибәрә, аңа Андрей да кушыла).*

Андрей. Искитмәле кеше! Өйләнешкәч, чит илгә китегез, акчалата үзем дә булышырмын, ди.

Заһидә. Куркам мин әллә кая китәргә. Телләрен дә белмим.

Андрей. Үзем өйрәтермен, Заһидәкәй.

Заһидә. Заһидәкәй! Ничек матур итеп әйттегез!

Андрей. Мин аны тагын да затлырак итеп әйтә алам.

Заһидә. Анысы ничек була инде?

Андрей. За-һи-дә-кә-ем!

Заһидә. Сез мине чын күңелдән яратасызмы соң, Әнвәр... әфәнде?

Андрей. Беренче күрүдә үк, үзем дә аңлап бетермәслек тойгылар кичердем. Көндезләрен уйларымда да сез, кич ятсам төшләремдә дә сез, Заһидәкәем!

Заһидә. Сәер. Сез дә бит минем төшләремә керәсез.

Андрей. Чынлапмы Заһидәм?!

Заһидә. Әйе! *(Куллары белән йөзен каплый).*

Андрей *(килә, кочып ала)*. Син минем мәңгелек ярым, мәңге-

лек мәхәббәтем, чын, саф беренче мәхәббәтем! *(Үбәргә үрелә).*

Заһидә. Юк, кирәкми! Мин оялам! *(Йөгереп чыгып китә).*

Андрей. Заһидәм! Мин шундый бәхетле бүген! Коля гына каядыр йөри, хәзер ул, кече офицер булгандыр инде. Их, аның белән дә бер күрешәсе, шатлыкларны уртаклашасы иде.

*Музыка.*

## II ПӘРДӘ

### V күренеш

*Гатаулла хәзрәт йорты. Каты итеп ишекне шакыйлар. Йокы бүлмәсеннән хәзрәт чыга.*

Гата. Галимулла, Галимулла дим. Кем икән ул анда?

Галимулла *(керә).* Ишекне ачарга да куркам инде. Көндез каччаннары туйдырып бетерде, инде төнлә дә шакый башладылар.

Гата. Сора әле, кем икән?

Галимулла. Әй, кем ул анда? Ярты төн уртасында йөрмәсәң!

Фәттах тавышы. Мин әле бу, Фәттах мулла! Гатаулла хәзрәтне күрәсе иде.

Гата. Фәттах ишан ахры бу!

Галимулла. Нишләтим?

Гата. Төн уртасында урамда тотмабыз бит! Мин хәзер өстемә генә элэм!

Галимулла. Яхшы, хәзрәт. *(Китә).*

Гата *(кәнәфидән чапанын кия, түбәтәен элә).* Төн уртасында Фәттах ишанның ишек дөбердәтүе юкка түгел! Яхшыга гына була күрсен инде. Әнә бит көне-төне пушкадан аталар.

Галимулла *(керә, аңа йончылган Фәттах ияргән).* Керегез, кер!

Фәттах. Ахырзаман бу, ахырзаман, Гатаулла хәзрәт.

Гата. Ни булды, Фәттах туган?

Фәттах. Булмаган кая, Гатаулла жаным! Эшче-крестьян гаскәрләре дигән башкисәрләр килеп бистәбезне, безнең кибет-лавкаларыбызны таладылар. 7 атыбызны тартып алдылар. Каршы төшеп караган идем, үземне типкәләп ыргыттылар. Олы кызым Гажиләмне исерек солдатлар бик аздан гына харап итмәделәр. Ярый әле араларында миндә шәкерт булган Гарафетдин килеп чыгып коткарды. Безгә ат биреп качып китәргә дә ул булышты. Тәмуг анда, тәмуг. *(Елый).*

Гата. Тынычланыгыз, Фәттах туган, иң мөһиме исән-сау котыла алгансыз.

Фәттах. Гомер буе жыйган мал-мөлкәтне ике-өч сәгать эчендә юкка чыгардылар. Беттек без, беттек. *(Елый).*

Гата. Башың исән булсын, мал табыла ул!

Фәттах. Анысы шулай инде, Аллага шөкер, үзебез өстебездә нәрсәбез бар, шул килеш көчкә ычкындык. Ни галәмәт бу, Гатаулла хәзрәт?

Гата. Рәсәйнең гасырлар буе жыйган имансызлыгы менә кайчан тишелеп чыкты.

Фәттах. Качарга кирәк, качарга. Тайгага, Себергә, хәтта Кытайга. Бик куркыныч афәт килә! *(Пушкалар тавышы).* Әнә, ишетәсезме? Бүген-иртәгә бире дә булачаклар. Беттек без, беттек! Йә ачтан кырылабыз, йә алар тотып үтерәчәкләр.

Гата. Кытайга хәтле качып китеп булмас. Мин шәкертләремне дә ташлый алмыйм. Болай итәргә кирәк. Сез, Фәтхулла хәзрәт, минем туган авылым Солтанайга китә торыгыз.

Фәттах. Анда килеп җитмәсләр дисезме?

Гата. Беренчедән, олы юлдан шактый читтә ул. Әлегә шунда әткәй-әнкәй нигезендә торырсыз. Азык-төлекне Галимулла мәзин кибеттән яздырып бирер. Калган мал-мөлкәтне дә, этләргә талатканчы, мохтаҗларга өләшеп бетерербез. Ходай Тәгалә ташламас, мал табыла ул.

Фәттах. Ташлый гына күрмәсен, Гатаулла хәзрәт. Югыйсә, эшләр коточкыч. Эшләр харап!

Гата. Һәрбер эшнең иртәмесонмы ахыры була. Озакка гына сузылмасын иде. Галимулла хәзрәт! *(Галимулла керә).*

Галимулла. Әйе, хәзрәт.

Гата. Хәзер үк складтан Фәттахулла хәзрәт гаиләсенә ике капчык он, ике капчык шикәр, 10 кап чәй, 5 кило тоз, 10 литр сыек май, 5 кило казылык, өч капчык ярма бир. Солтанайга әткәй-әнкәй йортына илтеп урнаштырсыннар. Ачкычы күрше Хәерниса апайларда. Бусы шулай. Керосин да җитәрлек бир.

Галимулла. Яхшы, Гатаулла хәзрәт.

Гата. Аннан үзенә дә онын, шикәрен, чәй-маен — барсын да ал. Начар көннәр килсә, запасың булыр.

Галимулла. Алланың рәхмәте яусын, Гатаулла туганым. Йөзе, меңе белән кире кайтарсын.

Гата. Амин шулай булсын. Тагын шуны да үтә: унике балалы Низаметдин абыйларга, сугыштан имгәнеп кайткан Миңлеәхәт солдатка, Таһирга, Мөнәҗиргә, багучыөшкерүче Бибиәсма әбигә бүген үк, хәзер үк ризык өләш. Кием-салым бир. *(Пушка аткан тавышлар).*

Галимулла. Әстәгъфирулла!

Гата. Кибет-складларга бар малны таратып бетерергә вазыйм. Тагын бер тапкыр исемлекне үзең барла!

Галимулла. Теге бурлак Хәтмулла картка да бирсәк?

Гата. Мохтаҗларның барысына да өлеш чыгар. Калганы синең намуста. *(Читкәрәк алып китә).* Аннан калган мал-мөлкәтне, чүпрәк-чапрак тукымаларны бүген таң атканчы Байгыш урманына малайларың белән умарталык тирәсенә илтеп күм. Бер генә чит кеше дә белергә тиеш түгел.

Галимулла. Аңладым, хәзрәт.

Гата. Аллага тапшырдык, җәмәгать.

Галимулла. Әйдәгез, Фәттах ишан, кузгалыйк.

Фәттах. Дөнья хәлен белеп булмый, бәхил булыгыз, Гатаулла хәзрәт.

Гата. Әле без яшәячәкбез, җиң сызганып шәкертләребезгә белем дә бирәчәкбез, Фәттах туган.

Фәттах. Йә, Ходаем, үзең генә саклый күр инде безнең газиз башларны. *(Китәләр).*

Андрей *(атылып керә).* Гатаулла хәзрәт, французлар табылды. Куедада качып ятканнар.

Гата. Хәзер кая соң алар?

Андрей. Сезгә керергә көтеп торалар.

Гата. Керсеннәр! Әнвәр энем, Зөбәрҗәт апаң белән Заһидәне дә уят, инде бу тавышка үзләре үк тормаган булсалар. Тиз генә аш-су әзерләсеннәр.

Андрей. Баш өсте, Гатаулла абый. *(Китә).*

Гата. Башның өсте аска да килергә мөмкин әле монда. *(Французлар керә, начар киемнәрдән).*

I француз. Кэс ки се пас иси?! У сом ну? Сетэң врэ анфэр!

Что здесь твориться?! Что! Куда мы попали? Это же сущий ад!

Гата. Экскюзе муа силь ву пле! Се таривэ ком са. Бонжур ме шэр коллег. Извините, пожалуйста! Так получилось. Здравствуйте, мои дорогие коллеги.

II француз. Бонжур. Ву заве пробаблман Гатаулла хазрат Бикташев, нес па? Здравствуйте. Вы, наверное, Гатаулла хазрат Бикташев, да?

Гата. Се врэ.

Правильно думаете.

I француз. Жорж Симони.

Гата. Аншанте.

Очень приятно.

II француз. Жан Франсуа!

Гата. Аншантэ! Ву зэт пробаллман фатиге сюр ля рут.

Очень приятно! С дороги вы, наверное, очень устали.

I француз. Ну сом фатиге! Он ну за эте воле дан зэн трэн. А ля стасьйн Чернушка а пэнь кл ле сертэн руж ну зэ тюе ком ле зеспилн франсэ. Пюи эн серэн пэйзан авэк эн шеф дө клян ну за при дан сө кон напэль виляж Куюду а мон ави.

Устали! Нас в поезде ограбили. На станции Чернушка красные какие-то чуть не расстреляли как французских шпионов. Потом какой-то крестьянин с атаманом повез нас в Куюду, так по-моему называется.

II француз. Лю нюи кан ну сом арете пур дормир дан лл фуэн иль а при ту но вэтман э а кяше дан ля форэ ну лессан прэскө ню.

Ночью, когда остановились спать на сене, забрал всю нашу одежду и скрылся в лесу, оставив нас почти голыми.

I француз. Пюи ну заривам анфэн а ля виляж Усы. Ля, ле резидан ну зон эде ком иль пувэ.

Потом добрались до деревни Усы. Там местные жители чем могли, помогли.

II француз. Си ну завон сю куа ну затандрө, ну нө сөрон па эн па ор дө Франс.

Если бы знали, что нас ждет, ни шагу бы из Франции.

Гата. Жл мэкскюз опрэ дө ву пур ту во суфранс. Маллразман лл терорисм кон напэль ля рэволюсьлн а комансе дан нотр пэи.

Перед вами за все ваши страдания извиняюсь. К сожалению, в стране начался террор, которого называют революцией.

I француз. Жө сюи дезоле, ну пө пувон плю ресте иси.

Извините, мы не можем больше здесь оставаться.

II француз. Это ты виноват, Жорж! Вот тебе романтика! Вот тебе бескрайние просторы!

I француз. У жө савэ, кэс ки се пас иси?!

Откуда я знал, что здесь творить-ся?!

II француз *(пушкалар, мылтыклар ата)* Ля катастроф! Иль ну фо ну совэ ан куран!

Нам уехать надо, месьл, пока живы, здоровы. *(Пушкалар, мылтыклар ата).* Вот видите, убьют нас, без всякой проверки! Какое здесь обучение детей! Катастрофа! Бежать надо, бежать!

Гата. Нө ву зэнкиете па, жө вэ ву зедэ кө жө пө. Жө вэ курир тут во депанс. Жө вэ ву зедэ дө рантрэ а ля мэзон.

Не волнуйтесь, я вам помогу, чем смогу. Все ваши расходы прикрою. Өегезгә кайтып китәргә булышачакмын.

I француз. Уи, уи, уи! А ля мэзон, иль ну фо рантрэ а ля мэзон.

Да, да, да! Домой нам надо.

II француз. Силь пу пле, ну рэтурнэ!

Пожалуйста, верните нас!

I француз. Э ву, Гатаулла хазрат, ву завэ оси безуэн дэшапэ. Иле трэ данжерө дө рэстэ иси.

Вам, Гатаулла хазрат, тоже надо убежать. Здесь оставаться очень опасно.

Гатаулла. Жө вудрэ партир авэк ву авэк плезир. Жө рөвэррэ ля бэль арщитэктюр паризьен, ле бэль фам паризъен, ле марше авэк ле мэрвэй дю монд!

Я бы с удовольствием уехал бы с вами. Еще раз увидел бы красивую Парижскую архитектуру, прекрасных парижанок, базары чудесами со всего света!

II француз. Дө куа эстиль ля кэстьлн? Ву парле парфэтөман лл франсе!

Тогда в чем вопрос? У вас с французским языком прекрасно! Поехали.

Гата. Жө сюи нэ иси, мжэ гран-

ди иси э ма мор сөтрув аңкор иси.

Не могу я бросить своих татар, учеников. Здесь у меня Родина! Здесь и похоронят. Монда тудым, монда үстем, мондадыр минем әҗәл.

I француз. *(Ату тавышлары ишетелә).* Иль соң дэжа прош!

Когда все утихомириться, обратно бы вернулись. *(Ату тавышлары ишетелә).* Они уже рядом!

II француз. Иль фо кяше!

Спрятаться надо!

Гата. Жантаң. Мэ жө нө пө па дө манфюир. Жө круа аңкор аң бонтэ э сажесс де жаң. Иль я боку дө жаң коңпэтаң парми ле большевик ком Ленин, Плеханов.

Слышу. Но убежать не смогу. Все равно я еще на мудрость, на доброту людей верю. Среди большевиков грамотных людей много, Ленин, Плеханов.

I француз. Пуркуа донк оң мэ та сак, оң фрап э оң масскрө?

Почему тогда грабят, бьют, убивают?

Гата. Иси илья ле масс попюлер эңконтролябл... Сө соң ө ки фэ дэбридөмаң.

Здесь что-то не управляемые массы... Вот они и беспредельничают. *(Ату тавышлары якыная).*

Андрей *(Заһидә белән керәләр).* Гатаулла хәзрәт, большевиклар гаскәре Бардага бәреп кергәннәр! Нишлибез?

Заһидә (йөкле икәнлеге сизелә). Жизни абый, нәрсә соң бу?!

Гата. Андрей, сез әле яшь! Менә французлар белән Парижга качыгыз! Дөньялар рәткә кергәч, үзем хәбәр итәрмен.

Андрей. Шундый чакта сезне калдырып ничек китим?!

Гата. Туасы балагыз хакына. *(Мылтык аталар, кешеләр сүгенешә).*

Заһидә. Йә Ходаем, кыямәт көнедер бу!

Галимулла *(керә).* Анда кызыллар! Хәсәнбай йорты дөрләп яна! Тиздән биредә булачаклар!

Гата. Галимулла, хәзер үк пар ат җигеп, кунакларны, Әнвәр белән Заһидәне урманга качыр. Җай чыгу белән чит илгә китәрләр!

Галимулла. Ничек озатыйм, Гатаулла хәзрәт, урам тулы качаклар?

Гата *(барып шкафтан револьвер ала).* Әйдәгез, үзем дә озатышам, җыеныгыз.

I француз. Аллн, аллн!

Идем, идем! *(Шулчак мылтык аткан тавышлар астында, чатанлап Коля килеп керә. Хәрби киемнән).*

Коля. Гатаулла хәзрәт, мине яраладылар! Мине... Андрей... *(Егыла).*

Андрей. Камил дустым! *(Коляга иелә).* Ул аңын югалткан!

Гата. Жө ву заң при! Вөнэ зиси!

Сез, зинһар, әнә теге бүлмәгә кереп торыгыз. Пожалуйста! Вот сюда!

II француз. Кэль өрөр! Аллн Жан Франсуа

Ужас. Пойдем, Жан Франсуа.

Гата. Вөнэ зиси. Экскюзэ ну силь ву пле!

Вот сюда. Простите нас! *(Французлар бүлмәгә кереп китәләр).*

Андрей. Коля, дустым минем, бу мин Әнвәр, Андрей.

Гата. Тиз бул, Зөбәрҗәт абыстаеңны чакыр!

Заһидә. Үзем, Гатаулла жизни! *(Йөгерә).*

Андрей. Ярасын бәйлисе иде!

Гата. Сулышы бармы?

Андрей. Әйе.

Гата. Әйдә, култыклап йокы бүлмәсенә кертеп салыйк әле. *(Икәүләп күтәрәләр, Коля ыңгыраша-ыңгыраша көчкә атлый).* Хәзер, хәзер, Коля улым, яраңны да бәйләрбез. *(Кереп китәләр).*

Зөбәрҗәт *(комган белән ләгән тоткан, җилкәсендә сөлге).* Әй, Алла, әй Алла, Коля бәбкәчем, бала гына бит әле син. Нәрсәгә кирәк булды инде сина хәрби булу?! *(Кереп китә. Атышлар якында гына. Шомлы музыка башлана. Кемнәрдер акырыша. Сүгенү тавышлары).*

Андрей *(чыга, артыннан Зөбәрҗәт күренә).* Утны кысыйк, бирегә бәреп кермәсеннәр. *(Лампаны кыса да, тәрәзә янына килә. Шул ак мылтык атыла, тәрәзә пыялалары коела).*

Зөбәрҗәт. Кит аннан тәрәзә төбеннән!

Гата *(башын тыгып).* Андрей, шкафтан коньякны алып кер әле, эчсә, авыртуы бераз басылмасмы?!

Андрей. Хәзер. *(Барып шешәне ала да, Гата хәзрәткә бирә).*

Гата. Ярасын бәйләдем. Аньна килде. Мин хәзер. *(Кереп китә).*

Андрей *(сак кына тәрәзә почмагыннан күзәтә).* Аста нindидер хәрбиләр йөгерешә.

Зөбәрҗәт. Кит аннан, кит. Торма тәрәзә төбендә.

Тавыш. Каядыр шушы тирәгә кереп качты. Мин ул падланы барыбер табам! Беләм мин аның оясын!

Заһидә *(коты очып килеп керә).* Әнвәр жаным, нишлибез?!

Андрей. Курыкма, жаным, курыкма, мин синең янында бит! *(Кочып ала).*

*Музыка. Ут сүнеп ала, кабына.*

***

Тавыш *(дорфа итеп ишек шакыйлар, тибәләр).* Ачыгыз, югыйсә, ватып керәбез, ачыгыз буржуа!

Заһидә. Әнвәр бәгърем!

Андрей. Борчылма, жанкисәгем, тынычлан, сина борчылырга ярамый!

Тавыш *(тагын да ныграк тибәләр).* Ачыгыз, Гатаулла хәзрәт, ачыгыз, югыйсә, жимереп керәбез! Открывайте!

Гата *(чыга).* Кемнәр анда?

Андрей. Белмим. Ишеккә тибәләр.

Гата *(кычкыра).* Барыбер жимереп керәчәкләр, Галимулла, ач ишекне!

Гриша тавышы. Кая яшердегез, мин ул ублюдокны барыбер табам! Где он?

Хәрби тавышы. Өскә меник! Син Танбаев бирелә кал!

Гриша. *(Килеп керә).* Кая ул? О кого я вижу! Андрей земляк та монда икән! Нинди очрашу, ә нинди очрашу. Кара әле ничек фраерларча киенгән. Алкаш Андриан малае дип һич белмәссен! Смотри-ка!

Андрей. Син минем туганнарыма тел тидермә! *(Каршы атлап куя).*

Хәрби *(наган белән яный).* Ну, ну, ну! Стоять! Син әтәчләнмә! Анладынмы? Гафу итегез, Гатаулла хәзрәт!

Гриша. Алар бит мине.

Хәрби. Отставить, красноармеец Григорий Мегайлов! Безгә, Гатаулла хәзрәт, самодержавие калдыгы юнкер Николай Варламов кына кирәк! Без аның яралы килеш сездә качып ятканын беләбез!

Гата. Беләсез?!

Хәрби. Гатаулла хәзрәт, мин сезне кеше буларак бик хөрмәт итәм! Әле сезнен мәдрәсәдә ике ел белем алган шәкерт тә мин.

Гата. Таныдым. Исхак байның келәтенә ут төртеп төрмәгә эләктен.

Хәрби. Дөрес, Гатаулла агай. Әтиемне кол урынына эшләтеп, бер тиен дә бирмичә өеннән куып чыгарган кравосос ул.

Гата. Син Канбаев акыллы гына малай иден, әйбәт тә укыдын.

Хәрби. Булды андый хәл. Ләкин мин буржуйларга, халык жилкәсендә типтереп яшәүчеләргә нәфрәт белән үстем. Әткәй белән әнкәй көне-төне бил бөксәләр дә, ат алырга гына да хәлләреннән килмәде. Хәзер ул империализм калдыкларыннан үч алырга вакыт житте. Кая ул буржуйларның ялчысы Николай Варламов?

Гата. Әшир углан! Ул нык яралы. Кагылмагыз ана, терелсен! Ходай Тәгаләдән куркыгыз!

Гриша. Юк ул синен Тәгалән! Сказка это все!

Хәрби. Гриша, теленә салынма, бүлмәләрне тикшер!

Гриша. Хәзер без аны буржуа ялчысын табабыз. Никуда не денет-

ся! *(Французлар бүлмәсенә кереп китә).* А ну-ка кто такие, на выход! Давай, давай!

I француз. Господин военный, мы французы, учителя из Парижа!

Хәрби. Нәрсә ди ул?

Гата. Алар безнең балаларга белем бирергә килгән француз укытучылары, кагылмагыз аларга, болай да котлары очкан.

Хәрби. Шундый вакытта буталып йөрмәсәләр.

II француз. Мы домой хотим, господин офицер.

Гата. Без өйгә кайтырга телибез диләр.

Хәрби. Килгәнче кайту турында ныграк уйларга иде сезгә.

Гата. Аларның ниятләре изгелектә иде. Нишлисең, уңайсызрак чакка туры килделәр.

Хәрби. Разберемься. Штабта кемнәр икәнлеген ачыкларбыз да.

Гата. Әшир улым, бер гаепсез кешеләрне, безнең илнең кунакларын, зинһар, рәнҗетмәгез!

Хәрби. Гатаулла абый, менә сез яралы дошманны качырып ятасыз. Ул беләсезме ничә кызыл армеецның башына житте? Инде хәзер сезнең сүзегезгә ничек ышанып йөрим. Бәлкем алар хәрби советниклар, шпионнардыр?!

Гата. Нинди шпионнар булсын алар!

Хәрби. Ачыкларбыз. Гриша теге бүлмәне дә тикшер. Тик сак бул, коралы булып зыян салмасын!

Гриша. Яхшы, иптәш комиссар. *(Ишеккә атлый. Андрей каршысына чыга).*

Андрей. Кагылма, ублюдок, югыйсә...

Заһидә. Андрей, кит, жаным!

Андрей. Мин сезгә яралы кешене алып китәргә ирек бирмәм!

Хәрби. Әй син, башың ике түгелдер ич! Яхшы чакты югал! Югыйсә, революция дошманы диеп...

Андрей. Сез бит адәм балалары. Нигә кирәк тагын бер ерткычлык?!

Гриша. Товарищ командир, можно я этого предателя шлепну. Расчитаюсь с ним!

Хәрби. Ашыкма! Кагыл, юләрләнмә!

Заһидә. Әнвәр дим. Жанкисәгем, кит аннан. *(Барып кочып ала).*

Хәрби. Гатаулла хәзрәт, бәлкем сезне тыңлар.

Гата. Әнвәр, кагылыгыз, сезгә әле яшәргә кирәк. Тыңла мине!

Андрей. Ул минем авылдашым, дустым!

Хәрби. Гриша! *(Ымлый).*

Гриша. Обоих что ли?

Хәрби. Юл бирмәсәләр, икесен дә!

Гата. Акылыңа кил, Әшир энекәш. *(Ишек ачылып китә. Коля көчкә чыга).*

Коля. Менә ул мин!

Гриша. Эләктеңме, гад?! Мин сиңа әйттем бит, убью когда-нибудь диеп.

Коля. Син бит хатын-кызларны, бала-чагаларны гына талый аласың! Иртәме-соңмы большевиклар үзләре үк сине йә атып үтерәчәк, йә төрмәгә утыртачаклар!

Гриша. Сиңа ул төрмә, сине үтерәчәкләр. Подлюга.

Коля. Кулың шакшы синең, үзең куркак!

Гриша. Ох ты, халуй буржуйский! *(Килә дә приклад белән эченә суга).* На получай!

Гата. Туктатыгыз бу хәлне!

Хәрби. Сез, Николай Варламов, эшче-крестьян гаскәрләренә каршы сугышканыгыз өчен кулга алынасыз. Хәрби трибунал сезгә решение чыгарачак.

Коля. Төкерәм мин сезнең партиягезгә. Төкерәм трибуналыгызга! *(Андрей ярдәме белән аягына баса. Бер урындыкны эләктереп ала да, Гришага таба атлый).* Төкерәм мин сиңа!

Гриша. Ах, подлец, ты еще так! *(Артка чигенә дә, атып жибәрә).* На получай, предатель!

Хәрби. Син нишлисең, дивана баш?! Үтердең бит!

Гриша. Шул кирәк аңа, буржуа калдыгына!

Андрей. Кабахәт!

Гриша. Якын килмә, сине дә үтерәм! Барыгызны да!

Заһидә. Зөбәрҗәт апам, аны үтерделәр бит.

Зөбәрҗәт. Коля, балакаем минем!

Гата *(иелә)*. Улым, Коля! Улым!

Коля *(күзләрен ача)*. Гатаулла... Гатаулла хәзрәт! Мине... үзең... дога белән җирлә! Андрей, Зөбәрҗәт апам, мин сезне яратам... *(Үлә)*.

Зөбәрҗәт. Балакаем минем!

Заһидә. Вәхшиләр, тәмуг ияләре! Ни өчен, ни өчен?!

Хәрби. Их, дубина, дубина, ул бит миңа тере килеш кирәк иде.

I француз. Ля Сент Мари, эдэ ну дө ну зашапэ диси!

Светая Мария, помоги нам от этого вырваться!

II француз. Гатаулла хазрат, кэски сө пасөра авэк ну?

Гатаулла хазрат, что с нами будет?

Гата. Французларга кагылмагыз! Аларның берсендә дә гаепләре юк!

Хәрби. Менә анысын ачыкларга кирәк әле, Гатаулла хәзрәт. Зинһар, минем белән тычканлы-мәчеле уйнамагыз!

Гата. Галимулла!

Галимулла Әйе.

Гата. Кәфенлекләр әзерләгез! Аңлавымча, сез мине алып китәргә телисез?

Хәрби. Бик дөрес уйлыйсыз, Гатаулла абый!

Андрей. Ни өчен аны алып китәсез?

Хәрби. Хәрби җинаятьчене качырып яткырганы өчен!

Зөбәрҗәт. Калдырыгыз, калдырыгыз аны! Ул бит аның шәкерте иде!

Хәрби. Ул гына да түгел! Сез бездән яшереп, Байгыш урманына мал-мөлкәтегезне күмгәнсез икән.

Гата. Байгыш урманында?

Хәрби. Туган авылың Солтанайга кемне озаттың! Аннан безне этләр диеп атагансың!

Гата. Солтанайга?! Этләр диеп?! *(Күзләре белән Галимулланы эзләп таба. Теге артка чигенә-чигенә барып, креслога килеп утыра)*.

Галимулла. Мин... Мин бит...

Гата. Синмени инде ул минем белән бер савыттан ашаган бәндә?!

Галимулла. Алар бит завод-фабрикаларны эшчегә, җирләрне крестьяннарга бүлеп бирәбез, дөньяда җәннәт төзиячәкбез, диләр.

Гата. Мин бит сине үз туганымдай күреп, өемдә асрадым, бәдбәхет!

Галимулла. Алары өчен рәхмәт, рәхмәт, хәзрәт. Үзегез әйтә торган идегез бит: «Бу илдәге комсыз, карун байлар, түрәләр халыкка өлеш чыгара белсәләр, бик күпкә бәхетлерәк яшәр идек без» дия иден. Дөрес түгелме?

Гата. Синең кебек доносчылар, вак җанлы бәндәләр күп булганда, азгын кешеләр кимемәячәк бу илдә. Шушы револьвер белән атып кына үтерер идем дә, кулымны пычратасым килми. *(Тери)*.

Хәрби. Туктагыз, Гатаулла хәзрәт! Пычратмагыз кулыгызны. Сез бит халык өчен изге кеше!

Гата. Чөнки мин халкымны яраттым. *(Револьверны хәрбигә суза)*. Алар да мине үз иттеләр. Мин аларга тугры калачакмын, Әшир малае.

Хәрби. Менә монсын дөрес эшлисен, Гатаулла абый!

Гата. Николай угланның рухына бер дога кылыйм да...

Хәрби. Яхшы, Гатаулла хәзрәт.

Гата *(тезләнә, укый)*. Бисмиллаһир рахманир рахим! Зөбәрҗәт, елама, иң яхшысы, балаларга күз-колак бул!

Зөбәрҗәт. Гатаулла, җибәрмим! Җибәрмим беркая да! *(Кочаклашалар)*.

Гата. Ходай Тәгалә ташламаса, бәлкем әле барысы да җайланыр!

Зөбәрҗәт. Гатаулла!

Заһидә. Калдырыгыз аны!

Гата. Без ничек бәхетле яшәгәнбез икән... Әнвәр, Заһидә сенлем, китегез сез бу илдән. Синең белем алуга булган тырышлыгың, талантың юкка чыгарга тиеш түгел!

Андрей. Сезне ташлап шундый чакта, мөгаллимем, ничек китим? *(Кочаклашалар).*

Заһидә. Апаем, җанкисәгем! Шулай итеп без ятим калабызмыни?!

Зөбәрҗәт. Йә, Ходаем, ярдәменнән ташлама. Гатаулла бәгъремә озын гомер, исәнлек-саулык бир! Без гел хәер-фатихада торырбыз.

Гата. Бәхил булыгыз!

Хәрби. Сез, Франциядән килгән бәндәләр! Әгәр дә гаебегез булмаса, илегезгә әйләнеп кайта алырсыз. Тиздән бөтен дөньяда революция уты кабыначак. Сезнең изелгән халкыгыз да буржуазиягезне океанга илтеп батырачак.

I француз. Ну навоң па бэзуэң дө тэль бонөр!

Не надо нам такое счастье!

Хәрби. Куркасызмы?

II француз. Ллроп нө пурра андюрэ сөт барбари. Сэтэн врэ анфэр!

Мондый вәхшилекне Европа күтәрә алмаячак. Тәмуг бит бу!

Хәрби. Халык җилкәсен кимереп яшәгәннәргә, әлбәттә, тәмуг. В.И.Ленин күрсәткән якты идеаллар өчен көрәштә, мин үземнең гомеремне дә кызганмаячакмын!

Гата. Ышанам. Сез көчле шәхес! Тик сезнең кебекләр дә вәхшигә әйләнсә?!

Хәрби. Бу мәсьәләдә сез хаклы, хәзрәт. Шактый гына хаталар җибәрелде. Ләкин без барыбер хокуклы, якты дәүләт төзиячәкбез. Моңа иманым камил. Тик көрәш корбаннарсыз булмый. Хуш иттек!

Гриша. Әйдәгез, Гатаулла хазрәт! Сез дә буржуа калдыклары!

I француз. Лессэ партир!

Җибәрегез безне! Отпустите нас.

Хәрби. Борчылмагыз, мөгаллимнәр икәнсез, җибәрербез.

II француз. Ну сом аң нэфэ ле прфэссөр!

Без чыннан да мөгаллимнәр!

Хәрби. Разберемся! Атлагыз!

Гриша. Теге предательне дә алабызмы?

Хәрби. Кушканны гына үтә син.

Гриша. Есть. Әйдәгез, әйдә. *(Андрейга)* А тебя я все равно достану. *(Китәләр).*

Зөбәрҗәт *(елый).* Гатаулла җанкисәгем!

Заһидә. Җизни абый! *(Елый).*

Андрей. Галимулла мөәзин!

Галимулла. Менә бит ничек, әй! Алып киттеләр бит, әй!

Андрей. Хәзер үк изге Гатаулла өеннән чыгып китүегезне сорыйм!

Галимулла. Мин бит бөтен гомеремне... халкыма хезмәткә бирдем. Сез кем соң?!

Зөбәрҗәт. Ул минем якын туганым, энем!

Галимулла. Зөбәрҗәт ханым, мин дә бит...

Зөбәрҗәт. Сау булыгыз! Сез саф кешене саттыгыз!

Галимулла. Ул булса, мине кичерер иде!

Андрей. Ул, бәлкем, кичерер иде. Тик без сезне гафу итә алмыйбыз!

Галимулла. Сез, ул түгел шул! Хушыгыз! *(Китә).*

Заһидә. Апам җаным, без сине беркайчан да ташламабыз! Җизни дә, менә күрерсең, исән-сау әйләнеп кайтыр. Көн саен Ходайдан дога кылып шуны сорарбыз.

Зөбәрҗәт. Рәхмәт, җаным!

Андрей *(керә).* Сез, Зөбәрҗәт апам, Заһидә белән аскы бүлмәгә төшеп ятып торыгыз. Мин Николай янында дога укып чыгармын!

Зөбәрҗәт. Әй, үскәнем, бәләкәчем, Камил энем. *(Якын килә, гәүдәсен сыйпый).* Бәхил бул, безгә рәнҗеп китмә!

Заһидә. Апа, әйдә, чыгыйк инде. Биредә мин үземне бик начар хис итәм.

Андрей. Барыгыз, бар, аска төшегез! Үтенеп сорыйм!

Заһидә *(ишек шакыйлар).* Анда кемдер килгән. Ни булды икән?

Зөбәржәт. Йә, Ходаем, бусы кем инде тагын?! Әнвәр наныем, бар карап мен инде.

Андрей. Яхшы, Зөбәрҗәт апа.

Заһидә. Мин дә синен белән.

Андрей. Юк, юк, Заһидә, биредә генә көтеп тор! Мин хәзер! Әнә үзе менеп килә.

Поп *(керә).* Ишегегез ачык, кердем инде. Что творится там, что твориться!

Андрей. Әйдәгез, Иван Генадьевич!

Поп. Гатаулла хазрат өйдә юк что ли? *(Идәндә яткан гәүдәне күреп).* Әллә чирләп киттеме?

Андрей. Юк, ул Коля-Камил ята!

Поп. Ни булган аңа?

Андрей. Аны үтерделәр!

Поп. Ничек үтерделәр?

Андрей. Гриша мылтыктан атып үтерде. Гриша Мегайлов!

Поп. Гриша... Шул адәм актыгы... Колянымы?! Шундый егетне харап иттеме?! Пусть он будет проклят!

Андрей. Большевик ул хәзер!

Поп. Большевиклар аны тиздән үзләре үк... Нинди егетне бит, нинди пареньне... Муены сынгыры! *(Килә, япманы ача, үбә).* Их, сынок, сынок, шулай япь-яшь килеш үлеп ят инде. Кирәк бит!

Андрей. Гатаулла хәзрәтне кулга алдылар.

Поп. За что?

Андрей. Ак офицер Николайны качырып яткырган өчен, имеш.

Поп. Иван. Әле бит анын белән иртән генә күрешкән идек. Когда?

Андрей. Күптән түгел.

Зөбәржәт. Иван Генадьевич, безгә нишләргә соң? Монда Коля үлеп ята, Гатаулланы алып киттеләр. *(Күз яшьләрен сөртә).*

Поп. Иван. Монда разьве можно нишләргә соң диеп утырырга. Халыкны күтәрергә, өндәргә кирәк!

Андрей. Әлбәттә шулай, Иван атакай. Мин үзем халыкка чыгам. Ул бит барысына да ярдәм итеп яшәде. Юкка гына халык аны зурлап, изге Гатаулла диеп атамады.

Поп. Иван. Алайса, мин селога кайтам, барысын да җыеп алып киләм!

Зөбәржәт. Аллага тапшырдык, хөрмәтле атакай. Без мәдрәсә шәкертләрен мәйданга чакырырбыз.

Поп. Иван. Так и сделаешь! Үзәк мәйданда җыен урыны! Бог с нами, туганнар. Төштән соң Николайны да халык белән бергә җирләрбез.

Андрей. Аллага тапшырдык!

Поп. Иван. Боже мой, что творится, что творится?! *(Китә).*

Андрей *(Зөбәржәт белән Заһидә чыгалар).* Хәтерлисенме, Коля, без синен белән Андрианнар бакчасын басарга кергән идек. Күбенгәнче яшь алма ашап, шартлар дәрәҗәгә җиттек. Аннан су коенганда, син чумдың да, юкка чыктың. Мин җылый-җылый авылга ярдәм сорап йөгердем. Син камышлар арасында гына качып яткансың икән. Мин барысын да хәтерлим. Ярый әле вакытында, урлашып йөргәндә, Гатаулла хәзрәткә тап булдык. Без синең рухына дога кылып яшәрбез. Урының җәннәтнен түрендә булсын, дустым. *(Музыка. Андрейнын дога укыган тавышы).* Иннә лиллаһи үә иннә иләйһи раажигун. Аллаһүмә иң кәнә һәзәлмәййиту мухсиннән фәзие фи ихсәниһи үә иң кәнә мусилэн фәтәнә үәз ганһ. Йә Рабби, әгәр дә бу мәет изге кешеләрдән булса, изгелеген арттыр, әгәр дә гөнаһлы кешеләрдән булса, гөнаһларын гафу ит!

## VI күренеш

*Луиза ханым, Ләбиб, Рәшит.*

Ләбиб. Ни белән бетә соң инде бу язмыш?

Луиза. Шуннан русы да, татары да, удмурты да күтәрелә. Гатаулла хәзрәтне чыгаруларын таләп итәләр.

Л ә б и б . Чыгаралармы соң?

Л у и з а . Үлемгә хөкем ителгән хәзрәтне чуалышлардан куркып азат итәләр.

Л ә б и б . Көчле шәхес булган үзе дә.

Л у и з а . Изге шәхес!

Л ә б и б . Әнвәр белән Заһидәнең язмышлары ничек?

Л у и з а . Алар мең бәлаләр белән Россиядән чыгып качалар. Соңрак Гатаулла хәзрәтне сагынып, үзләренә чакырып яталар. Ләкин безнең бабабыз туган җиренә тугры кала. Ыгы-зыгыларда сәламәтлеге какшаган була, 28 нче елда каты авырудан соң вафат була. Зөбәрҗәт абыстай тагын 15 ел яши әле. Нәселләре Төркиядә дәвам итә.

Л ә б и б . Аның өрәге ни өчен тынычлык таба алмый соң?

Л у и з а . Җавап бирүе бик авыр мина!

Р ә ш и т . Интектермә инде Ләбибне, Луиза сеңлем, кайткач, бабабызга багышлап, берәр әсәр язар.

Л у и з а . Ходай Тәгалә үзе кичерсен инде. Бабабызга карата зур гөнаһ кылына. Менә шушы тирәдә аның кабере була. Халыкның бирегә юлы өзелми, үзенә күрә бер изге урынга әйләнә. Тегендәрәк берничә кабер ташлары исән әле. Әнә күрәсезме?!

Л ә б и б . Әйе! Гатулла хәзрәтнеке сакланганмы соң?

Л у и з а . Бөтен бәла дә шунда шул! Халыкны бирегә йөрүдән биздерү өчен, мәктәп салабыз диеп, зират мәйданына да керәләр. Ташын аударып бина салалар.

Л ә б и б . Менә ничек икән ул!

Р ә ш и т . Менә шундый хәлләр, Ләбиб туган. Адәм баласына бу илдә үлгәч тә тынычлык юк.

Л ә б и б . Халык шул чакта нишләп яңадан күтәрелми соң?

Р ә ш и т . Ул чакта халык гасыр башындагы кебек бердәм булмый инде. Сталин режимында рухы сындырылган, күпме затлы адәмнәре үтерелгән!

Л у и з а . Менә шулай.

Л ә б и б . Их, Рәшит абый, шундый шәхесләребез күбрәк булсын иде...

Р ә ш и т . Булсын иде дә...

Л ә б и б . Луиза ханым, Гатаулла хәзрәтнең берәр рәсеме, фотосы сакланмаганмы?

Л у и з а . Бер гаилә фотосы бар. Аны да туганнан туганнары гына табып китерделәр. Менә ул! *(Сәхнәгә төп геройлар чыгып баса. Зөбәрҗәт скрипкада, Заһидә фортепьянода, Камил-Коля курайда, Әнвәр-Андрей гармун белән).*

Л ә б и б . Аллага шөкер, үзләрен күрәм!

Л у и з а . Менә скрипка тотканы Зөбәрҗәт абыстай, фортепьяно артында Заһидә ханым, курайлысы Камил, гармунлысы Әнвәр әфәнде, уртада Гатаулла хәзрәт үзе!

Л ә б и б . Нинди күркәм затлар! Әйтерсең, мин аларның уйнаганнарын, хәтта Гатаулла хәзрәтнең өздереп җырлаганына хәтле ишетәм!

Р ә ш и т . Мин дә тоям аларның барлыгын!

Л ә б и б . Чү, Рәшит абый, минем колагымда да ул моң чыңлый. Мин ишетәм ул көйне. «Тәфтиләү» ул! *(Музыка башлана, уйнаучылар хәрәкәткә киләләр).*

Г а т а у л л а . *(Җырлый).*

И, мөкатдәс, моңлы сазым, уйнадың
син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен,
аерылабыз, ахрысы.
Очты дөнья читлегеннән тарсынып
күңлем кошы,
Шат яратса да җиһанга, ят яраткан
раббысы.

*Җыр көчәя. Барысы да кушыла. Әкренәя. Азан тавышы.*

*Тәмам.*

Вера
Хәмидуллина

# САГЫШ МОҢЛЫ ҖЫРЫН СУЗАР...

* * *

Ут төсле канәфер чәчәге —
Бакчамда коелды таҗларың.
Сөюем үткәннәр куенында
Каршылар шатлыксыз таңнарын.

Мин көттем, борылып дәшмәдең,
Хушлашып үпкәндә җил булып.
Кушылды күк йөзе күкләргә,
Кайгыдан еларга сулыгып.

Яшь юды тәрәзә өлгесен,
Торналар сагышы күкләрдә.
Әбиләр чуагы кайтмастыр,
Мәхәббәт һәм бәхет үткәндә.

Ут идең, канәфер чәчәге!
Бакчамда коелды таҗларың.
Сөюем, хәтергә төренеп,
Каршылар шатлыксыз таңнарын.

## Ялан тәпиле балачак

Ялан тәпиле балачак,
Ник барасың артымнан?!
Мин оныттым инде сине,
Төштем агач атымнан.

Сагыш-моңнар баскан чакта,
Кочасың күңелемнән.
Телисеңме, иртәгә үк
Гафу үтенәм синнән?!..

Вера ХӘМИДУЛЛИНА — *шагыйрә, тәрҗемәче; күпсанлы китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

* * *

Кайдадыр еракта, еракта,
Яңгырлар һәм карлар артында
Җыр суздык, йөрәктә җиңеллек
Булганда, без сөю хакында.

Кайдадыр югалды саф хисләр.
Үткән җәй тыкрыгы тарайды.
Мәхәббәт адашты, ә күңел —
Хәерче, киеме ямаулы.

* * *

Хыял кошы кочагында
Өзгәләнә мәхәббәтем.
Янды үткән учагында,
Кире кайтмас ак бәхетем.

Төеннәрдән тора язмыш,
Икеләнү, ялгышлардан..

Әче яшьләр ага бары
Сагыш эзләр салган ярдан.

Сулган хисләрнең бәйләмен
Тотып тормый ватык савыт.
Томан сарган кайгыларны
Ялган сүзгә булмый манып.

* * *

Ни эшләттең мине, әйтче,
Иң кадерле, якын кешем?!
Күрәсеңме?! Синең алда
Горур башны аска идем.

Хәлдән килсә, карлыгачтай
Очар идем еракларак.
Яшерергә сагышымны
Күренмәс бер җепкә урап.

Карашыңда салкын ялкын,
Өтеп ала, яна йөрәк.
Шашкын уйлар адашкан да,
Йөри чыгар ишек эзләп.

Горур башны аска иеп
Басып торам алларыңда.
Син сындырдың язмыш дигән
Бер ботакны күз алдында.

* * *

Истә әле соңгы сүзләр,
Өзгәләнде нечкә кыллар.
Утка ятның сөюемне,
Ябык кире кайтыр юллар.

Ак кардагы эзләр төсле
Уелып калды агу-сүзләр.
Йөгерүдән туктап, күңел
Юанырлык җавап эзләр.

Йөрәк сизде ялган хисне.
«Эндәшмә!« — дип карар бирде.
Түз, йөрәгем, чишә күрмә
Җан төбендә калган серне.

Калтыранып, соң мәртәбә
Томаннарга изим кулны.
Тынычланыр күңлем беркөн,
Акылым табар туры юлны.

* * *

Мин дауламыйм синнән берни.
Китә алсаң, яп ишекне!
Хаталарсыз, югалтусыз
Бәхеткә соң кем ирешә?!

Ут эзләгән сукмакларда
Кычкырсам да җаным көеп,

Мин төннәрдә сине дәшмәм
Һәм үтенмәм, кичер, диеп.

Иртә таңда йөгерек салкын
Чигәләргә юллар сызар.
Адашкан бер көчек сыман,
Сагыш-моңлы җырын сузар.

## Көз кануны

Көз чишенә шундый матур итеп,
Алтын шәлен сала иңеннән.
Шәрәләнгән агачлыклар никтер
Сагышланып моңга төренгән.

Рәссам чиккән палас өсләренә
Сузылып яткан яфрак йокларга.
Яңгыр суын бер туйганчы эчеп
Кай сукмакка барып туктарга?!

Көз аеның аның үз кануны:
Кырпак карлар каплый юлларны.
Башка дөнья ишеген ачып куя
Чал вакытның жылы куллары.

Өмет итмим инде киләчәктән
Жиңү бүләк итәр мизгелне.
Кайтып алып булмый үткәннәрдән
Гомер атын тоткан тезгенне.

* * *

Баланнарның кызыл тәлгәшләре
Жиргә кадәр түбән иелгән.
Елак көзнең шушы мәлләренә
Гомер юлым ташып түгелгән.

Суларның да төсе кара-кучкыл,
Сагышлардан күмелә моңнарга.
Баш очымда канат кага козгын,
Тели, ахры, бәла юрарга.

Ак кыраулар каплар юл баткагын,
Кар агартыр безнең чәчләрне.
Кыш килер дә, көз гомерен өзәр,
Уйга күмәр ап-ак бәсләре.

* * *

Сөю матур көйгә тиңдәш,
Әйтә күрмә авыр сүзләр.
Өйдә тавыш куба калса,
Чормага юл күңел эзләр.

Жиде йозак элгән сандык
Саклап тора күпме керне.
Табу тыя таратудан
Дөньялыкка сыймас серне.

Үпкәләшсәк юкка-барга,
Арабыздан үтсә салкын,
Ачылмасын бикле сандык —
Өтеп алмас бозлы ялкын.

Әлфия СИТДЫЙКОВА *тәрҗемәсе.*



# Дилә 
# Булгакова

## Озын чәч

Кояш, диңгезгә башын куеп, йоклап китте. Аның алтын чәчләренә дулкын-куллары белән кагылып, Диңгез бишек җырын җырлады. Ә су төбендәге зур хәзинә иләндә бөтенләй икенче дөнья иде...

Яшь акула үз-үзенә урын таба алмый үрсәләнде. Кая соң сөйгәне? Аның, диңгезгә башын салып, дулкыннар ябынып, серле кояшны күрсәтәсе килде сөйгәненә. Кояшның мең төстәге чәч бөртекләренең нурлары диңгез төбендәге мәрҗәннәр иләнә уралып, хәзинәле дөньяның әкияткә әверелүен күрсәтәсе килде аның бердәнберенә. Диңгез төбендәге барча үсемлекләр дә, балыклар да алтынга төрелә. Бу гаҗәеп серле, гаҗәеп матур әкият иле! Әй, сөеклем, син кайда? Бу матурлыкны без икәү генә күрергә тиеш, чөнки без бер-беребезне яратабыз! — Яшь акула Елгыр тирә-якны айкап-байкап йөзде дә йөзде, үзенең Зәңгәр Түшен эзләде.

Зәңгәр Түш диңгез урманында үзенең яшьтәшләре белән уен корган иде. Үрсәләнеп ярсыган Елгыр, акула көтүеннән аерылып, бер читтәрәк уйнаган кызны — үзенең Зәңгәр Түшен тиз танып алды. Ул яшен тизлегендә аның янына йөзеп килде дә, көмеш тәңкәле кулбашына акрын гына кагылып: «Зәңгәр Түш, мин сине күптән эзлим инде, әйдә минем белән, сиңа бер могҗиза күрсәтәм», — дип, сөйгәненең канатына үзенең канатлары белән сак кына кагылып алды. Калган акула кызлары аларның мәхәббәте турында беләләр иде, шуңа күрә аларга игътибар итмичә, уеннарын дәвам иттеләр. Алар су астыннан өскә күтәрелделәр дә, янә диңгез төбенә кадәр түбән төшеп, уйнадылар да уйнадылар.

Елгыр белән Зәңгәр Түш, ниһаять, кояшның алтын чәчләре яктырткан мәрҗәннәр иләнә йөзеп килделәр. Яшь акула шатлыгын яшерә алмый, сөйгәненә: «Күрәсеңме, нинди гүзәл әкият дөньясы, телисеңме, шуларның барысын да сиңа бүләк итәм!» — диде. Үзе гәүдәсен сөйгәненең көмеш тәңкәләренә тидерде. Оялчан Зәңгәр Түше шатлыгыннан Елгырның канат-кулларына сырпаланып иркәләнде, назга исереп бөтергәләнде. «Зәңгәр Түшем, күрәсеңме, диңгез төбендә күпме хәзинә, аларның барысы да синеке. Тик син миңа үзеңне генә бүләк ит! Без гел бергә булырбыз, мин синең көмеш тәңкәләреңне мәрҗәннәр белән бизәрмен, сөеклем!» — дип Елгыр сөйгәненең күзләреннән үпте, аның көмеш канатлы кулларына кагылды. Шул мәлдә гүя су астының мәрҗәннәр дөньясы илаһи бер матурлыкка, нурга

Дилә БУЛГАКОВА – *язучы, шагыйрә; «Скрипка моңы», «Урмәкүч авы», «Илаһи низам» һ.б. китаплар авторы. Уфада яши.*

күмелеп тынып калды... Мәхәббәт тантана итте бирәдә. Ике яшь гашыйкның ургылып торган саф мәхәббәте хакимлек итте. Хисләр дөньясында озак онытылып назлады алар бер-берсен.

Елгыр белән Зәңгәр Түш акулалар көтүенә сон гына кайтып кушылдылар. Шул көннән соң алар бер-берсеннән һич тә аерылмас булды. Ләкин Елгырның йөрәгенә шатлык хисләре бүләк иткән, аны нииндидер бер ят та, ләззәтле дә тойгыларга чорнаган икенче бер сере дә бар иде. Бу турыда Зәңгәр Түшенә сөйләргәме-юкмы дип, озак баш ватты ул. Гаҗәеп татлы тойгы шул ул сер... Ярый да бердәнбере аны дөрес аңласа. Хәер, нигә әле ул хисләрдән куркырга тиеш Елгыр?! Әнә бит хәтта Кояш белән Дингезнең мәхәббәтен, дуслыгын бөтен Җиһан белә, күрә. Ә нигә мин — акула егете адәми кыз белән дус булырга тиеш түгел, дип уйлады Елгыр.

***

...Бүген озын чәчле нәфис кыз дингезгә мәрҗәннәр алырга төшәргә тиеш. Ул аны күрәчәк, аның дулкыннар тараган озын чәчләренә кагылып китәчәк. Шундый татлы уйлар белән Елгыр дингез төбенә — мәрҗәннәр дөньясына ашыкты. Тик анда да кыз юк иде. Ул ашыгып дингез өстенә чыкты. Андагы көймәдә дә башка кешеләр иде. Җанына урын таба алмыйча, үрсәләнеп, уктай атылып, тирә-якны чайкады ул. Борчылды, озын чәчне юксынды. Юк, бу мәхәббәт түгел, бу — дуслык! Саф дуслык тойгылары гына иде...

Көтмәгәндә газиз, кадерле гәүдә пәйда булды. Ул! Озын чәчләрен таратып, сузылып кына мәрҗәннәр иленә килде кыз. Яшь акула егете аның янына уктай атылды, шатлыгын яшерә алмыйча, тыны бетеп: «Әй, Озын Чәч, курыкма, бу мин — синең дустың Елгыр, тимим мин сиңа. Мәрҗәннәр илендә байлык җитәрлек. Әнә, күрәсеңме, синең нәни генә нәфис кулларың кагылачак мәрҗәннәргә нурлар уралган, ә минем дингеземнең дулкыннары синең чәчләреңне иркәләп юа»,—дип кызны мәрҗәннәр иленә кадәр озатты. Кызның юлына каршы чыккан дингез еланын ул үткер канаты белән бәреп очырды. Еланнан курыккан кыз чынлап та бу акула егетенең үзенә тимәячәген, аның чын дус булуын аңлады булса кирәк, тынычланып китте. Ул акула егетенә рәхмәтен белдереп, кулын күтәрде. Зур бер мәрҗән кисәген сындырып алыйм дисә, күкрәгенең өздереп авыртуын тойды. Аның күкрәгенә сөт төшкән иде. Кыз ашыга-ашыга өскә күтәрелде, сабые ачыккандыр инде, елыйдыр. Көчле, җитез яшь акула кызны көймәсенә кадәр озатты, ул күздән югалганчы аңа сокланып карап торды. Тынычланып калды Елгыр һәм Зәңгәр Түше янына — акулалар көтүенә ашыкты. Тик Зәңгәр Түшнең кәефе начар иде. Ул Елгырның каядыр китүен шунда ук тойды. Зәңгәр Түшнең тәннәре авырта башлады. Озакламый уылдыгын салырга тиеш, ә әти кеше кайдадыр читтә йөри. Нәфрәтеннән ни эшләргә белми, үзенә урын таба алмый дингезне айкый-айкый йөзеп китте читкә Зәңгәр Түш...

Икенче көнне дә кызлар көймә белән дингез уртасына килделәр дә берәм-берәм мәрҗәннәр иленә төштеләр. Озын Чәч тә килде. Тик нигәдер ул дингезгә төшәргә ашыкмады, кулларын күтәреп: «Якты кояшым, исәнме! Тагын килдем, фатиханы бир, кояшым. Күкрәгем тулы нәниемнең ризыгы, аның бәхетенә, аның өчен дингезеннең бүләкләрен төшеп алырга рөхсәт итче?! — дип үтенде ул. — Диңгез тынычмы, мине Елгыр дустым каршы алырмы?» Хатынының кояшка табынып нидер сөйләнүенә ачуы килгән ир: «Йә, тизрәк бул, бала уянганчы кайтып өлгерергә кирәк», — дип сөйләнә-сөйләнә Озын Чәчнең биленә бәйләнгән бауны кысыбрак бәйләде дә, сикерергә кушты. Хатын озак итеп тын алып торды да уктай дингез төбенә атылды. Кинәт аның юлын күкне япкан кара болытлардай караңгылык каплады. Үзенә якынлашкан акуланы күреп, кыз шатланып куйды, аңа кул болгады һәм йөзүен дәвам итте. Ашыга-ашыга

зур бер мәрҗән кисәген йолкып алып, борылырга дип омтылган иде, кинәт нәрсәнендер каты итеп аркасына бәрелүен тоеп, чак кына һушын югалтмады. Тик янәшәсенә йөзеп килгән акуланы күреп тынычлана төште. «Дустым, нигә саксыз кагыласың?» — дип кулы белән үрелүе булды... күзләренә кан сауган Зәңгәр Түш аның сөттән тулышкан матур түшен умырып та алды. Зәңгәр Түш кан исенә тагын да котыра төште, үрсәләнгән яшь хатынның йомшак кулбашына үткер тешләрен батырды, һушын югалткан Озын Чәч ярдәм сорап авызын ачуга үпкәсенә тозлы диңгез суы ургылып тулды. Кан исенә башка акулалар йөзеп килделәр дә котырына-котырына хәлсез гәүдәне өзгәләргә керештеләр. Ниндидер бер хәвеф булганын җаны белән тойган Елгыр кан исе килгән җиргә уктай атылып килеп житте һәм... хәрәкәтсез калды. Зәңгәр Түш исә ниндидер бер эчке тантана белән ашыгып сөйгәне янына килде дә: «Елгыр, син бүләк иткән мәрҗәннәр дөньясы, диңгез байлыклары тик минеке генә, син дә минеке генә булырга тиеш, ишетәсеңме?» — дип аның канатына килеп сарылды.

Көтмәгәндә диңгез эченә гүя ярсыган давыл атлары килеп керде. Дулый-дулый бар көченә шаулап, кыя-тауларны тырнап ярсыды диңгез. Үкси-үкси ыңгырашып, дулкын-куллары белән яр читендәге көймәне үрелеп алды да, ачуланып, аны кисәкләргә ваклап ташлады. Аннары, шулай эшләгәненә үзе дә үкенгәндәй, аның йомычкага әйләнгән кисәкләрен кочагына алып үкседе. Әнә шул мәлдә көтүдән аерылган яшь акула егете Елгыр, дулкыннар өстендә сузылып сибелгән чәч бөртекләрен канатына урады да, хәсрәтле йөрәгенә урын таба алмыйча, диңгезне ташлап, океанга чыгып китте...

Кичкә табан арыган, ярсыган Диңгез тынычлана төште. Аның сөйгәне — олы Кояш, үзенең толымнарын сүтеп, Диңгез күкрәгенә башын салып, тирән йокыга китте. Яр читендәге бәләкәй генә өйдә ир кеше хатынын югалту хәсрәтеннән ни эшләргә белми өзгәләнде. Ул ярсып өстәл янына килде һәм анда яткан мәрҗәннәрне кулына алып, диңгез буена йөгерде. Ул шашынып, рәнжеп, илереп аларны диңгезгә атып бәрде...

...Яна таң туды. Кояш сөйгәненең куенында изрәп йоклады да, тагын үзенең көмеш нурларын — чәч толымнарын таратып җибәрде. Ә диңгез төбендәге мәрҗәннәр илендә алтынсу нурларга күмелгән тормыш дәвам итте...

### Бүләк

Таң ату белән урман каравылчысы Хөсәен бабай чаңгыларын киде дә, яңа яуган кар өстендә пар эз сызып имәнлеккә карап юл алды. Андагы улаклар янына тиздән пошилар да килеп житәр. Аларны биредә көн дә тәмле сый көтә. Алдан йөгергән Сарбай һәркөнне туктала торган кушимән янына житүгә, һау-һаулап өрергә кереште. Әйтерсең, ул үзенчә: «Без килдек, Сорыкай, хәерле иртә! Әйдә, безнең янга төш», — дип әйтергә тели иде. Шуны гына көтеп торган диярсең, имәннең иң аскы ботагында тиен пәйда булды. Ул арада Хөсәен бабай да килеп житте.

Нәни «ут йомгагы» күз ачып йомган арада бабайның бияләйләрен салган учына үрелде. Дөньясын онытып, чикләвек белән сыйланды. Шуннан, рәхмәт әйткәндәй, кушимән тирәли бер-ике кат сикерә-сикерә әйләнде дә, яшен тизлегендә агачка үрмәләп, күздән югалды. Карт, чүгәләгән килеш, Сорыкайны сокланып күзәтеп, сүзсез утырды. Аннары янәшәсендәге этнең аркасыннан сөеп:

— Әйдә, безнең бүтән дусларыбыз да күп, алар да көтәләрдер, — дип, сөйләнә-сөйләнә, урыныннан кузгалды. Ул эскерт янына барып, бер кочак печән алды. Каршы искән жил Хөсәен бабайның керфекләрен, озын кашларын, бүреген һәм якасын энжедәй бәс белән бизәде. Нәкъ Кыш бабай кебек булды да куйды урман каравылчысы.

Хөсәен бабай акланга чыгып, китергән печәнен улакка салды. Күп

тә үтмәс, пошилар килеп житәр. Кар бөртекләре көмеш тәнкәләредәй жемелдәп яна. Ана монда һәрнәрсә, һәр куак, һәр агач таныш һәм кадерле. Кечкенә чагыннан ук яратып үсте ул урманны. Бу мәхәббәте ана әтисеннән күчкән. Ул да шулай табигать жанлы кеше иде... Ләкин ана озак яшәргә генә насыйп булмады шул. Көннәрдән бер көнне браконьерлар каршына барып чыга ул. Шунда аларнын берсе мылтыкка үрелде... Хөсәеннен әтисе бәләкәч кенә болан баласын саклап калырга теләгән иде ул чакта...

Аучы уйларына бирелеп күпме баргандыр — кинәт, кар өстендәге миләш жимешедәй тезелеп киткән кан эзләрен күреп, сискәнеп куйды. Шул эзләр буйлап алга шуа башлады. Озакламый, зур тармаклы мөгезләрен чайкый-чайкый, ярдәм сорап килгән пошины күрде. Карт тукталды. Пошинын хәле чынлап та шәптән түгел иде. Анын жилкәсенә ябышкан селәүсен, картны күрү белән, тырнакларын ычкындырып, бар көченә читкә атылды. Сарбай өрә-өрә ерткычны куып китте. Хайванкай, рәхмәт әйткәндәй, картка мөлдерәп карады да, көрт ярып, урман эченә кереп югалды...

Жил көчәйгәннән-көчәя барды, арыган картны артка сөйрәде. Бераздан күз бәйләнде. Берни күренмәс булды. Хөсәен бабай каранғылык чаршавына уралган акланга күз салды да кайтырга юл тотты.

Күз ачкысыз буран башланды. «Бик ерак киткәнбез икән, Сарбай. Зарар юк, хәзер кайтып житәрбез», — дип этен юатты карт. Күпме вакыт үткәндер, тәмам хәлдән тайган урманчы кушимән янына килеп утырды. Чаңгыларын салды, азрак ял итмәкче булды. Анын хәлсез тәне салкынны да, искән жилне дә тоймады.

Таң аткач, ул еракта елап өргән эт тавышына күзен ачты. Якын-тирәдә тынлык: жил дә, буран да юк. Янәшәсендә генә сикергәләп йөргән тиенен күргәч, куанычыннан кулын күтәреп: «Сорыкаем!» — димәкче булды, ләкин бүрәнәдәй авыр куллар кузгалмады, сүз әйтергә теле әйләнмәде.

Көрткә бата-бата Сарбай артыннан ияргән берничә кешене күргәч, карт торып басарга теләде, шунда аңын жуеп, кабат кар өстенә ауды.

***

...Хөсәен бабайга больницада озак ятарга туры килде, врачлар аны үлем тырнагыннан алып калдылар. Картнын яныннан туганнары, дуслары китмәде. Өстәленнән тере чәчәкләр өзелмәде.

Беркөнне күчтәнәчләр арасында чикләвекләр күргәч, карт балаларча шатланды. Аларны бәләкәй тартмага салып куйды. Сорыкаем — тиенкәемә күчтәнәч булыр, дип уйлады карт. Күнеленнән дусты янына ашкынды, үзенең урманын, таныш юлларын, тугры Сарбаен сагынды.

Хөсәен бабай больницадан чыкканда ямьле жәй иде инде. Ике бәйрәм бергә туры килде — аны житмеш яше тулу көне белән котлап, дуслары, туганнары жыелды.

Тик сунарчыларнын берсе китергән бүләкне күргәч, карт бөтенләй сүзсез калды. Өстәлдә таныш тиен карачкысы утыра иде.

— Сорыкаем! Сорыкаем! Мә! — Карт кулына учлаган чикләвекләрен тиенгә сузды. Алар шылтырап идәнгә коелдылар. Хөсәен бабайнын күз яшьләре берәм-берәм өстәлгә тамды.

## Буаз елан

Талагы ташуына чыдар әмәле калмады Белланың. Каршы як ихатасыннан яңгыраган гармун моңын ишетмәс өчен, бармакларын колагына тыгып, юрган астына ук кереп чумды. Чигәләрен кысып, калын юрган астында өч минут та ятмады, кара тиргә батты, хәле бетте, тыны кысылды...

— Уф! Нинди ләззәт табалар икән монавы Мамай заманыннан калган жырларны тынлап! Туйдым, шулкадәр туйдым шушы мәндүәннәрдән. Кулымда гранатомет булса, авылын гына түгел, районын күккә очырыр идем дә котылыр идем, билләһи. Гомереңне шушында үткәрмәс өчен әллә ниләр эшләргә риза буласың. Бигрәк беркатлы, бигрәк тупой инде бу авыл ишәкләре. Сабантуй дип ай буе авыз суын корытып и әзерләнделәр, и әзерләнделәр. Нәрсәсе бардыр инде шул ел саен урман буена барып көтү-көтү жыелып эчеп, исереп, сугышып кайтуның. Эчә-эчә үлеп бетеп баралар бит инде. Никләр генә килде икән шушы авыл баткагына, башкайлары нигә эшләмәде икән! Их, әнисе йортын сатып Татарстанга — туган якларына китмәгән булса, ул бу якларга әйләнеп тә карамаган булыр иде. Кайчан, нишләп ялгышты соң әле ул. Югыйсә бит, ким дигәндә бер министрның тез башына гына кунаклыйсы кыз иде ул. Монавы авылда эт бугы иснәп яшисе түгел иде ул, түгел иде. И, Ходаем, анавы Фирдүс абыйны гына кара инде, гәрбил такта кебек корышып каткан ябык хатынының тункаеп сыер савуына сокланып:

Исемең матур, кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган! –

дип жырлый-жырлый гармун тартып утыруына гына да буман тотып тәгәрәпләр үләрсең. Кара, кара, теге тәрбияле елмаеп нидер жавап биргән була, әллә үзе дә жырлый инде. Уф, карап торулары кызганыч, амбал кадәр ирнең кагаеп беткән бәләкәч кенә хатынга табынып яшәвен һич акылы кабул итми Белланың. Ахмак инде, каешланып каткан ахмак бу авыл ирләре. Караган саен ут чыгарырдай булып мимылдап торган арт алмалары уйнаклаган, бармагыңның жиле генә кагылып китсә дә үрә сикерә торган мул күкрәкле, су сөлеге кебек яшь медсестра килененә һич игътибар итмәгән була мәхлук Фирдүс. Теләсә, бер атна эчендә бөгеп салачак бит аны Белла. Моңарчы кайгы-хәсрәте генә күп булды, шул гына бетерендерде Белланы. Уйна, Фирдүс абзый, уйна әле син бүген, шул кәкре тактаң алдында бөгелә-сыгыла уйна. Бераздан мин сине безнең якка — мин яшәгән йорт ягына ешрак караш ташлата башлаячакмын... Аннары... үзең кереп алдыма тезләнерсең... Тезләнерсең!!!

Иренең амбал кебек таза абзыйсы белән алда кичерәчәк ләззәтле минутларны уйлап, серле генә елмаеп куйды да, бөтен мускул жепселләре дә тартылырдай итеп, рәхәтләнеп бер киерелде Белла...

...Урман кочагына сыенып утырган Наратлы авылы бүген сабантуй үткәрде. Ата-бабаларыннан калган йола-гадәтләрне моңарчы түкми-чәчми саклап килә бу авыл. Сабан туйлары да, каз өмәләре дә борынгыча үтә, авылга төшкән кыз-киленчәкләрне дә бал-май каптырып, тупса аша мендәргә бастырып төшерәләр. Олыларга кечелекле, кешелекле мөнәсәбәт, күрше-тирәгә туганнарча хәстәрлекле булу монда гадәти бер халәт. Урлашу, кеше өлешенә авыз сузу бөтенләй дә ят аларга. Бәлки, шунадыр да эшләгән эшләре бәрәкәтле, мал-туарлары исән-имин килеш ишелеп арта тора, уртак чәчкән игеннәре күкрәп үсә.

...Зур авыл читендәге урамның аргы башындагы алпавыт утары хәтле ихатадан баян моңы түгелә. Кичкә кадәр сабантуйда күңел ачып, кардәш-туганнары белән очрашып, аларны да кунак итеп, үзе дә гаиләсе белән кунак булып кайткач, ак келәтенең күтәрмәсенә чыгып утырды да, күкрәгеннән ургылган хисләрен баян телләренә басып әйләнә-тирәгә моң итеп түкте дә түкте Фирдүс. Гармун телләреннән сирпелгән моң урман итәгендәге олпат имәннәргә, үсмер каен-усакларга, нарат ылысларына уралып сарыла

да, янә кайтаваз булып авыл өстенә тарала. Дөньясы түгәрәк, күнеле көр, йөрәгеннән, бөтен булмышыннан мәхәббәт бөркелеп торган ир өчен тагын ни кирәк? Әнә, үзе сайлап алган яры шаулатып сыер сава. Лапаста бозаулар мөгердәшә. Ду китереп атна-ун көн эчендә чәчүне бетерделәр. Тәне сәламәт, күкрәге тулы моң, мәхәббәт! Шушы үзедер инде ул бәхет тәхете, дип уйлана-уйлана уйнаган жиреннән шып туктады да, сыерын савып бетергән хатынын чиләге-ние белән күтәреп, ак келәткә алып кереп китте Фирдүс...

...Кичке моңга хисләнеп, көмеш яшьләрен үләннәргә, чәчәк таҗларына тамызып елый-елый яңа таң керфекләрен ачарга җыенды. Абзардагы китек кикрикле карт әтәч дөнья яңгыратып, «Кике-ри-кү-күк!» дип оран салуга, сакау әтәч малайлары да көрәя төшә биреп «кики-ли-ликук!» дип, ялгыша-ялгыша кычкырган булдылар.

Фирдүсләргә каршы йортта ялгыз яшәгән шәфкать туташы гармун моңына берчә үртәлеп-үрсәләнеп, берчә хисләнеп төне буе пошыргаланды, йоклый алмады. Яр читенә дулкын чыгарып ыргыткан балыктай, тыпырчынды, үте кайнады, ачуына чыдаша алмый үрле-кырлы йөренде. Фирдүснең хатынын — Зөһрәне күрәлмәде, үләр чикләргә җитешеп көнләшеп яшәде. Әнә бит, фотомодель булып кына йөрерлек нинди күркәм ир күтәреп кенә йөртә шул бөҗәк кенә кебек хатынын. Пәрдәсе дә тартылмаган каршы як йорт тәрәзәсенә ялгышып кына булса да ник бер караш ташласын! Чынлап та, чучка, ат, үгез печәргә укыган бетле күз зоотехник белән юньләп бодай белән борайны аера белмәгән агрономнан тагын ни көтәсең инде? Сыер исе килеп торган бичәләренә һушлары киткән мескеннәрнең...

Юк, китәргә кирәк бу авылдан. Гарык булдым. Сихерләп үземне үтерткәнче шул мәхлуклардан тизрәк таярга кирәк. Китсәм дә, үтләрен сытып, үзләрен сихерләтеп, бетереп китәм... Яманлап сөйләрлек бер генә килмәгән җире булмаса да, Белланың ничәмә-ничә еллар буе күкрәгендә ачышкан уйлары һаман килендәше Зөһрә тирәсендә кайнашты. Тәү күрүдә үк яратмады ул өлкән килендәшен. Уңган, егәрле, җыйнак, акыллы булганы өчен дә көнләште. Таң саен күтәрмәдә Фирдүсне күреп сокланырга да өлгерми, кәнтәй эт кебек иснәнеп артыннан чикерткәсе капка төбенә каләр озата да чыга. Аннары банкасын тотып Белла янына керә. Янәсе, килендәшенә иртәнге яңа сауган сөтне кертә. Юк инде, Зөһрә түтинкә, Белла хәзер син сихерләп керткән сөтне банкасын күтәреп эчми. Әнә, өй буена бәйләнгән карт эткә чыгара да сала. Эт тә озакка чыдамас, көн дә сихерләп өшкертелгән сөт эчә-эчә әнә өй буен сыек тизәк белән буяп бетерде. Исенә чыдар әмәл юк. Их, Фирдүс абый, маңгай күзкәйләрең дә, күңел күзкәйләрең дә сукыр шул синең, сукыр! Ул бөрчекле батист эчке күлмәген кисәк кенә салып ыргытты да, караватына басып, ике кулы белән түшләрен кысып, тәрәзә каршына барып басты. «Бер генә тапкыр бармакларың белән кагылып, яратып, ымсынып карасаң иде, Фирдүс абый. Күкне үрелеп үбәргә торган кызлар түше бит миндә. Нигә тилмертәсеңдер инде», — дип урын-җиренә капланып озак үкседе әллә ничә кала иренең һушын алып та, каткан авыл ирләренә теше үтмәгән, киселгән кала кызы.

Йөрәгендә үзе дә аңлап бетермәслек бер төер, тулышкан шеш кебек сыкрап, чәнчеп тора. Әллә ничек, каһәрле булды аның язмышы. Мәктәптә түбәнрәк класста укыганда ук бит инде ул физкультура укытучысының һушын алып, башын әйләндергән иде. Югары классларда укыган саен «дәрәҗәсе» арта барды аның. Корчаңгы эт кебек битен-муенын сыткы баскан классташлары бер малай кулы тотарга хыялланган вакытта инде ул агайларның «давай»ларын шактый әүмәләгән кыз иде. Арт алмаларын уйнатып, үзгә бер серле караш ташлау гына да аны алиһә итә иде бит. Медицина училищесын да җырлап кына тәмамлады. Районга китмәс өчен

дә юлларын эзләп озак баш ватмады Белла. Үзәк дәваханәсенең хирургия бүлегенә шәфкать туташы булып урнаштырганын сизми дә калды пеләш башлы министр урынбасары. Аннары абзыең озак тирбәлде Белланың «потрясающий» күкрәкләренә ятып... Башкалардан аерылып торган тәкәббер, горур, чибәр Беллочканы баш врач та тиз күреп алды. Селәгәен җыялмый, төнге дежурда торганда әллә ничә тапкыр килеп, «хәлен белеп» китте, сасы авыз. Көтмәгәндә Белла эшләгән бүлеккә авыл хуҗалыгы институтында укыган Искәндәрне китермәгән булсалар, Белла җаны теләгән кеше белән теләгәнчә типтереп, бер кайгы-хәсрәт күрми рәхәтләнеп яшәгән булыр иде әле. Сукыр эчәге шартлаган бу егеткә Белла берничә тапкыр укол кадап, ярасын бәйләде. Егетнең кендектән түбәнрәк урынына кулы кагылуы булды, кызның бөтен тәнен ут чорнап алды. «Сәленеп торган корсаклы ирләр белән чагыштырганда, кәртинкә инде бу егетнең тәне» дип уйлаганын сизми дә калды. Студент егет, әллә авыртуны сизмәде, әллә сизеп тә белгертмәде, Белланы күргән саен пешкән помидор кебек кызарды да куйды. Институтны тәмамлап диплом алгач, Искәндәр кала кызы Белла — Бакырбикәсен житәкләп туган авылы Наратлыга кайтып та төште.

Тынгысыз шаулы каладан соң, йолаларына-кагыйдәләренә, гаделлеккә-гадилеккә озак күнегә алмады Белла — Бакырбикә. Искәндәре Белласын җингәсе янына больницага эшкә дә урнаштырды. Әнә шул гәрбил тактадай шакыраеп каткан ябык Зөһрә килендәше больницаның баш врачы. Үз сенлеседәй якын итеп, жылы каршылады аны Зөһрә апасы. Әмма тәкәббер Белла Зөһрәнең яхшылыгын анламады, анларга да теләмәде. Аның ихлас киңәшләренә дә колак салмады, авызын кыйшайта биреп, мыскыллы көлемсерәгән булды. Иренең бертуган абзыйсы — Фирдүсне күргәч тә Зөһрәгә карата күнелендә нәфрәт болыты куера башлады. «Юк, әзмәвердәй асыл, үзе гармунчы, үзе җырчы ирне һич күркәмләми бу бөжәк, андый иргә мин кирәк, мин!» дип ныгытып куйды баштан ук. Туй көнне үк. Үз матурлыгына үзе сокланып, үсмер чагыннан ук башкаларны санламаска өйрәнгән Белланың шул көнне үк яулыйсы үре барлыкка килде һәм шул теләк аның күнеленә һич тынгылык бирмәде, һәм адым саен, жае чыккан саен Зөһрә апасына аяк чалырга, аның эшен юкка чыгарырга тырышты Белла. Ул билгеләгән даруларның йә микъдарын киметте, йә арттырып авыруларны җәфалады, һич тә булмаса, тиешсез дару эчереп, ничек тә баш врачның абруен төшерергә тырышты. Моны ул елмаеп, авыруларга ягымлы дәшеп, аларның бавырына керердәй булып әйбәт кыланып эшләде. Авырулардан килгән рәхмәт хисләре белән сугарылган хатларны баш врачка бирмичә, ерта барды, ә «үр»не Белла барыбер яулый алмады. Инде алты ел бирелә яшәсә дә. Дүрт ел яшәгәч, авырга калды. Шалкан кебек ир бала тапты Белла. Калага китеп тудырды. Авыл врачларына ышанмады. Өч айга кадәр шапылдап үскән бала беркөнне гәүдәсен тота алмый башлады да куйды. Церебраль паралич дигән диагноз куйдылар. Бу чирнең нәрсә икәнен белгән Белла коелды да төште. Аннары чәчен-башын тырный-тырный килен булып төшкән Наратлы авылын, ире Искәндәрне каргап елады да елады. Шушы ташландык өйнең генә зәхмәте тиде балама, килендәшем Зөһрә генә көнләшүдән бер-бер нәрсә эшләгәндер дигән кургаштай авыр, еландай кара уй йөрәк түренә кереп утырды да, һич кенә дә тынгылык бирмәде Беллага. Нинди генә врачларга бармадылар да, нинди генә әбиләрдән өшкертеп карамадылар Белла белән әнисе. Юк, бала башын да, гәүдәсен дә тота алмады. Хәсрәт, бәла-каза ялгыз йөрми икән. Ире районнан кайтканда уйларына уелып киткәндер инде, каршысына килгән җинел машинаны күрмәгән, туп-туры өстенә барып менгән. Дүрт кешене һәлак иткән. Сигез елга утырттылар үзен. Тышкы кыяфәтенә таянып дөньяны басып алырга

йөргән Белла югалып калмады, ялгызым карый алмыйм дип, баласын гариплэр йортына илтте дә бирде. Бер кешедән дә кинәш сорап тормады. Монарчы Бакырбикәне Матурбикә дип кенә йөрткән авыл халкы инде хәзер ана Белла дип, «а» хәрефен сузыбрак дәшә башлады...

...Корган планнарының һич гамәлгә ашмавына ярсыган, агуын үзе чәчәр чиккә житкән Белла иртәнге тынлыкны сискәндереп жилкапка келәсе ачылганын ишетеп калгач, төне буе керфегенә йокы эленмәсә дә, ялт итеп сикереп торды. Тәрәзә янына килеп караса — кутәрмәдә Зөһрә апасы басып тора. «Бу жен орган гәрбилгә нәрсә житмәгән тагын?» — дип мыгырдана-мыгырдана ишек ачарга чыкты. Кутәрмәгә чыккач үзе:

— Хәерле иртә, Зөһрә Хәләфовна! Бигрәк иртәләгәнсез, әллә бер дә йокламыйсыз инде сез? — дигән булды тавышын йомшартып.

— Иртә түгел инде, Белла туганым, менә яна сауган иртәнге сөт керттем, жылы көе эчеп куй әле, — диде Зөһрә, килендәшенә кызганыч караш ташлап. — Районнан килергә тиешләр иде, мин йөгерим әле, кичен очрашырбыз, — диде дә, шәп-шәп атлап чыгып та китте килендәше. Зөһрәне Белла елмаеп, рәхмәт әйтеп озатып калды. Ул чыгып киту белән сөтле банканы алды да өйгә керде. Үзе зәһәрләнеп:

— Хәстеруш, и хәстеруш! Хәлемә керә, янәсе. Кирәген бер тиен иде. Ну бу юлы да сөтенә шырпы сындырып салган булса, бетерәм тине, — дип, тиз генә марля кисәге белән буш банка алып, сөтне сөзә башлады. Юк, бернәрсә дә юк. Гажәп! Әмма сөткә кагылмады. Ипи турады да этка чыгарып салды.

Төннәр-көннәрне, көннәр-төннәрне алмаштырып кына торды. Жәй кызы үзенен жиләкле, чәчәкле кулмәген киеп, ялан тәпи генә урман, кырлар буйлап йөгерде.

Эшендә дә, өендә дә бер кара уй Беллага тынгылык бирмәде. Ниндн генә юллар белән булса да, Зөһрәгә үзенен сихерен үзенә кайтарып, Фирдүсне үзенә ияләштерергә тиеш ул. Ниһаять, тормышка ашырырга теләп, ул бер атнага түләүсез ял сорап гариза язды. Хәленә керделәр. Бер иртәдә бөрчекле жинел кофтасы белән чалбар киеп алды да, ишеген йозаклап, Наратлы авылы аръягындагы чуваш авылына багымчы Анна түтәй янына китте. «Мин сезгә кем икәнлегемне күрсәтәчәкмен, сихерегезне үзегезгә кайтарып, паралич суктырып кәкрәйтәчәкмен әле», — дип зәһәрен чәчә-чәчә атлады яшь хатын.

Урман буендагы чәчәк-үләннәрне кайбер урыннарда чабып та өлгергәннәр. Хуш ис бөркеп торган пакус өстендә тәлгәш-тәлгәш кипкән жиләкләр башларын иеп, тезелешеп яталар. Усаллыктан, жаһиллектән ярсыган, күзенә кан сауган Белла тирә-якны чорнап алган хозурлыкка тукталып күз салса да, күнел салмады. Ашыкты ул. Әйтеп бетергесез зур бер эш эшләп тизрәк куанасы, тантана итәсе килде анын. Шуннан сон гына күнелен кырган авыр, шикле кара төер эрер, таралыр кебек тоелды ана. Ярсыган хатын чуваш авылына ни арада килеп житкәнен дә тоймады. Бер үсмер кыздан Анна түтәйнен кайда торганын белеште дә, ашыга-ашыга шул якка китте.

...Бүген иртән үк ниндидер кара эчле кешенен кара ният белән киләсен сизгән иде Анна түти. Әмма жил капкада үзе яшь, үзе матур хатынны күргәч, яшен яшәгән, күрәсен күргән Анна карчык та гажәпләнеп бетәлмәде. «И, Тәнрем, гафу итә күр гөнаһлы бу бәндәнне, картайдым, саташам бугай», — дип чукынып алмыйча түзә алмады.

— Тетя Анна, исәнмесез! Мин күрше Наратлы авылыннан, медсестра Белла. Керергә мөмкинме? — дип тавышын йомшартып, назланып кына дәште.

Тавык-чебиләренә бәрәңге болгавы изеп утырган карчык, нидер хәтерләргә тырышып, үзалдына сөйләнеп куйды. «Белла, Белла... Наратлыда нинди Белла булсын тагын?»

— Белла, Белочка! Әллә оныттыгыз дамы? Больницада медсестра булып эшлим мин, — диде яшь хатын тавышын янә дә назландыра биреп.

— Батюшки, ак халаттан булмагач, сине танырлык та түгел бит. Малай кебексең ләсә. И-и-и, нинди йомышлар китерде сине безгә? Докторыбыз Зөһрә Хәләфовна ни хәлдә? И әйбәт тә кеше инде. Алтын куллы, алтын йөрәкле. Бүсеремнең кайдалыгын да оныттым, Ходайга шөкер. Игелекләр күрсен инде. Рәхмәтнең түрендә булсын!

Моны тыңлап торган Белланың саруы күбекләнеп-күбекләнеп кайнады. Карчык һаман сөйләнә бирде:

— Менә хәзер укол кадаучы, перевязкалар ясаучы Белланы да таныдым. Йә, кызым, әбиенә серләреңне әйтеп бир, берәрсенә әллә гыйшык тотасыңмы? — диде дә һәр авазыннан салкын бөркелерлек итеп, сәер генә көлеп куйды. Белла агарынып, калтыранып китте. Бераз сүзсез утырганнан соң гына карчыкның колагына якынрак килеп:

— Тетя Анна, минем эшләрем бер дә шәптән түгел бит, зур бәлагә тарыдым, синең ярдәмең кирәк, — дип еламсырый биребрәк сүз башлады. — Мине сихерләделәр!

— Ай-һай, кызым, ары-бире сизелми бит. Сихерләсәләр, мин шунда ук күрер идем. Бер дә сихерләгәнгә охшамагансың, наныем, гөл кебексең. Карчык алъяпкыч кесәсен капшап сигарет төпчеген алды, шырпы сызып сүзсез генә кабызды һәм ютәлли-ютәлли суыра башлады. Шактый вакыт тын утыргач, ул сүзен дәвам итте:

— Син яшәгән авылда бер дә яман кеше юк, кызыкаем. Әйләнә-тирәдә иман саклап яшәгән бердәнбер авыл ул. Анда андый эш белән шөгыльләнмиләр. Ялгышмыйсыңмы икән? Кем инде ул сихерче?

— Бар! Бар, тетя Анна. Ирен миннән көнли-көнли таракан кебек кибеп бетте. Чөнки мин аңардан яшьмен, уңганмын, матур итеп җырлыйм, чибәрмен. Минем нинди халатлар киеп эшләгәнне үзең күрдең, беркемдә юк андый кием, андый ак халатлар. Крахмалланган, үтүкләнгән...

— Анысы шулайдыр, кызым, һич сүзем юк. Менә күнел халатларыгызны да шулай агартып крахмаллыйсы иде дә бит... Күрәсең, агармаслык булып каралгандыр шул. Агармаслыктыр... — дип мыгырданган карчыкны Белла ишетмәде бугай. Ишетсә, сагая төшәр иде.

— Кара инде, онытып торам ич, мин бит сезгә менә дарулар, бинтлар алып килгән идем. Монда баш, йөрәк авыртканда эчә торган дарулар. Монысы томаулаганда борынга сала торганы, менә пипеткасы да, — дип сөйләнә-сөйләнә пакетка төргән даруларын карчыкның алъяпкычына салды. Мыгырданган карчыкның йөзе ачылып китте. Төрепкәсен авызыннан алмый гына Белланы ак келәт дип аталган искереп беткән келәткә чакырды. Түрдәге агач кроватьта йоклап яткан иләмсез зур кара песи аларны күрү белән мырылдый-мырылдый йоннарын кабарткан булды да, үзенә игътибар итүче булмагач, тиз генә ихатага чыгып тайды. Чебен-мазар кермәсен дип карчык келәт ишеген ябып куйды. Урындык алып агач кроватьта утырган Белла янына якынрак килеп утырды. Чыраен сыткан Белланың аркасыннан сөеп алды да, аның йөзенә төбәлеп:

— Инде хәзер кеше аңларлык итеп, тартынмыйча гына сөйләп бир, — диде. — Нинди хәсрәт китерде сине мина, кем җибәрде?

Әллә кара уйлары бер генә секундка да башыннан чыкмагангамы, әллә инде карчыкның җылы куллары тәнен генә түгел, җанын да бер мизгелгә җылытып алгангамы, күнеле тулышты да куйды Белланың. Елады да

җибәрде. Аптыраган чуваш карчыгы да каушап төште. Елгыр хатын үзен тиз кулга алды. Чөнки әбинен талканы коры икәнен ишеткәне бар иде, йә куып кайтарыр дип, тиз генә яшьләрен сөртеп алды. Калтыранган тавыш белән тезеп китте:

— Бер әшәке көнчел хатын шушы көнгә төшерде мине. Килгәч тә яратмады, ирен көнләп хәле бетте. Улыма авырлы чакта сихерләде. Эдигымны паралич сукты. Житмәсә, ирем авария ясап кеше үтерде. Хәзер утыра, ә үземнен сул аягымны баладан сон төннәрен көзән җыера, түзәрлек түгел. Коточкыч хәлгә төштем мин, тетя Анна. Ул көн саен ике тапкыр сөт кертә, ә сөте эчендә гел сындырылган шырпы була. Гел шикләндем, шикләнеп яшәдем шунардан. Менә шунын сихерен үзенә кире кайтарсан иде дә, мине шул шик-шөбһәләремнән азат итсән иде. Пусть ул явызнын үзен көзән җыерсын, пусть аны парализовать итсен!

Ярсыган хатынны тыныч кына тынлап утырган карчык урыныннан торып янып беткән корымлы чәйнегенә су салды да, кызу тимер мич өстенә утыртты. Аннары тавышын күтәрә биреп:

— Белла кызым, син яшәгән авылда сөткә шырпы сындырып салу гадәте гомер-гомергә яшәп килә ул. Бернинди дә сихер-мазар түгел ул, ә куе сөткә сокланып, сыерга күз тимәсен өчен шулай эшләнә. Сөтле савытны кулына тоткан кешенен карашы тәүдә сөт өстендәге шырпыга төшә. Менә безнен авылда сөтле савытка кызыл җеп кисәге салалар. Шуны белми иденмени, юләркәй! — диде дә кеткелдәп куйды карчык.

— Юк, юк, бер дә алай түгел. Мин тиктәскә генә шикләнмим ул. Интуициям көчле минем. Шул Наратлы авылына килен булып килгәннән бирле күнелемне кара бер шом басты. Ул анын гына эше, тетя Анна! Ярдәм ит, зинһар! Елан күкәе белән сихерне кире кайтарып була дип ишеткән идем. Хакыннан тормам, түтекәем...

— Ай-вай, бу бик гөнаһлы эш, кызым. Точно шулай булса гына тәвәккәлләргә була. Шикләнгән кешеннен фотосы кирәк булыр. Аннары карарбыз. Ялгышсак, сихер бит минем үземә кире кайтуы ихтимал. Үләр вакытым житкәндә Тәнренен каһәренә юлыгасым бер дә килми...

Карчык кайнап чыккан чәйнеген өстәлгә куйды, чәй пешерде. Булган нигъмәтен куеп, яшь хатынны чәй табынына дәште.

— Юлда килеп сусагансыңдыр, утыр, чәйләп алыйк. Уйлап эш итәргә кирәк. Кара эшне бер дә уйламыйча эшләргә ярамый ул. Хәзер чәй эчеп ал да, әнә, теге усак урманы башланган басу читенә колхоз былтыр тирес ташыды. Көн кызуында шунда барып, тирес өемен актар да өч елан күкәе алып кайт. — Карчык яшь хатыннын йөзенә бәреп чыккан шатлык нурларын шәйләп, сүзен дәвам итте:

— Кичкә калырга ярамый, еланнарнын усал чагы, бәла-казадан башаяк. Аңладыңмы, өч күкәй алып кил. Менә сиңа көл салынган банка.

Чәен эчеп бетергәч, карчык догасын укыды да, тиз генә җыенып ихатага чыкты. Белланын исә бар үе бер тирәдә чуала, ачуын, бар агуын, көнчеллеген шул елан күкәйләренә урап, Зөһрәнен җылы, тату гаиләсенә тизрәк илтеп саласы да, тантана итәсе иде бер... Ул ашыга-ашыга усак урманына илткән басу юлына табан атлады. Тирес өемнәре янына килеп басты да, калтыранган кулларына резина перчатка киеп алды. Тирес эчендә кирәк белән актарына торгач, әллә унлап елан йомыркасы тапты. Шатлыгы эченә сыймаган хатын, елан күкәйләрен кадерләп кенә көлле банкага салды да, Берлинны яулаган совет солдаты кебек, гәүдәсен горур тотып, канәгать елмаеп кайтырга чыкты. Банкадагы көл өстенә салынган йомшак елан күкәйләрен күргәч, чуваш карчыгынын йөзенә ягымлы бер хәйләкәр елмаю чыкты. «Әһә, тузбашлар йомырка сала башлаган икән. Ярар

соң, өшкереп карыйк үзеңне. Жаныңда әз генә иман дигән нәрсә калган булса, бәлки, кортыңны косып, дөньяга күтең биеклегеннән түгел, ә акыл күзе белән бага башларсың. Кара син аны, фәрештәләргә тиң килендәшен — гомер буе күз терәп торган докторыбызны нишләтмәкче? Күнелендә кешегә карата үч, хөсет йөртеп, баланны карынында чакта ук гарипләткән булгансың син, матур мөртәт! Паралич синең ише зәхмәтләрне сугып, дөнья йөзендә йөртергә тиеш түгел ул! Житмәсә, Фирдүснең юып бауга эленгән трусигын да урлап алып килгән. Имеш, өшкереп бир, тетя Анна. Аны да үзенеке итмәкче! Өшкерермен, Фирдүс белән Зөһрәнең арасына жил дә үтмәслек, мәхәббәтләре үз гомерләренә житәрлек итеп өшкерермен? Әйбәт кешене күрәләтә әрәм иттерәмме соң! Озын-озын гомер бирә күрсен Тәнрем изге жанлы Зөһрә Хәләфовнага. Кара син аны... Тапкан кемне сихерләтергә, көтеп тор менә», — дип Беллага акаеп бер карады. Мыгырданып кына эчтән нииндидер догалар укый башлады. Белланың биле аркылы өч елан йомыркасын уратып чыгарган булды. Аннары тавышын йомшарта биребрәк:

— Кайткач та ачулы кешеңнең абзарына кереп, яндырылырга өелеп куелган тирес эченә тык, кызым. Өч көн дигәндә елан балалары борынлар, ә калган догаларын мин үзем укырмын. Тияр, сихәте тимичә калмас, борчылма, — дип яшь хатынны юмалап, ышандырып кайтыр юлга озатты.

Капка төбендә озатып калган Анна карчык канәгать кыяфәттә үзалдына елмаеп куйды. «Шәфкать туташы бит әле үзе, елан күкәе белән сихерләтә, имеш! Сихерләү безгә ярый торган эш түгел ул, милая. Ышанасын икән, әйдә ышана бир, жиз баш! Тузбашлар сезнең авылда да үрчесен әле, бәлки, елан күреп елан булудан тыелып кала алырсыз...» Белла исә, дөньяда иң көтеп алган, иң кадерле нәрсәгә юлыккандай, жылы көл эченә салынган елан йомыркаларын сак кына тотып, йөгерә-атлый Урман авылына юнәлде. Авылга борыласы юл чатында аны бер атлы-арбалы ир куып житте. Бөтен нигъмәтләрен уйнатып атлаган бу матур яшь хатынны мут ир карашлары белән чишендерә дә башлады. Урман һавасын сулый-сулый печән әзерләргә китеп барган яшь ирнең ымсынуы озакка сузыла төште. Ниһаять, ир кеше шаян елмаеп:

— Шушы кадәр дә гүзәл хатынны урман буена ялгызын нинди ахмак абзый чыгарып жибәрде икән? — дигән булды. Күзләре янып киткән ир алдында каушаганын сиздермәскә тырышып Белла:

— Чуваш авылына бер әбигә медицина ярдәме күрсәтергә барган идем. Әле Наратлыга кайтып барышым, — дигән булды.

— Мин — урман каравылчысы Риф абзаң булырмын, — әйдә, сылу, утыр, илтеп куям үзеңне.

«Урман каравылчысы ди бит. Тукта әле. Бу тузбаш күкәйләре белән генә эш кыра алуыма бер дә ышаныч юк. Әгәр... әгәр агулы кара елан тотып бирсә...» Башына кинәт килгән гениальный планга сокланып, кәефе күтәрелеп китте Белланың. Ирләр генә тотып ала алган серле карашларын сирпеп:

— Урманчы булгач, кайсы агачка нинди кош кунып сайравына кадәр беләсездер инде, — дигән булды.

— Синең өчен, чибәр апасы, ата сандугачның үзен дә тотып бирергә әзербез без, — дип такмаклады мут карашлы ир.

— Врач кешегә сайрар кош түгел шул, агулы чагар елан ешрак кирәк була. Чага торган елан кирәк мина,— диде Белла үпкәләгән сыман тонга күчеп.

— Һи, быел еланнарның күплеге! Урман сукмакларыннан тыныч кына

үтәрмен дип уйлама. Елан тек, елан. Тотабыз аны. Әле еланнарның самый зверь чагы. Буаз чагы диюем. Ике-өч көннән балалый башлыйлар инде алар. Ничәү кирәк? Мин айн момент,— дип, Белланың арт чүмечләренә төртеп алды. Үзе тагын ышанмыйча:

— Сиңа, чынлап та елан кирәкме, нигә кирәк ул? — дип кабаттан борылып сорады. Бакырбикә тавышын йомшартыбрак, ялыныбрак:

— Елан агуы таба алмыйбыз, авыру кешегә срочно кирәк, — диде дә, сумкасыннан «ялт» итеп бер литрлы шешәгә тутырылган спиртны тартып та чыгарды. Өстәп йөз тәнкә акча да сузды.

— Авыру үлем эчендә ята, зинһар, туган, ярдәм ит инде, — дигәч, яшь ир тукталып калды. Аннары биш бармагын җәеп чәчен тарап алды да, ашыга-ашыга урман эченә кереп югалды. Бакырбикә ара-тирә каранып, курка-курка гына әйләнә-тирәне урап килде. Калын, биек үлән үскән урман акланында шактый көтәргә туры килде Беллага. Ниһаять, ир каен тузыннан юкә белән берничә урыннан ныгытылган тартманы Белла алдына китереп куйды.

— Мә, авыруыгыз игелеген күрсен. Әнә теге җепне тартсаң, тартма ачылыр. Сак кына кыланыгыз, бу бик тә зәһәр, бик тә агулы — буаз елан.

Белла тартмадагы зәһәр еланны, тузбаш йомыркаларын да алып, зәһәр еланның үзеннән дә зәһәррәк булып кайтып керде өенә.

Кояш батып күз бәйләнер алдыннан банка белән тартмасын тотып шым гына Зөһрәләргә юнәлде. Ихатада беркем дә юк иде. Әле һаман эштән кайтмаганнар булса кирәк. Иркенрәк тын алып, абзар артына өелгән тирес арасына кулын тыгып тузбаш йомыркаларын куйды. Почмакта күшәп яткан сыерларны куркытмас өчен, читләтеп кенә абзарга үтте дә, түр якта өелеп куелган хуш исле печән өстенә туз тартманы куйды һәм җәһәт кенә җебен тартты. Үзе, арт ягын корт чаккандай, ялт итеп абзардан чыгып тайды. Ихатадан ничек чыгып киткәнен дә сизмәде бугай.

Өенә керү белән, чишенеп тә тормыйча, караватына ауды һәм тынычланып тирән йокыга талды...

Ләкин Бакырбикә-Белла тынычланып йоклап китсә дә, иленнән, жиреннән-урманыннан мәхрүм ителгән буаз кара елан җанына һич кенә дә тынгылык таба алмады. Ике-өч көннән тирес өеме эчендәге йомыркалардан тузбаш балалары пипылдап килеп чыга торды, тирес тирәсе янында тибенеп йөргән чуар тавыклар аларны томшыклары белән чукып, ашап бетерә тордылар. Ә печән эчендәге кара елан тулгагы тота башлагач, үрсәләнеп чыгар юлын эзләде. Ниһаять, ихатада шау-шу тынып калгач, сак кына шуышып бакчага чыкты. Түтәлләр аша шомырт агачы үскән каршы якка — Белла бакчасына табан юл алды. Үләннәрне ерып болдыр буенда үскән шомырт агачына шуышып менде дә, ачыргаланып ысылдый-ысылдый балалый башлады. Вак кына, суалчандай елан бәбәйләре агач кәүсәсе буйлап шуышып төшә тордылар һәм Белла яшәгән өйнең астына кереп югала бирделәр. Зәһәр елан шомырт ботагына шуышып менде дә җаны-тәне белән сеңеп калды. Таң аткач, Белла җылы урыннан торып күтәрмәгә чыгып басты. Аяк очларына басып, кулларын артка каера биребрәк киерелеп җибәрүе булды, шомырт ботагына инде генә хәл алам дип сузылып ятып йоклаган еланның яман ачуын чыгарды. Зәһәр итеп бер генә ысылады да, елан, үрелеп, агулы телен Белланың нәкъ вена тамырына батырды...

*Казанда «Яңа федератив Россиянең үсеше: Татарстан Республикасының конституцион законнар чыгару тәҗрибәсе» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Ноябрь башында узган әлеге чара ТР Конституциясен кабул ителүнең 20 еллыгына багышланды. Аны ТР Дәүләт Советы, Фәннәр Академиясе, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Казан (Идел буе) федераль университеты оештырды. Аның эшендә, Татарстан Республикасы җитәкчеләре белән бергә, якын һәм ерак чит илләрнең күренекле галимнәре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, Казакъстан, Кыргызстан, Әрмәнстан, Төркмәнстан һәм Россия Федерациясе төбәкләренең парламент делегацияләре катнашты.*

*Татарстанның Беренче Президенты, ТР Дәүләт киңәшчесе М.Шәймиев чыгышын һәм Конференциянең пленар утырышында Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә.Мазһаров ясаган төп докладны укучыларыбыз хөкеменә тәкъдим итәбез.*



## Минтимер ШӘЙМИЕВ:

## «Вәкаләтләребезгә тыкшыну ышанычны какшата»

Моннан 20 ел элек — 6 ноябрь көнне 14 сәгать 28 минутта республика Югары Советы Татарстанның яңа Конституциясен кабул итте. «Вакыт — иң яхшы хөкемдар». Төп законның — теләсә кайсы дәүләт Конституциясенең дә тормышчанлыгын чынбарлыкта чагылдырган гыйбарә бу. Катлаулы сәяси вәзгыятькә карамастан, кайвакыт үтеп тә булмаслык тоелган каршылыклар аша, Татарстан Дәүләт суверенитеты турында декларация һәм республика статусы турында 1992 елның 21 мартында узган бөтен халык референдумында тавыш бирү йомгаклары нигезендә эшләнеп, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Конституциясе кебек үк, кеше хокукларын һәм ирекләрен яклауны гарантияләп, шушы еллар эчендә республикабызның тотрыклы социаль-икътисади үсешен тәэмин итеп килә. Без яңа Россия Федерациясе төзүнең беренче адымнарыннан ук илебезнең иҗтимагый-сәяси һәм законнар чыгару — хокукый кырында аның федератив төзелешен яклап чыктык һәм чыгабыз, чөнки Россия дәүләтен демократияле төстә үстерүнең бердәнбер юлы бу. Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм федерациянең башка субъектлары конституцияләре бер-берсеннән килеп чыга.

Россия Федерациясе Конституциясенең 11 маддәсендә болай диелгән:

«...1. Россия Федерациясендә дәүләт хакимиятен Россия Федерациясе Президенты, Федераль Җыен (Федерация Советы һәм Дәүләт Думасы), Россия Федерациясе хөкүмәте, Россия Федерациясе судлары тормышка ашыра.

2. Россия Федерациясе субъектларында дәүләт хакимиятен аларның үзләре тарафыннан оештырылган дәүләт хакимияте органнары тормышка ашыра.

3. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр бүлешү һәм

вәкаләтләр чикләрен билгеләү ошбу Конституция, Федератив килешү һәм вәкаләтләр чикләрен билгеләү турында башка килешүләр нигезендә хәл ителә».

Үзәк белән элеккеге автоном республикалар һәм калган субъектлар арасында Конституция нигезендә вәкаләтләр чикләрен билгеләү мөмкинлеге — Россия дәүләте тарихында монархчы күрелмәгән вакыйга иде. Ул үзгәртеп кору елларыннан соңгы яңа җәмгыятьнең сәяси тормышында зур алга китеш булды.

Тик, ни кызганыч, оппозицион партияләрнең фракцияләре генә түгел, Россия республикаларында яшәүчеләр әлегә дәррәү яклап-хуплап, үзләренә тавыш биреп килгән «Бердәм Россия» партиясе депутатларының бер өлеше дә империячел фикерләү сагышыннан бүгенгәчә аерыла алмый. Конституциядә, Россия Федерациясендә суверенитет һәм хакимиятнең бердәнбер чыганагы булып аның күп милләтле халкы тора, дип ачык итеп билгеләнүгә карамастан, хакимият институтларының «Россия — руслар өчен» кебек өндәмәләрне рәсми төстә гаепләүләрен ишеткәнебез яки Конституциянең 14 маддәсен тиешле дәрәҗәдә төгәл үтәгәнебез юк (анда, дини берләшмәләр дәүләттән аерылган һәм закон алдында тигез, дип бик ачык язылган). Яисә законнар чыгару шартларын булдыру проблемасын алыйк. Россия Федерациясе Конституциясенең 68 маддәсендә, Россия Федерациясе барлык халыкларына туган телен саклау, аны өйрәнү һәм үстерүгә шартлар булдыру хокукын гарантияли, диелгән. Глобальләштерү шартларында милли республикаларда туган телне саклауга үтә зур тырышлыклар куелса да, Конституциядә игълан ителгән нормаларга каршы килеп, аерым федераль структуралар халыкларның туган телләрен өйрәнүгә хокукларын өлешчә кысуга юл куйган мәгариф стандартларын кабул итә. Дәүләтебездә милли мәсьәләләр проблемалары күзгә күренеп тора һәм алар тиешле хакимият институтын булдыру аша төптән уйланылган чишелеш-карарлар таләп итә. Әле ярый ил Президенты Владимир Владимирович Путин бу хакта тагын бер кат искә төшерде. Әмма күренеп торган проблемаларга күз йомарга ярамый. Аларны хәл итү дәүләтнең алга таба нигуына китерәчәк ләбаса.

Ни өчен бүген, Татарстан Республикасы Конституциясе көнендә, барлык хакимият структуралары, барлык дәрәҗәләрдәге иҗтимагый оешмалар тарафыннан иң элек Россия Конституциясен төгәл үтәү зарурилыгы турында сөйләргә туры килә? Минемчә, җавап бер генә — чынбарлыктагы демократик федерация булдыру өчен кирәк бу. Безнең моңа инануыбыз шактый катлаулы булган соңгы егерме еллагы социаль-сәяси тормыш тәҗрибәсе белән раслана. Бу еллар РФ һәм ТР Конституцияләренең кайбер җитешсезлекләренә, кайбер нигезләмәләренең бер-берсенә туры килмәүләренә карамастан, бүген безнең өчен тотрыклылык гаранты булып торуын күрсәтә.

Конституция нигезендә вәкаләтләр чикләрен ике як өчен дә кулай итеп билгеләү мөмкинлеге гамәлдәге Конституцияләрне үтәү-тануның төп нигезе булып тора. Башка юл юк. Безгә алга таба да, зирәклегебезне җуймыйча, бауны үзебезгә артыгын тартмыйча, вәкаләтләр чикләрен билгеләү механизмын камилләштерү юлларын эзлисе иде. Шуны ассызыклап үтәсем килә: федерация субъектларыныкы гына булган вәкаләтләргә теге яки бу тыкшынулар депутатларга һәм Федераль Җыен вәкилләренә — ахыр килеп, югарыгы законнар чыгару хакимиятенә ышанычыбызны какшата. Федерация субъектларының гына карамагындагы яки уртак карамактагы вәкаләтләрне үзәк файдасына «аударып» кабул ителгән федераль законнар байтак.

Бу җәһәттән иң элек, Россия Федерациясе субъекты башлыгы Вазифасы атамасы буенча 2010 елның декабрендә кабул ителгән «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законга үзгәреш кертүне мисал итеп китерергә була.

Төрле чакырылышларның күп кенә депутатлары инде 2001 һәм 2005 елларда ук Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатлары Ищенко һәм Харченко тәкъдиме белән мондый үзгәреш кертүне кабул итү омтылышы булганын белә.

Шул ук вакытта шуны да беләбез: алар тарафыннан кертелгән закон проекты Россия Федерациясе Хөкүмәте ягыннан рәсми төстә инкарь ителде. Рәсми инкарьда, бу тәкъдим Россия Федерациясе субъектларының үз дәүләт хакимияте органнары атамаларын мөстәкыйль билгеләүгә хокукын чикли һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 11 маддәсенә каршы килә, дип күрсәтелгән иде.

Нәтиҗәдә Россия Федерациясе Дәүләт Думасының 9 декабрь, 2005 елгы карары нигезендә әлеге закон проекты кире кагылды.

Бу җәһәттән законнарны төгәл үтәргә тырышучы гражданнарыбыз (ә хәзер алар кемгә караганда да актив): «Шуннан бирле нәрсә үзгәрде, дәүләтнең Төп законын үтәүгә салкынрак карый башладыкмы әллә?» — дип аптырый.

Мәгълүм булганча, Россия Федерациясе Конституциясеннән бер елга алданрак кабул ителгән Татарстан Конституциясе, һичшиксез, аның кануннарына тулысынча туры килеп бетә алмый иде. Үзгәртеп кору елларыннан соңгы чордан күренгәнчә, гражданнарыбызның тормыш сыйфатын яхшыртуга, хокукларын һәм ирекләрен саклауга юнәлдерелгән тырышлыклар фәкать Россиянең, республикаларның конституцияләрен һәм федерациясе субъектлары уставларын үтәү нигезендә генә нәтиҗәле булырга мөмкин. Өстәвенә, инде алдан әйтеп үткәнемчә, үзара килешү өчен вәкаләтләр чикләрен билгеләүнең үтемле, әйбәт механизмнары бар. Яңа гына оешкан яисә бүген гамәлдә булган, тик перспективалары әллә ни күренмәгән партияләр һәм хәрәкәтләрнең «Нигезенә кадәр җимерик тә, аннан соң...» кебек теге яки бу өндәмәләрен без инде күптән ишеткән. Алар безгә кыйммәткә төште... Мондый өндәмә-белдерүләр Конституциягә каршы килә, һәм аек акыллы кешеләр өчен һич кулай була алмый.

Конституциябезне кабул итү көне алдыннан, Конституция Комиссиясе Рәисе буларак, сәяси карашларына бәйсез рәвештә, яңа Татарстанның киләчәген кайгыртып, шәхси амбицияләрен читкә куеп, Төп законыбызны бертавыштан кабул иткәннәре өчен, шәхсән үз исемемнән һәм Татарстанда яшәүче барча халык исеменнән республика Югары Советы комиссияләренә, депутатлары һәм җитәкчелегенә, Министрлар Кабинеты, Президент аппаратының җаваплы хезмәткәрләре, галимнәр, иҗтимагый эшлеклеләргә рәхмәт белдерәсем килә. Бик зур рәхмәт сезгә!

Шул еллардагы катлаулы эш татар милләтенә мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртте, лаеклы киләчәккә юнәлешле милли үзаңның үсүенә китерде. Социаль-икътисади, сәяси һәм мәдәни өлкәләрдә күп милләтле республикабызның күзгә бәрелеп торган уңышлары «Без булдырабыз!» дигән сүзләрне тагы да ышанычлырак әйтү мөмкинлеге бирә.

Чын күңелдән рәхмәт, исәнлек-саулык, иминлек сезгә. Булдырабыз, эшлибез, яшибез. Бәйрәм белән!

---



## Әхмәт МАЗҺАРОВ

## Татарстан Республикасы Конституциясе: тарих һәм бүгенге көн

Без бүген гаять әһәмиятле вакыйга — Татарстан Конституциясенең 20 еллыгы уңаеннан җыелдык. Республиканың төп Законы Татарстанда яшәүче күпмилләтле халкыбызның, татар халкының күптәннән килә торган барлык өметләрен һәм гамьнәрен, киләчәккә ышанычын үзенә туплаган хәлиткеч документ булды. Бер үк вакытта ул Россиядә яңа федератив дәүләтчелек урнашу этабына хас проблемаларны һәм катлаулылыкларны чагылдыра. Нәкъ менә Конституциядә без беренче тапкыр хокукый социаль дәүләтне, демократия ирегең һәм халыкларның иминлеген югары кыйммәт буларак игълан иттек. Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич Миннеханов Республика Дәүләт Советына юлламасында билгеләгәнчә, «Татарстан Конституциясенең егерме еллыгы Төп законның тарихи әһәмиятен һәм республиканың заманча дәүләтчелеге формалашудагы ролен ассызыклап күрсәтте».

Егерме еллык ул – бәйрәм дә, узганнарга йомгак ясау да, һәм киләчәккә үсеш перспективалары турында уйланулар вакыты да. Шуна күрә конференция уздыру эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе башлап йөрде. Чөнки без, рәсми фикер белән һәрчак туры килеп бетмәсә дә, ил тарихын, халыкара хокукны, республиканың күпмилләтле халкы мәнфәгатьләрен исәпкә алып, үз фикерен турыдан-туры әйтә торган фәнни оешма.

Татарстан Фәннәр академиясе 10 академик институтны һәм 23 гамәли фәнни-тикшеренү институтын; 40 хакыйкый һәм 80 мөхбир әгъза, 30 шәрәфле һәм 14 чит ил әгъзаларын берләштерә. Алар арасында Нобель премиясе лауреаты Ж.И. Алферов та, Р.З. Сәгъдиев, Р.А. Сөнәев, Хәрби Фәннәр академиясе президенты, армия генералы М.Ә. Гәрәев, М.Б. Пиотровский, Россиянен Бөекбританиядәге илчесе А.В. Яковенко һ.б. дөньякүләм танылган галимнәр дә бар. Безнен өчен Татарстан шушы елларда үткән юлны бәяләү һәм көнүзәк мәсьәләләрне үзебез күргәнчә тәкъдим итү мөһим.

Татарстанның беренче Конституциясе 1926 елда кабул ителгән иде. Ул 1920 елда төзелгән милли дәүләтчелек формасын ныгытты. Татар автономияле совет социалистик республикасы ул вакытта ук инде дәүләтчелекнен кайбер атрибутларына ия була. Алар – конституция, закончылык, территория, рәсми административ оешмалар, дәүләт телләре һәм символлары. Рус теле белән беррәттән, татар теле дә актив өйрәнелә, милли мәдәниятләр хөкүмәттән финанс ярдәме ала.

1936 елгы СССР Конституциясен әзерләү барышында республиканың статусын союз дәрәҗәсенә күтәрү турында тәкъдимнәр әйтелә, ләкин Сталинның бу мәсьәләгә карата катгый позициясе бары тик автоном статусны кабат беркетүгә генә китерә. 1937 елгы ТАССР Конституциясендә аеруча мөһим нормалар «Дәүләт төзелеше» дип аталган аерым бер бүлеккә туплана, ТАССР гражданлыгы, шәхси суд органнары һ.б.ш.ны булдыру хокукы турында нигезләмә эшләнә. Әлбәттә, тоталитар режимның ныгуы сәбәпле, республиканың фактик хокуклары партия оешмаларының карарларын үтәүне оештыруга кайтып кала. Шуна да карамастан, аерым республика төзелү, мәдәниятне үстерү максатыннан кайбер оешмаларга нигез салыну унай йогынты ясый һәм зуррак мөстәкыйльлеккә ирешү юлында мөһим этап була.

Ил тарихындагы сугыштан сонгы чор, шәхес культын фаш итүгә карамастан, республика хокукларын киңәйтүгә китермәде. Киресенчә, коммунистик идеология милләтләрнен берләшүен котылгысыз дип игълан итте, хакимият татарлар өчен тел, мәгариф, китап бастыру, массакүләм мәгълүмат чаралары кебек өлкәләрдә чикләүләр кую ягыннан конкрет адымнар ясады.

Шул чорда республика, «Милләтләрнен һәм телләрнен югалуы – бөтен кешелекнен генофонды җимерелү», дигән аксиомага таянып, татар мәдәниятен саклау мәсьәләсендә үзенчәлекле калкан ролен үтәде. Совет федерациясенен формаль төстә булуы һәм номиналь дәүләтчелек республикага үз икътисади һәм мәдәни сәясәтен корырга мөмкинлек бирмәде. Шул ук вакытта Татарстан зур үсеш алган сәнәгате, авыл хуҗалыгы, фәне һәм югары мәгарифе булган көчле төбәккә әйләнә барды.

1978 елгы Конституцияне кабул иткәннән сон, Татарстанның дәүләтчелеген билгеләүдә берникадәр үзгәрешләр барлыкка килде, хокук институтлары «Татарстан АССРның милли-дәүләти һәм административ-территориаль төзелеше» исемен алды. Үзгәрешләр шулай ук Татарстан АССР белән РСФСР арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә, республиканың РСФСР карамагында булган аерым мәсьәләләрне чишүдә катнашуына кагылды. Шуның белән бергә, 1978 елгы Төп Закон автономия статусының дәүләти-хокукый билгеләре исемлеген теркәп бара торган нормаларны үзгәрешсез калдырды.

1978 елгы ТАССР Конституциясенә кертелгән төзәтмәләр халыкның социаль-икътисади һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмадылар. Зыялылар арасында әледән-әле СССРда республикаларның тигез хокуклы булмавы, Татарстанга союздаш республика хокукы бирү турындагы мәсьәләләр күтәрелә иде. Үзгәртеп корулар башлангач, мондый фикерләр матбугат битләренә дә үтеп керде, аннары

«Татариягә — союз статусы!» дигән лозунг астында күпсанлы митинглар рәвешен алды. Сүз иреге шартларында кешеләрнең фикере хокук чыгаруның аерылмас өлешенә әверелде.

Бүген без, Конституциянең отышлы һәм отышсыз яклары турында фикер алышканда, еш кына аның Татарстан өчен генә түгел, гомумән бөтен ил өчен үтә дә авыр шартларда әзерләнүен оныттабыз. Конституциябезнең әһәмиятен тиешле дәрәҗәдә бәяләү өчен 90нчы еллар башындагы вәзгыятьне искә төшереп үтү кирәк.

Үзгәртеп кору — асылда җәмгыять төзелешендә революцион үзгәрешләр барышында, сүз иреге, демократия, базар мөнәсәбәтләрен игълан иткәндә без Россия Совет Федератив Социалистик Республикасында гамәлдәге хокук кысаларында яшәүне дәвам иттек. Сәясәтчеләр капиталистик мөнәсәбәтләрнең янадан торгызылуы турында сүз алып барды, ә ил фактик һәм юридик яклардан социалистик ил булып кала бирде. Иске структураларны үзгәртү һәм тоталитар ялган федерациядән (асылда империядән) — чын, реаль федерализмга күчүнең ышанычлы юлларын эзләү барды. Бу иҗади процесс иде. Туа килгән күпсанлы сорауларга беркемдә дә анык кына җавап юк. Демократия нормаларын үтәү Татарстан законнары җыелмасында авыр тарихлы, үпкәләре һәм күпсанлы стереотиплары җыелган күп милләтле халыкның мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны таләп итте. Төрле позицияләрне һәм сәяси карашларны, яңа социаль-иҗтимагый мөнәсәбәтләргә күчүнең кулай вариантын табу өчен, үзара килештерергә кирәк иде.

Республика житәкчелеге һәм халкы ССР союзын Татарстан республикасының статусын Союз дәрәҗәсенә күтәреп яңарту өмете белән яшәде. 1991 елгы «Татарстан Республикасының Союз килешүе төзүдә катнашуы турында Белдерү»дә шундый юллар бар: «Татарстан ССР Югары Советының Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул иткәннән соңгы карарларының асылы шунда, Татарстан Республикасы үзен, башка барлык союздаш республикалар белән беррәттән, ССР Союзын мөстәкыйль төзүчеләрнең берсе сыйфатында карый. Әлеге позиция республикаларны союздаш һәм автоном рангларга бүлүне бетерүгә һәм СССРны тигез хокуклы республикалар Союзы буларак ныгытуга юнәлтелгән».

Ул чакта беркем дә СССР таркалыр дип уйламады һәм барлык таләпләр союз статусын тануга кайтып калдылар. Искә төшереп үтәсем килә: ул вакытта республикалар гына түгел, Россия үзе дә хокуксыз иде, суверенитет игълан итеп, ул үзенең лаеклы статусы өчен көрәште. Ә Татарстан тагын да хокуксызрак хәлдә иде. Мисал өчен, республиканың ул елларда барлыгы 2 процент милке бар иде, ә сәнәгатьнең 80 проценты союз милкендә иде. Нинди автономия турында сүз була ала? Республика бөтен Балтыйк буе кадәр эшләсә дә, акчасын татар зыялылары сораганча үз мәдәнияте үсешен тәэмин итүгә тота алмады.

Республика өчен башлангыч хокукый акт булып 1990 елның июнендә кабул ителгән Россия дәүләт суверенитеты турындагы Декларация торды. Анда бөтен халыкларга үзләре сайлаган милли дәүләтчелек формасында үзбилгеләнү хокукы бирелгән иде. Шуннан соң Татарстан да үзенең Дәүләт бәйсезлеге турындагы Декларациясен кабул итте. Россия белдергән хокукларга туры килү өстенә, моны халык үзе дә катгый таләп итте. Ул көннәрдә Россиянең шул чактагы Президенты Борис Ельцин Казанга килде һәм инде хәзер бар кешегә дә таныш булган канатлы сүзләрне әйтте: «Суверенитетны булдыра алган кадәр алыгыз!». Ул Татарстанда халыкның кәеф-хәлләтен үз күзләре белән күрде. Татар милли хәрәкәте активистлары гына түгел, зыялылар, аерым партияләр, хәтта Казанның, башка шәһәрләрнең, республика авылларының гади кешеләре дә мөстәкыйльлек даулады. Бу — заман авазы иде. Әлеге авазга колак салмый калу мөмкин булмады.

Бүген күпләр Ельцинны Татарстан суверенитетына теләктәшлек күрсәткәне өчен ачуланалар, ләкин ул шуның белән киеренкелекне йомшартты. Урамнарда өзлексез митинглар бара, милләтара каршылыклар бәрелешләргә күчү белән яный, уннарча партияләр матбугат битләрендә бәхәсләшә, парламентта депутатларның кайнар дебатлары бара. Сәяси көчләр позицияләренең капма-каршы якка аерылуы һәм килешмәүчәнлекләре территорияләрнең идарә ителмәс хәлгә килүенә китерергә мөмкин иде.

Эш 1991 елнын 24 октябрендә «Татарстан Республикасынын дәүләт бәйсезлеге акты»н кабул итүгә кадәр барып җитте. Анда шундый юллар бар: «Татарстанның Дәүләт бәйсезлеге турында Актның үтә дә әһәмиятен искә алып, шуна бәйле рәвештә республиканың югары органнарына, аның күпсанлы халкына йөкләтелгән җаваплылыкны истә тотып, Министрлар Кабинетына бер ай вакыт эчендә, республиканың бәйсезлеге турындагы Актны кабул итү нәтиҗәсе буларак, Татарстан Республикасының сәяси-хокукый, социаль-сәяси хәл-халәтендәге үзгәрешләр хакындагы анализ-прогнозны Татарстан ССР Югары Советы тикшерүенә куюны йөкләргә». Әлеге документта сүз, әлбәттә, тулы бәйсезлек турында бармый, ул заманында янартылган ССР Союзының тиңдәше кебек кабул ителгән Бәйсез Дәүләтләр Оешмасына керү теләген чагылдыра. Бер үк вакытта Акт хисләрнен кайнарлык дәрәҗәсен күрсәтте, ул үзеннән-үзе Россия Федерациясен республика белән сөйләшүләр алып барырга этәрде. Икенче яктан, Мәскәүдә Россиянең бөтенлегенә куркыныч янау, республикалардагы сепаратизм һәм алар тарафыннан РСФСР Конституциясе бозылу турында сүзләр ишетелде, сәясәтчеләр һәм депутатлар иң катгый чаралар күрүне таләп иттеләр. Алар Россия хокук актларынын үзләре үк әле һаман да совет, социалистик булып калган Конституциясен бозуларын онытала иде.

Шундый катлаулы шартларда Б.Н. Ельцин ачыктан-ачык демократиягә күчү кирәклеге турында белдерде, һәм аның алдына тоталитар системаны чын федерациягә әйләндерү механизмы мәсьәләсе килеп басты. Ил Президенты Татарстан Республикасы халкының ихтыярына каршы бара алмый иде. Җитмәсә, башка республикалар, шулай ук өлкәләр дә күбрәк хокук һәм ирек таләп иттеләр. Берләнбер юл булып төбәкләргә максималь мөстәкыйльлек бирү калды.

Безнең Конституция Татарстанның дәүләт суверенлыгы турындагы Декларациягә нигезләнеп туды. Декларация республиканың барлык күп милләтле халкы исеменнән кабул ителгән суверенитетның табигатен, ике дәүләт теленең дә тигез хокуклы булуын билгеләде, кеше хокукларын һәм ирекләрен, шулай ук РСФСР белән шартнамә төзүнең зарурилыгын игълан итте. Шуның белән бергә, Конституциягә таба хәрәкәт юлында 1992 елның мартына билгеләнгән республика статусы турындагы референдум мөһим адым булды. Ул яшәп килүче хакимиятнең легитимлыгын раслау, аның стратегиясенең дөреслеген бәяләү, халыкның төрле катлам вәкилләрен республикабызның абруен күтәрү максаты тирәсенә берләштерү ихтыяҗыннан үсеп чыкты.

Референдумда «Татарстан Республикасы — Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә кора торган суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуы белән сез килешәсезме» дигән сорауга җавап бирергә кирәк иде. Тавыш бирү көне якынайган саен, сәяси вәзгыять ахыр чиккә җитеп киеренкеләнде. Мәскәүдә кайбер аеруча кайнар башлар Ельцинга Татарстанга гаскәр кертергә тәкъдим иттеләр. Россия Федерациясенең Конституция суды референдум үткәрүнең дөрес түгеллеге турында карар чыгарды, ягъни халыкны үз ихтыяҗларын белдерүнең иң демократик формасыннан мәхрүм итте. Россия Федерациясе һәм аның карамагындагы республикалар арасындагы мөнәсәбәт Конституция нигезендә төзелергә тиеш, алар килешергә мөмкин, әмма ул килешүләрнең дә шулай ук федераль Конституциягә нигезләнүе шарт, дигән хокукый позициянең дөреслеген суд нигезләде. Әмма яна Конституция әле кабул ителмәгән, ә искесе Россиянең дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә каршы килә. Хокукый коллизия хасил булды. Билгеле, мондый шартларда Конституция суды хокукый түгел, ә сәяси карар кабул итте.

Шушы вакыйгаларга бәйле рәвештә республиканың Югары Советы түбәндәге «Белдерү» белән чыкты: «Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты һәм референдум турындагы актлары берничек тә Россия Федерациясенең дәүләти һәм территориаль бөтенлегенә янамый... Алар республика гражданнарын милли һәм дини билгеләре буенча дискриминацияләмиләр һәм бүлмиләр, ә гражданнарның, нинди милләттән булуына карамастан һәм дини ышануларына бәйсез рәвештә, тигез хокукларыннан чыгып, татар һәм рус телләрен дәүләт телләре сыйфатында

нығыталар... Татарстан Республикасының күрсәтелгән актлары РСФСРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациясенең 4нче маддәсе һәм Россия Федерациясенең халыкара хокук бурычлары тарафыннан билгеләнгән халыкларның ирекле милли-дәүләти үзбилгеләнү принципларына туры килә». Бу вакыйгаларны һәм шул вакытта кабул ителгән документларны кабат искә төшерергә мәҗбүрбез: чөнки бүген дә, республика 90нчы елдан һәр этапта Россиянең хокук нормаларына һәм халыкара стандартларына тулысынча йөз тотуга карамастан, Татарстан адресына Россияне җимерүгә омтылышларда, илнең законнарын бозуда гаепләүләр ишетелә.

Сепаратизмда уйдырма гаепләүләр Татарстанның 1991 елның августыннан башлап федераль үзәк белән ике яклы килешүләр төзү турында сөйләшүләр алып бару факты белән дә кире кагыла. Әлеге сөйләшүләр ышанычлы булды. Әйтик, 1991 елның 15 август Беркетмәсендә «мөнәсәбәтләрне җайлауның килешү формаларын куллануга йөз тоту» кирәклеге билгеләнгән иде. 1992 елның 2 апрель Беркетмәсендә яклар, «Россия Федерациясенең бөтенлеген саклап калу теләгеннән чыгып», «Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе арасында аерым мөнәсәбәтләр урнаштыру кирәклеге турында» килештеләр. Катлаулы сөйләшүләр алып бару өчен Татарстан делегациясе хокукый теләктәшлеккә мохтаҗ иде. Бу яктан Татарстан Конституциясен кабул итү аеруча әһәмияткә ия.

Югары Совет тарафыннан Минтимер Шәрипович Шәймиев җитәкчелегендә Конституция комиссиясе төзү турындагы карар инде 1991 елның 31 августында ук кабул ителде. Күпчелек халык республиканың статусын саклап калу өчен тавыш биргән референдум Конституция кабул итү юлында гаять мөһим этап булды. Шуннан соң сәяси вәзгыять тотрыклылана башлады. Төп закон проекты өстендә эш ике елдан артыкка сузылды, аның барышында илебезнең федератив төзелеш тәҗрибәсе, чит дәүләтләрнең конституция төзелешендәге фәнни һәм гамәли үрнәге исәпкә алынды. Проектны бөтен халык тикшерүе вакытында республика гражданнарыннан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керде. Хатлар һәм телеграммалар республикадагы районнардан гына түгел, чит төбәкләрдән дә күпләп килде. Документ шулай ук җирле советларда, иҗтимагый оешмаларда тикшерү узды. Татарстан Конституциясен әзерләүчеләр фикеренчә, ул чит илләрдә конституцион закон чыгаруның иң яхшы якларын исәпкә алырга һәм халыкара хокук нормаларына туры килергә тиеш иде. Документ проектын тикшерүгә танылган чит ил белгечләре, шул исәптән, Швейцария, Алмания (Германия) галимнәре җәлеп ителде. Алар барысы да Төп законның ахыргы вариантына уңай бәя бирделәр.

Конституция бик җентекләп, кайнар бәхәсләр эчендә әзерләнде, кайвакыт парламентта фикерләрнең каршылыгын үзара килештереп булмас кебек тоела иде. Бәхәсләр шулай ук Югары Совет стеналарыннан тышта да кызды. Республика җитәкчеләренең хәле турында М.Ш. Шәймиевнең түбәндәге сүзләре гыйбрәтле: «Берәүләр безне акрын кыймылдаган өчен, икенче берәүләр – ашыккан өчен тәнкыйть иттеләр, һәм һаман да тәнкыйтьләүләрен дәвам итәләр. Кемнәрдәндер без, янәсе, Россия составыннан чыккан, аның белән тарихи һәм башка мөнәсәбәтләрне өзгән өчен шелтә сүзләре ишетсәк, икенче берәүләр безне Россия белән сөйләшүләр алып барган өчен тәнкыйтьләделәр». Акрынлап алтын урталык табылды. Милләтара, сәяси һәм социаль мәсьәләләрдә мәнфәгатьләрнең тигезлеген булдыру принцибы мәҗбүри нормага әйләнде.

Татарстан Конституциясе Россия Конституциясеннән бер ел алда кабул ителде һәм соңгысының эчтәлегенә дә йогынты ясады. Республикада кабул ителгән карарларның Россиядән алдан баруы 1993 елгы Конституция кинәшмәсенең эшендә этәргеч фактор булды. Россия Федерациясе Төп законының республикалар мәнфәгатьләре чагылган аеруча әһәмиятле маддәләре дә шул хакта сөйли. 5нче маддәнең 2нче пунктындагы «республиканың үз конституциясе һәм законнар системасы бар» дигән формулировка республикаларда яшәп килгән тәҗрибәне исәпкә ала. 68нче маддәдәге түбәндәге сүзләр зур казаныш булды: «Республикалар үзләренең дәүләт телләрен урнаштыру хокукына ия. Республиканың дәүләт җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә алар Россия Федерациясе теле белән беррәттән кулланыла». Боларда халыкның бик күптәннән яшәп килгән тигез

хокукка омтылышы чагыла. Үзәк белән субъектлар арасында килешүләр төзеп (11нче маддә, 3 п.) идарә объектларын һәм вәкаләтләрне бүлешү турындагы үтә мөһим нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясенең башлангыч проектында юк иде. Ул нигезләмә Дәүләт бәйсезлеге турында Декларациянең һәм Конститутициянең үзәк белән килешүле мөнәсәбәт урнаштыру таләбенә тугры республика житәкчелегенең максатчанлыгы нәтиҗәсендә пәйда булды. Әлеге маддәне кабул итүнең нәтиҗәсе булып киң масштабларда килешүләр төзелү санала ала.

1994 елгы Шартнамәнең безнең республика үсешендә роле искиткеч зур булуны ассызыклап узарга кирәк. Россия тарихында беренче тапкыр үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәт административ команда бирү диктаты ярдәмендә түгел, ә үзара шартнамәләр рәвешендә төзелә башлады. Шартнамә Татарстан белән федераль үзәк арасында сәяси аныклык кына кертеп калмады, ә республика гражданнарының сәяси һәм икътисади эшчәнлегенә иҗади рух өстәп, халыклар күңелендә тынычлык урнаштырды. Акрынлап халык 90нчы еллардагы митингларны һәм каты бәхәсләрне оныта башлады.

Ике яклы мөнәсәбәтләрне җайга салуның бер нәтиҗәсе республиканың федераль органнарга сайлауларда катнашуында күренде. 90нчы еллар башында Татарстанда гомумфедераль парламентка һәм Россия Президентын сайлаулар узмады. Килешүгә кул куелганнан соң хәл тамырдан үзгәрде, һәм 1995-96 елларда республика җирлегендә илнең закон чыгару органнарына узган сайлаулар гомуммилләт юрисдикциясен тануны белдерде, Россия белән Татарстанның «бәйсезлек нисбәте» турындагы бәхәсләренә нокта куйды.

1994 елгы Шартнамәгә кул куюны Татарстандагы күпмилләтле халыкның үзләре сайлаган формада үзбилгеләнүен федераль үзәкнең тануы дип карарга мөмкин. Алга таба хөкүмәтара Килешүләр пакетын имзалау Мәскәү белән Казан арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә цивилизацияле төсмер өстәде, Россия һәм Татарстан җитәкчелеге бөтен дөнья җәмәгатьчелеге каршында халыкара хокук нормаларын саклауларын күрсәттеләр. Болар барысы бергә «Татарстан моделе» дигән исем алды. Еллар үткән саен без бу модельнең республикада тынычлыкны саклауда гына түгел, ә башка төбәкләр өчен дә милләтара мәсьәләләрне конфликтсыз чишүнең, социаль-икътисади проблемаларны уңышлы хәл итүнең, федератив мөнәсәбәтләрнең отышлы формуласы буларак әһәмиятен ныграк аңлый барырбыз

20 ел эчендә республика федератив мөнәсәбәтләр кору үрнәге генә түгел, ил икътисадын яңарту мәйданының флагманы булып җитеште. Татарстан конституциясе хөкүмәткә, сәнәгатьчеләргә, белгечләргә мөстәкыйль икътисади сәясәт булдырырга мөмкинлекләр тудырды. Иң әүвәл, җитәкчелек алдында республика территориясендәге СССР һәм Россия милекләрен бүлү бурычы тора иде. Безнең хокукый позиция оборона сәнәгатеннән тыш барлык милекне дә диярлек Татарстан кулына күчерергә мөмкинлек бирде. Бу икътисадны базар мөнәсәбәтләренә күчергән вакытта хәлиткеч роль уйнады. «Базар мөнәсәбәтләренә йомшак керү» хосусыйлаштыруга әзерлекле якын килергә җай тудырды, халыкны массакүләм хәерчелектән коткарды, адреслы социаль ярдәм күрсәтер өчен шартлар булдырды, авылны саклап калды, мәдәниятне яклауга юл ачты. Нәтиҗәдә Татарстанның беренче Президенты М.Ш. Шәймиев җитәкчелегендә республика «Иске торакларны ликвидацияләү» программасын, йөз процентлы газлаштыруны, юллар төзүне, телефонлаштыруны һәм интернетлаштыруны башкарып чыкты. Заманча инфраструктура булдыруда 90нчы елларда яулап алынган мөстәкыйльлек ярдәм итте.

Икътисади стратегияне төзүдә мөстәкыйльлек, республикабыз Президенты Р.Н. Миннеханов һәрчак ассызыклаганча, чималга бәйлелектән – нефть химиясендә һәм химиядә, автомобильләр төзү сәнәгатендә, авиациядә, it-сферада, авыл хуҗалыгында югары технологияләргә күчәргә мөмкинлек бирде. Сәяси тотрыклылык һәм югары сыйфатлы законнар системасы Татарстанның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген күтәрде.

Республиканың казанышларына халыкара элемтәләр сферасын да кертеп була. Федераль үзәк республиканы халыкара система субъекты буларак карамаса

да, фактта Татарстан халыкара бәйләнешләрен актив үстерә. Ел саен республика йөзләрчә иң югары дәрәҗәле делегацияләр кабул итә. Үз чиратында, безнең вәкилләр рәсми визитлар белән төрле илләрдә булалар һәм күпсанлы килешүләр имзалана. Күп илләрдә Татарстанның вәкиллекләре ачылды. Республика шулай ук халыкара оешмалар тарафыннан да танылды. Аерым алганда, Европа төбәкләре конгрессында актуаль мәсьәләләр буенча комитетны Ф.Х. Мөхәммәтшин житәкли. Халыкара бәйләнешләр республиканың абруен күтәреп кенә калмады, икътисади эшчәнлекнең мөһим элементына да әверелде.

Безнең хокук белгечләренең шиксез казанышы булып Россия субъектларының халыкара эшчәнлек принципларының федераль кануннарда һәм аларга нигезләнгән актларда закон белән теркәлүе тора. 1994 елдагы Килешүдә теркәлгән төп нигезләмәләр Россия кануннар системасына урнаштылар һәм бөтен Россиядә гамәлгә керделәр.

Совет чорында игътибар үзегеннән читтә калып килгән мәдәният һәм милли мәгариф системасы безнең өчен четерекле өлкә иде. Аларның әһәмиятен мәгърифәт кысаларында гына аңлау дөрес түгел. Татар мәдәниятен, милли мәгарифне үстерү үз чиратында халыкның милли үзаңын күтәрү, бигрәк тә яшь буынны милли тормыш, көнкүреш, йола-гадәтләр даирәсендә туган телле итеп тәрбияләү белән бәйләнгән. Республиканың мөһим хокукый инициативасы булып Татарстан Конституциясендә (14нче маддә), ә аннары Килешүләрдә татар мәдәниятен үстерү өчен илкүләм жаваплылыкны беркетү тора. Федераль хакимият мондый караш белән килешеп кенә калмады, аны хуплап та чыкты. Бүген уртак мәдәни сәясәтнен гәүдәләнеше булып ил төбәкләрендә Россия күләмендәге сабантуйлар уздыру күрсәтелә ала. Юлдаш телевидениесе һәм Интернет мөмкинлекләре Россия һәм БДБ гражданнарына Татарстанда, дөньяның төрле почмакларында яшәгән татар жәмгыятьләренең эшчәнлеге турында мәгълүмат биреп торуны яңа баскычка күтәрде. Планетаның күпчелек өлешенә ике дәүләт телендә тәүлек буе тапшырулар алып бару безнең уңышларыбызның һәм мәдәният өлкәсендәге мөмкинлекләребезнең символына әверелде.

СССРда барлык автономияләрнең дә Конституцияләре бер үрнәкне күчереп язылган иде. Үзгәртеп корудан соң республикалар үзләренең законлык актларын эшли башладылар. Бу «суверенитетлар парадында» һәм кайвакыт стихияле закон чыгаруда, әлеге процессны күпме генә сүксәләр дә, позитив момент бар: кешеләрдән аларның нәрсә көткәннәрен сорадылар. Законнарны унификацияләү билгеле бер дәрәҗәдә генә файдалы, ләкин ил төбәкләренең төрлелеген исәпкә алмау үзен тулысынча фаш иткән бер партия житәкчелеге астындагы социалистик, иске идарә системасына кире кайтуны белдерер иде. Татарстанда хокук актларының әйдәп баруы ул вакытта котылгысыз булса, ул бүген дә тиешле кысаларда бик кирәк. 90нчы еллар ахырында безнең законнарны федераль законнар белән тәңгәлләштерү чоры житте. Галим буларак мин бик яхшы аңлыйм: республика Конституциясе объектив рәвештә даими камилләштерүне сорый. Россия жәмгыятенең һәм Татарстан Республикасының үсеше чишелешләрен табу котылгысыз булган конституцион төстәге яңа мәсьәләләрне көн тәртибенә куя килә.

Бөтендөнья практикасында конституцион төзелешкә кагылышлы төрле карашлар очрый. Бөекбританиянең асылда язмача конституциясе юк. АКШта нибары 7 маддәдән торган конституция 1787 елда кабул ителгәннән соң, аңа бары тик 26 төзәтмә ясаганнар. Кайбер илләр вакыт узу белән Төп законнарына билгеле бер үзгәрешләр кертәләр. Мәсәлән, Швейцария – 1874 елдан ук конституциясе булган, хокук мәсьәләләренә килгәндә үтә дә консерватив ил – 2000 елда яңа Конституция кабул итте. Бу – табигый процесс.

Төп законда билгеле дәрәҗәдә тотрыклылык, хәтта консервативлык булырга тиеш, конъюктурага ияреп конституцияне үзгәртергә ярамый, шул ук вакытта закон чыгару тормыштагы үзгәрешләрдән артта кала алмый. 20 ел элек Татарстанда икътисад тотрыксыз, федератив мөнәсәбәтләрнең принциплары да ачык түгел иде әле. Сәясәт коммунистик һәм демократик карашлар арасында бәргәләнде. Бүген базар мөнәсәбәтләренең табигатен һәм төп социаль-икътисади өстенлекләрен аңлау

вакыты килде. Республика да, тулаем ил дә тотрыклылык һәм ачыклык чорына аяк бастылар, шуна күрә Төп законга үзгәрешләр кертү ихтыяжы туды. Татарстан Конституциясендәге кайбер маддәләрнең декларатив булуы ачыкланды һәм аларны саклауның инде әһәмияте юк, кайберләренең федераль законнар белән каршылыкка керүе беленде һәм алар үзгәртелде. Ләкин шуны ачык аңларга кирәк: тикшерү кысаларына кабаттан кертелми торган нигез законнар бар!

Әйтик, Татарстан Конституциясенең беренче маддәсенә дәүләт суверенлыгы турындагы Декларациянең иң мөһим нигезләмәләре кертелгән, республиканың статусы референдумда расланган. Алар вакыт сынавын узган, һәм бүген дә күпмиллэтле халыкның бу нигезләмәләрне яклавына шик юк.

Билгеле булганча, Россия Федерациясе Конституция суды суверенитет төшенчәсен республиканың хокукый сыйфатламасыннан төшереп калдыруны таләп иткән иде. Мондый вердикт юридик күзлектән чыгып караганда гадел түгел, чөнки 2007 елгы Килешү икеяклы мөнәсәбәтләрне һәр ике – федераль һәм республика – конституцияләрен тану нигезендә ныгыта. Россия Конституциясе дә, 5нче маддәдә телгә алынмаса да, дәүләтләрнең суверенлыгын бөтенләй үк кире какмый. Шул ук вакытта 73нче маддәдә турыдан-туры: «Россия Федерациясе карамагыннан тыш, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрдә Россия Федерациясе субъектлары тулы хакимияткә ия», диелә. Әлеге контекстта «тулы хакимият» дигән тәгъбир безнең аңлыбызда дәүләтнең суверенлыгын белдерә. Фәнни күзлектән чыгып караганда, республика дәүләт кебек суверенлыкка ия, яки, гадирәк итеп әйткәндә, аның үзенең чикләнмәгән хокуклары булырга тиеш. Мәсәлән, Швейцария Конституциясенең 3нче маддәсендә: «Кантоннар аларның суверенлыгы Федераль Конституция белән чикләнмәгән дәрәҗәдә суверен», дип язылган. Ә Швейцария федератив мөнәсәбәтләрнең бик бай һәм гомум танылган тәҗрибәсе белән танылды.

Хәзерге дөньяны глобальләштерү шартларында берәү дә абсолют суверенлык хокукына ия түгел. Теләсә кайсы дәүләт, халыкара килешүләргә кул куйганда, халыкара яки төбәкара оешмаларга кергәндә, үз өстенә төрле йөкләмәләр алып, үзенең милли суверенлыгын бүлешә. Теләсә кайсы федерация ил эчендә вәкаләтләрне чикләү нигезендә төзелә. Бу юлга федератив дәүләтләр генә түгел, унитар дәүләтләр дә басты. Дөньякүләм тәҗрибәдә үзәкләштерүдән баш тарту гадәти күренешкә әйләнде, шулардан чыгып компетенцияләрне чикләү вакытында аерымланган суверенитет турында түгел, ә субсидиарлык, ягъни вәкаләтләрне максималь түбән дәрәҗәдә куллану турында сөйләүне артыграк күрәләр. Нәкъ шундый принцип Европа Союзында беркетелгән. Бу – Россия исәпкә алырга тиеш булган дөньякүләм тенденция.

2000 елдан башлап Федераль закон чыгаручы күп кенә уртак вәкаләтләрне, субъектларның закон чыгаруын чикләп, аларны җентекле регламентлап, Федерациягә бирде. Бүген Федерациядәге вәкаләтләрнең артык булуы ачыктан-ачык сизелә, аларны бердәм үзәктән чыгып башкару кыенлаша бара. Идарә структурасында административ аппаратның акланмаганча киңәюенә, бюрократлыкка, коррупциягә китерә торган ачыктан-ачык янәшәлекләр хасил була. Хакимиятнең катгый вертикале нәтиҗәсе буларак, аерым территорияләрдә җирле органнар эшчәнлеген координацияләү авырлаша. Болар барысы да идарә эшенең нәтиҗәлелеге кимүгә алып бара. Субъектларны тулаем дотацияләү шартларында тырышып эшләргә, җирле ресурслардан файдаланырга омтылыш кими, шуңа күрә төбәкләрнең үз потенциалы тулысынча файдаланылмый кала. Аңлашыла ки, үзәкләштерүдән баш тартуның котылгысызлыгы һәм Татарстанның бу өлкәдәге уңай тәҗрибәсе илне алга таба федеральләштерү юлларын күрсәтә.

Федераль үзәкнең Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында таләпләренә бәйле рәвештә Татарстан Парламентының безнең Төп законның асылына һәм рухына сакчыл карашын билгеләп үтәсем килә. 2000 еллар башында федераль закон тарафыннан Федерация субъектының югары вазифадагы затын ачыклау тәртибе үзгәртелде. Төбәк җитәкчесе, урында бөтен халык тарафыннан сайлану урынына, Россия Президенты тәкъдим итүе буенча парламент тарафыннан

билгеләнә башлады. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, алдан күрә белүчәнлек күрсәтеп, республика Конституциясендәге Президентның үз халкы тарафыннан сайлануын күздә тоткан норманы гамәлдән төшереп калдырмады, ә вакытлыча туктатып кына торды. Һәм хаклы да булып чыкты: бүген Россия субъект башлыкларын халык сайлап куюга әйләнеп кайта. Яна федераль законга һәм Республика Конституциясенә туры китереп, Татарстан Президенты гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән сайланачак.

Житәкчеләрне сайлау, аеруча федерация өчен, тарихи расланган адым. Ышанып әйтәм, республика башлыгының атамасы белән дә шулай ук булачак. Бу субъектларның үз вәкаләтендә һәм республиканың югары вазифадагы затына карата «Президент» атамасыннан баш тартуга бернинди ихтыяж да юк.

Сайлау алды шау-шуы белән мавыккан кайбер кайнар башлар әледән-әле, тарих дәресләрен онытып, республикаларны юк итү тәкъдимен күтәрәләр. Дәүләт төзелешен лабораторияләрдә уйлап табарга, тарихны чиста биттән башлап язарга мөмкин түгел: теләсә кайсы дәүләтнең узганы бар. Россия баштан ук күп милләтле дәүләт буларак төзелгән. Федераль конституция очраклы гына «Без, Россия Федерациясенең күп милләтле халкы» кебек тирән мәгънәле сүзләр белән башланмый. Әлеге сүзләр илнең фундаменталь идеологиясен – аның күп милләтле булуын чагылдыра, ә бу, үз чиратында, дәүләт төзелешендә чагылыш табарга тиеш.

Россиягә федерализм түгел, ә унитаризм хас дип әйткәндә, тарих сәхифәләрен күздән ычкындыралар. Россия йөзләгән халыкларның мәдәнияте нигезендә, жирле традицияләрне исәпкә алып барлыкка килгән һәм төзелгән. Сәясәтчеләр һәм галимнәр еш кына телгә алган Россия монархлары үз илләренең үзенчәлеген яхшы аңлаганнар. Дипломатик визит белән 1839 елны Россиядә булган француз де-Кюстин бал вакытында император Николай I белән мондый сөйләшүне искә төшерә: «Сез үзегезне руслар арасында дип уйлыйсыз инде, – ди аңа император, тирә-юньдәгеләргә күрсәтеп. – Сез ялгышасыз: менә бу – алман, монысы – поляк, бу – грузин, тегендә – фин, монсы – татар. Һәм болар барысы бергә Россия була».

Этник төрлелекне аңлау Россиядә һәр заманда күзәтелгән. Инкыйлабка кадәр Дәүләт Думасында патша Россиясен федеральләштерү мәсьәләсе күтәрелү очраклы гына түгел. Монархия үзенең суверенлыгын нинди дә булса чикләүләрдән курыккан, һәм, нәтиҗәдә, инкыйлаб вакыйгалары тарафыннан себереп түгелгәч, ил мәҗбүри рәвештә, большевикларның беренчел планнарына карамастан, федеральләшү юлына аяк баскан.

Яңа Россия демократияне дә, федерализмны да үзе көрәшеп алды. Халыкларның алга таба хокукларын һәм демократик ирекләрен киңәйтүдән башка юл юк. Россия федерализмының үз формасын эзләү вакытында Татарстан һәрвакыт башлап йөрүчеләрнең беренче рәтендә булды һәм булачак, ул моңа көченнән килгән кадәр үз өлешен кертергә әзер. 2007 елны Россия Президенты В.В. Путин тарафыннан имзаланган Федераль үзәк һәм безнең республика арасындагы килешүнең яңа нөсхәсе федераль Закон көченә ия һәм федерализм нигезендә яткан килешүләр формасының дәвамы булып тора. Ул республиканың яшәп килүче статусын кабат беркетә, Татарстан Конституциясен республика дәүләтчелегенең асылы буларак таныта. «Көчле төбәкләр — көчле Россия!» шигаре белән барган юлыбызның дөрес булуын раслый.

Конференцияне оештыручылар һәм шәхсән мин үзем безнең халыкара фәнни-гамәли форумның нәтиҗәле эше Россия Федерациясенең бердәм хокук даирәсе кысаларында Татарстан Республикасының алга таба камилләшү юлларын табарга ярдәм итәр дип ышанам.

# БЕРЕНЧЕ ТӨРКИ БАСМА КИТАП

## И.МЕГИЗЕРНЕҢ «INSTITUTIONUM LINGUAE TURCICAE LIBRI QUATUOR» («ТӨРКИ ТЕЛ НИГЕЗЛӘРЕ», 1612) КИТАБЫНА 400 ЕЛ

Тормышыбызга тирән үтеп кергән китапның, басма сүзнең озын тарихы бар. Шул тарихта безнең дә тирән эзебез бар.

XVII-XVIII гасырларда Европаның икътисади, иҗтимагый, сәяси тормышында зур үзгәрешләр барлыкка килә. Географик ачышлар күп яңа телләр барлыгын күрсәтә. Галимнәр туган тел белән беррәттән Европа, Азия һәм Африка дәүләтләрендә яшәүче халыкларның телләрен системага салу, өйрәнү, сүзлекләр төзү эше белән шөгыльләнә башлыйлар. Мәсәлән, К.Геснерның «Митридат»ы, (1555) И.Мегизернең «Барлык телләрнең хәзинәсе» (1592) сүзлекләре, 1787-1791 елларда Петербургта П.С.Палласның «Бөтен телләр һәм шивәләрнең чагыштырмалы сүзлеге» дөнья күрә. Хезмәтнең 1791 елда чыккан басмасында Европа, Азия, Америка, Африкада яшәүче халыклардан 272 тел һәм диалектлары урын алган.




Бу дәвердә мәгърифәт, фән, сәнгать зур үсеш ала, китап басу эше җайга салына. Китап басу эшенең киң колач җәюе иҗтимагый фәннәрнең гуманитар юнәлешенә дә зур йогынты ясый. Текстларның тиражлап басылуы уку-укыту эшен стандартлаштыру өчен мөмкинлек бирә. Яңа тарихи шартларда изге китап теле әкренләп үз позициясен югалта бара, милли телләр формалаша башлый. Мәсәлән П.Рамус/Раме (1515-1572) грек, латин һәм француз телләреннән грамматикалар төзи. Аның шәкерте Я.Аарус (1538-1586) беренче булып француз теленең фонетик үзенчәлекләрен тасвирлый. Дж.Уоллис (1616-1703) 1653 елда инглиз теле грамматикасын яза. Алман теленең беренче тулы грамматикасы Ю.Г.Шоттель (1612-1676) тарафыннан төзелгән. Аның эшен И.К.Готтшед (1700-1766) һәм И.К.Аделунг (1732-1806) дәвам итәләр. Л.Зизаний 1596 елда Вильнода славян теленең грамматикасын төзи. Рус теленең беренче грамматикасын латин теле грамматикасы үрнәгендә инглиз тикшерүчесе Г.В.Лудольф яза. Әлеге чор тел теориясе туган телнең төзелешен этимологик һәм тарихи планда карарга омтыла. Бу омтылыш милли үзаң уянуы, милли телләрнең язма формасының үсүе белән аңлатыла.

Сәяси вакыйгаларга бәйле төрки телләрне өйрәнүгә игътибар арта. Алтын Урда җимерелеп, анда яшәгән төркиләрнең (башлыча кыпчакларның) зур гына өлеше Көнбатыш Европага күчеп килгәч, католик чиркәү әһелләре төркиләр арасында миссионерлык эшен бик көчәйтә, Ватикан Европада һәм аннан читтә дә төрле көчләү яки пропаганда юллары белән католицизмны урнаштырырга омтыла. «Изге Рим империясе» составына кергән Европа илләренең барысында да диярлек Көнчыгыш телләре институтлары һәм аларның филиаллары булдырыла. Миссионерлык максатларыннан төркиләрнең тарихын, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен өйрәнү, төрки телле сүзлекләр һәм грамматикалар төзү һәм китап итеп бастырып тарату өлкәсендә зур эшчәнлек алып барыла.

Беренче тапкыр гарәп хәрефләрен кулланып язылган төрки грамматика «Institutionum linguae Turcicae libri quator» («Төрки тел нигезләре») исеме белән нәкъ менә «Төрки телләр институты» тарафыннан хәзерләнеп 1612 елда Лейпцигта дөнья күрә. Грамматиканың авторы — тарихчы һәм филолог, профессор Иероним Мегизер[1]. Бу хезмәт — беренче төрки басма китап һәм төрки-татар тел белеме формалашуын күзалларга мөмкинлек бирә торган төп чыганакларның берсе булып тора. Урта гасырларда иң зур китап нәшрияте урнашкан үзәк булып Лейпциг шәһәре саналган. И.Мегизернең грамматикасы нәкъ шунда басыла һәм Лейпциг университетының китапханәсендә саклана.

Иероним Мегизер 1553 елда Штутгардт шәһәрендә туып, 1618 елда Линза шәһәрендә вафат була. Т.Эльценың билгеләвенчә, И.Мегизер – төпле, күпьяклы белем туплаган, бай тәҗрибәле фән эшлеклесе. Ул тарих, география, фәлсәфә, әдәбиятка караган утыз алтыдан артык төрле хезмәт калдырган, һәм аларның күбесе берничә тапкыр нәшер ителгән. Мегизер полиглот һәм күп сәяхәт иткән галим булган. Аның 1603 елда басылган 750 биттән гыйбарәт «Thesaurus poliglottus» («Бөтен телләрнең хәзинәсе») исемле күп телле сүзлеге бу фикерне раслый.

И.Мегизернең «Төрки тел нигезләре» хезмәте латин теле грамматикасы үрнәгендә язылган. 340 биттән торган дәреслекнең эчтәлеге түбәндәгечә: кереш, фонетика, этимология, әдәби текстлардан торган өлеш, сүзлек.

Кереш өлеше ул вакытның традицияләренә туры китерелеп язылган багышлау хатларыннан башлана. Автор илтифат белән корольгә һәм аның якыннарына мөрәҗәгать итә, төрки телне өйрәнүнең әһәмиятен билгели. Лингвистик яктан әһәмияте белән берргәтән, төрки телне өйрәнүнең хәрби-сәяси максатлары да ассызыклана. Керештә тарихи вакыйгалардан берничә мисал китерелә. Мәсәлән, Рим императоры Оттон II нең сарациннар белән 982 елда сугышкан вакытта ничек сарациннарга әсирлеккә төшүе һәм аның төрки телдә сөйләшүе белән дошманнарын алдавы турында бер хәл сөйләнә. Рим императорының төрки телне белүе ана үзенең нинди милләттән булуын яшерергә ярдәм иткән. Автор гаскәриләрнең генә түгел, телләрнең дә сугыша алулары, гомерне саклап калуга ярдәм итүләре турында искәртә. Телне белү дошманның стратегиясен өйрәнергә, шулай ук мөселманнар арасында христиан динен пропагандалауга ярдәм итәчәген белдерә. И.Мегизер бу грамматиканы шәхсән үзе төзүен, бу эштә ана телләр белү зур ярдәм итүен искәртә. Автор хезмәтне бастыру өчен рөхсәт сорый. Шунда ук фәлсәфә һәм медицина докторы Петр Кирстенийның кыска бәяләмәсе бирелгән. Ул авторны галим буларак югары бәяләгән.

Дәреслекнең икенче өлешендә гарәп хәрефләренә нигезләнгән төрки әлифба хакында бик тулы мәгълүмат китерелгән. Милләте буенча алман галименең гарәп графикасының төрки телгә яраклашуын шул хәтле тәфсилле аңлатуы, гүзәл каллиграфик үрнәкләр китерүе телне бик нечкәләп өйрәнүен күрсәтә.

Гарәп графикасының иҗекләр системасын аңлатканда, төркиләр үзләре кулланган укыту алымын, ягъни кулны күнектерү өчен бик күп язма күнегүләр эшләүне үрнәк итеп куя. Дәреслектә гарәп матур язуына күп урын бирелгән: төрле тартыкларга, сузыкларга башлана һәм бетә торган иҗекләрне мисалга китерә.

Бишенче-алтынчы бүлекчәләрдә (61-77б.) гарәп шрифтында Коръәннән үрнәкләр һәм мәкаль-әйтемнәр китерелгән, аларның латин графикасында транскрипциясе, латин теленә тәрҗемәсе урнаштырылган.

Икенче өлеш «Төрки тел нигезләре» дип атала. Теоретик материал латин теле үрнәгендә 14 бүлекчәдә аңлатылган, сүз төркемнәре һәм аларга хас грамматик категорияләр тикшерелгән, телләрдәге аермалыклар һәм охшашлыклар күрсәтелгән. Әлеге материал төрки телне чит халыкларга өйрәтүнең теоретик нигезләрен ачыклау өчен әһәмиятле чыганак булып тора.

Өченче өлеш тулысынча әдәби текстлардан гына тора. Анда христиан дине догаларыннан өзекләр һәм төрки мәкальләрдән мисаллар китерелгән, аларның транскрипцияләре һәм латин теленә тәрҗемәләре бирелгән. Аерым очракларда чагыштыру өчен итальян һәм алман телләреннән дә үрнәкләр китерелә.

[1] Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт. Татар басма сүзенең сәхифәләреннән / Ә. Кәримуллин. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1979. – 14 б.

И.Мегизер грамматикасы турында татар филологиясендә беренче булып язып чыккан Ә.Кәримуллин фикеренчә, бу китап өчен төп чыганак булып шул вакытта Көнбатыш Европада күпләп яшәгән кыпчаклар теле материаллары хезмәт иткән. Галим китапта китерелгән сүзләрнең 60-65 проценты бүгенге татар кешесе өчен таныш дип саный. Фольклорчы, филология фәннәре докторы Х.Ш.Мәхмүдов та әлеге саннарның мәкальләр мисалына туры килүен ачыклаган: «Мәкальләрнең зур күпчелеге хәзерге татар фольклорына бик якын, хәтта сүзгә-сүз туры килгән тәрдәшләре бар. Гомумән, борынгы һәм хәзерге текстлар арасындагы аерма күп очракта архаик һәм диалекталь сүзләрдә яки фонетик үзгәлекләрдә генә күренә. Менә кайбер мисаллар:

| **И.Мегизер тәкъдим иткән мәкальләр:** | **Татар халык мәкальләре:** |
|---|---|
| Атылган ок дүнмәс. | Аткан ук кире кайтмый. |
| Алма агачтан ерак дүшмәс. | Алма агачыннан ерак төшмәс. |
| Куншы хакы тәнре хакы. | Күрше хакы тәнре хакы. |
| Жимештән агачы беленер. | Агач жимешеннән беленер. |
| Бал тутан бармак ялар. | Бал тоткан бармак ялар. |
| Ялгыз таш дивар олмас.<br>Эл әли юар, ике эл йөзи юар. | Ялгыз таш кала булмас.<br>Кул кулны юар, ике кул битне юар. |
| Коркак базирган файда итмәс. | Куркак сәүдәгәр файда күрмәс. |
| Куру янында йәш тә янар. | Коры янында чи дә янар. |
| Бүгенги йомурта жәренги тавыктан йегдер. | Бүгенге йомырка тандагы тавыктан хәерле[2] |

Әлеге мәкальләр Ә.Кәримуллин, Х.Мәхмүдов тарафыннан өйрәнелгән һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: И.Мегизер дәреслегендәге мәкальләр нигездә татар халык мәкальләре белән сүзгә-сүз туры килә, шулай да лексик берәмлекләрнең фонетик һәм грамматик бирелешендә үзенчәлекләр булуын да искәртергә кирәк.

Дүртенче өлештә ике сүзлек китерелә: латинча-төркичә (2460 сүз), төркичә-латинча (2440 сүз). Сүзләрнең күпчелеге җәмгыятьтә, кеше тормышында, көнкүрешендә иң әһәмиятле төшенчәләрне белдерә.

И.Мегизернең 1612 елда басылган грамматикасы төрки тел белеме һәм теориясе формалашуы хакында кыйммәтле чыганак булып тора. Шул ук вакытта XVII гасырда төрки халыкларның дөньякүләм тарихтагы урынын, дәрәҗәсен ачыклау өчен яна материал буларак та әһәмияте зур. Әлегә кадәр уникаль китап аз өйрәнелгән, тәрҗемә ителмәгән һәм фәнни әйләнешкә кертелмәгән хезмәт булып кала килде. Татарстан Фәннәр академиясенең чит илдә сакланган төрки-татар мәдәниятенә бәйле материалларны кайтару өлкәсендәге хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә, Иероним Мегизернең Лейпциг университетының сирәк китаплар бүлегендә сакланган «Institutionum Lingua Turcicai Libri quatuor» репринт басмасы Татарстанга кайтарылды. Безнең тарафтан әлеге басма татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителде. Басмага тәкъдим иткәндә, оригинал текстның үзе (факсимиле) һәм тәрҗемәләр янәшә урнаштырылды. Бу адым алдагы тикшеренүләрдә оригинал текст белән эшләү мөмкинлеген бирәчәк һәм яңадан-яңа эзләнүләр өчен җирлек булып торыр дип ышанабыз.

**Ф.Ш.НУРИЕВА, М.М.ПЕТРОВА, М.М.СӨНГАТУЛЛИНА**

[2] Мәхмүдов Х. Борынгылар әйткән сүз (VIII-XVIII г. төрки-татар ядкәрләрендә афоризмнар) / Х. Махмүдов. – Казан: "Фикер", 2002. - 175-178 б.

Фәйзелхак
Ислаев

# ЯҢА КЕРӘШЕН КАНТУРЫ

## Сильвестр Гловацкий — иң нәтиҗәле миссионер

Казан епископы Лука Канашевич һәм архимандрит Димитрий Сеченов тәкъдимнәре буенча Яңа керәшен кантурының яңа җитәкчесе итеп миссионерлык эшендә зур тәҗрибә туплаган Сильвестр Гловацкий билгеләнә һәм ул 1742 елның 18 декабрендә үз вазифаларын үтәргә керешә.

Сильвестр җитәкчелегендәге миссионерлар башта көтелмәгән каршылыкка тап була. Христианлаштыру өчен бүленгән акча Яңа керәшен кантурына килеп җитми. Белгәнебезчә, христиан динен тарату өчен елына 15 меңнән артык акча бирелергә тиеш булса да, 1743 ел өчен 18 мең акча 1744 елның июль аенда гына килеп җитә. Акча мәсьәләсе белән патшабикә Елизавета Петровна үзе шөгыльләнүгә дә карамастан, бу мәсьәлә бары тик 1746 елда гына хәл ителә. Ул елны кантур үткән еллар өчен дә 30745 сум ала, ә 1748 елны 39459 сум акча 1744-47 еллар өчен бирелә. Акча килү чукынучылар санын күпкә арттырып җибәрә. 1746 елда алар 74 мең кеше булса, 1747 елда исә 113 меңнән артып китә. Бу— күпләп христианлаштыру еллары өчен иң зур күрсәткеч һәм акча күләме белән керәшеннәр саны аерылгысыз булуга өстәмә бер дәлил.

Сильвестр тәкъдиме белән 1743 елның 28 сентябрендә сенат чыгарган указ нигезендә керәшеннәр өчен налог бөтен Казан губернасы татарлары өстенә салына һәм ул һәр гаилә өчен түли алмый торган салымга әверелә. Тарихчы Н.А.Фирсов мәгълүматларына караганда, Казан губернасында керәшеннәр өчен салым алты мәртәбә арта һәм һәр кешегә элекке 53 тиен урынына 3 сум 10 тиен түләргә туры килә. Шуңа күрә алдагы елларда татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән сенат исеменә керәшеннәр өчен салымнан азат итүне сораган үтенечләр килеп тора, тик алар канәгатьләндерелми.

Бу елларда христиан динен кабул итүчеләр санын арттыруга чукындыру процедурасын гадиләштерү дә тәэсир итә. 1746 елга кадәр чукындыру йоласын монахлар гына башкара алса, Сильвестр Гловацкий тәкъдиме белән бу инде гади чиркәү священникларына да рөхсәт ителә ала. Чукынырга теләүчеләрне Зөя монастырена китерү ихтыяҗы да юкка чыга.

Сильвестр күп мәртәбә миссионерлар командасын җитәкләп төрле төбәкләргә бара, шактый гына татар, ар-удмурт, чирмеш-мариларны чукындыра. 1744 елның ахырында — 1745 елның башында ул Вятка провинциясендә актив рәвештә миссионерлык эшен алып бара. Чукынып акчалата премия алырга теләүчеләр күп булганлыктан, ул кантурдан тиз арада акча җибәрүне үтенә, чөнки үзе белән алган 1610 тәнкә акчаны чукынганнар өчен бүләк итеп, кием-салым алуга тотып

*Ахыры. Башы 10 санда*

бетергән була. Бу бер баруында гына да ул биш мең ар-удмуртны чукындыра. Тик бу тарафта татарлар булмаганга охшый, чөнки татарлар арасында чукынучылар саны елына биш кешедән артмаган. 1782 елда Глазов өязендә 44 керәшен-татар саналган, ә мөселманнар саны 338 кеше була һәм алар Ильяс, Карин, Починошная авылларында яшәгәннәр.

Сильвестр атакай Алабугада керәшен мәктәбен ачу өчен шактый тырышлык күрсәтә. 1748 елның җәй айларында авылның Спас чиркәве тирәсендә, Туйма елгасы ярыннан ерак булмаган урында, керәшен мәктәбе төзү өчен урын күрсәтә һәм бирелдәге төзелешне һәрдаим күзәтеп тора. Укырга 23 татар, 15 чуаш, 3 удмурт, 9 мордва кабул иткән керәшен мәктәбе 1750 елның 1 гыйнварында эшли башлый. Мәктәпнең беренче укытучылары — дьяк Федор Кочкин һәм украиннардан Яким Магеровский. Тик бу керәшен мәктәбе Алабугада озак эшләми. 1751 елның 1 октябрендә мәктәптә янгын чыгып, ул көлгә әверелә, ә укучылары исә Казанга, Иске татар бистәсендә урнашкан керәшен мәктәбенә күчерелә.

**Идел буе халыкларын чукындыру нәтиҗәсе (1743—1749 еллар).**

| Халыклар | Еллар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1743 | 1744 | 1745 | 1746 | 1747 | 1748 | 1749 |
| Татарлар | - | 139 | 159 | 184 | 371 | 1173 | 2041 |
| Мордвалар | - | 1189 | 3420 | 8183 | 14614 | 1035 | 117 |
| Чуашлар | - | 1756 | 2819 | 52545 | 79235 | 19172 | 9251 |
| Чирмешләр (Марилар) | - | 661 | 242 | 4372 | 18486 | 4017 | 11163 |
| Удмуртлар | - | 292 | 4346 | 8685 | 686 | 3517 | 4431 |
| **Җәмгысе** | **10025** | **4037** | **10986** | **73969** | **113392** | **28914** | **27003** |

Сильвестр җиде ел Яңа керәшен кантурын җитәкләү вакытында 268326 кеше православие динен кабул итә. Бу елына уртача 38332 кеше дигән сүз. Ягъни күпләп чукындыру чорында миссионерлар тарафыннан ирешелгән иң зур нәтиҗә. Яңа чукындыру кантуры чукындыруда иң зур казанышларга 1746 һәм 1747 елларда ирешә: 73969 һәм 113392 кеше.

Нәкъ шушы елларда татарлар арасында да христиан динен кабул итү очраклары арта башлый: 1747 елда татарлар арасында 371 кеше православие диненә күчсә, чуашларда бу сан — 79235, мариларда — 18486, мордваларда — 14614, удмуртларда — 686, татарлар арасында православиегә күчүнең артуы алдагы ике елда дәвам итеп, 1749 елда ул 2041 кешегә җитә. Бу елларда (1745-1749) татар-мөселманнарны христианлаштыру Русиянең барлык төбәкләрендә алып барылса да, Зөя, Казан, Сембер өязләре сан ягыннан башка төбәкләрдән нык аерылып тора. Татарларның 90 проценты шушы өязләрдә чукындырыла.

Идел буендагы татарларны һәм мәҗүсиләрне көчләп чукындыру буенча зур тәҗрибә туплаган Сильвестр Гловацкий миссионерлык эшен камилләштерү, җанландыру өчен Себергә озатыла. 1749 елның 8 июлендә Сильвестр Мәскәү кирмәнендә урнашкан Зур Успения соборында Тубыл һәм Себер митрополиты итеп билгеләнү турында патшабикә Елизавета Петровна кулыннан указ алып, 25 олау белән Тобол шәһәренә юлга чыга.

Себер епархиясендә Сильвестр Идел буендагы шикелле үк христианлаштыруда югары нәтиҗәләргә ирешү өчен төрле яңа тәкъдимнәр ясый. Иң әүвәл иксез-чиксез Себер җирләрендә миссионерлык эшен системалы алып бару өчен Долматов монастырендә керәшен кантурын оештырырга, керәшен татарлары яшәгән авылларда мөселманнар ярдәмендә чиркәүләр төзергә, чукынганнар өчен салым түләүне

чукынмаганнар өстенә салырга, чукынмаганнарны керәшен авылларыннан икенче авылларга күчереп утыртырга, миссионерлык эшен алып бару өчен проповедниклар, толмачлар билгеләүне тәкъдим итсә дә, синод бу тәкъдимнәрне кире кага. Шулай да ул 1754 елда Тубыл шәһәрендәге Татар бистәсе уртасында Казандагы татар бистәсендәге шикелле үк чиркәү салдыруга ирешә.

Дин өлкәсендә чамасыз көчләүгә, төрле яктан басымга күнекмәгән Себер татарлары миссионерларның кылган гамәлләре турында сенат-синодка туктаусыз шикаятьләр язып торалар. 1750 елның 13 ноябрендә, 1751 елның 6 апрелендә, 23 июнендә, 5 июлендә синод яисә сенат исеменә язган хатларында митрополит: «Себер татарларын көчләп чукындыру очраклары юк», — дигән җавапны гына кабатлап тора.

Митрополит Сильвестр Гловацкий җитәкчелегендәге дини эзәрлекләү, урыслаштыру максаты белән православие динен төрле Себер халыклары арасында тарату Тубыл якларында да әлләни зур нәтиҗә бирми, биредә дә мөселманнар үз диннәрендә нык торалар, тик мәҗүси халыклар гына урыс диненә күпләп күчәләр. Бу хакта берничә мисал китерик. 1750 елда 1051 кеше православие диненә күчкән булып исәпләнә. Алар арасында— Краснояр өязендә яшәүче телеутлардан 1 мең кеше, ә Тубыл татарларыннан нибары 20 генә; тагын Исәт провинциясеннән 10 башкорт һәм сөргенгә сөрелгән 3 татар һәм башкорт чукындырыла. 1751 елда чукынучылар саны 1658 кешегә җитсә дә, алар арасында бары тик 6 Тубыл татары, ә чукынучылар арасында башкортлар һәм сөргенгә сөрелгән мөселманнар юк. 1752 елда Исәт провинциясендә татар, башкорт, мишәрдән 6 кеше генә урыс диненә күчә; 1754 елда шул ук провинциядә 25 татар чукына.

Митрополит Сильвестр атакайның үткәргән миссионерлык эшенә Себер татарларының нәфрәте, сенат һәм синод исеменә туктаусыз язылган шикаятьләре, бигрәк тә халкыбызның мәшһүр улы Батырша мулла җитәкчелегендәге 1755 елгы восстание бу руханины мөселманнар яшәмәгән урынга күчерү өчен этәргеч була. 1755 елның көз айларында ул Тубыл епархиясеннән китәргә мәҗбүр ителә.

## Евмений Скаловский — күпьеллык җитәкче

Евмений Скаловский Зөядәге Богородицки монастыре архимандриты һәм Яна керәшен кантуры җитәкчесе итеп 1750 елның 7 февралендә билгеләнә һәм бу вазифаны 14 ел буенча, 1764 елда кантур ябылганга кадәр тырышып үти. Казан епископы Лука Канашевич 1749 елның 11 октябрендә синодка Зөядәге Богородицки монастыре архимандриты итеп Евмений Скаловскийны тәкъдим итә һәм аңарга бик уңай характеристика бирә: «Казан семинариясендә укытучы буларак, балаларны игелекле тырыш хезмәткә тәрбияли, урыс булмаган халыкларга Алла сүзен белеп тарата, чиркәүләрдә вәгазьләр укып зур абруй казана». Лука Канашевичның синодка язган бу хаты Евмений Скаловскийның язмышын хәл иткәндә иң мөһим роль уйнагандыр, мөгаен, чөнки ул 1750 елның 25 мартыннан рәсми рәвештә монастырь архимандриты булып эшкә керешә.

Архимандрит Евмений Скаловский (монах булганчы Филипп Соколовский) Украинада туып-үскән, Киев академиясен тәмамлагач, Казанда шактый еллар семинариядә укытучы булып эшли һәм 1740 елгы указ нигезендә миссионерлык эшенә җәлеп ителә.

Евмений Скаловский 1744 елда Уфа өязендә миссионерлык эшен җәелдерү буенча тикшерү үткәреп, башка диндәге кайбер кешеләрне үзе чукындырып китә.

1752 елда Яна керәшен кантуры җитәкчесе Евмений Скаловскийның вәкаләтләре киметелә. Сәбәбе — Евмений Лука Канашевич белән киңәшләшмичә керәшен мәктәбендә эшләүче ике укытучыны кимчелекләрен табып эштән азат итә һәм ул урынга бүтәннәрне ала. Бу вакыйганы Канашевич үзен ихтирам итмәү дип бәяли һәм синодка шикаять юллый. Шушы шикаять нигезендә синод Яна керәшен кантурын хезмәткәрләре, казнасы белән Казан епархиясенә тапшыра һәм миссионерлык эшен тулысынча епархиягә йөкли. Шушы елдан алып Евмений Скаловскийның

миссионерлык эше буенча яңа башлангычлары күренми. Шулай да ул көндәлек миссионерлык эше белән житәкчелекне дәвам итә.

Татарлар синод һәм сенатка миссионерларның көчләп чукындыруы хакында шикаятьләр язып торганнар. Мондый шикаятьләргә чик куяр өчен синод үзе таләп православие динен кабул итү хакында махсус документ кабул итә. Православие чиркәвенең Исламга булган карашын дөрес чагылдырган бу оригиналь документның урысча текстын тәкъдим итәбез: «...посланный божия глаголемы Магомет не есть и никогда не был от Бога посланный, но самый студный и лживый пророк и предтеча антихристов тако же закон его (Коран или Ал-коран названный) есть самый же лживый богомерзкий же и богопротивный и по таковому моему всесовершенному чрез проповедь узнанию, оного лжепророка Магомета и его Алкорана отрицаюсь и проклинаю». Формаль рәвештә һәр керәшен кул куйган бу документ христианлаштыру чорында бернинди роль уйнамаса да, ул замандагы миссионерларның исламга карашына һәм көчләү чынлап та булганлыгына бер дәлил.

1750 елларның урталарына кадәр дини һәм милли эзәрлекләү, татар һәм башка халыкларны көчләп чукындыру сәясәте Евмений Скаловский житәкләгән Яңа чукындыру кантуры тарафыннан һичшиксез тормышка ашырыла. Бу вакытта инде мәҗүси халыкларның күбесе православие диненә күчә, мөселманнар исә миссионерларга каршылык күрсәтүне дәвам итәләр. Православие руханиларының бөтен басымы мөселманнарга юнәлтелә. Миссионерларның хезмәте дә әкренләп үзгәрә, алар православие диненә күчкән халыкларны яңа дингә күнектерү җәһәтеннән, күбрәк чиркәүләр салу, керәшеннәрне христиан догмаларын өйрәтү белән шөгыльләнәләр. 1751 елның 3 июнендә сенат яңа чукынган халыклар яшәгән авылларда, 150 йорт-хуҗалыкка бер чиркәү салу ниятеннән, 33 яңа чиркәү төзү турында карар кабул итә. Бу вакытта инде хөкүмәт акчасына чукынган халыклар арасында 208 чиркәү салынган була.

Формаль яктан Евмений Скаловский кантур житәкчесе булып саналуга карамастан 1755 елга кадәр Яңа керәшен кантуры белән турыдан-туры Лука Канашевич житәкчелек итә, миссионерлык эшен дәвам итү өчен төрле чаралар күрә.

**Идел буе халыкларын чукындыру нәтиҗәсе (1750—1762 еллар)**

| Народы | 1750 | 1751 | 1752 | 1753 | 1754 | 1755 | 1756 | 1757 | 1758 | 1759 | 1760 | 1761 | 1762 | Барысы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Татары* | 1985 | 1441 | 917 | 421 | 1076 | 594 | 456 | 491 | 319 | 272 | 245 | 134 | 115 | 8466 |
| Мордва | 125 | 214 | 674 | 147 | 27 | 14 | 641 | 18 | 24 | 18 | 91 | 37 | 3 | 2033 |
| Чуваши | 2336 | 3611 | 846 | 1139 | 753 | 3025 | 2468 | 1627 | 1223 | 402 | 623 | 204 | 34 | 18291 |
| Черемисы | 3885 | 2126 | 2880 | 715 | 1322 | 1939 | 790 | 1062 | 416 | 712 | 585 | 52 | 29 | 16513 |
| Вотяки | 2723 | 2950 | 2945 | 2016 | 1639 | 1462 | 1236 | 1828 | 3364 | 2389 | 1238 | 816 | 15 | 24621 |
| Итого | 11054 | 10342 | 8262 | 4438 | 4817 | 7033 | 5591 | 5026 | 5346 | 3793 | 2782 | 1243 | 196 | 69924 |

Унсигезенче гасырның алтмышынчы елларында чукындыру кантуры оештырган миссионерлык эшендә йомшаклылык сизелә, мөселманнарны һәм мәҗүси халыкларны православие диненә тарту буенча яңа омтылышлар күренми.

Шулай да татарларны христианлаштыруда ул заманда да көчләү кулланылган. Бу хакта янә бер мисал. Бу хәл Казан өязендә Нугай даругасының Акташ авылында 1760 елның башында була. Авылга поп Василий Иванов житәкчелегендә Яңа керәшен кантурыннан ике солдат, керәшен-татарлары Александр Степанов һәм аның туганы Андрей Лукин килеп төшәләр. Башта авыл халкын христиан динен кабул итәргә үгетли башлыйлар. Чукынырга теләүчеләр табылмагач, халыкны камчы белән кыйнап та алалар. Тегермән янында елгада өч мәртәбә чумдырып, 12 кешене чукындыралар. Чукынучылар арасында Урка Аиткулова һәм аның кечкенә малае да була. Көчләп чукындырылган татарлар сенат исеменә хат язалар. Сенат бу хәлне тикшереп, «о нечинении иноверцам к принятию православной веры принуждения» дип указ чыгару белән чикләнә.

Бу вакытта инде мәҗүсиләрнең күбесе чукынган була, мөселманнарны көчләү исә әлләни нәтиҗә бирми. Патша тәхетенә Екатерина утыру да бу вәзгыятькә тәэсир иткәндер, мөгаен.

## Лука Канашевич — Аксак Каратун

Казан епархиясенең епископы Лука Канашевич халкыбыз хәтеренә хәзерге көнгә кадәр Аксак Каратун исеме белән кереп калган. 1738 елдан 1755 елның ахырына кадәр урыс булмаган халыкларны дини һәм милли эзәрлекләү, корал һәм камчы ярдәмендә православие диненә дүндерү, аларны көчләп чукындыруда иң мөһим, төп рольне уйнаган бу зат татар тарихында аерым урын билəп тора.

Данлыклы миссионерның кылган үзенчәлекле гамәлләрен тәфсилләп күрсәтер алдыннан бер искәрмә биреп китү зарур. Күп кенә тарихи язмаларда Лука Канашевич ялгыш Яңа чукындыру кантуры житәкчесе итеп күрсәтелә. Бу дөрес түгел, күп китап-мәкаләләргә кергән уйдырма гына. Казан епархиясенең житәкчесе, ягъни епископы булган Лука атакай Яңа керәшен кантуры белән турыдан-туры житәкчелек итмәгән, ул Зөядәге Богородицки монастыренең архимандриты булмаган. Казан епархиясе жирләрендә урнашкан Зөя монастыре, Яңа чукындыру кантуры миссионерлары, епископның кыйммәтле киңәшләрен тыңлап, «изге эш» алып барганнар.

Казан епископы Луканың (Конашевич Лаврентий Кононович) туган елы һәм чыгышы билгесез. Конашевич Украинада шактый таралган Конон исеменнән ясалган фамилия булырга мөмкин. XVIII гасыр документларында Лука фамилиясе Конашевич түгел, Канашевич дип язылган, һәм без аны шулай кулланабыз. 1724 елны ул мәшһүр Киев академиясен тәмамлый һәм биредә укытучы итеп калдырыла. Ул заманда бу дини уку йорты Русиядә православие руханиларын хәзерләү буенча иң мәртәбәледән саналган. Шуңа күрәдер, Идел буендагы иң данлыклы миссионерлар да гадәттә Киевта белем алганнар. 1725 елда монахлык кабул итеп, Киев шәһәрендә урнашкан София монастырендә бераз хезмәт иткәннән соң, Мәскәүгә Киев епархиясе вәкиле итеп жибәрелә. 1728 елдан Мәскәү академиясендәге башлангыч классларга укытучы итеп билгеләнә. Санкт-Петербургта дворян балалары өчен махсус ачылган кадет корпусына иеромонах итеп куела. Башкалада хезмәт иткәндә үк ул миссионерлык эше белән кызыксына, мөселманнарны, мәжүсиләрне, чит ил гражданнарын урыс диненә күчерүдә катнаша. Бу хакта берничә мисал китерик. Санкт-Петербург тирәсендә артиллериядә хезмәт иткән Енидеев фамилияле бер татар 1732 елда православие диненә күчәргә теләк белдерә. Изге синод аны, православие диненең нигезләре белән таныштыру өчен, Лука Канашевич янына озата. Канашевич биредә беренче мәртәбә татар кешесе белән очраша һәм ана православие дине нигезләрен өйрәтә. Енидеевны Санкт-Петербург каласының үзәгендә урнашкан Исаак соборы протопобы Иосиф Чедневский 1732 елның 25 октябрендә чукындыра һәм аңарга Дмитрий дигән исем куша. Лука Канашевичнын 1734 елда француз Мелардны һәм ике японны православие диненә күчерүе дә билгеле. Шул ук елнын 16 мартында ул чирмеш Еремей Ильмюшкинны, чуаш Андрей Индиряковны, татар Салит Ахтяуловны чукындыра. Христиан дине нигезләре белән таныштырганнан соң, 1735 елның 24 апрелендә тышкы эшләр коллегиясе тәржемәчесе Мостафа Турчаниновны чукындыра. 1756 елны шушы Мостафа-Александр Турчанинов Санкт-Петербургта Петропавел крепостенда Яшерен кәнсәләрдә Батырша мулладан сорау алганда тәржемәче була.

1735 елның 20 октябрендә Лука Канашевич, кадет корпусындагы эшен дәвам итүгә карамастан, Мәскәү кирмәнендә урнашкан Симонов монастыре архимандриты итеп, 1737 елның 28 сентябрендә исә Устюг епархиясе епископы итеп билгеләнә. Тик ул биредә 8 ай гына эшләп кала, 1738 елның 9 мартында аны Казанга күчерү турында указ кабул ителә. Ул Казанга июль аенда килә һәм унжиде ел буена, 1755 елның көзенә кадәр Русиядәге иң зур епархияне житәкли, Идел буендагы урыс булмаган халыкларны күпләп көчләп чукындыру буенча зур эш алып бара.

Ул бигрәк тә Казанда православие дине тулаем жиңеп, аны урыс шәһәренә әйләндерү өчен тырыша. Лука Казанга килү белән урыс булмаган халыклар арасында миссионерлык күбрәк дингә үгетләп түгел, ә административ басым, көч кулланып тормышка ашырыла башлый. Аксак Каратун Казанны урыс шәһәре итү өчен шактый гамәлләр кыла. Моның өчен ул 1749 елның 3 маенда шәһәрдәге зур янгыннан оста файдалана. Татар бистәсендә башланган бу янгын тиз арада бөтен шәһәргә диярлек тарала һәм бик күп чиркәүләрне, торак йортларны юкка чыгара. Кремльдә генә дә

Спас-Преображение һәм Троицк монастырьлары, Вознесение чиркәве, губернатор йорты, архивы белән губерния кәнсәләре һәм башка биналар янып көлгә әйләнә. Янгын башлануда гаепләп, Лука атакай 900 татарны бистәдән куарга һәм алар урынына урысларны күчереп утыртырга дип сенатка тәкъдим ясый. 17 майда ук, татарларны бистәдән куар алдыннан, Лука атакай тәкъдиме белән бистә уртасына тәре-хач утыртыла һәм биредә 8 ноябрьдә Захарий һәм Елизавета исемендәге чиркәү нигезе салына, һәм ул чиркәү тиз арада төзеп тә куела. Ул замандагы кануннар нигезендә чиркәү булган урында мәчет төзергә рөхсәт булмаган. Шуңа күрә, татар имамнары һәм морзалары Иске татар бистәсендә мәчет салуга рөхсәтне 1767 елда Әби патшаның үзеннән алырга мәҗбүр булалар. Алланың рәхмәте, ашык-пошык салынган чиркәүнең гомере озын булмый — 1825 елда, Русия патшасы Александр I Казанга килер алдыннан, ярым җимерек чиркәү урыны бөтенләй чистартып куела. Ә татарларны бистәдән куу мәсьәләсенә килгәндә, Лука Канашевич күпме генә тырышса да, аларны биредән куып чыгара алмый, гәрчә бернечә татар гаиләсен урыслар яшәгән Поповка авылы янында Яңа татар бистәсенә нигез салырга мәҗбүр итсә дә.

Лука тырышлыгы белән Казанда, хәзерге Кремль урамында, Казан университетының геология факультеты булган бина салынып, биредә Казан семинариясе урнаштырыла. Ул Киев академиясеннән укытучылар чакыртып ала. Бу елларда Казан семинариясе дин әһелләрен хәзерләү буенча уку йортлары арасында Киев һәм Мәскәү академияләреннән кала өченче урында исәпләнә.

Лука Канашевич Идел буе халыкларын православие дине традицияләре буенча тәрбияләүгә гаять зур өлеш кертә. Аның тырышлыгы белән төрле төбәкләрдә чукынганнар өчен 4 керәшен мәктәбе ачыла, 1754 елда исә ул дүрт мәктәптәге барлык укучыларны Татар бистәсендә махсус төзелгән мәктәпкә күчерә. Биредә 200 бала белем ала торган мәктәп комплексы ачыла һәм ул XVIII гасыр ахырына кадәр үз эшен дәвам итә. Менә шушы керәшен мәктәбен тәмамлаган руханилар чукынган татарларны, чуашларны, мариларны, удмуртларны һәм мордваларны ана телендә православие динендә тәрбияләүгә зур өлеш кертәләр.

Канашевич миссионерлык эшенә барлык көчен биреп, барча мөселман һәм мәҗүсиләрне православие диненә күчерергә һәм аларны чын урыска әйләндерергә тырыша. Тик ул кулланган ысуллар рухани-түрәләр тарафыннан да бик хупланмаган бугай, чөнки ул Казанга епископ булып килә, епископ булып китә. Ә бит Казан руханилары 1749 елның 22 июлендә синодка Лука Канашевичның миссионерлык эшендәге уңышларын, керәшен мәктәпләре, чиркәүләр төзүдә тырышлыгын исәпкә алып, аңарга— митрополит, анысы булмаса, архиепископ исемен бирүне сорыйлар. Тик бу хат эзсез югала, данлыклы миссионер дәрәҗәле исем ала алмый.

Татар халкы хәтерендә сакланган риваятьләрнең берсендә Лука Канашевич хакында мондый кызык юллар бар: «Күп еллар элек, Казанда мәчетләр булмаганда, урыс патшасы мәчет төзергә рөхсәт бирмәгән чорда, мөселманнар өйләрендә генә дога кылырга мәҗбүр булалар. Шул чорда Казанда бер архиерей яши. Ул бөтен татарны урыслаштырмакчы була. Ул күп кенә татарга урысларның кара чапанын һәм ыштанын кидертә, күп кенә мөселманны чукындыра. Татарларның теләген исәпкә алмыйча, архиерей аларны урыс итмәкче була дип татарлар министрларга хәбәр итәләр. Министрлар архиерейны ачуланалар һәм Себергә сөргенгә сөрәләр». Риваятьнең икенче вариантында Лука Канашевичны Казаннан Зөядәге монастырьга сөргенгә озаталар. Күп кенә мөселманнар аны коточкыч хәлдә күрәләр. Монастырь ишек алдында ул тузып ертылып беткән киемдә, муены борылып артка карап йөри икән. Бу риваятьнең өченче варианты да бар, анда Аксак Каратун болай сурәтләнә: «Аксак Каратун Зөя монастырендә күп гомер сөреп, ахырында йөзе тискәре әйләнеп вафат булмышдыр. Безнең бистә халкы Мәкаржәгә барганда монастырь ишек алдында койма ярыгыннан карарлар икән. Аксак Каратун һаман арлы-бирле шунда йөрер икән; йөзе тискәре килгән икән. Патшаның әмере белән Аксак Каратунны төшереп монастырьга куйганнан соң, мөселманнар бераз иркенләп, йортлар һәм мәчетләр сала башлаганнар».

Шулай итеп, халык хәтерендә Лука Канашевичның миссионерлык хезмәте үзенчәлекле тасвирлана. Әлбәттә, мөселманнарны рухи эзәрлекләү, көчләп

чукындыру өчен ул җавапка тартылмый. Шулай да, Батырша восстаниесе сабакларын искә алып, 1755 елның 9 октябрендә аны Казаннан Белгород епархиясенә күчерәләр һәм ул биредә 1758 елның 1 гыйнварында вафат булганчы житәкче булып эшли.

## Борис Ярцев — күренекле күчерүче

Керәшеннәрне һәм мөселман-татарларны туган авылларыннан икенче урынга күчерү христианлаштыру чорында бик мөһим урын алып торган һәм ул чукынучылар саны үсүгә нык тәэсир иткән. Күчерү ысулы православие динен кабул итүдән баш тарткан мөселманнарга каршы бигрәк тә еш кулланылган. Мохтаҗлык кына татарларны дин алыштырырга мәҗбүр иткәнен белгән миссионерлар элек яшәгән урыннан башка урынга күчереп утыртуны бик яхшы файдаланганнар. Синод тарафыннан кабул ителгән бер документта мондый сүзләр бар: «... селить из новокрещен только из татар, а других из разных вер крещеных таковой турбации не чинить, дабы де им, яко простому народу, в крещении препятствия не учинить, ибо-де в преданном им законе дальнего заблуждения в них не находится, а из махометанского-де закона своею волею б к призыванию и увещанию, кроме приключившейся нужды, ко святому крещению не приходят, не как де прочии беззаконные язычники, простой и подлый народ».

Туган илен, туган авылын яраткан, йорт-хуҗалыгын төзек, матур итеп тоту өчен тырышкан татарларның йортларын, җир биләмәләрен калдырып икенче урынга күчеп китәргә теләмичә православие динен кабул итәргә ризалашырга мәҗбүр булырлар дигән фикер миссионерларда юкка гына тумаган. Әлбәттә, яна урынга күчереп утыртуны, бигрәк тә урыс авылларына, православие дине белән тизрәк таныштыру һәм урыс халкы белән тизрәк кушылу ысулы итеп тә караганнар.

Керәшен кантурында 1742 — 49 елларда күчереп утырту мәсьәләсе белән дворяннардан Борис Ярцев шөгыльләнә. Ул күп еллар кавалериядә хезмәт итеп, поручик дәрәҗәсен алып отставкага китә, 1738 елны Зөя шәһәре воеводасы итеп билгеләнә. Миссионерлык үзәге булган Зөядәге воевода башка диндәгеләрне чукындыруда да бик теләп катнашуын искә алып шушы эшкә билгеләнә дә инде. Сенат кабул иткән инструкция буенча Борис Ярцев чукынганнарны төрле кыерсытулардан сакларга, керәшеннәр өчен чиркәүләр төзергә, православие динен яхшы тоткан керәшеннәрне вакытында бүләкләргә, мәчетләр җимерүнең ничек баруын күзәтергә, ислам динен тарату очрагын булдырмаска, керәшеннәргә льгота бирүне, чиркәүгә килеп дога кылуны, дини бәйрәмнәрдә катнашуны күзәтеп торырга тиеш була. Ә керәшеннәрне элек христиан динен кабул иткәннәр янына яисә урыс авылларына күчереп утырту карала. Күргәнегезчә, Борис Ярцевның вазифалары миссионерларныкыннан аерылмый диярлек.

Борис Ярцев күчереп утырту кагыйдәләрен тормышка ашырганда башта ук керәшеннәр тарафыннан зур каршылыкка очрый. Керәшеннәр үз авылларыннан башка урынга күчеп китәргә риза булмыйлар. 1742 елда ук Борис Ярцев керәшеннәрнең туган авылларын, йортларын ташлап урыс авылларына, Саратов һәм Царицын арасына күчәргә теләмәгәннәрен таныргa мәҗбүр була һәм керәшеннәр булган авыллардан мөселман татарларны күчереп утырту турында сенат указы чыгарта.

Борис Ярцев керәшеннәрне ин башта урыс авылларына күчерергә тырышса да, алар арасында мондыйлар табылмый. Без дә керәшеннәрнең урыс авылына күчеп килүе хакында архивта документлар әлегә тапмадык. Киресенчә, православиене кабул иткән татарларның элек чукындырылган татарлар яшәгән авылларга күчеп утыруы турында шактый документ Татарстан Республикасы милли архивында сакланган. Ул хакта берничә мисал: Казан өязе Сасна авылыннан чукынгач Мирон Осипов дип исемләнгән керәшен Евмений Скаловский карары белән Кушкет авылына 1755 елда күчерелә һәм керәшен кызы Марина Семеновага өйләнә; Уры авылыннан Сәгыйть Сәгыйтов (чукынгач Савелий Дмитриев) булып теркәлгән Чепья авылына күчерелә һәм дә керәшенгә өйләнә; Мортыш-Тамак авылындагы Алексей Иванов Шәле авылына күчерелә һәм керәшен Окулина Моисеевнага өйләнә.

1762 елда үткәрелгән халык санын алу материалларын өйрәнгәндә дә шуна

игътибар итәсең — рекрут булудан котылу максаты белән христиан динен кабул иткән татар егетләре керәшен авылларына күчерелгәннәр һәм анда керәшен кызларына өйләнгәннәр. Тагын шунысы кызык: гаилә корган егетләрдән хатыннары 5-6 яшькә олырак. Монысы да яхшы аңлашыла, чөнки ул заманда рекрут итеп 12-15 яшьлек балаларны да армиягә алганнар, ә кияүгә чыкканда керәшен кызлары балигъ булырга тиеш булган. Димәк, бу егетләрнең хәләл җәфетләре хатын гына түгел, ә дини тәрбияче вазифасын да үтәгәннәр. Миссионерлары менә шундый оригиналь ысул белән татарны православ динендә тәрбияләгәннәр.

Керәшеннәрне күчереп утырту, аларны мөселманнардан кыерсытудан саклау, мәҗүсиләр арасында уңышлы православие динен таратуны тирәнтен анализлаганнан соң Борис Ярцев 1744 елның яз айларында сенат һәм синод исеменә махсус хат юллый. Аның фикеренчә, христиан динен таратудагы төп кимчелек— православие динен кабул итмәүчеләрнең керәшеннәрне кыерсытуы. Алпавытлар да крепостной дәрәҗәсендә булганнар, христиан динен кабул итүгә карамастан, коллыктан азат ителми, төрле сәбәп табып төрмәгә утыртыла, олаучылыкка түләмичә тартыла, салымнан азат ителми, рекрутлыкка алына, алар өстеннән уйлап чыгарылган шикаятьләр языла. Мондый кимчелекләрдән арыну өчен ул түбәндәге чараларны тәкъдим итә:

— керәшеннәр булган урыннарда вулыс старшиналарын һәм йөзбашларны керәшеннәрдән генә билгеләргә һәм алар күршеләре арасында килеп чыккан аңлашылмаучылыкны җайга салырга тиешләр;

— керәшеннәрне кыерсытудан саклау өчен дворяннардан махсус управитель билгеләргә.

Сенат, бу тәкъдимнәрне урынлы булуын аңлап, Борис Ярцевны Санкт-Петербургка чакырып ала. Борис Ярцевның чыгышын тыңлаганнан соң, тәкъдимнәр кабул ителә. Шуна өстәп керәшеннәрне кыерсытудан саклап күчереп утырту өчен Казан һәм Нижгар губерналарында өлкән офицерлардан берәр кеше, аның үзен саклар өчен 12 солдат һәм бер капрал билгеләнә. Воронеж губернасы Казаннан ерак булганлыктан, Борис Ярцевка һәрвакыт шунда яшәргә кушыла. Ярцевның ярдәмчесе итеп Цивил шәһәре дворяннарыннан чуаш телен белгән Андрей Завадский, Шацкидан Петр Антонов һәм Иван Оленин билгеләнәләр. Алар 1749 елда синод тарафыннан йөкләнгән вазифаларны яхшы үтәгән өчен бүләкләнәләр.

Борис Ярцев тәкъдиме белән 1743 елның 26 июлендә сенат «О принятии Новокрещенской конторой мер к целесообразному расселению новокрещеных инородцев Уфимской губернии» дигән указ кабул итә. Указ Ырынбур каласы тирәсендәге Сакмар шәһәрчегеннән алып Карабаш авылына кадәр Яна Мәскәү тракты буена керәшеннәр өчен аерым авыллар, ә авылларда чиркәүләр төзергә боера. Бигрәк тә бирегә Иван Грозный заманында ук чукындырылып та православие динен үзләштермәгән татарларны күчереп утырту карала. Татарстан Республикасында Абрамовка, Кәләй, Илтен-Бута, Түбән Абдул исемле керәшен авыллары нәкъ шушы указны тормышка ашырган вакытта пәйда була да инде.

Керәшеннәрне күчереп утырту буенча уңышлы проект дип Нугайбәк кирмәненә һәм аның тирәсендә 10 авылга күчерүне атап булыр иде. Бирегә күчерелгән татарларны казак сословиесына язу 1736 елдан башланса да, 1740нчы елларда гына чын-чынлап гамәлгә ашырыла. Бирелә башта чиркәү булмаган, керәшеннәрне дингә священник өйрәткән. Нугайбәктә һәм Бакалы авылында 1746 елда чиркәү дә төзелгәч, татарларга дини тәрбия бирү тагын да көчәя. Бирегә Казан артында чукындырылган татарлар белән бергәттән ислам илләреннән Русия мәмләкәтенә килеп урнашырга теләгән чукынган фарсыларны, әфганнарны, гарәпләрне, бохаралыларны, каракалпакларны күчерәләр. Алар әкренләп татар телен үзләштереп, керәшен татарлар булып китәләр.

1768 елда Нугайбәктә казак хезмәтендә 450 урыс һәм 685 чукындырылган мөселман була. Тик аларның күбесе христиан булып исәпләнә генә. Шулай да бирегә күчерелгән керәшеннәр белән системалы дини эш алып бару, казак сословиесенә күчерү һәм һәрвакыт урыслар белән аралашып яшәү нугайбәкләр дип аталган керәшеннәр формалашуга китерә.

Борис Ярцев керәшеннәрне бүтән урынга күчереп утырту белән бергә турыдан-туры чукындыру белән дә шөгыльләнгән. Кулланган ысулларын аңлар өчен бер мисал

китерик. Бу— Тамбов провинциясенең Югары Лом өязендәге Решетино авылында 1744 елның 13 июлендә булган хәл. Гадәттә миссионерлар командасы белән очрашу өчен берничә авыл халкын бергә җыя торган булганнар. Бу авылга да тирә-як салалардан 500ләп татар чукындыру турындагы указны тыңлар өчен җыела. Борис Ярцев, 1740 елның 11 сентябрь указын халык алдында укыгачтын, басып тыңлап торган татарлардан «Кайсыгыз беренче булып чукына?» дип со рый. Тик җыелган татар арасында чукынырга теләк белдерүче табылмый. Киресенчә, алар бердәм рәвештә «Чукынмыйбыз!» дип җавап бирәләр. Моның белән килешергә теләмәгән миссионерлар башта авыл старостасын халык алдында эскәмиягә сузып салып, камчы белән кыйный башлыйлар. Камчы башка татарларга да эләгә. Тик шунда чыгырдан чыккан татарлар миссионер командасын саклап торган солдатларның үзләрен кыйнап ташлыйлар.

Ярцев шикаяте нигезендә Югары Лом өяз кәнсәләре 12 татардан сорау алып тикшерү үткәрә. Тикшерү вакытында татарлар Ярцевны ачуланмадык, солдатларны да кыйнарга теләмәгән идек, миссионерларның камчы белән кешеләргә сугуы гына солдатларны кыйнарга сәбәп булды дип аңлатырга тырышканнар. Тик бу авыл татарларына чукындыру өчен басым ясау алга таба да дәвам итә. Моңа түзә алмаган, чукынырга теләмәгән авыл кешеләре Тамбов якларыннан Ык буена, хәзерге Азнакай районы Илбәк авылына күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

1749 елны Борис Ярцев, авырганлыктан, бу эштән азат ителә һәм аның урынына элек ярдәмчесе булып эшләгән Федор Вячеслов исемле кеше куела һәм ул вазифаларны ун ел дәверендә тырышып башкара. Тик бу юнәлештә әлләни зур казанышларга ирешә алмый, чөнки Батырша восстаниесе тәэсирендә татарларны үз авылларыннан икенче урынга күчерү тыелган була. Элегрәк, 1751 елның 7 августында, Федор Вячесловка дини эшләр буенча сенатны борчымагыз дигән указ тапшырылу да аның активлыгын чикләгәндер, күрәсең.

Көчләп чукындыру сәясәтен тормышка ашыру Идел буенда яшәгән татарларны миссионерлар күрсәткән урынга түгел, ә бәлки Урал, Себер якларына күчеп китәргә мәҗбүр итә. 1762 елда үткәрелгән халык санын алу вакытында Казан губернасында яшәгән 42185 ир-атның кайда икәнлеген ачыклый алмаганнар. Татарларның көнчыгышка качып китүе Казан губернасында татарлар санын шактый киметә. Элек Казан губернасы халкы арасында татарлар 22,2 процент тәшкил итсә, 1762 елда бу күрсәткеч 20,1гә кадәр кими. Татарлар саны арткан урыннар да бар. Бу бигрәк тә Уфа, Минзәлә, Бөгелмә, Ырынбур өязләре.

## Яңа керәшен кантурын ябу

Екатерина II тәхеткә утыргач, Русия дәүләтендә ислам диненә мөнәсәбәт әкренләп уңай якка үзгәрә башлый. Әлеге үзгәрешнең нигезендә— мөселманнарның дини кысуга каршы, мөселманча яшәү өчен фидаи көрәше. Бу хәл миссионерлыкны да киметүгә китерә. 1762 елның 25 июлендә Казан епархиясе җитәкчесе итеп күпләп чукындыруны башлап йөрүчеләрдән булган Василий Пуцек-Григорович билгеләнә. Бу вакытта Идел буенда христианлаштыру процессы тәгәлләнеп килә. Мәҗүсиләр инде тулаем чукындырылган диярлек. Миссионерлар да, дәүләт эшлеклеләре дә мөселманнарны көчләп чукындырып булмаганлыгын төшенгәнлектән, ислам динен инде Русия дәүләтенең куәтен күтәрү өчен файдаланырга телиләр.

1764 елның 6 апрелендә Яңа керәшен кантурын ябу турында сенат указ кабул итә. Указ нигезендә кантур эше туктатыла, башка диндәгеләрдән чукынганнар өчен салым түләтү, рекрут итеп алу, рекрутлыкка өстәмә акча җыю бетерелә, керәшен татарлар дәүләт крестьяннары сословиесенә теркәлә, кантур хезмәткәрләре, офицерлар килгән урыннарына кире кайтарылалар.

Шушы указ яңа керәшен һәм иске керәшен төшенчәсенә дә ачыклык кертә. Әйтергә кирәк, керәшеннәрнең барлыкка килүе хакында әлегә кадәр бәхәсләр бара. Тик ул бәхәсләрнең тарихи нигезе юк, алар үткәнне белергә теләмәгәнлектән генә хәзерге көнгә кадәр яши бирә. Менә шушы указ «яңа керәшен» дип православие динен беренче ревизиядән сон (1720 елларда Русиядә беренче халык санын алу шулай дип аталган) кабул иткәннәрне, ә «иске керәшен» дип моңа кадәр кабул итүчеләрне

атый. Указ бу мәсьәләгә ачыклык кертсә дә, чынбарлыкта яна һәм иске керәшеннәр бер авылда яшәгәнлектән, бер-берсе белән туганлашып-буталып бетәләр һәм алар арасында аерма юкка чыга диярлек. Шуна күрә хәзерге керәшеннәр үзләрен бик борынгы чорда, кайберләре Иван Грозный заманында, ә кайберләре хәтта ана кадәр үк христиан динен кабул иткән дип уйлыйлар.

Указ Яна керәшен кантурын япса да, христианлаштыру буенча миссионерлык эшен бөтенләй юкка чыгармый, аны бары урындагы епархияләргә генә тапшыра. Казан епархиясендә— өч, Тобол, Иркут, Тамбов епархияләрендә— икешәр, Нижгар, Вятка, Рязан, Әстерхан епархияләрендә берәр дингә өндәүче (проповедник) билгеләнә. Анна Иоанновнанын 1740 елнын 11 сентябрендә чыгарылган указы нигезендә алар миссионерлык хезмәтен алып барырга тиеш булалар.

| Кантур житәкчеләре | Еллар | Православиегә күчүчеләр саны | Ул еллардагы уртача сан |
|---|---|---|---|
| Алексий Раифский | 1731-1738 | 2140 | 267,5 |
| Димитрий Сеченов | 1739-1742 | 22031 | 5507,7 |
| Сильвестр Гловацкий | 1742-1749 | 268326 | 38332,3 |
| Евмений Скаловский | 1750-1761 | 69924 | 5378,8 |

Яна керәшен кантуры эшенә йомгак ясаганда мондый нәтижәгә килеп булыр иде. Хакимият белән бергә эш алып барган миссионерлар нәкь менә шушы елларда урыс булмаган халыкларны христианлаштыруда монарчы күрелмәгән нәтижәгә ирешәләр. 33 ел дәвамында православие динен кабул итүчеләр саны 384226 житә; (алар арасында татарлар— 12699 кеше). Ин күбе — 277326 кеше — 1743-1749 елларда православиегә күчә. Яна керәшен кантурынын ин нәтижәле эше дә шушы елларга туры килә. Бу— Лука Канашевич, Димитрий Сеченов, Вениамин Пуцек-Григорович, Давидовлар, Сильвестр Гловацкий, Иоанн Орловский, Евмений Скаловский кебек миссионерларнын тырышлык нәтижәсе.

Югарыдагы таблица Яна керәшен кантуры ирешкән «унышларны» күрсәтә. Дүрт житәкче арасыннан эшенен нәтижәлелеге белән Сильвестр Гловацкий аерылып тора. Күптән куелган ямьсез максатка ирешү юнәлешендәге бу нәтижәне дәүләтнен һәм православие миссионерларынын триумфы дип карау дөрес булыр.

Башка диннәрне бетереп, Русияне бер динле православие дәүләтенә әверелдерүне максат итеп куйган күпләп христианлаштыру сәясәтен гамәлгә ашыру мөселманнарда табигый ризасызлык тудыра, күпләрдә нәфрәт уята. Халыкнын мондый сәясәткә каршы көрәше Уфа өязендә 1755 елда Батырша мулла восстаниесе белән тәмамлана. Шушы восстание нәтижәсендә керәшеннәр өчен өстәмә салым, рекрут жыю туктатыла, жимерелгән мәчетләр урынына яналарын салырга рөхсәт бирелә, ин явыз миссионерлардан Лука Канашевич һәм Сильвестр Гловацкий эшеннән азат ителәләр.

Хакимият белән бергә Яна керәшен кантуры миссионерларынын төп нәтижәсе — бер тамырдан яралган татар халкын дин ягыннан мөселманнарга һәм дә керәшен татарларга бүлү. Гасырлар дәвамында бүлү һәм хакимлек итү лозунгысын гамәлгә ашыру нәтижәсендә бердәм генетик тамырлы татар ике дини халәттә кала һәм бер халыкта ике дин — ислам һәм христиан кыйммәтләренә нигезләнгән рухи мәдәният формалаша башлый. Ә Яна керәшен кантурын ябу Русия дәүләтендә ислам диненен рәсми рәвештә танылган дингә әверелүе юлында бер адым ул.

Татар халкы ислам динен һәм халык буларак үзен саклап калу өчен барган фидаи көрәштә жинеп чыга дип нәтижә ясау да дөрес булыр. Ин авыр елларда да ул төшенкелеккә бирелмәгән, мөселманлыктан ваз кичмичә, яшерен рәвештә мәчетләр төзегән, үз динен тоткан, исламга тугры булып калган. Миссионерларга каршы көрәш елларында ислам куәтләнә, мәжүсилек калдыкларыннан чистара. Дини кысу кими төшүгә керәшен татарлары янадан ислам диненә күпләп кайта башлый, һәм бу процесс XVIII гасыр башында башланып 1905 елга кадәр, Русиядә вөждан иреге игълан иткәнче бара.

# ИМАМ ҺӘМ МӨДӘРРИС

## СӘРВӘРЕТДИН БИНЕ МИФТАХЕТДИННЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Халкыбызның рухи мирасы әлегә барланып бетүдән бик ерак. Архивларда, китапханәләрдә кул тими ята торган борынгы кульязмалардан, иске китап, газета һәм журнал битләреннән эзләп табып, милләтебезгә кайтарасы бихисап галимнәребез, руханиларыбыз, зыялы шәхесләребез бар. Болар — үзләре яшәгән чор тарихының мөһим сыйфатларын җыйнап, үз күңелләренә сыйдырып, буыннан-буынга тапшыруга сәләтле булган остазлар, акыл ияләре. Аларның эшчәнлеген, иҗатын өйрәнү һәм җәмәгатьчелеккә таныту өчен махсус хәзерлеге һәм иң әһәмиятлесе, бу эш белән шөгыльләнергә теләге булган яшь буын галимнәргә бүген ихтыяҗ гаять зур.

Бу язмада шундый өйрәнелми килә торган руханиларыбызның берсенә — имам һәм мөдәррис Сәрвәретдин бине Мифтахетдин шәхесенә тукталып, белгечләрнең һәм киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итәсебез килә. Быел аның тууына 150 ел тула, әмма, ни кызганыч, XX гасыр башында берничә китап язып бастырган, даими рәвештә Риза Фәхретдинов чыгарган «Шура» журналында язышкан бу автор турында бүгенге көнгә кадәр татар җәмәгатьчелегенең мәгълүматы юк, хезмәтләре дә һаман әйләнешкә кереп китә алмый. Бабасының мирасын танытыр өчен җан аткан оныгы — математика буенча дөньякүләм танылган галим, физика-математика фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт университеты профессоры Иҗат Хак улы Сабитов фикеренчә, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин — үз заманының күренекле укымышлысы дип аталырга тулы хокукка ия шәхес[1]. Шәехзадә Бабич аның турында үзенең *«Китаб-ен-нас фи хакк-әл-хавас»* («Күренекле шәхесләр турында китап») исемле атаклы әсәрендә хәтта аерым эпиграмма да язып калдырган:

*Сәрвәретдин Мифтахетдин — һәм мөдәррис, һәм имам,*
*Ул тугандык «ислам, ислам, ислам, ислам...» дип туган!*[2]

Хәзерге көннәргә килеп җиткән хезмәтләре буенча без аны олылап, хәзрәт дип атый алабыз. Оныгының тырышлыгы белән Сәрвәретдин хәзрәтнең исеме «Татар энциклопедиясе»нә кертелде һәм русча басылган V томда (Казан, 2011) аның турында түбәндәге мәгълүмат урын алды.

*Дин эшлеклесе һәм мәгърифәтче Сабитов Сәрвәретдин Мифтахетдин улы 1862 елда Казан губернасы Чистай өязендә (кайбер чыганаклар буенча, Самара губернасы Бөгелмә өязендә) туган. Троицк мәдрәсәсендә белем алган, 1890-1913 елларда Оренбург өязенең Бушман-Суун-Каракыпчак волостенең Теләумбәт авылында имам-хатиб һәм мөдәррис булып торган, 1913 елдан Оренбург өязе Югары Биккузино авылында яшәгән. Ысул-ы җәдит мәктәпләрен оештыру белән шөгыльләнгән. Ислам дине белеме, педагогика буенча хезмәтләре бар: Вәзаифе инсан. Казан, 1898; Әдәбе тәзәввуҗ. Оренбург, 1908; Ислам. Тәрәккый. Ислах. Казан, 1913.*

«Татар энциклопедиясе»нә кадәр үк, тарих фәннәре кандидаты Денис Денисов Уфа, Оренбург архивларыннан Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең тормыш юлы белән бәйле кайбер документлар табып, «Уралда ислам» энциклопедиясендә (2009) беренче булып аның хакында аерым бер маддә бастырган иде[3]. Анда Сәрвәретдин хәзрәтнең Төркиядә белем алуы, 1907 елда Бушман-Суун-Каракыпчак волостенең мөселман җәмгыятен төзүдә башлап йөрүе һәм аның рәисе булуы, актив рәвештә җәдитчелек идеяләрен, аеруча мәдрәсәләрдә рус телен һәм дөньяви фәннәр укытуны яклавы, шуның аркасында кадимчеләрнең яла ягуларына дучар булуы, бай китапханә туплавы һ.б. мәгълүматлар хәбәр ителә. Вафат булу тарихы 1916

[1] Иджад Сабитов. Мечтаю вернуть имя деда//Татарские новости.- 2009. - №3-4.
[2] Шәехзадә Бабич. Зәңгәр җырлар. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990.- 270 б.
[3] Ислам на Урале. Энциклопедический словарь. Серия «Ислам в Российской Федерации». Выпуск V. - М.-Нижний Новгород, ИД «Медина», 2009. С.-324.

елдан соң дип әйтелә. Д.Н.Денисов хәзерләгән белешмә бүгенге көндә Сабитов Сәрвәретдин Мифтахетдин улының тәрҗемәи хәле буенча иң тулы чыганак булып тора, ләкин, кызганычка ки, монда да сораулар җаваплардан күбрәк, бу өлкәдә әле эзләнәсе дә эзләнәсе.

Нигездә, Сәрвәретдин хәзрәтнең китапларының саны җиде-сигез булып, аларны Казан һәм Мәскәү китапханәләреннән табу бик кыен түгел. Кыен булганы — авторның телен һәм әйтергә теләгән фикерен ачык аңлау мәсьәләсе, чөнки Сәрвәретдин бине Мифтахетдин XX гасыр башы сөйләм теленнән аермалы буларак, шактый күп гарәп һәм фарсы сүзләрен кулланып, гаять катлаулы дини-фәлсәфи темаларга язган. Әсәрләрен өстән генә карап чыкканда да, аның ислам фәлсәфәсе, дин социологиясе буенча тирән фикер йөрткәнлеген күреп була. Ләкин бүгенге көндә дә бу фәннәр буенча татарча атамалар (терминнар) эшләнмәгәнлеген һәм саф татар телендә гыйльми хезмәтләр язылмаганлыгын искә алсак, нигә һаман Сәрвәретдин хәзрәт әсәрләренә галимнәрнең кулы тимәгәнлеген фаразларга була: теле авыр, темасы катлаулы, атамалар аңлашылмый. Шул ук вакытта Сәрвәретдин хәзрәт кулланган фәнни тел, нигездә, аның белән бер чорда яшәгән дин галимнәре Муса Биги, Зыя Кәмалиләрнең теленнән әллә ни авыр түгел, дип әйтергә мөмкин.

«Шура» журналында басылган мәкаләләре буенча гына фикер йөртсәк тә, Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең берничә зур күләмле язмасында Аллаһның берлегенә нигезләнгән тәүхид темасын күпьяклап эшләгәнен күрәбез, шулай ук галим үз заманы фәннәренең ислам дине белән мөнәсәбәтен, диндә тәкълид (иярүчәнлекнең) урынын, исламдагы әхлак мәсьәләләрен яктырта, аурупалылар күзлегеннән чыгып караганда мөселманнарның тормышы ничек күренгәнлеген анализлый. Мәкаләләрнең күпчелегендә тәнкыйди караш өстенлек итә: язучы ислам әһелләре арасындагы торгынлыкны, мөселман дөньясының Аурупадан артта калу сәбәпләрен эзләгәндә христиан миссионерларын гына сүгеп калмый, мөселманнарның үзләрендә дә кимчелекләр күп булуын әйтә. Мәсәлән, «Шура» журналының 1911 елның 13 нче санында чыккан «Исламның хәле хазирәсе вә бүгенге мөселманнар» мәкаләсеннән бер өзек китереп, авторның тел-өслүб үзенчәлекләренә һәм фикер сөрешенә игътибар бирик:

*«Әгәр дә хәзрәти пәйгамбәр шимдики (хәзерге) заманда кабереннән кайтып, шимдики өммәтләренә нәзар кыйлса (караса) иде: «Бунлар бәнем өммәтем дәгел (түгел),» — дия белгел (дия алыр), аңлардан фырар идәр (качар) иде. Чөнки хәзерге өммәтләренең гамәлләре, хәрәкәтләре исламиятнең асыл мәүзугы (темасы) вә кавагыйде мөкатдәсенә (изге кагыйдәләренә) бигрәк хилаф (хата) улынмактадыр»,* — дип сүз башлый автор. Үз заманы гыйлемнәренең хыялдан гына гыйбарәт булуын, мөселманнарның тәрбиясенә һәм үсешенә файда китермәвен әйтеп, автор, бу гыйлемнәрнең чын дини тәгълиматтан һәм Коръән хакыйкатеннән тулысынча ерак калуын тәнкыйть итә. Үз чоры галимнәренең *«нәфак (шом һәм дошманлык тудыру), ... рия (икейөзлелек) вә мөдаһнә (ялагайлык), хәсед (көнчелек) вә гайбәт, бөһтан (яла ягу) вә ифтира (нахак сөйләү) кеби зәмаим (начарлык) илә мөтассав (тулган) иделдекләре күрелер»,* — ди (389 б.).

Үз дәвере суфилары һәм тарикатьләр (суфи оешмалар) турында Сәрвәретдин хәзрәт болай ди: *«Хәлбуки хәзерге голамәмез илә шәйхләремез вә суфиларымыз бу көндә бөтен мөселманнарның мөкатдәсләре (изгеләре) вә юлбашчылары булып, бөтен галәме ислам аларның тәрбияләрендәдер. Боларның күбесе асыл исламиягә вә рәсуллаһның сөннәт рәшидәсенә муафикъ дәгел (туры килмәгән) кагыйдәләр илә мөселманнарны тәрбия кыйладыр. Хәзерге тарикъләр вә кагыйдәләрне гакыл вә хикмәт узрә татбик идеп (чагыштырып, тикшереп) карасак, бу икенең арасында һич тә мөтабакат (охшашлык, туры килү) күренмәс. Аларның күбесе бидгать (исламга соңыннан кертелгән яңалык) вә дүзмәләрдән (уйдырма) гыйбарәт, әсас хакыйкатьдән хариҗдыр (читтә, тышта)»,* — ди. Аурупалыларның мөселманнарга кимсетеп каравына, мөселманнар үзләре дә гаепле, чөнки алар үз хокукларын белмиләр һәм якламыйлар, ди. Әлеге фикер «Шура»да 1913-1914 елларда басылган *«Ислам вә мөселманнар»* исемле мәкаләдә дә дәвам иттерелә.

*«Аурупалылар вә шимдики мөселманнар» («Шура», 1911 №14, 427-429 б.)* исемле

мәкаләсендә исә автор мөселманнарга һәм исламга дошманлык яки тәнкыйть күзе белән караучы аурупалыларны өч группага бүлеп күрсәтә һәм һәрберсенә төпле бәяләмә бирә. Беренче төркемгә ул миссионерларны кертә: алар, христианнар белән мөселманнар арасындагы сәяси каршылык һәм көрәшләр тарихын гел истә тотып, үзара дошманлык хисен арттырып тору яклы, ди. Автор Шам, Мисыр, Әндалусиядә булган ислам-христиан бәрелешләрен, хәлифәлекнең Госманлы дәүләтенә күчкәннән соң булган дини юнәлешле сугышларны анализлап, христиан миссионерларның «төп максаты бу дөньядан әһле исламны юк итү» икәнлегенә басым ясый. Миссионерларны, кайчан да булса ислам дине өстен килер дә, мөселманнар бар дөньяга хуҗа булырлар дигән курку тойгысы биләгән. Шуңа күрә алар бар көчләренә мөселманнарны каралау, аларга яла ягу белән шөгыльләнәләр, ислам динен золым итеп күрсәтергә тырышалар, ди.

Икенче төркемгә *«исламның хөкемнәрен аңламаган Ренан һәм башка Аурупа философлары»* керә. Бу акыл ияләренә, автор фикеренчә, барлык диннәргә, хәтта христианлык, яһүди һәм ислам тәрбия ысулларына да түбәнсетеп карау хас. Болар исламга миссионерлардан да көчлерәк һөҗүм итәләр, аларның карашы буенча, исламның мәдәният белән бер бәйләнеше дә юк, бу дингә кыргый бер тәгълимат дип карыйлар, ди. Сәрвәретдин хәзрәт өченче төркемгә материалистлар һәм рационалистларны аера. Болар бар нәрсәне акыл һәм мантыйк күзеннән генә тикшереп, фәнгә мөнәсәбәттә бәялиләр. Шуңа күрә ислам динендәге кайбер догмаларны кире кагалар. Мәсәлән, Коръәндә әйтелгән җиһанның алты көндә яратылуы, Адәм галәйһиссәламнең җирдәге бар кешеләрнең атасы булуы, хатын-кызларның аның сөягеннән яратылуы, туфанда Нух пәйгамбәрнең тереклекне коткарып калуы һ.б. вакыйгалар физиология фәненә бөтенләй туры килми дип ассызыклыйлар, ди.

Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең «Шура» журналының 1908-1909 елгы саннарында урын алган зур күләмле *«Тәүхид, хәят, ислам»* мәкаләсе, 1898 елда басылган *«Нәүгы бәшар»* («Кешелекнең яратылышы») китабы кебек, дөнья яратылышы, эволюциясе һәм киләчәге турында фәлсәфи уйлануларга нигезләнгән. Китабына язган кереш сүздә ул, хәзерге телгә күчереп әйткәндә, болай ди: *«Барлык адәм балалары өстенә кешелеккә хас булган күркәм сыйфатларны тулы рәвештә саклап калу һәм бөтен тиешле вазифаларны Аллаһның хикмәте вә намус кушканча үтәү бурычы йөкләнгән. Һәрбер кешегә үзен һәм Хакыйкатьне танып белү, Аллаһының хикмәте белән бәйле намус кануны кушканча хәрәкәт итүе дә тиеш булганга, адәм балаларының күркәм сыйфатларын тасвирлауга багышланган кечкенә генә бер хезмәт яздым. Ватанпәрвәрлегемнең нәтиҗәсе булган бу хезмәтнең язылуы ватандашларым өчен бер үрнәк һәм аңлатма булуын гына телим».*

Ун ел соңрак басылган мәкаләсендә дә автор әлеге максатны күздә тотып, адәм баласының дөньяга яратылган вакытыннан алып ия булган үзенчәлекләрен аңлата һәм аларның ни рәвешле үстерелә алуы турында сөйли. Аның фикеренчә, адәм баласының тормышы бер-берсе белән бәйле булган ике нәрсәгә нигезләнә: берсе — кешенең туганда ук үзенә бирелгән мөмкинлекләрен, сәләтен, теләкләрен күрә һәм бәяли белүе, икенчесе — гыйлем һәм мәгърифәт. Кешеләрнең күркәм сыйфатларын (фазиләтләрен) өч төргә бүлә: 1. Нәфес сыйфатлары *(фазаиле нәфсия)*. 2. Тән (гәүдә) сыйфатлары *(фәзаиле бәдәния)*. 3. Иҗтимагый сыйфатлар *(фәзаиле иҗтимагыя)*. Бу сыйфатларның һәрбере язмада аерым-аерым аңлатыла һәм тәрбия нәтиҗәсендә үстерелә алу мөмкинлеге әйтелә. Алар арасында иң әһәмиятлесе итеп, Сәрвәретдин хәзрәт беренче төрне күрсәтә, чөнки нәфес фазиләтләренең нигезен тәүхид һәм мәгърифәт тәшкил итә, тәһарәт, гыйбадәт, гадәләт, гыйффәт кебек әхлак сыйфатлар тулыландыра, ди. Дин, яратылыш, кешенең яратылыштан ия булган үзенчәлекләре бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора, гыйлем һәм мәгариф ярдәмендә тәрбия иткәндә кешенең акыл (акли) һәм дини гыйлемнәрдә зур мөмкинлекләргә ирешә алуы әйтелә.

Күргәнебезчә, мәкалә, дин социологиясе күзлегеннән чыгып, инсан тәрбиясе, рациональ һәм дини гыйлемнәр ярдәме белән кешенең җитлегү, үз-үзен үстерү мөмкинлеге һ.б. хакында укучыларга юл күрсәтүне максат итеп куя, дин аша гуманизм

идеяләрен күтәрә. Галимнең аңлату ысулы, гарәпчә-фарсыча гыйбарәләрне һәм атамаларны еш куллануга карамастан, тәфсилле һәм эзлекле дип әйтергә кирәк.

Хәзрәтнең эшчәнлеген хронологик яктан күзәткәндә, үзе күтәргән катлаулы темаларга аның кабат-кабат әйләнеп кайтып эшләвен күрәбез. Мәсәлән, 1898 елда Казанда нәшер ителгән *«Вәзаифе инсания»* («Кешенең вазыйфалары») китабындагы фикерләр соңрак «Шура»да басылган тирән эчтәлекле мәкаләләрендә дәвам иттерелә. Өйләнешү һәм гаилә этикасы темасына багышланган *«Әдәбе тәзәввүж»* (*«Өйләнешү әдәбе»*) (1908) һәм *«Балалар тәрбиясе»* (Эстәрлетамак, 1911) китаплары шәригать нигезенә корылган тәгълим-тәрбия, ягъни педагогика фәне буенча тәүге татарча дәреслекләр рәтендә санала ала. Изге китапның һәм гарәп теленең мөһим хосуслары турында язылган *«Коръән газыйм»* (Оренбург, 1903) һәм *«Коръән шәриф»* (Оренбург, 1911) исемле хезмәтләрендәге фикерләр «Шура» журналында 1912-1914 елларда басылган күләмле *«Тәгълиде әхвале инсан вә Коръән»*, *«Хакыйкый ислам вә тәрбия»* мәкаләләрендә дә дәвам ителә. Монда шуны да әйтергә кирәк, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин Оренбургта Ризаэтдин Фәхретдин җитәкләгән «Шура» журналы белән актив эшчәнлеген бу басма рәсми рәвештә ябылганга кадәр алып бара: иң соңгы язмасы *«Диннәр хакында нәзарият»* 1917 елның 3-10 саннарында урын алган. Гомумән, «Шура» журналының библиографиясенә караганда, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин дини темаларга иң күп мәкалә язучы авторлардан хисаплана ала[4]. XX гасыр башында чыккан башка журналларда да Сәрвәретдин хәзрәтнең язмалары булуы бик мөмкин.

Китаплары арасында махсус тукталып тикшерү-өйрәнүне сорый торган *«Ислам. Тәрәккый. Ислах» («Ислам. Прогресс. Реформа»)* 1913 елда Казанда басылган һәм безгә билгеле булган соңгы китабы санала. Бу әсәрендә авторның бер бүлектә шул чорда хәлифәлек мәркәзе булган Төркиядә алып барылган мәгариф сәясәтенең дөрес булмавы хакында әйтелгән тәнкыйть фикерләре, госманлы империясенең тарихын һәм бүгенгесен яхшы белүе, гомумән, кулланган теленең дә госманлычага нык якын торуы Сәрвәретдин хәзрәтнең нинди дә бер сәбәп белән (мәсәлән, белем алу яки хаҗ юлында тукталу) чынлап та күпмедер вакыт Төркиядә яшәвенә ишарәли.

Әлбәттә, бу кечкенә язмабызда Сәрвәретдин бине Мифтахетдин иҗатының һәм фикер дөньясының төп хосусиятен ачып бетерүне максат итеп куймадык, киресенчә, без игътибар иткән үзенчәлекләр арасында бәлки иң кирәклесе әйтелми дә калгандыр әле дигән шөбһәбез юк түгел. Инде югарыда әйтелгәнчә, имам һәм мөдәррис Сәрвәретдин бине Мифтахетдин әсәрләрен аңлау һәм анализлау өчен шактый зур көч сарыф итәргә, махсус рәвештә җентекләп шөгыльләнергә кирәк. Тик шунысы шиксез ки, мәгърифәтче һәм дин галиме буларак, ул тормышын үз халкына хезмәт итүгә багышлаган, әсәрләре белән җәмгыять әхлагын тазартырга, милләтенең дөньяга карашын киңәйтергә, рухи байлыгын, тән һәм җан сихәтлеген арттырырга омтылган. Әлбәттә, Мифтахетдин улы Сәрвәретдин Сабитов кебек зыялы милләт хадимнәребез татар рухи мирасы тарихында кирәгенчә бәяләнергә, онытылмаска, хөрмәт белән искә алынырга бик тә лаеклы.

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы, профессор*
*(Мәскәү).*

---

[4] Бу уңайдан Иҗат абый Сабитовның Миркасыйм Госманов турындагы җылы хатирәләрен дә искә аласы килә. Ул Казанда бер математика конференциясендә булган вакытта бабасының эшләре турында киңәш алу өчен Миркасыйм абыйга мөрәҗәгать иткән. Бабасының "Шура" журналында басылуын ишеткәч, Миркасыйм абый тиз генә үзенең китабында Сәрвәретдин хәзрәт язган мәкаләләрнең исемлеген табып, әйткән: "Менә карагыз, бабагыз берничә генә түгел, ә күп дистә мәкалә язган, "Шура" журналында ул ел, аның башыннан азагына диярлек, бастырылган, ә аның редакторы Ризаэтдин Фәхретдин бик таләпчән кеше булган, бабагызның хезмәтләрен һәрвакыт бастырган икән, димәк, ул аларны югары бәяләгән булырга тиеш".

# МИЛЛИ МОҢНАРЫБЫЗ ИЛЧЕСЕ

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ ҖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕНӘ 75 ЕЛ

«Халык җырлары – бабаларымыз тарафыннан калдырылган ин кадерле вә иң бәһале бер мирастыр», – дип әйтүе белән Тукай мең тапкыр хаклы. Әнә шул мирасны югары дәрәҗәдә затлы, зәвыклы итеп башкаручы, саклап килүче Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле үзенең 75 еллыгын билгеләп үтә.

1937 елда Филармония кысаларында барлыкка килеп, озак та үтми аерым оешма булып яши башлаган ансамбль милли сәнгатебезгә хезмәт итүне үзенең бурычы итеп куя.

Билгеле, әлеге җаваплы, мәртәбәле эшне оештыруда үз эшенә чын күңелдән бирелгән осталар да сорала. Талантлы музыкантлар Зөләйхә Әхмәтова, Александр Ключарев – ансамбльгә нигез салучылар булып саналырга хаклы.

Моңарчы көй-җырларыбыз, биюләрнең аерым башкарылып килүен генә күреп ишетеп белгән тамашачыга күмәкләшеп бию, ике яки берничә тавышка җырлау, төрле уен коралларында берьюлы уйнау, халкыбызның гореф-гадәтләрен яктырткан сәхнә күренешләре яналык була. Халык арасыннан талантларны ансамбльгә тарту максатыннан сайлап алу смотрлары да оештырыла. Композиторлар М. Мозаффаров, З. Хәбибуллин, М. Латыйпов, Г. Шаһиев хор өчен дә, бию өчен дә яна әсәрләр иҗат итәләр. Ансамбльнең солисты, талантлы җырчы Разия Тимерханова башкаруында озын көйләр, чиста, янгырап торган тавышлы Галия Гафиятуллина, бай тембрлы күкрәк тавышы белән җырлаучы Сөләйман Йосыпов... Талантларны таный белүче кем генә сагынмый икән аларның моңнарын!

Ватан сугышы башлану – зур планнар белән яшәгән, үсеп килүче ансамбльнең яшәешенә дә үзгәрешләр кертә, артистлар бригадаларга бүленеп тылда, фронтта эшли башлыйлар.

1944 елда ансамбльгә Фәйзи Гаскәров килү зур табыш була. Халык тормышын якыннан белгән талантлы сәнгатькяр эчтәлекле биюләр куюы белән ансамбльгә яналык кертә, яна рух өсти. Аның куелышындагы «Шома бас», «Тыйнаклык», «Җизнәкәй» (Г.Гафиятуллина белән С.Йосыповның җыр дуэты да) ансамбльнең төп бизәкләре булып тора. Хореография буенча икенче талантлы шәхес Гай Таһировның исеме дә ансамбль тарихына кереп калган. Татар опера һәм балет театрында балетмейстр булып эшләү белән бергә әлеге оста җыр һәм бию ансамблендә дә биюләр куя.

Олуг талант ияләре, оста оештыручы, татар сәнгатенең үсеше өчен чын мәгънәсендә янып-көеп яшәгән ансамбльнең сәнгать җитәкчеләре З. Әхмәтова, А.Ключарев, Ж.Фәйзи, Ж.Айдаров, Ә.Абдуллин, Ж.Котдусов һәм башка сәнгатькярләр Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамблен чын мәгънәсендә профессиональ югарылыкка күтәреп, үзебездә генә түгел чит өлкәләрдә дә таныта алуга ирешәләр.

Башлангыч чорында ике-өч гармунчы булса, тора-бара ансамбль эчендә милли уен коралларыннан торган тулы бер оркестр эшли башлый.

Гореф-гадәтләребезне, фольклорны, сәнгатьне тирәнтен өйрәнү, репертуарны тагын да баетуда фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт, милли киемнәребезнең кабатланмас матурлыгын сурәтләүдә сынчы-рәссам Бакый Урманченың, көй-моңнарыбызның үзенчәлеген ача алуда музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗановның да өлеше зур.

Сәнгать – һәрдаим эзләнү, яналыкка омтылу сорый торган өлкә. Илдә барган үзгәрешләр сәнгатьтә дә чагылмыйча кала алмый. Яна талантлар үсеп чыга. Кемдер

китэ, кемдер килэ... 1970 елда хормейстер, 1978 елда сэнгать житэкчесе итеп Лима Кустабаева билгелэнү ансамбльнең эшчэнлеген үзгэртеп жибэрэ. «Вакытында әйтелгән сүз – ин кадерле сүз» икэнлеген истэ тотып Л. Кустабаева эле ансамбль репертуарында яналык булган, милли hэм дини тематиканы яктырткан «Сабан туй», «Тәрки дөнья», «Корбан бэйрэме», «Сэйдэшем», «Рамазан» h.б. эсэрлэре белэн тамашачы мэхэббэтен яулый, анын тырышлыгы нэтижэсендэ чит иллэргэ гастрольлэргэ чыгулар янартылып жибэрелэ. Италия, Мальта hэм Африканын күп кенэ иллэрендэ булу, милли моннарыбызны, сэнгатебезне тагын да еракларда янгыратуга ирештерэ.

Ансамбль үзенен 75 ел эшлэү дэверендэ күп кенэ югары исемнэргэ ия була. Алар арасында Туниста уздырылган Халыкара Карфаген, Франциядэге 43 нче интернациональ фестивальдэ лауреат булу да, Халыклар Дуслыгы ордены белэн бүлэклэнү дэ бар. Ин зур дэрэжэ, элбэттэ, Республиканын Г. Тукай премиясе бирелү.

Бэйрэм унае белэн Татарстанның халык артистлары – ансамбльнен сэнгать житэкчесе Айрат Хэмитов, хор житэкчесе (кинэшчесе) Венера Гэрэева, бию коллективы житэкчесе Раилэ Гарипова, оркестр житэкчесе Рэшит Мостафин белэн сөйлэшеп алырга булдык.

*— 75 ел — аз гомер түгел. Бу вакыт эчендэ милли сэнгатькэ караш төрлечэ булды. Тик шулай да җыр һәм бию ансамбле халык мэхэббэтен яулый, югары дэрэҗэгэ ирешэ алды. Бигрэк тэ «Аулак өй», «Сабантуй», «Гармун-гармун», «Казан турында риваять», «Корбан бэйрэме» кебек тамашаларны халык үз итте.*



**Айрат Хэмитов:** Эйе, алар безнен «Алтын фонд»ка кергэн хезмэтлэребез. Без бит аларны да янартып торабыз. Яна юнэлеш салып, яна төсмерлэр белэн баетып. Бэйрэм унаеннан, «Жиде энже бөртеге» исемле этно-шоу эзерлэдек. Техник яктан югары бизэлешле, заманча программа килеп чыкты.

*— Исеме ягыннан чыгып карасак, күп мэгънэне үз эченэ ала кебек...*

**Айрат Хэмитов:** Монда кешелэр арасындагы мөнэсэбэт тэ, ата-анага мэхэббэт, туган илгэ хөрмэт, егет белэн кыз мэхэббэте, hөнэр сайлау, гыйлемгэ ирешү — hэммэсе дэ яктыртыла.

*— Безнең халык талантларга бай. Музыка көллияте, сэнгать академиясе, консерватория дэ эзерли аларны. Сайлап алу турлары оештырасызмы, эллэ үзлэре сездэ эшлэргэ телэк белдереп килэлэрме?*



**Венера Гэрэева:** 90 нчы елларда ансамбльдэ буыннар алышыну вакыты житте. Башлап жырлаучылар олыгая башлаган иде. Ансамбль алдына бурыч куелды — ансамбльне яшэртергэ. Шушы максат белэн Казан музыка көллиятендэ татар бүлеге ачылды, татар фольклорын, татар жырларын өйрэтү өчен укытучы итеп чакырылдым. Көллиятне тэмамлаган Зоя Борисова, Дамир Имамиев, Фэрит Гафиятуллин, Чулпан Сэмигуллина, Рамил Миннегалиев бүгенге көндэ ансамбльнен төп солистлары. Татар жыр бүлегенен программасы ансамбль репертуары булганлыктан, безгэ эшкэ килгэндэ алар инде бөтен репертуарны белеп килэлэр, озак еллар эшлэгэн жырчылар белэн рэттэн сэхнэгэ чыгалар. Хэзерге вакытта ансамбльнен сиксэн проценты музыка көллиятен тэмамлаучылар. Шулай ук консерватория, сэнгать академиясен тэмамлаучыларны да алабыз.

**Рэшит Мостафин:** Шэхсэн үзем Казанда уздырыла торган төрле конкурсларда да булырга яратам. Жюрида булмаганда да шыпырт кына арткы рэтлэргэ кереп сайлап, күзэтеп утырам.

*— Рэшит ага, сезнең оркестр татар халык җыр һәм бию ансамбленеке саналса*

*да, гел милли уен коралларыннан гына да тормый кебек, монда гобой, тромбон, флейта да бар.*



**Рәшит Мостафин:** Нишләп татарныкы булмасын алар, бераз онытыла гына төшкәннәр. Без бит татар халык көйләрен генә уйнамыйбыз. Алар бер-берсенә ярдәм итә, көйгә янгыраш бирер өчен кирәк. Ә кем әйтә скрипка татарныкы түгел дип? Гомер-гомергә татар скрипкада уйнаган. Мандолина кертеп карадык, кабул итеп бетермәделәр. Ә Татарстан гимны? Аны уйнаганда нинди генә уен кораллары кулланылмый. Татарстан гимнын Англиядә беренче булып без башкардык. Мәскәүгә кайткач, «тиешле җиргә» чакыртып сүктеләр, Рәсәй гимнын уйнарга кирәк иде, диделәр.

**Венера Гәрәева:** Франциядә фестиваль тәмамланганда һәрбер илнең байрагын күтәрергә кирәк иде. Рәсәй байрагын күтәрергә диләр. Юк, без Татарстанныкын күтәрәбез, — ди Рәшит.

— *Күтәрдегезме?*

**Рәшит Мостафин:** Рәхәтләнеп, һич икеләнмичә. Сәнгать тә сәясәт бит ул, формасы гына бүтән. Туган як, Ватан турындагы җырлар, «Идегәй» дастанын хәтерләсәк тә, монын шулай икәнен аңлыйбыз.

— *Бию кую өчен фикер ничек туа? Инде бит 75 ел буе фольклор да аз өйрәнелмәгәндер. Сәхнәгә чабата да менде, аны да зурладык, читек-кәвешләрнең дә нindиен генә күрмәдек?*



**Раилә Гарипова:** Һаман да халык традицияләренә таянабыз. «Чабата биюе»н чабата киеп бию дип кенә аңларга кирәкми. Һәр якнын үз гореф-гадәтләре, җыр-бию хәрәкәтләре. Әйтик, Саба ягы белән Сарман, Питрәч керәшен йолалары белән Зәйнеке гел бертөсле түгел. Барасын, өйрәнәсен, чагыштырасын. Ә минә «Чыштыр» биюе ул шәһәр фольклоры. Сәнгать белгечләре аны татар биюендә яңа сүз дип атадылар. «Гармун-гармун»ны, Александр Ключарев эшкәртүендәге вокаль-хореографик куелышны, көйгә яраклаштырдык.

— *Әйе, ул искиткеч әсәр. Ансамбльнең төп бизәкләреннән тагын берсе — күз явын алырлык костюмнары. Алар да бит әле һәрдаим яңартылып, куелышка туры китерелеп тегелә. Күп чыгымнар да тотыладыр?*

**Айрат Хәмитов:** Иң проблемалы урын — костюмнар инде. Гел эзләнү, яңалык сорый. Кабатлану булырга тиеш түгел. Бу эштә югары зәвык, затлылык таләп ителә. Ансамбль сәхнәгә чыгып баскач тамашачы «ах» итәрлек, үзенең татар булуы белән горурланырлык булырга тиеш. બездә вак-төяк юк. Без бит татарнын йөзен билгеләүчеләр. Рәссамнар белән дә эшлибез, эзләнәбез.

— *Ансамбльгә эшкә урнашу авырмы?*

**Айрат Хәмитов:** Авыр. Китү тагын да авыррак.

— *Шулайдыр. Ләкин бит йөрәк һаман унсигездәге кебек тоелса да, җиденче дистәне тутырганда гел җырлап-биеп йөреп булмаска да мөмкин бит әле. Үзегезгә алмаш әзерлисезме? Шигырь белән әйтсәк: «Акыллы ир бер карарга тиеш, кемнәр бара диеп, безнең арттан». Хор белән җитәкчелек итәргә дә, оркестрга да читтән китерү, бәлки, бик үк дөрес тә булмыйдыр. Үзегездә үскән, тәрбияләнгән традицияләрне дәвам итә алырлыклар бармы?*

**Венера Гәрәева:** Әлбәттә бар. Юкса кырык-илле ел буе нишләп кенә йөргән булабыз сон? Тик ул алыштыру әзерлек белән булырга тиеш. Үзен хорда җырлап басып тору бер хәл — житәкчелек итү, дирижерлык итү икенче мәсьәлә. Шәхсән

мин дирижер таякчыкларын Нияз Гәрәев исемле егетебезгә тапшырдым инде, анын кинәшчесе вазифасын башкарам.

**Раилә Гарипова:** Дөрестән дә шулай, кеше уйнаган көйгә бию жинел ул. Ә менә «үз кубызына биетү» күпкә катлаулырак. Монда тәҗрибә дә, югары зәвык, үзенә дә, артистларга карата таләпчәнлек тә, йомшаклык-нәзакәтлелек тә сорала.

*— Алай да күңелне борчып торган бер сорауны бирмичә кала алмыйм. Нишләптер элекке еллардагыча Сөләйман Йосыпов, Таһир Якупов, Шамил Әхмәтҗанов, Ания Тушева, Нәфисә Василова, Лена Бичарина кебек ансамбльдә чарланган, халык арасында танылган җырчыларыбыз, Әнсәрия Кретова, Халисә Шәрәпова, Равил Габдрахманов, Фердинанд Гыймадиев, Ләйсән Хәмитова, Айрат Хәмитов кебек аерылып торган аерым биючеләребез күренми? Сәбәбе концертларыгызның Казанда аз булганга халык аларны белмиме яисә фанатик рәвештә милли җыр-биюгә бирелгән яшьләр юкмы?*

**Венера Гәрәева:** Ансамбльнең һәр җырчысы-биючесе диярлек, оркестр үзе генә дә аерым концерт бирә алырлык профессиональләр. Акча заманы бит. Концерт залларын алыр өчен генә дә күпме түлисе.

*— Алайса ни сәбәпле милләтебезнең йөзек кашы булган, Татарстанны бөтен дөнья буенча танытып йөргән, инде 75 ел буе халыкка хезмәт иткән, югары дәрәҗәләргә ирешкән җыр һәм бию ансамбленең бүгенге көндә дә аерым концерт залы юк соң? Шушы ук талантларыбыз анда аерым концертлар куеп, хәтта ансамбльнең үзенә дә күпмедер керем дә кертә алыр иде бит?*

**Айрат Хәмитов:** Төрле биналарны тәкъдим итеп карадылар, безгә бит зур сәхнәле заллар кирәк. Өстәвенә яртышар елга гастрольгә чыгып киткән чакларыбыз да бар. Казанда елга ике генә концерт куябыз.

*— Азрак түгелме бу? Ничектер үзегез гастрольгә килгән сымаграк. Концертларыгызның аз булуы тамашачыны югалтуга китермәсме? Язучының каләме — укучыга, сәхнә — тамашачыга юнәлгән бит. Бүген милли сәнгатебезне яктырткан тамаша залларында күпчелек өлкән һәм урта буын тамашачысы. Әле бит киләчәк тә бар. «Гарри Потер»ларны укып, «Дом-2»ларны карап, «Макдоналдс»ларга йөреп үскән буында милли моңнарыбыз белән кызыксыну ни дәрәҗәдә булыр икән — шунысы да уйландыра...*

**Айрат Хәмитов:** Ул хакта без дә уйланабыз, заман ритмын тоеп яшибез. Безнең беркайчан да, чит илләрдә дә, үзебездә дә яртылаш буш залларга концерт куйганыбыз юк. Ансамбль үз дәрәҗәсен киләчәктә дә югалтмас дип ышанабыз. Төрле кичәләргә дә еш чакырылып торабыз.

*— Әйе, милләтебезнең йөзек кашы булган Татар халык җыр һәм бию ансамбле катнашу ул кичәләрнең дәрәҗәсен күтәрә, эчке мәгънәсен арттыра. Безнең журналның юбилей кичәләрендә дә катнашып милли әдәбият һәм сәнгатьнең тәрбия чарасы, тормышта әһәмиятле урын алып торуына инандырып, тамашачыны сөендерәсез. Рәхмәт сезгә.*

**Айрат Хәмитов:** Күңелдә булган милли хис — кайда яшәсәң дә, ничә яшьтә дә югалмыйдыр ул. Омскида бер татар әбисенең сәхнәгә менеп, ансамбль алдына тезләнеп: «Мин татар булуым белән горурланам», — дип әйтүеннән күпләребезнең күзләренә яшь килде.

*— Әйе, Татар халык җыр һәм бию ансамбле — милли моңнарыбыз аша кыйтгаларны, чорларны-буыннарны тоташтыручы илче дә! Киләчәктә дә ил күрке булып яшәргә насыйп булсын!*

*Әңгәмәдәш* **Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

# ХУНВЭЙБИННАР ЗАМАНЫ

Татар дөньясында «инкыйраз» төшенчәсе, ягъни татар халкының бетүгә йөз тотуы турындагы фаразлар XX гасырның тәүге елларында ук күренә башлый. Аның беренче сурәтләре белән укучы Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән хыялый повесть-хотбәсендә таныша. Ул татар укучысын тетрәндереп җибәрә. Монарчы мәгърифәтчелекнең «үң канаты» белән генә таныш булган татар укучысы хәлнең бу ягы турында бөтенләй уйлап та карамаган икән. Айдар Хәлимнең яна роман-эпопеясын укыганда син үзеңне шул Гаяз Исхакый фаразлаган дәверләр буйлап фаҗигаи сәяхәткә чыккандай тоясың һәм әсәрдә Исхакый, аның каһарманнары шәүләсенең әледән-әле пәйда булып, озата йөргән табигый бер чынбарлык итеп кабул итәсең. Алай гынамы? Нигә ике йөз? Инкыйраз дигән афәт большевиклар инкыйлабы нәтиҗәсендә йөз елдан ук килеп җитте, дип әйтергә мөмкин. Замандаш язучыбыз гүя Исхакый йөз ел элек гоманлаган инкыйразның тарихи басмакларына баса һәм алардан Исхакый көткәннән дә хәтәррәк чынбарлык манзаралар килеп чыга...

Әмма инкыйлаблар әлеге фаразларга төзәтүләр дә кертә: яна гасыр, алда төсмерләнгән яңа иҗтимагый үзгәрешләр мондый финалга юл куймас кебек. Ни дисән дә, иҗтимагый корылышлар да кешеләр тарафыннан хәл ителә ич. Димәк, мондый глобаль нәрсәләр дә бәндә акылына, шәхес характеры-холкына бәйле. Рәсәй яшәеше дә бу кануннан читтә кала алмыйдыр кебек. Тик урыс халкы, аның элитасы элек-электән башкалар исәбенә, бигрәк тә басып алган халыклар исәбенә яшәргә өйрәнгән. Шулай яши торгач, алар урыс дәүләтенә кергән йөздән артык халыкны «йотып» та җибәргәннәр икән инде...

Айдар Хәлим иҗат иткән «Хунвэйбин» роман-эпопеясының төп конфликты — «милләт кадәр милләтнең йотылу» касафаты — шушы заруриятта башланып китә. Тарихтан мәгълүм булганча, урыс гаскәре 1552 елда Казан ханлыгын басып ала. Дистә меңләгән татарны кылычтан үткәреп, гәүдәләрен Иделгә агызалар. Талап алган бихисап байлык, алтын-көмешне корабларга, олауларга төяп Мәскәүгә озаталар. Ләкин урыс хакимнәре моның белән генә чикләнеп калмый, аларга иң мөһиме — татарның рухын сындыру. Моның юлын да табалар — көчләп чукындыруга күчәләр. Бу вандаллык дәүләт күләмендә башкарыла һәм берничә этапка бүленеп эшләнелә. «Хунвэйбин» романындагы вакыйгалар шуның өченче баскычына күчәр алдыннан Татарстанның Мамадыш төбәгендәге Кизләү дигән авылда (атама шартлы алынган) башланып китә. Әсәрнең алдагы һәр бүлегендә киеренкелек артканнан-арта бара. Укыган саен ялкыннан бозлы суга килеп кергәндәй буласың. Роман күңелне шулкадәр били, һич кенә аерыла алмыйсың... Бер караганда, лирик-психологик, икенче караганда, публицистик, өченче караганда, сатирик, дүртенче караганда, мавыктыргыч, бигрәк тә «Фәкать» дип исемләнеп, хөкем барышына багышланган кисәгендә детектив көчәнеш алган бу роман тормышыбызның үзе кебек катлаулы һәм гади: биредә елаган урында җырлыйлар, җырлаган урында елыйлар. Әмма сүзебезнең башында ук шунысын да әйтеп куясы килә: мондый «гадилекне» кичерү җиңел түгел, ул шундый «күпкатлы гадилек» ки, аны кичәге татар әдәбиятында тәрбияләнгән һәр укучы күтәрә дә алмый, ул моңа әзер түгел — аның вакыт-вакыт баш мие кайнап, йөрәге шартлар чиккә җитүе мөмкин. Аеруча романның беренче китабы — татар әдәбиятында мондый экспрессив ташкын белән сурәтләнгән әсәрләр

булганы юк иде әле. Авторның мона кадәр реалистик бәрәңге бакчасында йөргән укучысын, нииндидер коточкыч сюрреалистик ботаника бакчасына алып кереп, һушыннан яздырып айнытасы, үзенең мәңгелек чирләреннән арындырасы килә...

Әйе, узган гасырның сиксәненче елларында күңелдә сәер бер үзгәреш сизелә башлады — ни өчендер бөтенләй уйлап чыгарылган сюжетка корылган, фантазия рәвешендәге әдәбият күңелне тартмый башлаган иде. Күрәсең, тормыш үзе хыял тудырган хәлләрдән баерак, үткенрәк була баргангадыр. Айдар Хәлим, язучы буларак, боларны тоймыйча калмаган. Ул да гәзиттә житлеккән публицист ләбаса! Шунадыр, күрәсең, «Хунвэйбин» романы да тормыш чынбарлыгыннан читкә китми. Китә дә алмый, чөнки, Гафури әйтмешли, «ятимлектә үткән тереклек» ана шундый кабатланмас биография биргән. Шуңа аның «уйлап чыгарганы» да тормышчан булып кала. Алай гына да түгел, ул чынбарлыкның укучы йөрәген сыкрата торган төсмерләрен тотып ала да, йөрәген әрнеткәнче селкетә, күңелдә давыл куптара...

Автор тарихи дөреслеккә һәрдаим тотынып бара. Әнә бит, әсәрнең төп герое Иркеннең бабасы Сөләйман хәзрәт тормышын сурәтләгәндә дә ул меңләгән татар авылы кичергән фажиганы гомумиләштереп күз алдына бастыру өчен Мамадыш төбәгенең кечкенә Кизләү авылын күрсәтә. XIX гасырның туксанынчы елларында булган чукындыру хасафәтен чын вакыйгаларга бәйләп бирә. Ике тапкыр чукындырып та максатларына ирешә алмаган поплар өченчегә кизәнә башлыйлар. Шул рәвешле, Кизләү авылы өстендә янә яшенле болытлар куера. Хәзер инде Сөләйман хәзрәтне һәм аның туган-тумачасын исән калдырмаячаклар. Боларны төшенгән авыл мулласы, бәла-казага тарыганчы, туган авылыннан китүне хуп күрә, кара төннәрнең берсендә, гаиләсен ике арбага төяп, гомер иткән ихатасын ташлап, качып китәргә мәжбүр була. (Шул юлларны яздым да, XX гасырның утызынчы елларында колхозлаштыру афәте чыккач, хәллерәк кешеләрнең йорт-жирләрен тартып алып, үзләрен сөргенгә озата башлагач, караңгы төннәрдә авылдан качып китә алган авылдашларны күз алдына китердем).

Әйе, татар язмышы әнә шулай төрле чорда туып-үскән жиреннән качып китүләр белән аралашып тора. Без бүген шул «куылып-качып китү»ләрнең нәтижәсен күрәбез!.. «Китәсем килеп китмимен,/ Туган жирдән кем туйган», — дигән жыр юллары юктан гына тумаган, билгеле. Ул әнә шул Сөләйман хәзрәт һәм аның гаиләсе кебекләр тарафыннан чыгарылган бит! Айдар Хәлимгә монда әсәр өчен яңа конфликтка нигез эзлисе дә түгел. Кизләү авылы язмышы ул Рәсәйдә татарлар яшәгән барлык төбәкләр өчен гадәти вә типик күренеш.

Юллар... юллар... Әле алда аларның исәбе-хисабы юк: тайга урманнары, далалар, чүлләр, баш өсләренә кардан ак чалма урап яткан таулар... Шушы юлда Сөләйман хәзрәт Сәлахи корбаннар бирә-бирә алга бара. Башта егет чорына кереп килгән улын жирли. Ул тау бизгәгеннән мантый алмый. Бераздан ун яшьлек Камиләсе, аннан төпчеге — Гөлфаные гүр иясе була. Аны жирләүне сурәтләгән урыннар беренче китапның гына түгел, ә бәлки берничә китапка сузылган барлык эпопеяның иң тетрәткеч өлешедер. Һәм, ниһаять, безнең сәфәрчеләр Шәрык Төркестанының башкаласы Өремчегә килеп «егылалар»...

Шуннан инде автор үз геройларына бераз ял бирә кебек. Сөләйман хәзрәт, Элә дигән матур елга тирәсеннән жир алып, йортлар төзи башлый. Бу урыннар романда лирик шигырь ташкыны булып ташый. Язмабыз озынга сузылудан куркып, без конкрет мисаллар китереп тормыйбыз. Бура өмәсенә бу төбәккә элегрәк килгән татарлар, уйгырлар, дөнгәннәр (кытай мөселманнары) жыела. Нәтижәдә кечкенә татар авылы, аның уртасында мәчет тә, каршысында мәдрәсә бинасы да калкып чыга. Кыскасы, авыр сәяхәт юлы үткән юкташларыбыз мал-туар тотып, татар кәсәбәчелегендә чәчкә атып, мул тормышта, бернинди изү-кысу сизмичә яши башлыйлар. Әйе, биредә Рәсәй империясеннән качкан татарлар бер авыл үрнәгендә кечкенә татар дәүләте булдыруга ирешә. Яңа авылга Кизләү исеме бирелүен дә онытмыйк әле. Автор бу авылны, аның исемен-жисемен туган ягының сагышлы бер бүләге сыман, кыйтгадан кыйтгага күчереп, хәтта Америка континентына да «алып китәчәк».

Әсәрне шушындый хикәяләү тонында дәвам итсә, аның авторы Айдар Хәлим

дә булмас иде. Менә берчак шушы оҗмахка да, капкаларны каерып, яшькелт яшеннәр уйнатып, «мәдәният инкыйлабы» сәясәтенең ачы җилләре килеп керә. Социализм төзибез дип СССР юлын кабатлаучы Мао-Кояш үзенең бөеклеген раслар өчен, илне тетрәтеп торучы «реформа яңалыклары» уйлап чыгара башлый. Шуларның иң афәтлесе — Хунвэйбинчылык җене булган икән. Дөрес, без, ул чактагы яшьләр, баштарак аның асылын аңлап бетермәгәнбез. Кытайда бу хәрәкәт башланганда мин үзем, мәсәлән, Башкортстанда татар телендә чыгып килгән үзәк «Кызыл таң» газетендә эшли идем. Бу 1966 елда булды. Әйе, без, яшьләр, берәр кеше башкаларга илтифатсызрак, масаючанрак булса, сүзендә тормаса, чалыш басса, шаяртып, андыйларны «Хунвэйбин» дип атарга ярата идек. Үзәк матбугатта да бу сүзнең асылын ачык кына аңлатмыйлар иде. Барысы да тиз үтәчәк имеш-мимештән чыккан вакытлы чир дип уйлыйлар иде. Баксаң, Хунвэйбинчылык борынгыдан килгән мордарлык (рухи шакшы-әшәкелек), бидгатьлек (элекке иманга каршы килә торган имансызлык), батыйльлек (бозыкка, ялганга чыгачак үзгәлек, көнкүреш хыянәтчелеге) икән. Аның чагыштырмача ачык калыпланган гамәле кытайларга хас конфуцианлык белән сугарылган Мао социализмында чагылган булган. Бәс, болай булгач, синең белән иңгә-иң «социализм төзүче» дус илнең кимчелеген күршесендәге урыс социализмы ничек күрсен инде? Аның асылы бөтенләй явыз булган икән. Роман авторы моны без әлегә кадәр аңлап җиткермәгән конкрет мисалларда гына түгел, явыз рухият чынбарлыгында сурәтләп күрсәтә.

Тәүге тапкыр ишеткәндә әсәрнең исеме күңелгә ятып бетмәгән иде. Татар тарихында күләме белән генә түгел, һич арттырмыйча әйткәндә, күтәргән проблематик тирәнлеге белән дә тиңдәше булмаган бу романны тулысынча укып чыккач, исемнең бик тә төгәл кушылганлыгына инанасың. Чөнки ул Кытай экстремистларына гына бирелгән атама түгел. Ул дөньякүләм хәл-вакыйгаларны, хәтта, инде күп гасырлар элек булып үткән «тәре походлары» нечкәлекләрен дә ачып сала торган сәяси гамәл, идеологик төшенчә икән. Аның эчке халәте аерым шәхеснең шәхессезлек кризисын, кабиләырунын, ниндидер катламнарның, төркемнең күптөрле кире, караңгы, җинаятьчел сыйфатларын үз эченә ала. Әнә бит урыс дәүләтендә мөселман-татарларны чукындыру галәмәте шул ук Хунвэйбинлык булган ләбаса! Урыс Хунвэйбинлыгы татарның үз Хунвэйбинлыгына юл ачкан, нигез салган. Хунвэйбинлык — кешелеккә карата булган җинаятьнең дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелгән бер яңа формасы. Урыслар вак кенәзлекләр булып яшәгән чорда, хәтта бертуганнар бер-берсенең биләмәсен басып алып, ягъни «барымтага» чыгып, байлыкларын талап, кешеләрен үтереп, исән калганнарын коллыкка алып китүләр дә даими Хунвэйбинлык күренешләре булып тора. Бары тик Алтын Урда ханнары чорында гына, барымта «батырларын» җәзалап үтерә башлагач кына, Русьтагы моңдый «геройлыкларга» киртә куела.

Роман-эпопеяның өлкән буын геройлары Казан төбәгеннән качып китеп, Уйгырстанның Өремче шәһәре янына барып тернәкләнәләр, дигән идек. Менә шушы туфракта (автор аны хаклы тантана белән «тупрак» дип атый) романның булачак төп герое дөньяга килә. Ана ата-анасы Иркен дигән исем бирә. Күрәсең, колакка сәеррәк ишетелгән әлеге исем белән оныгын картатай (дәү әтине безнең якларда бабай дип вакламыйлар, картәти, ягъни картатай дип зурлыйлар), улыбыз Иркен иркен дөньяда яшәр, рух иркенлеге аңа бәхетле юл ачар, хәр тормыш бирер дип фараз иткәндер. Ул үсеп буйга җитә, әсәрдән күренүенчә, укырга, гыйлем эстәргә бик тә хирес бала булып чыга. Биология фәне буенча югары белгечлек танылыгы ала. Уйгыр халык-демократик инкыйлабы җиңеп чыгып, уйгыр дәүләтчелеге төзелгәч һәм аны милләтчел Мао хыянәтчел рәвештә юкка чыгара башлагач, Иркен, башка милләттәшләре кебек, кимсетелеп яшәгән уйгыр туганнарын яклап татар батальоны составында сәяси көрәшкә күтәрелә. Әмма уйгыр-татар инкыйлабы канга батырыла. Бер мәгънәсез «культура революциясе» вакыйгалары, аннан Кашгар төрмәсе... Өч елга сузылган Тәклә-Макан сөргеннәре... Мао Хунвэйбиннарыннан кыйналу... Кытай Халык Республикасында кеше хокуклары иләмсез рәвештә бозыла дигән сүзләр дөньяга тарала башлагач кына, АКШ җәмәгатьчелеге кысымы нәтиҗәсендә Хунвэйбиннар төрмәләрнең ишекләрен бераз вакытка ачарга мәҗбүр була. Хәтта СССР матбугаты да бу турыда зур булмаган хәбәрләр биргәләгәне истә калган.

Шулай итеп, романның төп герое булган Иркен Сәлахи төрмә-сөргеннәрдән гаиләсе янына кайта. Хатыны Мәдинә аны барлык көчен, белемен биреп аякка бастыра. Ачлыктан һәм кыйналулардан шешенгән ир-егетнең тәне берничә айдан үз хәленә кайта, кешегә күренерлек рәвешкә керә. Менә шулчак инде Иркен Сәлахи ныклап уйга кала. Мондый илдә ары таба яшәп буламы? Һәм үзенә-үзе җавап бирә — юк! Ничек кенә «тыйнак-тәртипле» яшәсән дә, кешенең рухын буууга нигезләнгән иҗтимагый режимда бәхетле яшәп булмаячак. Автор менә шушы җан әрнешен барлык нечкәлекләре белән ышанычлы буяулар белән сурәтләүгә ирешә.

Айдар Хәлим үзенең геройларын экстремаль хәлләргә куеп сынарга ярата. Бу алым авторны күпсүзлелектән коткара, укучыны да роман өстендә «йоклап китүдән» тотып кала. Шушы җәһәттән бигрәк тә Иркеннең гаиләсе белән Элә буендагы Кизләүдән кояш баешына таба качып барган мәле гыйбрәтле һәм драматик сурәттә бирелә. Атларга, дөяләргә кунаклаган гаилә озатучылар сагында Тянь-Шань белән Памир таулары арасындагы үткеннән чыгарга була. Бу исә дүрт мен ярым метр биеклектәге сукмактан бару дигән сүз. Аяк астында көзгедәй тайгак боз; үзәкләргә үтәрлек салкын җил... Әмма адәм баласы түзә. Алдагы азат тормыш өметенә җылынып түзә. Бабасы Сөләйман Сәлахи бәхетле язмыш эзләү юлында корбаннар биргән иде. Бу золым инде аның оныгы Иркен Сәлахине дә урап үтми: кислород җитмәүдән буылып, өч яшьлек кызы Гөлфаный ачы давылда дөнья куя. Тик яраткан баласы гүр иясе булгач та Иркен Сәлахи үз алдына куйган максатыннан баш тартмый. Кызчыгын зәңгәр боз ләхеткә «җирләп», сызлаган йөрәген учына йомарлап дигәндәй, юлын дәвам итә... Табигатьнең явыз көчләре белән көрәштә адәм баласының рухи ныклыгын сурәтләгән дөньяга танылган әдипләрдән без Э.Хэмингуэй, Ч.Айтматов кебекләрне беләбез. Шулар катына мин бүгенге чорның күренекле татар әдибе Айдар Хәлимне дә куяр идем. «Хунвэйбин» романындагы әлеге эпизод, һичшиксез, мәктәп дәреслекләрендә урын алырга хаклы.

«Хунвэйбин» романында автор, чынлап та оста хирург-табиб кебек, татарның бүгенге тормышындагы иң мөһим, иң кискен проблемаларны күтәреп чыгып, һәр чиргә катлаулы операцияләр ясый. Кансырап торган җәрәхәтләрне күрсәтә: атом афәтеннән барлыкка килгән мохитсезлек, эчкечелек, наркомания, хакимнәрнең хөсетлеге, рәхимсезлек, милләтара низаглар... И-и, санап китсәң, очына чыгарлык түгел! Шуларның күбесен уртага, кояш яктысына чыгарып тезеп куя әсәр авторы. Шулай итмичә, татарның рухын тазартып булмый да торгандыр, күрәсең. Әлеге әсәр, бер яктан, татарның бүгенге халәтенә диагноз кую үзәге ролен үти. Икенче яктан, шул чирләрдән дәвалау өчен дарулар аптекасы кебек. Романнан укучы үзен борчыган бихисап сорауларына җавап табар дип уйлыйм.

Татарлар арасындагы бигрәк тә эчкечелекнең кин колач җәюе Иркен Сәлахине таң калдыра. Бабасы Сөләйманның сөйләвенә караганда, аның мәхәлләсендә хәмер белән дус булган бер генә кеше дә булмаган. Бүген исә ул күргән хәлләр бабасы сөйләгәннәрнең бөтенләй киресе... Бөгелмә — Татарстанның билгеле төбәге. Монда зур аракы заводы бар икән. Җиһазларын чит илдән алтынга сатып алганнар, ди. Аның житәкчесе, Гыйльман Корманов илле ел буена шушы хәмер заводына җитәкчелек итеп, аны алдынгылар сафына чыгарган икән. Халкыбыз анда житештерелгән хәмерне яратып эчә, ди. Татарстанга килгән урыс патшасы Б.Ельцинга да ошаган ул. Шуңа күрә атна саен аның өстәленә махсус КамАЗ белән аракы ташучы фельдъегер йөри, ди Бөгелмә аракы заводы белән Мәскәү Кремле арасында. Шушы фидакарьлеге өчен завод җитәкчесенә «Корманов» исемле аракы чыгарырга рөхсәт бирелгән. Хәзер татарлар шуны гына эчеп яталар, ди. Тагын да яңалыклары бар: озакламый янә алты аракы фирмасы ачарга әзерләнәләр, ди. «Шушы хәбәрне ишеткәч, тыңлаучылар котырып кул чапты», дип тәгалли новелланы Айдар Хәлим.

Интрига — нәфис әдәбиятның аерылгысыз элементы. Аны белеп кулланган язучы күпне ота. Айдар Хәлим дә интриганы куллана. Мондый колачлы әсәрдә төп герое ерак чит илдән булу әлеге алымны үзе таләп итә кебек. Бабасы Сөләйман мулланың туып-үскән төбәгенә «тамырларын» эзләп кайткан бит ул... Ләкин ни гаҗәп, төп ояларында — Кизләүдә инде аларны беркем дә хәтерләми. Иркен Сәлахи монда

аптырамый: күпме сулар аккан, күпме тормыш гарасаты булып узган. Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы еллары, аңа кадәр колхозлаштыру мәле — үзләре генә дә ни тора! Боларның һәркайсы өлкәнрәкләр хәтерендә саклана́дыр. Ә менә кумәк хуҗалык төзегән мәлдә «халык дошманы» дип кемнәрне Магниткага җибәрүләрен бүген хәтерләмиләр дә. Шуларны аңлаган Иркен Сәлахи борчыла башлый. Аның белән бергә әсәрне укучы да хафага төшә: Америка тикле җирдән тарихи Ватанына кил дә, күрешерлек туганыңны да тапма! Шулай да Кизләү авылында кемдер Чаллыдагы КамАЗ заводында шундый Сәлахи фамилияле кеше — корыч коючы бер инженер булганын хәтерли икән. Моны ишеткәч, Иркен Сәлахинең күңелендә янә өмет чаткысы кабына. Ул Чаллыга кайткач, аны эзләп чыгып китә. Һәм, ниһаять, эзенә төшкән кебек була. Салют Сәлахи дигән кеше икән ул. Гаиләсе белән тулай торакта яшәгәннәр, әле хатыны-балалары белән аерылгач та, тулай торакта аерым яшәүләрен дәвам итәләр. Әммә «бөрадәре» Салют — тулаем антитатар гына түгел, антиҗәмгыяви элемент булып чыга. Туган телен белми, Иркен-агасы белән ул тылмач аша гына сөйләшә. Житмәсә, «фазадагы» наркоман. Магнитогорскида институт тәмамлагач, КамАЗга эшкә җибәргәннәр. Татар милләте вәкиле булып исәпләнүе нәтиҗәсендә эштән кыскартылгач, Чечняга китеп, «Дудаевларны манчып йөреп», наркоман булып кайткан.

Аяныч-фаҗигале дә, сагышлы да тәмамлана Америкадан кайткан Иркен Сәлахи белән аның «төп тамыр» илендәге — Татарстанда яшәгән Салют Сәлахинең очрашулары. Наркоманга әйләнеп, эшсез, бомж булып яшәгән Салют Иркен-агасының башына кадак суыра торган чүкеч белән сугып, мең ярым долларын талап ала. Иркен-ага алты ай «бульниста» ята. Әйе, безнең чор, урыс дөньясы гына тудыра ала торган затсыз адәми «зат» ул. Димәк ки, бирегә, тарихи Ватанында, татардан икенче сортлы халык ясап, чүплек базына чыгарып ыргытканнар. Аның кирәге калмаган. Ул инде янадан тернәкләнеп китәрлек дәрәҗәдә түгел. Дучар ителгән... Сурәтләүдә иң нечкә, оста алымнарны кулланган автор бу персонажы белән татарны уйланырга, үз язмышын кичектергесез рәвештә үз кулына алырга чакыра. Читтән кемнәндер ярдәм көтү — инкыйразга, бетүгә йөз тоту белән бер икәнне чаң кагып кисәтә.

Айдар Хәлим әлеге әсәрдә бер нәрсәне сызык өстенә ала: бүгенге хәлгә калуда татар күбрәк үзе гаепле, ди ул. Югыйсә, тарихта кем кемне басып алмаган. Алай дип француз француз, инглиз инглиз булудан туктамаган. Мең еллык мәдәни тарихы булган татарның йөз ел эчендә юкка чыгуы халыкара чаң сугарлык фаҗига бит! Сәбәпләр нидә? Төп сәбәпләр — анарда ихтыяр көче калмаган, аның белән имансызлык һәм бердәмсезлек хакимлек итә. Шулар аның иң зур хатасы һәм бәласе.

Романда укучы күңелендә тирән эз салырлык образлар байтак. Әммә автор аларның кайберсен аеруча яратып, мөкиббән китеп сурәтли. Әсәрне укып чыккач та әле әнә шул «кайберәүләр» укучының күз алдыннан китми. Айдар Хәлим безнең арабызда йөргән типларны ача белүдә көчле. Аның һәр герое әлегә кадәр без күреп өлгермәгән тип. Алар дистәләгән!.. Димәк, язучы героеның мөһим характер сыйфатын танып, тирәннән табып алган. Шул персонажларның берсе — Баулы төбәгендәге Шәмдәл авылыннан «Мәгариф абзый». Тыштан караганда ул гади генә авыл карты. Әмма сөйләшә башлагач, Иркен әфәнде аның тирән акыллы, үзенә генә хас фәлсәфи фикер йөртүче шәхес булуына инана.

...Мәгариф тормышның ачысын-төчесен бала чактан ук татый башлый. Ике самоварлары булган һәм колхозга керергә ашыкмаган өчен унбер балалы гаиләне, кулак итеп, Пермь ягына сөргенгә озаталар. Берничә елдан, ярты гаиләсен сазлыкларда күмеп калдырып, болар Шәмдәлгә әйләнеп кайта. Аннан сугыш еллары... «Бөек Жину», герман җирендәге хезмәт... Тугыз ел хәрби хезмәттән соң, Мәгариф, немес милләтеннән булган Магда-Мәгърифәсе белән авылына кайтып төшә. Коммунист фронтовикны, ай-ваена карамый, колхоз рәисе итеп куялар. Нидән башларга? Хуҗалык җимерек, маллар кутәрткән, фермалар тирес сазлыгы эчендә, мал азыгы да юк, ягарга да юк. Ә менә авыл тирәсендә чыгарылган нефть белән чыккан иярчен газ факеллары көне-төне янып һава җылыта... Һаваны җылыт, тик кешене генә җылытма! Мәскәү кушмый!..

Кайвакыт татар кешесенең тапкырлыгына гаҗәпләнеп тә куясың. Германиядә «аш пешерүче газ күреп кайткан» безнең фронтовик-герой әле шул заманнарда торбалар үткәреп, бушка янган факеллар белән малчылык фермасын җылытуга җөрьәт итә. Барыбер һава җылытып исраф була ич. Шул «попутный газ»ны мал абзарларына үткәрү юлын да таба. Әмма ул совет чорындагы законнарны (дөресрәге — законсызлыкны!) белеп житкермәгән шул. «Татнефть» управляющие Сергеев «башбаштаклы» татар өстеннән органнарга жалоба-шикаять җибәрә. Нәтиҗәдә «социалистик милекне әрәм-шәрәм иткәне өчен» җиде елга төрмәгә утыртып та куялар. Газ үткәрү корылмаларын трактор белән издерәләр.

Күренеп тора, автор үзенең бу героен бик яратып, сокланып сурәтли. Аның фикерләре белән килешми мөмкин түгел. Чыннан да, әгәр бизмәнгә салып үлчәсәң, кайсы як тәлинкәсе аска тартыр иде икән? Мина калса, татарның бушка киткән «кара алтын»ына караганда халкының бушка вә мордарга киткән рухи байлыгы күпкә кыйммәтрәк. Моны мең елларда гына төзәтеп булмаячак. Асфальт юлларны яки кирпечтән салынган биек йортларны ремонтлап булыр да, ә менә дастаннарны...

Татарстан авылы фәлсәфәчесе Мәгариф абзыйның карашы белән килешмичә чара юк. Башкортстанда да, татар яшәгән һәр төбәктә шундый хәл ич! Бүген бөтен Рәсәй империясен ашаткан-эчерткән себер газы да шул ук татар — Күчем хан газы ич!.. Үзебездә дә түзем бар икән!.. Әлеге новеллада тагын бер образга — Магда-Мәгърифәгә игътибар итмичә мөмкин түгел. Мәхәббәттәге тугрылыкка, тормыш авырлыкларына чыдамлыкка һәйкәл ясарга кирәк булса, сынчы-художник нәкъ менә шушы сурәтне: ире белән авыр сынаулар үткән, нефть һәм газ өстендә яшәп тә, гомере буе утын ягып көн күргән, ниһаять, илле елдан соң үзләренә дә газ кергәнлеген онытып, аш пешергән саен мичкә ягам дип йортының күтәрмәсенә утын бәйләме күтәреп менгән хатын-кыз сурәтен нигез итеп алсын иде. Һич үкенмәс! Магда-Мәгърифә образының тормыштагы шәхесе булганны да исәпкә алганда, укучының бу әсәр белән кызыксынуы тагын да артыр дип уйлыйм.

Гомумән, романдагы унай сыйфатлар белән сурәтләнгән хатын-кыз образлары укучы күнелендә җылы тәэсир калдыра. Иркеннең сабыр һәм түзем Мәдинәсе, тыйнак һәм кыю Сихәт-сылу, кара милләтче иреннән туйган башкорт кызы Зөһрә — болар әсәргә лирик яктылык өстиләр. Эпопеяның соңгы битен укып бетереп, ябып куйгач та, әле бу унай геройларның якты карашлары укучыны озатып бара кебек.

Роман-эпопеяда икенче төрле характердагы «гүзәл» затлар да бар. Автор аларның эчке дөньяларын, күңел лабиринтларын да белеп сурәтли. Ямьсезнең ямьсезлеген бөтен барлыгында бирә алган икән, димәк, каләм әһеле теләгенә ирешкән. Айдар Хәлимне татар яшәешендәге кире үзгәрешләрнең татарга файда бирмәве, кайчандыр уңай булган импульсларның кире импульсларга әверелүе, аның әлмисактан килгән иң яхшы үзенчәлекләренең, гомумкешелек сыйфатларының юкка чыгуы борчый. Моны ул хатын-кызның гаиләдәге роле белән бәйләп аңлата. Ни дисәк тә, кешене дөньяга ул китерә бит. Тәрбия мәсьәләсендә дә аның роле беренче урында. Гаилә учагындагы утны сүндермичә саклау да аның кулында. Бу тормыш фәлсәфәсе артында татарның киләчәге белән бәйле күп нәрсә ята. Моны тирәнрәк аңлар өчен әсәрнең бер герое Стомат Сибгатулловичның Иркен агага «зары» рәвешендәге новеллага тукталу кирәк. Гыйбрәтле хикәят ул. Бүгенге яшьләргә байтак фәһем бирерлек.

...Стомат бала чактан ук нәчәлник булырга хыяллана. Гаиләдән башлап аны шуңа өйрәтәләр. Тик моңа ничек ирешергә? Өйрәтүчеләр дә табыла. Егетебез карьера өчен яһүд кызына өйләнә. Әмма ике арада мәхәббәт булмагач, гомер елгасы «сөрсеп» кенә ага. Бераздан «суверенитет заманнары килгәч», ул гаилә бәхете үз кавеменнән булган кеше белән бергә булуда икән, дигән фикер ягына авыша. Туган ягына кайтып, Чаллыга эшкә урнаша. «Яшел байраклылар» ягына чыгып, милли хәрәкәттә катнаша башлый. Озын-озак уйлап тормыйча, татар кызына — Элексир Хәнифовнага өйләнеп тә куя. Әмма икенче тапкыр гаилә корса да, уйлап житкермәүдәнме, формаль ашыгуданмы, профессор дәрәҗәсендәге укымышлы ир заты янә «дөрләп яна».

Мин бу новелланың укучыга тәрбияви файдасы зур булыр дип уйлыйм. Ни өчен? Татар тормышына кинәт килеп кергән КамАЗ татар хатыны шушы төбәкнең татар иренә, татар гаиләсенә һәм, киресенчә, КамАЗ конвейерындагы татар ире, үз чиратында, татар хатыны психологиясенә, татар гаиләсенә, барлык татар холкына кире йогынты ясамадымени? КамАЗ конвейеры татарны авыллардан куптарып, безне җимереп, авылсыз калдырмадымы? Бу хикәят бүгенге татар гаиләсе, шәһәр һәм гаиләсез калган татар авылы, аларның ныклыгы турында фикер йөртергә этәрә. Хикәятнең практик бурычы шунда, минемчә. Ныклы гаилә элек-электән татар милләтенең нигезе исәпләнгән. Ул нык булса, татар милләте дә элекке хәленә кайтачак дигән өмет бар.

Рәсәйдә иҗтимагый формацияләрнең үзгәрүе — социалистик корылыштан кыргый капитализмга күчү — миллионнарның рухи дөньясын әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык антисоциаль борылышларга китереп чыгарды. Илдә җинел кәсеп белән көн күрүче төрле күрәзәчеләр, ырымчылар, шарлатаннар һәм шулерлар сыйныфы барлыкка килде. Урам баганаларына, йорт стеналарына ябыштырылган, ыбыр-чыбыр гәзитләрдәге белдерүләрдә төрле авырулардан котылдыручы «духтырлар», диплом сатучы белгечләр, үзләрен сатучы кызлар чакырып тора... «Хунвэйбин» романының авторы да бу мөһим теманы урап узмаган. Моңа ул үзенчәлекле аспект белән килеп керә һәм укучыга кызыклы һәм гыйбрәтле бер новелла багышлый. ...Әсәрнең үзәктәге герое Иркен-ага Чаллыда яшәгән чорында шәһәр урамнарында, күпкатлы таш йортлар арасында куелган төрле сыннар күрә. Үзе эстетикада шактый белемле кеше буларак, аларның сирәк талант иясе тарафыннан эшләнгәнлеген аңлый. Авторы кем икән? Берәүләр аны инде сынчы һөнәрен ташлаган, табиблык белән шөгыльләнә, диләр, икенчеләр, ул хәзер дин галиме икән, диләр. Әлеге җаваплар мөһаҗирнең кызыксынуын тагын да арттыра. Һәм ул, Татарстаннан китәр көне якынлашса да, бу сәер кеше белән мотлак очрашырга тели.

Роман-эпопеядагы бер мөһим фикри аспектны аңларга теләсәң, Иркен-аганың сынчы, дәвачы, Галәм Гыйбадәтханәсен төзүче Вилдан Ханов белән очрашуын, аның белән әңгәмәсен укырга кирәк. Шунда Вилданның эчке дөньясына беркадәр үтеп керергә мөмкин булачак. Бу күләмле әсәрнең әлеге серен ача торган ачкыч нәкъ шунда ята. ...Вилдан — репрессияләнгән мулла оныгы. Сәләтле, энергияле кеше. Әнә бит, гади төзүче-инженер сынчы, рәссам булып күпләрне гаҗәпкә калдырган. Табиблык өлкәсендә дә уңышлары бар кебек: электроүтүк белән алкоголикларны, наркоманнарны аякка бастыра. Дөрес, алар дәваланып чыккач, бераздан, аның кул астына тагын килеп яталар икән. Шулай да, ярдәм сорап, аңа киләләр ич! Галәм Гыйбадәтханәсен төзү идеясен дә Вилдан изге теләктән чыгып башлый: барлык дини конфессияләрне берләштереп, «җир йөзен сугышлардан азат итү». Әлеге «винегрет» бинаны күтәрү әнә шул идеяне гамәлгә ашыру өчен икән... Галәм Гыйбадәтханәсенең эш максатын аңлату, бер караганда, урыс әдәбиятындагы «12 урындык» әсәрендәге Остап Бендерның Васюки шәһәрчегенең киләчәктә ничек итеп «дөнья кендегенә» әйләнүе турындагы хыялый хикәятне хәтерләтә.

Яна төр гыйбадәтханәне карап чыккач, Америка татары Иркен Сәлахи үзенең фикерен сынчыга ачык итеп әйтеп сала: «Сез мәнкорт кына түгелсез... сез — Хунвэйбин». «Монда сезнең амбициядән, яна пәйгамбәрлеккә дәгъва кылудан башка бернәрсә дә юктыр». Шушындый космополитлык уеннарын сурәтләгәннән соң, роман-эпопея авторы әлеге Хунвэйбинлык күренешенә үзенең аңлатма-бәясен бирә. Баксаң, ул яшәү шартларыннан туган халыкара социаль күренеш икән. Татар Хунвэйбинлыгының өч таганы исә ул — конформизм (борынны җил уңаенда тоту), коллоборация (туган халкына каршы үз дошманың белән хезмәттәшлек итү) һәм меркантилизм (алып-сатарлык, торгашлык). Шулардан арынмый торып, татар аякка баса алмаячак, ди автор.

Европадан кергән бу «матур» сүзләрнең иң явызы һәм астыртыны — икенчесе, чөнки ул кайчандыр үзеңне кол иткән, халкыңны кырган, затыңны түбән төшергәннәр белән дуслык-туганлык, хәтта катнаш никахлык мөнәсәбәтләренә керү. Бу инде явызлыкны ярлыкау дигән сүз. Ягъни, таш белән атканга аш белән ату була. Бу мәкаль нигезеннән үк дөрес түгел. Безнең халык аның асылына төшенми.

Әнә шуна күрә дә үзен кол иткәннәр ягына басып, аны яклап, Әфганда, Чечняда кан коя, гомерен бирә... Ул гынамы, баласын бирә, кода-кодагый ясый, баласының милләтен-динен үзе үк тартып ала!..

Шул рәвешле, язучы Айдар Хәлим житди фәнни нәтиҗәләр ясарга сәләтле галим, тарихчы булып та күз алдына килеп баса. Мондый колачлы нәтиҗәләрне тирән белемле, тормыш агышын, сәясәт җилләренең кая таба искәнен анык аңлаган кеше — талантлы язучы-психолог кына ясый ала. Иркен Сәлахи үзенең тарихи Ватанында күргәннәрне чит илләрдәге татар диаспоралары белән чагыштырып, Рәсәйдәге татар халкы теленнән тел, татар ашыннан аш эзләп, аның үз рухи байлыгыннан күп нәрсәне югалтканына төшенә. Борынгыдан килгән гореф-гадәтләрдән, йолалардан байтак мөһим сыйфатлар җилгә очкан. Бу аяныч хәл. Шулай да мөһаҗир аларның бөтенләй исраф булмаганын да тоемлый. Шуна да ул еш кына Дәрдемәнд иҗатындагы билгеле шигырь юлларын кабатлый — «Сөт калыр, Ватан китәр!»

Героебыз Чаллыда яшәгән чорында күп кешеләр белән аралаша. Алар гомумиләштерү өчен матдә булып хезмәт итә. Мамадыштагы Кизләүдән Шәрхенур, аның улы Ильяз, Ачулы Зарифлар, Баулы туфрагындагы Шәмдәлдән Елмаймас Габбәс кебек дистәләгән образлар бүгенге татар әдәбиятының байлыгы итеп кабул ителергә хаклылар. Айдар Хәлим күтәргән һәр темага әдәбият фәне трактатлар багышлый алыр иде. Аларда кичәге һәм бүгенге тарихыбыз сынланган. Үткән гасыр азагы — яна гасыр башында кузгалып киткән татар милли хәрәкәте, Чаллыдагы болгарчылар корылтаеннан, татар иҗтимагый үзәге җыеннарыннан сурәтләнгән күренешләр — боларны киләчәктә үзе шушы вакыйгаларның уртасында кайнаган гамәлче-язучы АйдарХәлим романыннан гына укып белергә мөмкин булачак. Ул берничә чалым белән генә алардан типаж, хәтта образ тудыруга ирешә. Алар арасында хатын-кызлар аеруча күп. Бу гүзәл затлар, чынлап та, татар табигатенә хас күркәм сыйфатларны күбрәк саклап калган икән. Әнә бит Сихәт-сылудагы рухи тыйнаклык, сабырлык, тәрбияле мөнәсәбәт күренеп тора. Шуна да, күрәсен, Иркен ага бу гүзәл ханым белән тиз арада уртак тел таба. Ә инде аның Кизләүдән, бабаларының туган авылыннан икәнлеген белгәч, Ходай Тәгалә бүләге бу дип кабул итә.

...Сихәт-сылуның язмышы җинел булмаган. Авыл кызы КамАЗ төзелешенә килеп эшли башлый. Яшьләр күп, алар төрле милләттән. Ә менә ул урыс егете белән тормыш кора. Имеш, интернациональ гаилә. Совет чоры өчен аеруча мактаулы нәрсә. Ләкин катнаш никах сүздә генә яхшы икән. Чынында исә бөтенләй башка булып чыга. Урыс ир көн саен эчеп-исереп кайта, тавыш куптара, кыйный. Игезәк балалары дөньяга килгәч тә тәртипкә утырмый ул. Поп чакыртып, балаларын чукындырырга ниятлиләр. Моны белгән яшь ана, чирле булса да, балаларын поп кулыннан тартып алып качарлык көч таба. Ул ике улын да, чүпрәккә төреп, яланаяк килеш, сабыйларын танышларына илтеп куя. Сонрак, саламәтләнә төшкәч, улларын Кизләүгә әти-әнисе янына кайтарып, татарча исемнәр кушып, үз авылында тәрбияли. Хәзер инде алар буйга үскән акыллы егетләр, әниләренең зур сөенече.

Бу хикәятне ишеткәч, Иркен аганың Сихәт-сылуга булган ихтирамы тагын да арта. Ул ана чын батыр хатын итеп карый башлый. Әнә шулай, Айдар Хәлим «Хунвэйбин» әсәрендә татар милләтен юкка чыгаручы тагын бер хәйләкәр идеяне — «интернациональ семья»ны сүтә башлый. «Татурыс»ларның килеп чыгышын, аларның татар милләтенә китергән зыянын халкыбызга күптән һәм ныклап, дәүләткүләм аңлатырга кирәк иде дә бит, тик мона юл бикле иде шул. Бик тиз милләтче ярлыгы тагып, хөкемгә тарттыру юлын карыйлар иде. Әле дә без әнә шул астыртын эшчәнлекнен яман шешләре йогынтысында яшибез. Чөнки бүген дә «постель интернационализмы» дигән тозсыз идея үзен сиздереп тора.

Бер-берсенә тартылган ике йөрәкнең — Америка татары Иркен-ага Сәлахи белән Нократ кызы Сихәт-сылуның язмышларын автор ничек тәгәлләр икән? — дигән уй укучыны романның башыннан азагына каләр борчып килә. Чыннан да, ничек? Язучы әлеге нечкә мәсьәләне дә итагать белән чишә. Иркен ага — диндар кеше. Ул ислам диненен төп кагыйдәләренә буйсынып яши. Әлеге мөһим мәсьәләдә дә ул шунардан читкә китми: алар Татарстандагы Кизләүгә, ягъни Сөләйман хәзрәтнең

туган авылына кайтып, никах укыталар. Бераздан Сихәт-сылуның көмәне барлыгы билгеле булгач, Иркен-аганың түбәсе күккә тигәндәй була. Димәк, Сәлахиләр нәселе туган Ватанында да югалмаячак. Ул инде затлы анадан тәрбия алып, нәселне дәвам итәчәк...

Әсәр авторына тәнкыйди фикерләребез дә бар. Роман-эпопеяда татар милләтенең язмышына кагылышлы бик күп проблема күтәрелгән. Аларның катламнары да төрле-төрле. Шактый сузылганнары да бар. Бәлки, беркадәресен бераз кыскартыргадыр? Аларның барысын да бер әсәрдә бирү фикер йөген авырайта кебек... Кайбер темаларны аерым трактат иткәндә кулайрак булыр төсле. Мәсәлән, Һ.Такташ иҗатына караган бүлек кысасыннан шактый читкә чыгып китә һәм әдәби эзләнүләрне хәтерләтә башлый. Романның төп темасыннан аерыла. Хәйдәр Бигичев белән Зөһрә Сәхабиевалар турындагы новелла тарихи-биографик повестька әйләнмиме?..

Әсәрдәге кече хикәятләрне новелла дип әйткәнбез икән, шул жанрга караган сыйфатларны тагын да көчәйтә бирергә иде. Авторның мөмкинлекләре дә зур. «Болгарчылык» мәсьәләсендә дә сатира белән генә үтеп китү дөрес түгел, минемчә. Ул проблема татар халкына каршы эшләп, шактый зыян китерде. Меңләгән кеше, мәсьәләнең кая барганлыгын аңламыйча, җилнең каян искәнен тоемламыйча, үзләрен «болгар» дип яздырып, татарлар санын киметте. Ырынбурда чыккан гәзитләре ялган мәкаләләр бастырып, укучыны дөреслектән читкә алып китте. Мин ул чорда «Кызыл таң» гәзитендә баш мөхәррир идем. Бу хәрәкәт җитәкчеләре мине дә болгарлыкка өндәүче материаллар бастырырга кыстап караганнар иде, хәтта.

Гомумән, «Хунвэйбин» романы — ифрат колачлы әдәби тукыма. Ул күләме белән генә түгел, күтәрелгән темасы, проблемасы һәм идеясе белән дә соңгы чор татар әдәбиятында күренмәгән әсәр. Бүгенге көндә мондый романны укучыга тәкъдим итү язучыдан зур батырлык сорый, чөнки ул кешелек тарихында тирән эз калдырган татар халкының язмышы белән бәйле. Әсәр аның бүгенгесе һәм киләчәге турында сагышлы җыр — сага. Аны укыганда күңелдән тагын бер сорау китми. Мин моны язмамның башында да әйтә биреп куйган идем шикелле. Ни өчен автор әсәрнең төп герое итеп гомере чит илләрдә үткән Иркен-ага Сәлахине алган? Бу сорау белән мин үзем дә язучыга мөрәҗәгать иттем. Ул миңа болай дип җавап бирде: «Бездә, Рәсәйдә, аеруча Татарстанда, ни кызганыч, татар халкын саклап калу мәсьүлиятен — бездәге барча проблема-тенденцияләрне сиземләр, шуларны тартынмыйча-курыкмыйча ачып салырлык, сәяси, иҗтимагый, эстетик зәвык, белем, әдәп-әхлак ягыннан күтәрә алырлык шәхесләр инде калмагандай күренде. Юк, бу Татарстанда һәм Рәсәйдә шәхесләр бөтенләй дә калмаган икән дигән сүз түгел. Шулай да, ничек кенә булмасын, татар өстеннән барган биш гасырлык изелү бездә шәхес нисбәтен бик нык такырайтты. Дөрес фикерләп тә куштан, ялагай булып калу тенденциясен алдагы планга куйды. Минем бурычым — татарга шәхес эзләү юлында импульс бирү... Әгәр мин ялгышкан булсам, куана-куана үземне төзәткән булыр идем. Бу Рәсәй татарларын кимсетү өчен әйтелми. Мин мондый хәлләрне татарның Рәсәй шартларында инде нәселсез дә кала барып, милли менталитетын югалтуыннан чыккан касафат дип уйлыйм. Кызганыч, бүгенге татарның барлык хәл-әхвәлен белеп, аны саклап калу хакына фикердән тыш, гамәл дә кыла алырлык кешеләр — абсорбентлар бары тик читтә генә сакланган кебек. Бу үзенә күрә Герценның «Колокол» теориясен дә хәтергә төшерә: фикерне милләткә читтәге кардәшләр бирә, гамәлне җирле кардәшләр кыла...»

Төптән уйлап карасаң, дөрес тә бит, мондый зур рольне интернациональ рухның аек акыл белән эш итүче агымында тәрбия алган, кыю фикер йөртә торган шәхес кенә башкара ала. Рәсәйнең шовинистик кызыл идеология һәм төрле сәяси фикер кысымында ихтыяр көчен югалткан, хәзерге көндә күп нәрсәгә битараф булган «үз татарыбыз» әлеге йөкне күтәрә алмаячак. Монда нәкъ менә урысның ялган, астыртын милләтчел идеясе астында яшәмәгән, ә гадел демократик шартларда гомер кичергән Иркен Сәлахи кебек шәхес кирәк.

Татарның бүгенге хәле белән танышыр, тормышын күрер өчен автор үзенең героен ата-бабасы яшәгән Мамадыш төбәгенә, әбисе туып-үскән Баулыдагы

Шәмдәл авылына «җибәрә». Героебыз анда төрле катлам вәкилләре белән очраша, тормышларын, яшәү рәвешләрен күрә. Шулай итеп, «чын татар» илендәге хәлләр белән таныша. Гаҗәп хәл, бүгенге татар үзен-үзе аңламас дәрәҗәгә житеп, дистәләгән «шивәдә» сөйләшә икән. Сөләйман бабалары сөйләшкән гомум тел культурасы инде югалган... Әгәр тел тәмам юкка чыкса, милләт тә һәлакәткә дучар булачак! Бу нәтиҗә аны тетрәндереп җибәрә. Һәм ул дөнья җәмәгатьчелеген уятырлык чаң сугуның кирәклегенә төшенеп, кулына каләм ала. Ак кәгазь битенә «Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясына» дигән сүзләрне язып куя. Әнә шулай итеп, Айдар Хәлим үзенең «Хунвэйбин» роман-эпопеясының төп герое Иркен-ага Сәлахигә татар халкы, Татарстан республикасының язмышын тапшыра.

Бу язмада татар халкының XVI гасырда ничек итеп урыс баскынчыларына коллыкка төшүен, гасырлар буена нинди җәберлә яшәвен, көчләп чукындырылуын һәм башка золымнарны башыннан кичерүен тәфсилләп аңлатыла. Инде менә 1960 елда БМО тарафыннан «Колониаль илләрне һәм халыкларны коллыктан азат итү турында» дигән резолюция кабул ителсә дә, дөнья күләмендә бу әмер үтәлсә дә, Рәсәйнең изелгән халыклары, беренче чиратта аның беренче колы — татар халкына карата үтәлмәве ассызыклап күрсәтелә. Иркен Сәлахи Берләшкән Милләтләр Оешмасына юллаячак Меморандумда Рәсәйнең иҗтимагый-сәяси булмышын тәнкыйтьләүдән дә курыкмый. «Басып алынган халыкларның, мәсәлән, Идел-Урал буе татарлары, Себер татарлары, ненец, чукча, юкагирларның нефтен-газын, якутларның алмазын, урманын, тимер, ташкүмер яткылыкларын гасырлар буе талап, үз бюджетының туксан процентын тәэмин иткән, шул ук вакытта бу халыкларны сәяси, икътисади, социаль яктан хокуксыз калдырып, үлемгә дучар иткән Рәсәй империясе шушы җинаяте өчен генә дә Халыкара Гаага хөкемендә хөкем ителергә тиеш».

Әлеге мөрәҗәгатьтә шулай ук мөселман егетләрен Әфганга, Чечняга җибәреп, мөселман халкына каршы сугышка җәлеп итүне дә каты тәнкыйть утына тота Иркен Сәлахи. Бу документта татар милләте өчен аеруча мөһим булган тел мәсьәләсе дә күтәрелә. «Рәсәй хакимияте милләтләрне урыслаштыру юлы белән бер милләтле һәм бер динле дәүләт төзү эшен тизрәк тәмамлау өчен кысымны тагын да көчәйтте», дип ассызыклап күрсәтә Иркен Сәлахи Берләшкән Милләтләр Оешмасына юллаячак язмасында. Әле кайчан гына урыс патшалары күрше төрки һәм башка халыкларны «татар теле ярдәме» белән яулап алганнар иде. Дөньякүләм мөһим документта да ул үндүрт халыкара тел рәтендә исәпләнә. Бүген исә үз кадерен үзе белмәгән империя татар теле кадерен бетереп бара. Бердәм булган татар милләтен уннан да, султан да бүлгәләп, аның телен дә, үзен дә вакларга һәм юкка чыгарырга хыялланалар. «Җир шарында XXI гасырга кол сыйфатында кергән кеше калмаска тиеш» дигән җөмлә белән тәмамлана әлеге язма. Әнә шундый тирән мәгънәле, изге ният һәм теләк белән иҗат ителгән әсәр ул «Хунвэйбин» эпопеясы.

Айдар Хәлим — фидаи шәхес. Ул татар халкын биш йөз еллык коллыктан коткару теләге белән янып, көрәшеп яши. Әлбәттә, бу көрәш җиңел генә бармый. Аңа «милләтче», «җәнҗалчы» һәм башка түбәнсетү ярлыклары тагучылар да булды һәм әле дә барлар. Хәтта физик юк итү теләге белән һөҗүм итүләр дә булды. Әмма хаклык һәрвакыт өстен чыга. Ходай Тәгалә аны афәттән саклап килә. Күрәсең, туган халкына ярдәм итсен бу туры сүзле, дөрес гамәлле кеше ди торгандыр.

Җыеп кына әйткәндә, Айдар Хәлимнең «Хунвэйбин» роман-эпопеясы, һичшиксез, әдәбиятыбызның соңгы дәвердә иҗат ителгән иң күренекле, иң мөһим әсәрдән исәпләнәчәк. Мин роман-эпопеяга колачлы анализ ясадым дип әйтүдән ерак торам. Киләчәктә аны өйрәнерләр, укучылар үз фикерләрен белдерер һәм, иманым камил, үз милләтен хөр тормышта бәхетле, азат итеп күрергә теләүчеләр Айдар Хәлим дигән каләм остасына бары тик рәхмәт кенә әйтер.

**Муса МӨЛЕКОВ,**
*филология фәннәре кандидаты.*
*(Уфа).*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Дүрт Өйле

Дүрт Өйле авылы Чистай районында, район үзәге Чистай шәһәреннән 29 чакрымда, тимер юл станциясе Нурлаттан 103 чакрым ераклыкта урнашкан.

Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII гасыр) Дүрт Өйле авылы да искә алына. Белешмә мәгълүматларына караганда, анда 59 йомышлы, 13 керәшен татары, 11 алпавыт крестьян көн күргән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә авыл Кондралеева-Четыре двора дип бирелгән, анда татарлар яшәве искәртелгән. К.П.Берстель белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Дүрт Өйле тагын Гадралеево дип тә бирелгән, авылда 171 татар кешесе яшәгән.

Олылар сөйләвенә караганда, башта авыл урынына Кадыйр исемле кеше килеп утырган һәм шуның өчен ул Кадерәле дип аталган. Аннары тагын 3 хуҗалык килгән һәм авылның исеме Дүрт Өйле дип йөртелә башлаган.

Олылар сөйләвендә дөреслек булса кирәк, чөнки К.П.Берстель белешмәсендә авыл Гадралеево дип күрсәтелә.

Авылның оешу вакытлары XVIII гасырның ахырларында булган булса кирәк. Авыл тирә-юнендәге атамалар бирелеше, кайбер нәселләрнең шәҗәрә тамырлары шулай уйларга нигез бирә.

Авыл яныннан Бахты суы агып үтә. Аның бассейнында Алтын әби елгасы бар. Бу елга янында җиләк бик күп булып үсә. Анда барган халык төнгә калмаска тырыша икән, чөнки ул җирдә кетү көткәндә дә, җир сукалаганда да күзгә кеше ышанмаслык хәлләр күренә, кешеләр адаша, саташа ди.

Унсигез каенлык атамасын халык онытмый. Унсигез каенлык атамасы шактый сәерсендерә һәм шомландыра. Кайчандыр, имеш монда унсигез каен-кыз яшәгән, ди. Алар бер-берсен яратып балаларын карап яшәгәннәр, ди. Бер-берсен яратмаганнар да, дип сөйлиләр, кем белә!? Хәзер анда унсигез генә түгел, каен күп үсә, үзе бик матур урын. Аның янындагы кырлар да Унсигез каен дип йөртелә. Бу җирне дә адаштыра, саташтыра диләр. Белмәссен...

## Җәмәк

Татарстанның Минзәлә районында Җәмәк (русча Ямаково) авылы һәм Кама Тамагы районында Җәмәки авылы булган, ләкин ул беткән. Кама Тамагы районының Кече Кариле авылында Җәмәк чокыры һәм Җәмәк чыгышы исемендәге топонимнар теркәлгән. Авыл янында соңгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәсе билгеләнгән. Олы Кариле тирәсендә борынгы һәм соңгы болгар заманаларындагы зират табылган. Шул ук районда гы Атабай авылында бер кое Җәмәки исемен йөртә. Атабайда борынгы болгар чорларына караган табылдык әйберләрнең ике зур җыелмасы мәгълүм. «Җәмәк» берәмлеге катнашкан гидронимнар да байтак. Җәмәк суы Саба районында, ул Олы Мишәгә коя. Балтач районында ага торган Кугубор елгасының Җәмәкәй дигән кушылдыгы бар, тагын бер Җәмәки суы Кама Тамагы районында ага. Ул — Зәя суы кушылдыгы. Җәмәк чокыры

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

— Балык Бистәсендәге су, ул Елга дип йөртелгән инешкә килеп кушыла. Җәмәк күле Агыйдел суы бассейнында урнашкан.

«Җәмәк» атамасы тарихи чыганакларда шактый искә алына.

Минзәлә районындагы Җәмәк авылы оешуын өлкәннәр болай сөйли.

Имеш, кайчандыр елга буена (хәзер Минзәлә елгасы дип атала) ике туган килгән. Берсе Җәмбәк, икенчесе Кадербәк исемен йөрткән. Җәмбәк тау астына урнашкан һәм шунда авыл барлыкка килгән, ә икенчесе Кадербәк тау өстенә утырган. Андагы авыл хәзер Кадрәк дип атала. Кадрәкнең яртысы –керәшен.

Җәмәк авылы бик матур җиргә утырган. Авылны тау уратып алган, чокыр төбендә авыл урнашкан. Тирә-якта урманнар, әрәмәлек, болын һәм посадкалар бар. Чишмә һәм күлләр дә сакланган, ләкин аларга игътибар җитми.

Бер-берсеннән шактый ерак урыннарда очрый торган «җәмәк» атамасы нәрсә аңлата? Ата-бабаларыбыз бу исемне юкка гына кулланышка алмаган. Бу атама борынгы һәм кызыклы.

Югарыда саналган барлык атамаларның да килеп чыгышы йәмәк-җәмәк этнонимына мөнәсәбәтле. Йәмәкләр — кимак этнонимының нигезен тәшкил иткән төп кабиләләр. VII гасырда алар Көнбатыш Төрки каганлыгы составына кергән һәм Алтай, Иртеш тирәләрендә күчмә тормыш алып барганнар. XI гасыр галиме М.Кашгари фикере буенча, Иртеш – Ямәк сахрасындагы бер елга. 656 елда Көнбатыш Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, ямәкләр үзләре бер мөстәкыйль төркем булып аерылып чыга. Кимак федерациясе Югары һәм Урта Иртеш буйларын, төньяк-көнчыгыш Казакъстан тирәләрен биләгән. М.Кашгари язуына караганда, төркиләр егерме төп кабиләдән торган. «Румга якын булганнары түбәндәгеләр: бәҗәнәк, кыпчак, угыз, ямак (ямәк), башкорт, басмыл, кай, ябаку, татар, кыргыз...» Т.М.Гарипов аларны Идел тирәләренә монгол яуларына кадәр килгән дип уйлый. Урал тирәләрендә нигезендә «ямәк» сүзе яткан антропонимнар бар. Мәсәлән, XVIII йөздә бер башкорт тарханының урысча фамилиясе Ямәкев булган, татар сөйләшләрендә йәмәк мае дигән сүз горчица мәгънәсендә кулланыла. Галимнәр Казан татарларының нигезен Йәмәкләр тәшкил итә дип саный. «Йәмәк» исеме белән язып алынган елга һәм авыл атамалары бу кабиләләрнең Казан арты, Кама аръягы, Тау ягы районнарына, гомумән, Татарстан җиренә килеп урнашуларын күрсәтә.»

## Җөлби авыллары

Иске Җөлби авылы Арча районына керә, ул район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән 26 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Кушлавыч авылыннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан. Ә Яңа Җөлби Әтнә районына карый, ул район үзәге Олы Әтнә авылыннан 10 чакрым ераклыкта урнашкан.

Җөлби атамасы тарихи чыганакларда шактый урын ала. XVIII гасыр мәгълүматларын чагылдырган Д.А.Корсаков җыентыгында Иске Җөлби авылында 71 йомышлы татар яшәгән дип күрсәтелә. Яңа Җөлби (шулай ук Көек, Мәрҗән) дип аталган авылда 130 йомышлы татар исәпләнгән.

1766 — 1861 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында Иске Җөлби авылы искә алына. Сәрдә суы ярына утырган бу авылда чукынмаган йомышлы татарлар яшәгән. Мәчет эшләгән. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган, тимерчелек һәм тегермәнчелек белән шөгыльләнгәннәр.Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Иске Җөлби, Яңа Җөлби, Комыргужа, Олыяз һәм Сасмак авыллары халкы бергә җыелышып Кызыл яр җыены үткәргән. Ул икенче төрле Җөлби җыены яисә Сасмак җыены дип тә аталган.

Иске Җөлби һәм Яңа Җөлби авыллары Сәрдә суы буена утырганнар. Елга ярлары, әйләнә-тирә калын урман белән капланган булган. Халык иген игәр өчен басу-кырларны урманнан чистартып ясаган. Урман байлыгы булган вакытларның истәлеге булып Аю елгасы атамасы калган. Каенсар күле дә заманасында урман эчендә җәелеп яткан. Кече су елгасы суларын Краснага илтә. Ул Сәрдә авылы белән ике арада. Күгәрчирмә сулары да Краснага килә. Сулы елга — Күгәрчирмәнең бер тармагы. Мөхтәр елгасы янында аерым хуҗалык вакытларында Мөхтәр исемле кешенең җире булган. Мулла, Мөәзин, Солтангол, Корбанай елгалары янында шул шәхесләрнең җире булган дип уйларга кирәк. Апакай

суы да Краснага коя. Атау елгасы (ярында чишмәсе дә чыга) Краснага кушыла. Краена бассейнында Ташчишмә дип аталган ике чишмә бар. Сулары таш арасыннан көчле итеп тибеп һәм кайнап чыга. Йомырка болыны янында Кирәмәт атавы урнашкан.

Авылда Чирмеш чишмәсе һәм Чирмеш зираты билгеле. Мичкә бите дигән тау урман арасында урнашкан булган. Анда, имеш, марилар торган һәм алар мичкә ясаганнар, аны Әтнә базарына илтеп сатканнар. Аксакаллар сөйләвенә караганда, авылда чирмеш нәселләре, ягъни мариларның ислам кабул иткән аерым кешеләре яшәп калган. Халык аларның бабалары мари булганлыгын хәтерли әле.

## Җөри

Теләче районында борынгылыкка китә торган атамаларның берсе Җөри дип әйтсәк, һич тә ялгыш булмас. Иске Җөри, Яңа Җөри, Алан Җөри авыллары Иске Җөри җирле үзидарә советына карый.

Атама күп кенә тарихи чыганакларда, аерым алганда, Казан губернасының теркәү кенәгәләрендә, авыл атамалары исемлекләрендә искә алына. Тарихи Җөри юлы өстендәге Җөри авылы Казан ханлыгы чоры документларында да очрый. Казан өязенең теркәү кенәгәсендә (1602 – 1603) Җөри авылында йомышлы татарлар һәм ясаклы чувашлар (сыйнфый термин) яшәве күрсәтелә. Иске Җөри авылы зиратында Н.И.Воробьев һәм Һарун Йосыпов XVI йөзнең беренче яртысына караган кабер ташы билгелиләр. Бу ташны археологлар да күрсәтеп үтә.

Авыл янындагы шәһәрлекнең урлары Мишә суына килеп тоташкан булган. 1955 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һем тарих институты оештырган экспедиция әгъзалары бу хәрабәләрне һәм урларны таба алмый. Күрәсең, алар инде җир белән тигезләнгән булгандыр.

Җөри авылларын И.А.Износков болай сурәтли. Кече Шия суы буена утырган Җөри авылында 269 ир-ат һәм 297 хатын-кыз яшәгән. Авылны Иске Җөри авылыннан күчеп утыручылар нигезләгән.

Алан-Җөри, Казаклар, Мурза авылы Мишә суы буена утырган. Анда ислам дине тотучы 16 ир-ат һәм 17 хатын-кыз яши.

Яңа Җөри, Кара-Тау, Карачтау авылы Мишә суы буенда. Авылда 112 ир-ат һәм 96 хатын-кыз исәпләнә. Иске Җөри шулай ук Мишә ярына урнашкан. Анда 278 ир-ат һәм 278 хатын-кыз көн иткән. Авыл янында, Мишә суы ярында шәһәрлек бар. Монда элек Җөри шәһәре булган. Тарихи Җөри юлын да искә төшереп китү урынлы булыр. 1898 елгы белешмәдә күрсәтелгәнчә, Алан-Җөри (Казалар), Иске Җөри, Яңа Җөри авылларында татарлар яшәгән.

Иске Җөри, Яңа Җөри, Урта Саба, Сатыш, Орымширмә, Караширмә, Зур Тиләҗе, Баландыш, Урта Мишә, Елыш, Югары Шытсу, Түбән Шытсу, Чәбки Саба, Бигәнәй, Казаклар һәм Теләче авыллары халкы июнь урталарында Мамалай җыены үткәргән (Н.Борһанова).

Авыл аксакаллары хәтерендә калган риваятьләргә караганда, Иске Җөригә XVI йөздә нигез салынган. Монда ин беренче булып килгән кеше Җөрихан исемле булган. Ләкин ул бирдән күчеп киткән дип сөйлиләр. Монда анын кызы үлеп кала. Бу кабер әле дә булса саклана икән.

Авыл атамалары, күрәсең, тарихи Җөри юлы белән бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән. Кече Җөри авылын икенче төрле Карачтау, ә Алан Җөрине Бәләкәй Казаклар, Морзалар, Тукмак Җөри дип тә йөртәләр.

Бай тавы. Элек бу тау Николай тавы дип йөртелгән. Николай бик бай кеше булган, атлары, сыерлары, сарыклары һәм этләре күп булган. Анын ишегалды уртасында чишмә дә агып торган. Йортлары белән янәшә тауда тирән базы булган. Ул баз әле хәзер дә бар икән. Бу кеше пыяла заводы хуҗасы булган. Бай тавы дип атау, димәк, шуннан калган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Һ

**НӘҖМИ** (Нәҗметдинов) Кави (Габделкави) Һибәтулла улы (15.12.1901, Сембер губ., Курмыш өязе, Кызыл Атау а. – 24.3.1957, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1919 да Сембердә пед. курсларын, 1922 дә Мәскәүдә Югары хәрби-пед. ин-т тәмамлый. Укытучылык итә, 1927 дән 6 нчы Берләштерелгән татар-башкорт (хәрби) командирлар мәктәбе комиссары, бер үк вакытта 1928-33 елларда - «Кызылармеец», 1933-34 елларда – «Совет әдәбияты» ж-лы г-тасы баш мөхәррире. ТАППның оештыручылары һәм җитәкчеләренең берсе. 1932 дә ТАССР Язучылары берлеген оештыру комитетында тора. Соңыннан берләшмә эшендә актив катнаша. 1934 тә 1нче Бөтенсоюз язучылар съездында доклад ясый, Берлек идарәсенә сайлана. 1934-37 елларда ТАССР Язучылар берлеге җитәкче. 1937 дә контррев. фетнә әзерләүдә гаепләнә, репрессияләнә; 1939 ның декабрендә азат ителә, реабилитацияләнә. Ф.Кәримне реабилитацияләү өчен күп көч куя. 1942-45 елларда ТАССР ХКС Радиофикация һәм радиовещание буенча Татар рескомы агитация һәм пропаганда бүлеге җитәкче, 1947-49 елларда «Совет әдәбияты» ж-лы редакциясендә. 1954 тә 2нче Бөтенсоюз язучылар съездында татар әдәбияты турында доклад ясый.

1912 дә «Көз» исемле беренче шигырен яза, татар теленә М.Кольцовның «Урман» («Лес») шигырен тәрҗемә итә. 1918 дә Н. тырышлыгы б-н туган авылында «Безнен иҗат» исемле кульязма ж-л чыга башлый (1941 гә хәтле чыгып килә). Матбугат битләрендә шигырьләре 1918 дән соң күренә башлый. «Өермәләр» исемле беренче шигъри, «Кабыргасы белән тора» шигырь һәм хикәяләр җыентыклары 1925 тә чыга. Н.нең бу чор поэзиясе стиль, образларның оригинальлеге, яна шигъри формалар (кара: Имажинизм) эзләү б-н аерылып тора. Автор чор б-н аваздаш булган иң актуаль социаль-әхлакый мәсьәләләр күтәрә, аның шигырь һәм поэмалары үткәннәрне инкяр итү б-н сугарылган. Новаторларча яңгыраш Н.нең тәүге прозасына да хас. Аның тематикасы – борылыш чорында татар авылы язмышы, халыклар дуслыгы, интернационализм. Геройлары – гадел-лек нигезендә яна җәмгыять төзү хыялы б-н янучы солдат һәм матрослар, эшче һәм крестьяннар. «Шобага» (1926), «Иң соңгысы» (1927), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1927) хикәяләрендә, «Яр буендагы учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929) повестьларында рев-ция вакыйгалары, Гражданнар сугышы, социализм төзү реаль күренешләре чагыла. Социаль-икътисади формациянең алмашуы б-н бәйле катлаулы һәм каршылыклы иҗтимагый процессларны анализлап, язучы мәңгелек – иске б-н яңаның, яхшы б-н яманның көрәше – темаларга килеп чыга. Аның әсәрләре хәрәкәтчән һәм тәэсирле сюжет борылышлары, көчле, истә кала торган характерлар, татар теленең сәнгати чараларын оста куллануы б-н аерылып тора. Ш.у. вакытта Н. прозасы ул еллар чоры әдәбиятында хөкем сөргән вульгар социологизм тәэсиреннән дә азат түгел. Бөек Ватан сугышы елларында Н. күбрәк публицистика жанрында эшли. Аның мәкалә, очеркларында барлык халыкларны берләшергә чакыру яңгырый, совет кешеләренең немец илбасарларыннан мораль-психологик өстенлеге тасвирлана: «Азатлык сугышы» (1941), «Намус эше» (1943), «Гани Сәйфуллин» (1944). Сугыш еллары поэзиясе ватанпәрвәрлек, Ватанга һәм сугышчы бурычына тугрылыкка дан җырлый: «Хәят апа» (1941), «Фәридә» (1944, композитор М.А.Юдин тарафыннан ш.у. исемдә опера языла). Ул «Ватан сугышы фронтларындагы улларына татар халкыннан хат»ының башлап оештыручысы һәм авторларының берсе була. Н. - Советлар Союзы Геройлары булган татарлар батырлыклары турында сөйләүче «Батырлар китабы»ның мөхәррире һәм төзүчесе. М.Җәлилнең исемен аклау мәсьәләре буенча актив катнаша (ҮК КПСС һәм СССР ЮС аның исемен аклауны сорап мөрәҗәгать итә); «Моабит дәфтәре»нең рус теленә беренче сүзгә-сүз тәрҗемәсен ясый.

Язучының 1928 елдан башлап язылган «Язгы җилләр» (1949, СССР Дәүләт премиясе, 1951) тарихи-революцион романы – социалистик реализмның классик әсәре булып танылды. Әсәр чын вакыйгаларга

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

нигезләнгән, яза башлар алдыннан язучы озак кына архив материаллары б-н эш итә. Хикәяләү үзәгендә - зур татар гаиләсенең тарихы. Геройлар язмышы киң тарихи җирлектә күрсәтелә; алар рев-ция вакыйгаларында катнашалар, соңыннан социализм нигезләренә таянып яңа тормыш төзиләр. Роман күпмилләтле совет әдәбиятының зур казанышы дип табыла, 26 телгә тәрҗемә ителә. Бәхәссез югары сәнгати дәрәҗәсенә карамастан (гади эшчеләрнең тормышын күрсәтү, аларның психологиясен ачу, хезмәт батырлыгы, сыйнфый көрәш, интернационализм темаларын тасвирлау), әсәргә күпмедер дәрәҗәдә күрсәтмәлелек һәм схемачылык хас. «Язгы җилләр» романының дәвамы булып «Тирән агым» язылырга тиеш була. Автор роман буенча гомеренең соңгы елларына кадәр эшли, ләкин төгәлләргә өлгерми. Н. - балалар өчен йомшак лирика, нечкә юмор б-н сугарылган шигырьләр авторы. Рус теленнән татарчага А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, А.А.Блок, С.Я.Маршак, А.И.Безименский һ.б. әсәрләрен тәрҗемә итә. Гражданнар сугышында катнаша. 1947-57 елларда ТАССР ЮС депутаты булып тора. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Н. яшәгән йортка мемориаль такта элегән.

Әс.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1981-84.

Әд.: Кашшаф Г. Кави Нәҗми // Совет әдәбияты. 1947. №2-3; Гиззатуллин Н. Кави Наджми. К., 1957; Нежметдинов Т. Течения и водовороты жизни // Казань. 2000. №10; Фаттахов Р. Кави Наджми. Личность и эпоха // Татарстан. 2001. № 10; Сильнее смерти и страха жизни: История любви: Док., письма, стихи. К., 2004.

*Р.А.Фәттахов,*
*Т.К.Нәҗметдинов.*

**НӘЗИРОВ** Марис Нәзиф улы (4.8.1949, Башкортстан АССРның Чакмагыш р-ны Каракөчек (хәзерге Үрнәк) а.), шагыйрь, Башкортостан Респ-касының атказ. матбугат һәм киң мәгълүмат хезмәткәре (2004). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Бөре пед. ин-тын тәмамлый (1972). 1973-93 елларда «Кызыл таң» (Уфа шәһ.) газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, үзхәбәрче, мөхәррир-күзәтүче вазифаларын башкара, 1994-95 һәм 2000-01 дә «Мәгърифәт» (Уфа) нәшрияты мөхәррире, 1995-2000 дә «Тулпар» ж-лы җаваплы сәркатибе, соңрак баш мөхәррир урынбасары. 2003 тән Башкортостан Респ-касы «Чакмагыш мәгълүмат үзәге» редакция-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе директоры. «Сакматаш» (Уфа, 1972), «Мәңгелек осош» (Уфа, 1978), «Йолдызлар табын кора» (Уфа, 1992), «Янә утларга керәм» (Уфа, 1994), «Бәрәкәтле җирем — Чакмагышым» (Уфа, 2000), «Еллар кары» (Уфа, 2002), «Һаумы, кояш!» (Уфа, 2003), «Ак торналар бүләге» (Уфа, 2006) исемле шигырь җыентыклары авторы. Шигърияте бүгенге катлаулы тормышны чагылдыра, татар халкының язмышын фәлсәфи яссылыкта сурәтли, нечкә кичерешләргә бай, аһәнле яңгырашлы. Шунлыктан шигырьләренең күпчелеге композиторлар Р.Хәсәнов, Ф.Габдрәков, Ф.Гасакирова, һ.б.лар тарафыннан көйгә салынган, популяр җырларга әйләнгән.

Әд.: Марис Нәзиров шигърияте. Уфа. 2000.

**НӘСЕР** (гар. чәчмә әсәр), лирик, хис-кичерешләргә бай, кечкенә күләмле, шигъри сөйләмгә якын булган проза әсәре; шәрык әдәбиятларында киң таралган жанр. Хислелеге, сюжетсыз төзелеше б-н лирик поэзиягә якын, ләкин шигырьгә хас булган сыйфатларга (ритм, строфа, рифма) ия түгел. Татар әдәбиятында Н. жанрына Ф.Әмирхан, М.Максуд, Ф.Әсгать, Г.Кутуй, Ә.Еники һ.б. мөрәҗәгать итә. «Н.» атамасы б-н ш.у. хикәяләүгә корылган әсәрләрне атыйлар.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**НӘСИМИ** (псевд., чын исеме Сәед Имамеддин) (якынча 1369 — 1417, Алеппо ш., Сүрия), әзәрбәйҗан шагыйре. Төрки, фарсы, гарәп телләрендә аза. Дин гыйлемен, мантыйк, математика, астрономияләрне өйрәнә. Якын Көнчыгыш буйлап сәяхәт итә; хәрефчелек (пантеистик тәгълиматның бер төре — хәреф сүзеннән килә; нигез салучысы Фәйзулла Астрабатлы) тарата; матурлыкны табигатьтән һәм аның иң югары баскычы булган кешедән эзләргә өнди. Автор табигый куанычларга дан җырлый, кеше акылы һәм матурлыгы алдында тез чүгә. Рәсми руханиларны тәнкыйтьли, аларны «дин белән сатучылык итүчеләр» ди. «Көферлек өчен» үтерелә. Н. шигырьләре суфый шагыйрьләр җынтыкларына кертелә, ш.у. «Бакырган китабы»на да. Н. иҗаты С.Рәмиев, Н.Думави һ.б. татар шагыйрьләренә зур йогынты ясый. Шигырьләре Ә.Исхак (1995) тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән.

Әд.: Смирнов В. Очерк истории турецкой литературы. СПб., 1892; Ариф М. История азербайджанской литературы. Баку, 1971; Араслы Г.Т. Имамеддин Несими: Жизнь и творчество. Баку, 1972.

*Р.К.Ганиева*

**НӘСИ ХӨСРӘҮ** (псевд., чын исеме Әбү Могыйн әл-Кубанияни әл-Мәрвәзи) (1004 — Кубадиян а., Әфганстанның Бәлх ш. янында — 1072 дән соң, Иомган а. Әфганстанның Бадахшан өлкәсе), фарсы һәм таҗик шагыйре. Мөселманнарның исмәгыйльчеләр хәрәкәте идеяләрен тарата. Бәлхтән куыла. Гомеренең ахырына кадәр Бадахшан тауларында яши. Әдәби мирасын 12 мең бәеттән торган диван, «Нур китабы» поэмасы, Мисырга (1046-52) сәяхәт кылганда алган тәэсирләре нигезендә язылган «Сәфәрнамә»се, берничә дини-фәлсәфи трактатлар тәшкил итә. Әсәрләрендә Х. хакимият башлыклары алдында түбәнсенгән сарай шагыйрьләрен, фәнгә һәм фәлсәфи фикер үсешенә киртә куючы ортодоксаль руханиларны тәнкыйтьли, ярлыларга карата мәрхәмәтле булуны таләп итә. Җәмгыятьтәге бәлаларның сәбәбен «яман дин» һәм «гаделсез хакимият»нең таралуынннан күрә.

Әс.: Сафар-наме. Книга путешествия. М.-Л., 1933.

Әд.: Бертельс А.Е. Насир-и Хосров и исмаилизм. М., 1959.

**«НӘСЫЙХӘТЕС-САЛИХИН»** («Игелекле кешеләрнең нәсыйхәте»), татар. әдәбиятының урта гасыр (якынча XVI-XXII йөзләр) ядкәре; дини-дидактик һәм нәсыйхәт характерындагы кыска хикәятләр җыентыгы. Бер төрләре пәйгамбәр, мөселман әүлияләре, суфыйларга багышланган, икенчеләрендә эчкечелек, азгынлык, рибачылык ише кимчелекләр тәнкыйтьләнә. Аерым хикәятләрдә гыйлемле булу, һөнәр өйрәнүнең кирәклеге, кешенең әхлакый камиллеккә омтылуының әһәмияте турында бәян ителә. Төзүчесе билгесез. Кульязмалары татарлар арасында киң таралган була һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту әсбабы булып хезмәт итә. 1853 тән алып җыентык 20 дән артык тапкыр басылган. 1996 да хәзерге заман татар графикасында «Нәсыйхәтес-салихин, яки «Изгеләрнең нәсыйхәтләре» дөнья күрә (текстолог Ә.Алиева әзерли). Ш.у. кара: Нәсыйхәтнамә.

**НӘСЫЙХӘТНАМӘ,** урта гасыр фарсы һәм төрки-татар әдәбиятларында дидактик эчтәлекле чәчмә яки тезмә-чәчмә әсәр. Афоризмнар ярдәмендә укучыга киңәш, нәсыйхәт бирелә. Н. дә мөрәҗәгать, риторик сорау, комментарий, шәрехләү, антитеза һ.б. чаралар кулланыла. Иллюстрация сыйфатында төрле гыйбрәтле мәгълүматлар һәм фактлар китерелә. Н.гә идея-тематик төрлелек хас. Мәс., «Нәсыйхәтес-салихин» (XVI-XVII йөзләр) җыентыгы — дини әсәр; Р.Фәхреддиннең әсәрләре әхлакый-гуманистик идеяләр б-н сугарылган.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миннегулов.*

**НЕБЕНЦАЛЬ** (Nebenzahl) Леон (1910, г.Воронеж - 1991), немец язучысы, тәрҗемәче. 1920 дән Берлинда яши. Фашистлар хакимияткә килгәннән соң концлагерьга эләгә, 1945 тә азат ителә. Матбугат эшләре буенча совет хәрби администрациясе ведомствосында эшли. 1940 еллар ахырында «Печать Советского Союза» ж-лын оештыруда катнаша һәм аны 8 ел житәкли. 1957 дән (30 елга якын) «Проблемы мира и социализма» ж-лының немец телендәге вариантының мөхәррире, «ГДР-СССР» дуслык җәмгыятенең житәкчесе була. Немец теленә русчадан В.С.Гроссманның «Степан Кольчугин» романын, Д.Д.Нагишкинның «Бонивур йөрәге» («Сердце Бонивура»), Е.Я.Драбкинаның «Кара сохарилар» («Черные сухари») повестьларын, И.М.Майковның «Совет дипломаты истәлекләре» («Воспоминания советского дипломата») исемле мемуарларын һ.б. тәрҗемә итә. Камерада М.Җәлил б-н бергә утырган А.Тиммермансны, Шпандау төрмәсендә шагыйрь көрәштәшләре б-н очрашкан Р.Ланфрединины, Г.Кормаш төркемен җәзалауга караган документларны эзләп таба. Германия демократик республикасының Фәннәр академиясендә «Муса Җәлил — шагыйрь һәм көрәшче» исемле доклад укый. Муса Җәлилгә багышланган «Mussa Dshalils «Moabit Hefte» - Zeugnis der Menschlichkeit irmitten von Barbarei» («Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» — вәхшилекне фаш итүче кешелек доументы») мәкалә һәм күпсанлы башка публикацияләр авторы.

Әд.: Мансурова М. Леон Небенцаль — исследователь творчества Джалиля // Комсомолец Татарии. 1969. 29 окт.

*М.Ә.Мостафин.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# АККАН СУЛАР КИРЕ КАЙТМЫЙ

Һич уйламассың язмыш синең белән берәр вакыт шаярып алыр, яки сынап карар дип. Кайчагында авыр хәлгә каласың, көтелмәгән шатлыклы вакыйгалар була, күктән бәхет ява дигәндәй... Шунда менә шулай килеп чыкса кайсы юнәлешкә каерылыр иде икән минем тормыш дип тә уйлап куясың...

...Төзелеш институтының архитектура факультетына керү имтиханнары тапшырып йөрим. Бик нык әзерләндем, әлбәттә. Рәсем ясауны булдырам анысы. Тәҗрибә бар. Мәктәптә укыганда да барлык бизәү эшләре миңа йөкләнә иде. Математикадан әлләни мактанырлык чамам юк югын, әмма укытучыбыз Вера Павловнаның безне интектерүе белемгә гаять файдалы нигез салгандыр дип уйлыйм. Татарча диктант язуны чүпкә дә санамыйбыз инде.

Менә математикадан имтихан бара. Мәсьәлә, мисалларны тиз генә чишеп, имтихан алучы япь-яшь кыз алдына иң беренчеләрдән булып килеп утырдым. Чибәр дә инде, нәгаләт. Миннән яшьрәк тә бугай. Кай арада югары белем алып, бездәй ломоносовларны сыный бит, әй. Институтлар ташлап, төзелештә эшләп йөрсәң, шулай була ул, Хәмзин. Менә яшь кызлар үзеннән сынау алалар хәзер. Янаклар уттай яна, колаклар кызыша. Тирли-пешә чибәркәйнең минем кәгазьдәге мәсәлә-мисалларны тикшерүен күзәтәм. Алай сызгаламый тагын, ялгышлар юк, күрәсең. Менә тотынды бу өстәмә сораулар бирергә. Логорифмнар, ди, интеграллар... Соңгысын гомумән ишеткән дә юк. Үтмәдек без аны мәктәптә, мин әйтәм. Шундый чибәр кыз сораулар яудырганда җавабын да тиз генә табып булмый бит әле аның. Тотлыгам гына, күз алларым томаланып китте. Томан артындагы әлеге кыз убырлы карчыкка да әверелә, сихерче сурәтләренә керә, аждаһа төсле дә күренә. Агулы сорауларын чәчеп бетергәч: «Дүртле!» — диде бу. Дүртле? Нишлим мин ул «дүртле» белән? Конкурстан үтмим бит. Димәк, армиягә. Шагом марш! Нишлисең, юри батырды инде бу мине, юри. Конкурс зур, кемнедер сызарга кирәк.

Хезмәт итеп кайтсам кайтам, әмма «бишле» куегыз инде дип ялынмаячакмын. Гарьлеген кая куярсың. Татарның башы иелми аның!..

Еллар үтте. Армия хезмәте дә артта калды. Сөйгән ярлар без кайтканчы безне көтмичә кияүгә чыгып беттеләр. Яңалары күренми. Әллә акылга ныграк утырганбыз, әллә тормышка аеграк, төплерәк карыйбыз. Өйләнергә уйлаган юк. Дуслар бер-бер артлы башлы-күзле булып беттеләр. Менә соңгысын өйләндерәм. Мин — шаһит егет. Инде күпмесендә бу вазифаны башкарганмындыр, санаган юк. Дустым Азат өйләнә. Булачак җәмәгате Хәдичә искиткеч сөйкемле, булган кеше. Каян табалар шундыйларны, миңа берәү дә очрамый. Шулай да Хәдичә колагыма киртләп, туйга үзенең менә дигән сердәше шаһит кыз булып киләчәген әйтеп куйды. Кара аны, ычкындырасы булма, ялгышырсың, дип тә өстәде. Ярый, килсен, китәр әле. Инде миңа өйдәгеләр дә күп кандидатуралар күрсәттеләр, күнегелгән.

Менә туйга жыелалар. Кемнәр генә юк. Барысы да бәхетлеләр, парлылар, мин генә дуадак ата каз кебек басып торам. Әле кызмаганмын. Кызсам, туктатып булмый тагын үземне. Баянны алып уйный да, жырлый да башлыйм. Дөресен генә әйткәндә, шуның өчен чакырылам да инде мин туйларга. Карыйм, Хәдичә, Азатыннан вакытлыча аерылып, минем янга бер кызны житәкләп килә. Еsettлем ук сүзен таныштырудан башлый.

— Менә бу — Алмаз, шаһит егет, безнең дустыбыз. Ә бу кыз — минем сердәшем, Төзүчеләр институтының яшь доценты — Галия, — ди.

Мин күземә күренәме, бу — өнемме-төшемме дигәндәй авызымны ачып әлеге Галиягә карап каттым.

Шул бит, шул, әйе... Теге вакытта имтиханда мине батырган кыз.

Хәдичә сүзен дәвам итте.

— Нәрсә өнсез калдың, башка вакытта бик кыю бит үзең, — дип, миңа гына күзен кысып, кызның сыйфатын баш бармагы белән бәяләп, Азаты янына йөгерде.

Мин каушаган килеш торам. Әйе, ул мине белми, хәтерендә калмаган. Минем кебекләр аның күз алдыннан йөзәрләп, меңәрләп үтәләр ич...

Ниһаять, Галия сүзен башлады.

— Хәдичә сезнең турыда миңа бик күп сөйләде. Төзүчеләр институтын тәмамлый алмыйча армиягә алынуыгыз турында да. Карагыз әле, нигә шунда миңа мөрәжәгать итмәдегез. Мин бит еш кына керү имтиханнарын кабул итәм. Хәзер яңадан бездә укырга теләгегез юкмы? Мин барында сезгә уку бик жинел булыр иде. Сезнең талантлы икәнлегегез йөзегездә үк чагыла. Сезнең кыяфәтегез зыялы, сез музыкант, сез шагыйрь, композитор — бу күркәм сыйфатларыгыз арасында архитекторлык юнәлеше аеруча калку күренә. Әйдәгез, бергә булыйк.

— Рәхмәт сезгә. Менә бит мине тормышта нинди бәхетле борылыш көтә икән. Сез иреклеме?

— Әйе. Гафу итегез, мин сезгә һич яшерми әйтә алам: инде бер мәртәбә ялгышлык белән кияүдә булдым. Яшьлек хатасы. Бер студентым белән яшәп карадым. Институтка керттем, укыттым, хәзер качты. Ә сез акыллы, һичшиксез акыллы.

— Шулай шул, инде миңа акыл керде. Әйдәгез, бүген ул турыда сүз кузгатмыйк. Бүген бәйрәм — дусларыбыз тантанасы. Биик, жырлыйк.

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар ник болай?
Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай.

**Алмаз ХӘМЗИН**

## Альберт Хәсәновка 75 яшь



Язучы Альберт Бари улы Хәсәнов 1937 елнын 1 декабрендә Татарстаннын элекке Дөбъяз (хәзерге Биектау) районы Кече Кавал авылында укытучы гаиләсендә туа. 1955 елда Дөбъяз урта мәктәбен тәмамлап, берникадәр вакыт шул төбәктәге Кече Салабаш авылы мәктәбендә математика укытучысы булып эшләп ала. 1956—1961 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Институтны тәмамлагач, 1961-1969 елларда Лениногорск шәһәрендә әүвәл төбәк газетасы «Ильич васыятьләре» редакциясендә — әдәби хезмәткәр, аннары шәһәр телестудиясендә һәм радиостудиясендә соңгы хәбәрләр бүлеге редакторы булып эшли. Шул елларда көндәлек матбугатта аның туган як табигатенә һәм төбәк кешеләренә багышланган беренче хикәяләре, очерк язмалары басыла башлый, 1966 һәм 1967 елларда табигать һәм җәнлекләр турындагы хикәяләре тупланган «Озын аяк» һәм «Таң йолдызы» исемле ике китабы дөнья күрә.

Яшь каләм тибрәтүченең иҗади кызыксынуларын эшчеләр тормышына якынайтуны күздә тотып, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе тәкъдиме белән Альберт Хәсәновны 1969 елның гыйнварында «Татбурнефть» трестының вышкалар монтажлау конторына производство бүлеге инженеры итеп күчерәләр. Соңга таба ул анда (1976 елга кадәр) партком секретаре булып эшли, нефтьчеләр тормышын якыннан торып өйрәнә, алдынгы хезмәт коллективлары, төрле милләт вәкилләре белән аралаша, алар турында «Байрак тапшыру», «Фәндәм фонды» кебек документаль повестьларын иҗат итә, «Бер сафта», «Юллар үргә илтә» дигән очерк җыентыкларын бастырып чыгара.

1976-1986 елларда А.Хәсәнов Лениногорскидагы «Радиоприбор» заводында гражданнар оборонасы бүлеген җитәкли, аннары биш ел әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнеп, 1990 елдан янәдән журналистлык хезмәтенә кайта: «Ватаным Татарстан» газетасының Әлмәт төбәге буенча үз хәбәрчесе вазифаларын башкара.

Ул — ике дистәдән артык басма китап авторы. Аларның күпчелеге язучы иҗатының төп юнәлешен тәшкил иткән иң актуаль темага — табигатьне саклауга багышланган.

А.Хәсәнов 1985 елда «Дружба народов» журналында басылып чыккан «Несказанный свет» дигән повесте өчен журналның махсус бүләгенә лаек була, 1995 елдан «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртә.

А.Хәсәнов — 1982 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Каләмдәшебез Альберт Хәсәновны олы юбилее белән тәбрик итәбез, саулык-сәламәтлек, күңел тынычлыгы, иҗат уңышлары телибез.

*Быел ике зур әдип, бигрәк тә җыр өлкәсендә зур казанышларга ирешкән шагыйрьләр: Әхмәт Ерикәйнең тууына — 110, Мостафа Ногманның тууына 100 ел. Юбилейлары уңаеннан җырларыннан үрнәкләр тәкъдим итәбез.*

Әхмәт Ерикәй
(1902 – 1967)

## Тагын хуш ис бөрки сиреньнәр

*Н. Җиһанов көе*

**Җир йөзе яшәрә, шатлана май,
Сиреньнәр хуш исләр тарата;
Яз килгәч, яшәрәм гөл сыман мин,
Күңелем яз ямен ярата.**

**Уйларны тибрәтә–тибрәтә җыр,
Өздереп Иделдә җырлыйлар;
Шомыртлар талларга:
«Без дуслар!» — дип,
Хуш исле кулъяулык болгыйлар.**

**Алдымда бормалы–бормалы юл,
Мин карыйм еракка–еракка;
Күк күзләр һаман да, һаман да бит,
Тынгылык бирмиләр йөрәккә.**

**Елмая кәккүкле, тургайлы яз,
Күк күзләр дә, бәлки, елмаер;
Ай кебек бер генә елмайса да,
Язларның гомере озаер...**

**Ай кебек бер генә елмайса да,
Ачылыр дөньяның гөлләре;
Тагын да ямьләнер илемнең киң,
Гаҗәеп ягымлы җирләре.**

*1952*

## Юллар

*Л.Айтуганов көе*

Бизмәгәндәй яшәү бәхетеннән,
Юл йөрүдән мәңге бизмәм мин.
Юллар, юллар, инде ничә еллар
Аерыла алмыйм сездән мин.

Алларымда якты йолдыз төсле,
Мавыктыргыч утлар яналар.
Юллар, юллар, борма-борма юллар
Шул утларга таба баралар.

Яшьлек хисен, тынгысызлык дәртен
Вакыт яңгырлары юмасын.
Юллар, юллар авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын...

Тибрәндереп якты уйларымны,
Җәйрәп ята данлы, киң илем.
Юллар, юллар алга таба дәшә,
Бармый калыр хәлем юк минем.

*1960*

## Җырланмаган әле безнең җыр

*Р. Яхин көе*

Хуш исләрен гөлләр сипкәндә,
Тәрәзәмне җилләр чирткәндә,
Карамадың нигә әйләнеп
Яннарыңнан үтеп киткәндә?

Җылы язлар
тик башланды гына,
Әле генә яшел киде кыр;
Әйтер сүзләр әле әйтелмәгән,
Җырланмаган әле безнең җыр.

Сине генә, бәхет йолдызым,
Хыялымда назлап йөртәм мин;
Аерылышу төне килмәсен,
Кавышу таңын, иркәм, көтәм мин.

Җылы язлар
тик башланды гына,
Әле генә яшел киде кыр;
Әйтер сүзләр әле әйтелмәгән,
Җырланмаган әле безнең җыр.

*1960*

## Яшьлегемә кире кайтыр идем

*И.Якупов көе*

**Нинди ямьле безнең үзәннәр,**
**Түшәлгәннәр йомшак хәтфәләр;**
**Ал чәчәкләр, яшел үләннәр**
**Яшьлегемне хәтерләтәләр.**

**«Яшьлегем!» —**
**дип өзлеп җырлар идем,**
**Өзлеп җырлый торган җыр булса;**
**Яшьлегемә йөгреп кайтыр идем,**
**Кире кайта торган юл булса.**

**Яшьлегемнең узып китүен**
**Кошлар китүенә тиңлим мин;**
**Киткән кошлар кайта яз килгәч,**
**Кайтыр микән яшьлек, белмим мин.**

**«Яшьлегем!» —**
**дип өзлеп җырлар идем,**
**Өзлеп җырлый торган җыр булса;**
**Яшьлегемә йөгреп кайтыр идем,**
**Кире кайта торган юл булса.**

*1967*

# Мостафа Ногман

(1912 – 1976)

## Оныта алмыйм

*Р.Яхин көе.*

**Күзләремне тутырып карап калам**
**Син ерактан үтеп киткәндә,**
**Оныта алмыйм, бәгърем, оныта алмыйм,**
**Күңелем төшми синнән бүтәнгә.**
**Сезнең яктан искән җилләр белән**
**Килер сыман миңа бер хәбәр,**
**Бергә булган чакның минутларын**
**Ник сагынам икән бу кадәр?!**
**Таң алдыннан моңлы кошлар сайрый**
**Гөлбакчада яшел тирәктә,**
**Син дә минем сагыну җырым булып**
**Сакланырсың мәңге йөрәктә.**

*1951*

## Күзләрем тик сине эзлиләр

*Р.Яхин көе.*

Бакчага ямь керә,
Хуш исләр бөркелә,
Сиреньнәр чәчәккә бөреләнсә.
Син сөйгән сиреньнәр,
Син күргән сиреньнәр —
Күңелемә иң якын бер нәрсә.

Җырларың тыңласам,
Син барны уйласам,
Күңелемне сүрелмәс моң сара.
Канатлар кайрылган,
Юлыбыз айрылган,—
Без бергә булырга юк чара.

Мин җырлап юанам,
Гөлләргә күз салам,
Гөлләр дә:—Юксынма, түз,—диләр.
Сызылып таң атканда,
Ал шәфәкъ батканда
Күзләрем тик сине эзлиләр.

*1967*

## Әниләр

*Р.Яхин көе.*

Гомер таңнарыбыз аткан көнне
Зарыгу белән көтеп алучы,
Безнең өчен тау кадәрле йөкләр
Күтәрергә әзер калучы —

Әниләр,
Мәрхәмәтле безнең әниләр,
Җиргә матурлыкны,
Илгә батырлыкны
Сез бирәсез, гүзәл әниләр.

Сездә яши сүрелмәслек хисләр,
Йөзегездә шәфкать нурлары,
Сезнең җырлар аша күчә безгә
Туган халкыбызның моңнары,

Әниләр,
Мәрхәмәтле безнең әниләр...

Якты йолдыз кебек сез балкыйсыз
Тормыш юлларыбыз күгендә,
Иң кадерле бер кешебез булып
Сакланасыз күңел түрендә,

Әниләр,
Мәрхәмәтле безнең әниләр.
Җиргә матурлыкны,
Илгә батырлыкны
Сез бирәсез, газиз әниләр.

*1968*

## Киек казлар китә

*Р.Яхин көе.*

Киек казлар китә җылы якка,
Төркемнәре белән гел бергә;
Казлар китә, ә без — якын дуслар —
Сагынышып килдек күрешергә.

Кушымта: Казлар оча һаваларда,
Сызылып кала зәңгәр
юллары;
Казлар кебек үтә,
Тезелеп үтә
Онытылмаслык яшьлек
еллары.

Язгы күкрәү, тәүге шашкын хисләр...
Шат кичләрне искә кем алмас?
Саф хыяллар белән беркетелгән
Яшьлек дуслыгыбыз югалмас.

Кушымта.

Киек казлар китә каңгылдашып,
Ямансулап кала күңелләр,
Казлар кайтыр, ләкин кире кайтмас
Без кичергән матур бу көннәр.

Кушымта.

*1974*

# ИРЛӘР КЫРЫКТА СЫНАЛА

ГАЗИЗ МӨХӘММӘТШИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Прозабыз мәйданында югалтулар күбәйде, алмашка килгәннәре бигрәк аз...

Матур әдәбиятка илтифатлы һәр татар гаиләсенең түрендә шәхси китапханә булыр. Ул китаплар басылып чыккан елына, чорына, илдәге сәяси хәрәкәт йогынтысына карап хөрмәт белән билгеле бер тәртипкә салынган, телем-телем тезелгән булыр. Шунда ук, кулга якын гына, күз төшәрлек бер сөйкемле шүрлектә махсус сайланганнары кызыктырып торыр. Минем алда: Ф.Әмирхан, Ә.Еники, М.Әмир, Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, Ф.Шәфигуллин, Г.Мөхәммәтшин... Халәтенә, кәефенә, шөгыленә туры килердәен, вакыт-вакыт укыштырып, вакчыл язмыш низагларыннан онытылып аласың. «Сөйкемле шүрлек»тә күбрәк кичәге авторлар.



Газиз Мөхәммәтшинның «Без әле жирдә яшибез» (ТКН-1992) китабы да кул җылысында тузган, күз явыннан унган. Язучының 80 еллыгы унаеннан гына әйтелгән кызыл сүз түгел бу — чыны шул! Әлеге китап укыйсыны китереп, ымсындырып үзенә тартып тора. Аны укыгач, кичекмәстән юлга чыгып, язучы тудырган Кояшлы, Кәккүк, Иске Крахмал, Кызыл имән, Иске Алан кебек авылларга кайтасы килә; тау битеннән аяк очына күтәрелеп, көрәнсу-кара күк йөзенә сырышкан йолдызларны үрелеп тотасы; урман диңгезенең чиген үз күзләрең белән күрәсе; болында йөзем үстерәм дип башына кыстыбый куеп ант иткән Төер Гәрәйнең алмагач тавышын тынлап йөргәненә ышанасы һәм аның белән кара-каршы утырып бер сөйләшәсе килә...

Иҗатының буеннан-буена телгә алынган авылларның бөтенесен бергә кушсаң — 1932 елның кыш башында язучының киләчәге өчен тал бишек элгән Минзәлә районының гүзәл Ык буендагы Яңа Бикчәнтәй авылы күз алдына килә дә баса.

«Без әле жирдә яшибез» повестенда Сабир белән Жиһан гаиләсе бөтен унайлыклары да булган шәһәр фатирын калдырып авылга кайтып төпләнә...

Ирнең күчену турындагы хәбәре беркемне дә сөендерми. Хатын белән ике арада әрләшүгә охшаш сөйләшү башлана, ул урыннар бүлеге-бүлеге белән тоташ диалоглардан гына тора.

Автор повестьны гаиләнең бердәнбер иркә малае — Инсаф авызыннан сөйләттерә, аның күзаллавына таянып сюжет кора, кичерешләре аша жәлеп итәрлек вакыйгалар сайлый.

Әнисе Инсафны яклый, янәсе, Казанда гына яшәп калсалар, уллары композитор була алыр иде ди. Малайга кечкенәдән музыка тәрбиясе бирергә теләп аны зур белгечләр янына дәресләр алырга йөртәләр. Әйтерсең лә күренекле талант ияләре һәммәсе дә шәһәрдән генә чыккан (!)

Язучының тасвирлау хәйләсен чамалавы кыен түгел, Сабир белән Жиһан күчеп кайткан соклангыч жир — ул, әлбәттә, Газиз Мөхәммәтшинның туган авылы. Автор анда үзе, әле тугыз-ун яшьлек Инсафка әверелә, әле ир уртасы Сабир урынына баса...

Инсафны авылның тарту көче жиңә...

Тәрәз төбендә үскән гөл кебек аның әле буыны сыек. Шәһәр ышыгыннан

авылның кояшлы-сулы романтикасына килеп керүендә сөенечтән бигрәк сагаюы күбрәк.

Космоска очмаска дучар ителгән халыкның космонавт булырга хыялланып үскән малайлары аны ниһаять үз итә, чыныктыра, мөстәкыйль яшәргә өйрәтә. Ул үзенең житешсезлекләреннән кимсенмичә, алар белән хәтта мактана да бугай әле. Ә без беләбез — мактану ул табигать белән үрелеп беткән малайчакның чамасыз хыялыйлыгыннан килә...

Шәп язучы булыр өчен авторның үз биографиясе дә кызыклы булырга тиеш. Газиз Мөхәммәтшинның тормыш юлы повесть-хикәяләрендә ачык чагыла. Жентекләбрәк укысаң мажараларга бай балачагы, мәктәп һәм Минзәлә педучилищесы еллары. Түмән өлкәсендә укытучы булып эшләве, «Чаян» һәм «Ялкын» журналындагы әдәби хезмәткәрлеге, ниһаять «Казан утлары» кебек мәртәбәле журналда җаваплы редактор вазифаларын башкаруы — барысы да аның әсәрләрендә төгәл чагылыш таба.



*Султан уңга (беренче рәт) Б.Камалов, Х.Камалов; (икенче рәт) И.Юзеев, Г.Мөхәммәтшин. 1963 ел.*

Коеп куйган педагог булса да Г.Мөхәммәтшин прозасы диктант теле белән түгел, ә йөгерек, уйнак, халыкчан, ирекле инша теле белән язылган. Аның китапларында «балалар өчен», «яшьләр өчен», «өлкәннәр өчен» дигән бүленеш юк, алардагы тыйнаклык, яхшылык, мәрхәмәт һәм шәфкать хисе һәр буынны үзенә җәлеп итә. «Гиппократ анты»на табынган дәвалаучы кебек Газиз Мөхәммәтшин да үзе ачкан «Макаренко анты»на тугры кала. Ник дигәндә, әллә кайларга яшереп куйсаң да, «тыелган» китап бала-чага кулына килеп эләгергә мөмкин.

Язучы инде 60нчы еллар башында ук шушы Жирдә яшәүчеләр хакында борчылып, төп игътибарын экологик проблемага юнәлтә. Яшәү дәрте белән гыйшыкланып, кеше бүген табигать кочагына ташлана, ләкин күңел ачу өчен, саклау өчен түгел.

«Саумысыз аккошлар» повестенда, Вәкил исемле малайның өенә кайтып: «Әни, карт имәнне кисканнәр!» дип оран салуы, кереш өлештә үк лирик тынлыкны боза. Бер уйласаң, урманда агач кисми торалармы? Бура-матча, өрлек-багана, койма-киртәлекләр урманда гына үсә ләбаса! Карт имән киселсә яшь имән кала...

Юк шул, табигать баласына әверелгән авыл язучысы Карт Имәнне тере җан иясе итеп күрә, аның исемен дә баш хәрефләр белән яза.

«Түгәрәк аланның бизәге — Карт Имән сузылып юеш жирдә ята иде... Тиз генә үлмәгәнлеге, яшәү өчен жан тырнашып бик озак тартышканлыгы күренеп тора. Аның мич урыны хәтле төбен, балта белән әйләнә-әйләнә чабып, уеп кергәннәр. Коры яфраклар өстенә ястык калынлыгы көрәнсу-сары йомычка төшәлгән...» Шушы юлларны укыган кеше, белмим, үсеп утырган агачка балта күтәрә алыр микән?!. Карт Имән генә түгел, ә күпне күргән, озак түзгән чал табигать жан салып ятканда...

Әйткәнемчә, иҗат дөньясында югалтулар бихисап. Исән килеш онытылганнары да житәрлек... Газиз Мөхәммәтшин онытылмый, китаплары «сөйкемле кыштә»дә.

Талантлы язучыларның язмышын хәвеф-хаста эзәрлекли. Г.Мөхәммәтшин үзе сайлаган табигать кочагында нибарысы кырык кына ел яшәп калган... Арабыздан

киткәненә дә кырык ел. Илдәге вазгыятьнең кырыкка-кырык килгән чорында, күпме сынаулар кичеп тә исән калган повестьлары, роман-пьесалары, кырыклап хикәясе — бүгенге укучыга тансык, тәрбия чарасы буларак мөһим.

Бүген дә, һаман да мөһим.

Курантларны вакыт эталоны белән тигезләгән кебек, бүгенге прозаны Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, Ф.Шәфигуллин, Г.Мөхәммәтшиннар каләме белән төзәтеп-көйләп, җөмлә төзелеше, стиль, тел күркәмлеге, сурәтләү чараларының күплеген кайтаруга ирешсәк матур әдәбиятыбызның гомере озынаер иде.

Г.Мөхәммәтшинның чәчмә әсәрләрендә ялыктыргыч тынлык өсти торган монологлар юк. «Йөрәктәге эзләр» романы дисеңме, повестьлары-хикәяләреме — аларда сөйләшә торган проза — нәтиҗәле хәрәкәткә корылган туры сөйләм өстенлек итә. Язучы драматургия жанрына битараф түгел. Аның «Тынгысыз төн» комедиясе үз вакытында Күчмә театр сәхнәсендә шактый уйналып, тамашачыны сөендергән. Исән чагында ул «Дулкыннар җыры» дигән күләмле трагедиясен төгәлләп өлгергән булган. Билгеле бер сәбәпләр аркасында ул әле укучыга барып җитмәгән[1].

Турысын әйтик, Г.Мөхәммәтшинның иҗаты әле бүгенгәчә ныклап өйрәнелмәгән. «Ике әби бәрәңге ала» кебек хикәяләрен яттан белсәк тә яңа чорның әдәби теленә йогынты ясый алырдай иҗаты тәнкыйть игътибарына мохтаҗ хәлдә күләгәдә кала бирә.

Чын ирләр кырыкта сынала...

1982 елны «Казан утлары»ның декабрь санында Газиз Мөхәммәтшинның 50 еллыгы уңаеннан «Йөрәктәге эзләр» дигән мәкалә басыла. Язманың авторы, әле үзе дә кырык яшьтән әлләни узмаган талантлы язучыбыз Фаил Шәфигуллин, журналның ул санын күрми кала — фаҗигале төстә гомере өзелә... Кырык яшьтә өзелгән иҗади гомер генә түгел, аларның китапларын да янәшә куярлык сәбәпләр бар: икесе дә юмор жанрының фидакарьләре; икесе дә балалар язучысы; икесе дә «Чаян» журналында һәм «Казан утлары»нда эшләгән талантлы прозаик, танылган хикәяче.

Хикәя дигәннән, фикеремне «Ике әби бәрәңге ала» белән түгәрәкләргә телим. Фаил белән бер очрашуда Г.Мөхәммәтшин ул хикәянең язылу тарихын бик җинел генә әйтеп бирә: өстәл артына утырып язмадым мин аны, авылга кайткач киртә буена сузылып яттым да карт әби белән яшь әбинең әңгәмәсен күчереп кенә алдым, үземнән биш-алты сүз өстәгәнмендер ди...

Язарга өйрәнеп, укучысын табып өлгергәч, әдәби камиллеккә ирешкәч кенә арабыздан китеп бардылар...

Күпләребез ел саен бәрәңге алышырга кайтабыз.

Бәрәңге бакчасында лебер-лебер сөйләшкән тавыш ишетсәк, киртә аша үрелеп, кемнәрнедер эзли башлыйбыз...

**Камил КӘРИМОВ**

[1] Шушы көннәрдә язучының хатыны Ләлә ханым әлеге трагедияне редакциябезгә китереп бирде.

# КОЯШЛЫ КӨЗГЕ

КОЯШ ТИМБИКОВАНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Алар чорына журналист хезмәтенең мөгаен иң авыр, катлаулы вакыты туры килгәндер. Героинянның тимерюл шпалларын күтәргәндә сыгылып килүләрен, савымчыларның салкын-шыксыз, унайлыклары булмаган фермаларда эшләүләрен, бөтен эш кул хезмәте белән башкарылганлыктан төннәр буе сызланып чыгуларын, планны арттырып үтәү хезмәтнең кайсы гына тармагында да нинди авырлыклар белән бирелүе турында язасы килә дә бит — ярамый, язмаң партия куйган таләпләр кысаларыннан чыкмаска, очерк-репортажларында хезмәткәрләрнең шат-бәхетле йөзе чагылырга тиеш. Авыл араларында очраклы машиналарда, сөт бидоннары арасында баруыңнан әле кайткач зарланырга да тиеш түгелсең. Болар — юлсызлыклар, юксызлыклар, торгынлык чорының шулай булырга тиешле кебек язылмаган кануны... Һәм әле тагын шундый меңәрләгән тиешләр. Хәзерге кебек информацияне интернеттан алып, кесә телефоныңнан шалтыратып, редакция машинасында жилдереп кенә барып төшә алмыйсың. Өстәвенә журналистларның да, халыкның да аноним хатлар үзәгенә үткән вакытлар. Тәнкыйть мәкаләсе язарга дип җибәреләсең, ә анда бөтенләй башкача... Артыңнан ук үзеңә дә анонимка килеп төшәргә мөмкин. Әнә шундый шартларда иҗат итәләр коллективлары күпчелек хатын-кызлардан гына торган «Азат хатын» («Сөембикә») журналы хатын-кыз журналистлары.



Илдә зур төзелешләр — БАМ, КамАЗ төзелгән чаклар. Язмаңа «унай герой» эзләп атналар буе командировкаларда йөрисең, әле бит гаилә дә бар. Көтеп алган ял көнеңдә (бүгенге күзлектән чыгып караганда, бәлки, көлке дә тоелган) колхоз-совхозларга бәрәңге, чөгендерләргә йөртүләр... Язучы Кояш Тимбикованың «Көзге рәнҗү» хикәясе тикмәгә генә язылмагандыр.

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач та — 1959 елда килә ул «Азат хатын»га. Халкыбызның яраткан журналына әйләнүендә үз заманының фидакарь хатын-кыз журналистлары — Кояш Тимбикова, Диләрә Зөбәерова, Мәдинә Маликоваларның да өлеше зур. Әлеге өч хатын-кызны бергә эшләүдән тыш иҗади дуслык та бәйли. Шулай булмаса К.Тимбикова Д.Зөбәеровага багышлап җылы, якты хисләр белән сугарылган «Зәңгәр күзле дустым, жанкисәгем», М.Маликова турындагы «Без язларны бергә каршыладык» язмасын язар идеме...

«Бу журналның сугыштан соң янадан чыга башлавы татар укучысына да, журналистикабыз үсешенә дә, һәм, әлбәттә, шул нигездә бер төркем хатын-кыз язучылар тәрбияләнүгә дә зур этәргеч бирде. Алтмышынчы еллар башында бу редакция гаҗәеп көчле рухлы кызларны туплады. Монда хак алып эшләүчеләрне генә әйтүем түгел, аның редколлегиясе дә, штаттан тыш ярдәмчеләре дә, хәтта гап-гади хат язучылары да — барсы бер булып, бер йодрыкка төйнәлеп, бу журналны дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрде. Бик тиз арада аның тиражы йөз меңнәр белән исәпләнә башланды», — дип яза үзенең егерме ел гомерен әлеге журналга багышлаган К.Тимбикова истәлек язмасында.

К.Тимбикова әлеге журналда әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире вазифаларын башкарса, «Казан утлары»на 1979 елда инде танылып килә торган язучы, «Зәңгәр күлмәк», «Сөлге булсын бүләгем», «Синең өчен» исемле хикәя-повестьларын туплаган берничә китап авторы булырак җаваплы сәркәтип итеп алына. Бирелә инде, авторларны да

санап, коллективта күпчелек ир-атлар. Ул заманнарда җаваплы сәркәтип урыны чын мәгънәсендә җаваплы, газета-журналларның йөзен билгеләүче, вакытында тапшырылып, тиешле көндә санны кулга алуга җаваплы, һәрбер сүз-хәреф кулдан җыелганлыктан, фотографияләр тимер клишеда ясалганлыктан типография белән ике арада чабып йөрүче дә, финанс мәсьәләләре, эшкә кабул итү-китү кәгазьләрен тотыручы да...

Кояш апа нечкә күңелле хатын-кыз булса да, холык-фигыленә егетлек сыйфатлары да хас иде. Ялагайлык-куштанлыкны сөймәде. Уйлаганын турыдан ярып әйтә белде. Кайчак, бәлки, артыграк та әйткәләгәндер. Турысын әйткәнне туган да яратмый бит... Хатын-кызларның иҗатка килүләренә сөенә иде. «Хатын-кыз ир-атка караганда әйбәтрәк тә яза, танырга гына теләмиләр, яз, язганыңны (бер шагыйрьнең исемен әйтеп) аңа күрсәтергә дә кыенсынма, үзе яза белмәсә дә кешенекен әйбәт төзәтә ул», — дияр иде миңа да.

Шигъриятне ярата иде ул. Шагыйрьләр белән дус иде. Талантлы шагыйрьләр белән, Нәҗар Нәҗми, Мостай Кәримнәр белән... Шагыйрәлеккә дәгъва кылмыйча гына Вафирә Гыйззәтуллинага күңелләрне кузгатырлык, бәгырьләргә үтеп керерлек моң белән сугарылган җыр сүзләре дә бүләк итә.

*Тирән кардан, мин барырмын алдан,*
*Зинһар яннарымда бул гына.*

Җыр халык арасында тарала алмый калды, җырчы белән бергә китте, югалды... Бәлки Кояш апа башка берәү җырлавын теләмәгәндер дә.

Иҗатташ дуслары турында язарга ярата иде ул. Үзенә генә хас булган алым белән, киң итеп, иркен итеп. «Уйланулар» дип атаган ул аларны. Исән вакытта, аралашкан вакытта әйтергә теләп тә әйтелми калган ярату, зурлау хисләре белән язылган алар.

Бәхетле идеме Кояш апа тормышта — әйтүе кыен. Хәтта моны ин якыннары да әйтә алмас кебек. Соңгы ризыгын кеше белән бүлешә алса да, соңгы серен бүлешә алмагандыр ул. Тормышның фасыллары берничә бит: ямьле җәйләре, моңсу көзләре, салкын кышлары... Уй-бәһаләр дә халәткә карап төрлечә булырга мөмкин... Туган елы гына да нинди — 1937 ел.

...Һәрвакыт зәвыкъ белән киенгән Кояш апа соңгы вакытларында милли киемгә күчте. Милләтләрнең уяну чорын көтеп кенә торган диярсең. Ак шәле дә, калфагы да килешә иде аңа. Күпләр арасыннан бердәнбер булып күз алдына шулай килә дә.

*Ул үзе дә анда... әрфиядәй*
*Нәзек кенә шәлен ябынган...*
*Күзләребез сүнсә — сүз эзләгез,*
*Бездән калган сихри янгыннан.*

Дусты, күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов әйткәнчә сорауларыбызга җавапларны шигырь юллары арасыннан эзләргә генә калды...

Бервакытны шулай Кояш апа утыра торган бүлмәгә килеп кергәндә аңа каяндыр күчтәнәчләр белән посылка килгән иде. Матур гына, кечкенә генә савытлы бер көзгене алып миңа бирде дә: «Монысы сиңа, төсем итеп карарсың», — диде. Гаҗәп, менә инде 20 еллап, кояш нурларын чагылдырып ул көзге өстәлемдә тора, ялгыш кына төшереп җибәргәнем дә, югалтканым да юк үзен. Югыйсә әллә-нәрсәләр югалып бетте. Кояш апа килеп керсә үзенең бүләген һаман саклавымны күреп и сөенер иде! Тагын, Илсөяр Иксанованың баш мөхәррир булуына, халкыбызның гореф-гадәтләрен үз эченә алган «Түгәрәк уен» журналы чыгара башлауларына сөенер иде...Сабакташ дусты Фәрваз Миннуллинның кызы Йолдызның уңышларына сөенер иде... Каләмдәш дусты Марсель Галиевнең халык язучысы, озак еллар бер бүлмәдә утырып эшләгән Рәдиф Гаташның халык шагыйре исемен алуына сөенер иде... Үзенең 75 еллыгы уңаеннан мәкалә язып утырганымны күреп тә сөенер иде әле. «Менә, әйттем бит мин», — дияр иде... Кешеләр өчен сөенә белә иде ул. Сөендерик без аларны, рухлары шат булсын...

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

# 2013 елда дини бәйрәмнәр<br>һәм истәлекле көннәр

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1434-1435 ҺИЖРИ ЕЛЛАР

**8 гыйнвар (сишәмбе)** — Сәфәр ае башланган көн.

**24 гыйнвар (пәнҗешәмбе)** — Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**11 май (шимбә)** — мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хаҗы кылына.

**16 май (пәнҗешәмбе)** — Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич — Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**21 май (сишәмбе)** — Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310нчы һижри, 922 нче милади ел).

**5 июнь (чәршәмбе)** — Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**10 июнь (дүшәмбе)** — дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай — Шәгъбан ае башлану көне.

**23 июнь (якшәмбе)** — Бәраәт кичәсе, ягъни "ләйләтул-Бәраәт". Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**9 июль (сишәмбе)** — чират изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә — Кадер кичәсе. 3 август, шимбә)

**8 август ((пәнҗешәмбе)** — Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**14 октябрь (дүшәмбе)** — Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**15 октябрь (сишәмбе)** — Гайдел-Әдхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**16, 17, 18 октябрь (чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)** — Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**4 ноябрь (дүшәмбе)** — 1435 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**13 ноябрь (чәршәмбе)** — Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

*Төзүче-мөхәррир*

**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

# ИПТӘШЛӘР ГАЕП ИТМӘСЛӘР

***Автордан:** Әдәбият һәм сәнгать кешеләре дә, фани дөньяның башка кешеләре кебек үк, тормышта кызыклы яки сәер хәлләргә юлыгып торалар, тапкыр яки «тузга язмаган» сүзләре белән мәзәкләргә керәләр һәм мәзәкләрнең кайберләре матбугат битләренә дә кереп китүчән. Елмайтырлыкларын мин дә күп еллар инде аерым дәфтәргә теркәштерел барам. Нишлисең бит, әле генә әйткәнемчә, һәркайсыбыз фани... Бу мәзәкләрдәге «геройларның» да шактые җәннәткә күчеп өлгергән... Матур эшләре, бай иҗатлары тарихта калган кебек үк, кызыклы гамәлләре дә тарихта калса, укучыларның җылы хатирәләре тагын да баер гына...*

### Авыздан гына чыкмас...

Әллә Актаныш, әллә Минзәлә ягына концерт белән килгән Гали Ильясовны фатир хуҗасы зурлап сыйлый икән. Өстәлгә аш та, ит тә, бәлеш тә килә. Башка нигъмәтләрне дә ташып кына тора хуҗабикә. Әле сәгать чамасы элек кенә үзе дә Ильясов концертын карап кайткан хуҗаның икенче яртыны ачкан вакытта теле чишелеп китә.

— Менә син, Гали энем, җыйнак кына, тәбәнәк кенә гәүдәле кеше үзең. Концертта шаккатып утырдым: кайлардан чыгадыр шушы бәләкәй генә гәүдәдән шул кадәр көчле тавыш дип әйтүем...

Көтелмәгән сүздән югалыбрак калган Гали Ильясов:

— Соң... чыгар җирләре бардыр инде аның... Әй... — дип кенә әйтә алган.

— Бардыр шул, энем, бардыр, — дигән кызмача агай, баш чайкап. — Авыздан гына чыкмас бу хәтле тавыш!..

### Алмаш

Тукай клубында Наис Гамбәрнең юбилеена багышланган тантаналы җыелыш бара икән дә, шунда Батулланың өч-дүрт яшьлек малае әледән-әле кычкырып җибәрә, шаулый икән. Шуңа игътибар итеп утырган-утырган да Марсель Гали,Фәнзаман Батталның колагына пышылдаган:

–Элек Батулла үзе кычкырып утыра иде җыелышларда. Хәзер инде, картайгач, кычкырыр хәле калмагач, малаен алып килгән.

### Агым уңаена

Җәйге эссе көннәрнең берсендә ике Баттал — Салих Баттал, Фәнзаман Баттал һәм Батулла Казан елгасы буендагы комлыкта су кереп, кызынып яталар икән. Шулчакта алар елганың өске ягыннан бер кешенең бата-калка йөзеп килүен күреп алалар.

— Бата бит адәм баласы, ба-та-а! — дип кычкырган элеккеге хәрби очучы Салих Баттал, реактив тизлек белән комлыктан сикереп торып. — Коткарыйк тизрәк, җәмәгать!

Яшьрәк булгангадыр инде, Фәнзаман Батталның күзләре әйбәтрәк күрә икән. Ул дулкыннар арасында чәбәләнгән кешенең язучы Гариф Ахунов икәнлеген танып алган:

— Юкка борчыласың, Салих ага, — дигән Фәнзаман Баттал, олы каләмдәшен тынычландырып. – Берни дә булмас, безнең Гариф абзый агым уңаена бик оста йөзә торган кешеләрдән ул.

## Ансат нәрсә

Күренекле артистка Шәхсәнәм Әсфәндиярованың кияүгә чыккан көннәре икән. Бервакыт болар, ягъни кияү белән кәләш, сәфәргә киткәннәр. Арыгач, тамаклары җилләгәч, урман аланында тукталганнар. Ашап утыралар икән шулай, Шәхсәнәм иркәләнеп-назланып кына иренә:

— Тирә-якта гел йомшак чирәм генә, Хәйдәр. Йомыркамны ваталмыйм, — ди икән.

— Бик ансат ул, былбылым, — дигән хәләл җефет. Шәхсәнәм кулындагы йомырканы алып, шул ук Шәхсәнәмнең маңгаена шык итеп бәреп ваткан да кулына кабат тоттырган. — Тәмләп аша, сандугачым.

## Ачыгырга язмасын!

Ял иткән чакларында күгәрченнәр сыйларга яратучы Фәнзаман Баттал каршында бер ата күгәрчен ана күгәрченне иркәли башлый: томшыгы белән йомшак кына итеп баш түбәсен, муенын кашыштыра, күз тирәләрен назлый... Ана күгәрчен тәмам җебеп беткәч, корсагына чүккәч, Баттал читкәрәк көнбагыш сибә. Шулчак «батырлык» кылырга тәмам әзерләнеп беткән ата күгәрчен көнбагыш сибелгән якка томырыла да комсызлык белән чүпли башлый.

— И Ходаем, шушы кадәр үк ачыгырга язмасын! — дип куя бу хәлдән гыйбрәт алган Баттал.

## Әйтәм җирле...

Фәнзаман Батталның эш бүлмәсенә мәшһүр җырчы Апуш — Габдулла Рәхимкулов хәл белергә кергән.

— Хәлләр хөртирәк әле, Габдулла абый, — дигән Баттал. — Теш сызлый, алдыртасы бар...

— Ай-һай-һай, авыр ул, малай, теш алдыртулары! — дип ыңгырашып куйган җырчы. — Гастрольләр вакытында акыл тешем сызлый башлады бервакыт. Мал суючы сыман кансыз теш врачына туры килгәнмен бит, әй. Тешемне, вата-сындыра ике сәгать каезлады, мөртәт, җәфалап бетерде — үләм дип торам...

— Бәй, — дип аптыраган Баттал. — Җырчыларда да акыл теше буламыни?!

— Бүтән җырчылардан андый сүзне ишеткән юк-югын. Ләкин миндә бар иде ул, малай.

— Әйтәм җирле, сиңа халык җырчысы дигән исемне бирми килделәр*, акылың комачаулаган икән бит, Апуш туган. Хәзер инде бирми калмаслар, — дип нәтиҗә ясаган шешкән яңагын сыйпап утыручы Баттал.

Искәрмә: Фәнзаман шушы мәзәкне матбугатта бастырып чыгаргач, ай да үтмәгән, Габдулла абыйга «Татарстанның халык артисты» дигән исем биргәннәр.

## Әрәм булып йөргән

Мәшһүр Батулла үзе белән Мәскәүдә укыган,соңыннан урыс шовинистына әйләнгән сабакташына каршы урыс телендә бик усал мәкалә язган да, аны брошюра итеп чыгарган. Марсель Гали шуны укып чыккач, һушы китәрдәй булып сокланган:

—Батулланның чын таланты урыс телендә ачыла икән бит! Татарча язып,әрәм булып кына йөргән бу!..

## Бабасын ашамаган

Татарстан радиосының буфетына корбан балыклары кайткан. Чиратка Рафис Корбан белән Фәнзаман Баттал да баскан. Тора-торгач, Баттал сизә, әгәр алдындагы Корбан балык алса, үзе буш кул белән калачак. Шулчак ул чираты җиткән Корбанга:

— Оят дигән нәрсә юк та инде синдә, ә, Рафис? — дип, аркасына төрткән.

Тегесе чәпчергә керешкән:

— Нәрсә, нәрсә? Кем оятсыз?

— Син оятсыз, — дигән Баттал. — Син бит бабаң башын да ашарга әзер кеше.

— Ничек инде, ничек?.. — дип кызган Корбан.

— Менә син Корбан башың белән корбан балыгы ашамакчы буласың. Әгәр шушында «баттал»дигән балык сатсалар, мин якын килергә дә оялыр идем бу чиратка.

Рафис Корбан гомерендә беренче мәртәбә кеше сүзенә колак салган, имеш — чираттан чыгып шылган. Баттал бер үзенә өч корбан ашаган ди ул көнне.

## «Батырлык»

Фәнзаман Баттал үзе яши торган йортка якынлашып барганда, гомер буе көче, мускуллары белән мактанып яшәүче якташы очраган.

— Исәнме, Фәнзаман, хәлләрең шәпме? Көч-куәт якларың ничек, мускулларың ныкмы? — ди икән теге, сабантуе батырыдай күкрәк киереп.

Беркайчан да бил алышмаган, сугышу түгел, йодрык та төйнәмәгән Фәнзаман, кем белән сөйләшүен исендә тотып:

— Көч-куәтнең чиге юк икән миндә, парин. Әле, ачуны бик китергәч, үзебезнең йорттагы унлап ирне берьюлы кыйнап ташладым, — дигән.

Якташы ышанмаган.

— Ышанмасаң, әйдә, йортның подъездлы ягына чыгабыз. Алар мине күрүгә үк куркып качалар хәзер...

Йортның алдына чыгу белән, Фәнзаман тамак кырган һәм кычкырыбрак сөйләшә башлаган. Подъезд төбендәге эскәмияләрдә тезелеп утыручы әзмәвердәй ирләр, ялт-йолт карашып алганнар да, кайсылары — өйгә, кайберләре йә урамга, йә куак арасына тайганнар. Ә бер пәһлеван гәүдәлесе, Фәнзаман каршына баскан да, кулын күкрәгенә куеп, ялварыпмы-ялвара икән:

— Гафу ит, брат, гаеп миндә!.. Валлаһи дип әйтәм, озакка сузмам, түләлермен. Берүк, кичерә күр. Үзем дә оялып йөрим...

Еламый гына, ди, күршесе. Ә Фәнзаман эре генә карап торган да:

— Бу юлга гафу итәм. Ләкин кара аны!.. — дип бармак янаган.

Кодрәтле якташы гаҗәпләнүдән телсез калган. Ә ирләрнең качышу сәбәпләре бөтенләй бүтән: Фәнзаманнан кайсы — бер, кайберләре икешәр-өчәр яртылык бурычка алганнар да, Фәнзаман күзгә күренү белән төрлесе төрле якка сибелеп бетәләр икән.

**Фәнзаман БАТТАЛ**

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2013 ел өчен вакытлы матбугатка язылу тәгәлләнергә санаулы көннәр калды. «Казан утлары»нын индексы физик затлар өчен – **73210**; ярты елга язылу бәясе **272 сум 94 тиен**, юридик затлар өчен – **16262**, ярты елга язылу бәясе **309 сум 30 тиен**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

90 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы «Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Федеральное государственное унитарное предприятие " ПОЧТА РОССИИ" Ф. СП-1

Бланк заказа периодических изданий

Ф.СП-1

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*«Казан утлары»* (наименование издания)

количество комплектов

На 2013 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому

Линия отреза

ПВ | место | литер

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА — 73210 (индекс издания)

На ~~газету~~ журнал *«Казан утлары»* (наименование издания)

| Стои-мость | подписки | руб. коп. | Кол-во комп-лектов |
|---|---|---|---|
| | каталожная | руб. коп. | |
| | переадресовки | руб. коп. | |

На 2013 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

почтовый индекс — город / село / область

район

код улицы — улица

дом | корпус | квартира

фамилия и. о.

## Батулла

# БАТУЛЛА МЕЛЛА ХИКӘЯТЛӘРЕ

### Комган

Шантыйны партиядән чыгардылар. Каян белгән парторг Кутыр Гафи, каян белгән райком секретаре Кырчын Далашев Шантыйның сөннәткә утырганын. Шантыйның әбисе оныгының теңкәсенә тиеп бетте: адәм көлкесе, әстәгъфирулла, шушы яшькә житеп, һаман сөннәтсез йөрисең, сиңа тавык суярга да ярамый. Мин үлгәнче сөннәткә утырмасаң, бәхил түгел, диде.

— Әби, мин партийный бит, миңа ярамый! — дип караса да, әби каты торды: — Бу атнаны сөннәтчегә барасың!

Якын-тирәдә генә сөннәтчесе дә юк бит әле аның. Шантый мал духтыры, аръякның исерек Турак янына китте. Исерек Турак ара-тирә сөннәтче вазифаларын да башкара иде. Шантыйдан бер литр аракы, бер түтәрәм каз алгач, егерме биш яшьлек Шантыйны яткызып, Турак сөннәт ясады.

Шәп булды. Бот арасы чәнчешсә дә, Шантый ашыгып, өенә кайтып:

— Әби, мин сөннәтле, мин тавыкларны үзем суячакмын! — дип сөрән салды.

Өйдә бәйрәм булды. Сөннәтне шәпләп юдылар.

Икенче көнне үк парторг Кутыр Гафине, Шантыйны райкомга чакырттылар да келәм башына бастырдылар. Сорау алу башланды. Ике потлы гер чаклы йодрыгы белән секретарь Кырчын Далашев ялтыравыклы өстәл почмагына сукты, почмак кителеп төште.

— Скандал! — дип кычкырды Кырчын. — Коммунистлар партиясе члены сөннәткә утырсын, имеш! Хакмы бу эш?

Шантый ыкы-мыкы килә башлады.

— Хак! — диде парторг Кутыр. — Турларыннан узганда үзем ишеттем: мин сөннәтле, тавыкларны үзем суям, диде.

Кутыр сүзенә генә ышанмыйча, секретарь әйтте:

— Ышанычлы булсын, күрсәт! — диде.

Бичара Шантый бюро членнары алдында чалбарын төшерергә мәҗбүр иде.

— Сөннәтле кешегә КПССта урын юк! — дип Шантыйны партиядән чыгарып аттылар.

Фажига иде бу Шантый өчен. Бетте карьера. Бетте тормыш. Партиядән чыгарылу ул партиясез булуга караганда да куркынычрак иде. Партиядән чыгарылганнарга караш төрмәдән чыккан кешегә караганда да тискәре иде. Әллә урманга менеп, агачка асылыныйммы, дигәндә аңа дусты Сырлан очрады.

— Бик бетерешмә әле син, ахир! — диде Сырлан. — Баш ватылып, күз чыкмаган, син сөннәтеңне кире кайтар, кире кайтарсаң, партиягә кире алачаклар.

— Тик сөннәтне ничек кайтарырга соң? — диде аптыраган Шантый.

Сырлан тагын әйтте:

— Турак синен кисеп ташлаган өлешен тегеп куйсын! Бетте-китте.

Шантый исерек Турак янына китте.

— Каян табыйм инде мин синең ул нәстәңне? — диде Турак. — Мин аны тиреслеккә чыгарып аткан идем, карга-козгын алып китмәгән булса...

Айнымас Турак чүплектә казына башлады, ләкин Шантыйның сөннәт тиресен табалмады. Шулай да ул кичә генә үлгән әтәч мәетен күреп шатланып куйды.

— Ярамаган тагын, шушы әтәч кикриген тегеп куярмын! — дип пәкесе белән әтәч кикриген кисеп, өйгә алып керде.

— Ят! — дип кычкырды хужа.

Шантый ятты. Операция уңышлы узды. Тагын бер литр аракы, тагын бер түтәрәм каз Турак өендә калды.

Икенче көнне Шантыйны дусты Сырлан райкомга алып китте. Шантыйның гаризасын алып, шаһитләрне чакырып, янә бюро утырышы булды. Гаделлек жиңде. Шантыйның чалбарын тагын төшертеп, сөннәтенең кире кайтканлыгын күреп, партиягә янадан алдылар.

Эшләр худта. Шантыйның әтәче иртә-кич гел кычкыра торганга әйләнде. Хатын-кызлар да Шантыйга ныграк тартыла башлады кебек. Ләкин парторг Кутыр Шантыйны тагын парткомга чакыртты. Бу юлы Шантыйның персональ эше каралачагын әйтте. Тагын партбюро жыйдылар, сүзне парторг Кутыр башлады:

— Жә, иптәшләр, жыелышып беттек, башлыйк.

Президиум әгъзалары үзара пышылдашып алды.

— Димәк, башлыйбыз! — диде парторг. — Бүгенге көн тәртибендә коммунист Шантый Жумбавызның шәхси эше карала. Сөйлә, Колатун!

Колатун Куштан кирәкмәсә дә тамак кырыштыргалап, язганнарын укый башлады.

— Менә, ни... иптәшләр, нәрсә дип әйтием, иеме, кых... иптәшләр аны ни... яшереп торасы юк иеме... кых... — Колатун графиннан стаканга су агызып, йотып куйды. — Көпә-көндез булган хәлләр инде, иптәшләр, һич кенә дә гафу ителә торган эш түгел, иптәшләр, бу безнең коммунистик әхлакка туры килми, ие... ни... Бу — Шантый Жумбавызның иң зур жинаяте, котчыккыч әхлаксызлыгы, әгәр дә ул һаман да шулай жәзасыз калса, башкалар да аннан күреп, аныңча эшли башласалар, кая китә ул, иптәшләр, ие... Мона кадәр дә Шантый жинаять өстендә тотылып, бер котылган иде. Мин, иптәшләр, жинаятьчене бу юлы каттый жәзага тартырга, күргәзмә хөкем итәргә тәкъдим ясыйм, башкаларга да сабак булсын.

Парторг Кутырның көр тавышы яңгырады:

— Колатун, турысын әйтеп сөлә! — диде Кутыр. — Шартлатып әйт, башка иптәшләр дә аңлап калсын!

Колатун Куштан тагын тамак кырды:

— Кыхым, әйтәм, иптәшләр, әйтәм, шартлатып әйтәм бу жүнсезнең жинаятен. Без бөтен көчебезне, вакытыбызны кызганмыйча, фидакарьләрчә батырлык белән халык зиһенен томалап торучы агу булган дингә каршы көрәшәбез, гореф-гадәтләрне, хорафатларны, төрле ырымнарны төбе-тамыры белән йолкып алу өчен күпме еллар мәшгульбез, иптәшләр, ә арабызда бар шундый элементлар, ул элементлар безнең изге эшебезгә аяк чалалар, иптәшләр: менә бу кабахәт Шантый Жумбавыз — шул корткыч элементларның берсе. Мин аның белән күрше булып өч ай ярым тордым, иеме... кыхым... шул өч ай ярым дәверендә мин аның һәр адымын күзәтеп, язып, фотога төшерә бардым... Ул... ул... әйтергә генә оят... юк, телем әйләнми, иптәшләр...

Колатун Куштан сүзен өзде. Парторг аягүрә басты:

— Әйт, Колатун, гадел хөкем өчен дөреслекне әйт. Әйтергә оят булса да әйт!

Колатун тирән сулыш алып әйтте:

— Шантый Жумбавыз, иптәшләр, бәдрәфкә, әбрәкәйгә чыккан саен тәһарәт ала: хатыны да, между прочим! Хатыны да комгансыз тышка чыкмый анын. Хатынын да, иптәшләр, Жумбавыз, хәтта балаларын да шуңа өйрәтә, иптәшләр, ие... Бу кадәр наданлык, бу кадәр артта калганлык белән килешеп булмый, иптәшләр... ие... Оятсыз ул Шантый. Комганын яшереп тә алып чыкмый, ичмасам. Анын хатыныннан күреп, минеп хатын да комган сатып алып кайткан, ие, кыхым... Жумбавыз кеше күрсен дип, өйрәнсеннәр дип, комганын юри болгый-болгый ишегалдында йөри.

Залда тынлык урнашты. Шантыйның ияге күкрәгенә тигән, халык Шантый өчен куркып утыра иде.

— Дөресме шул, Шантый? − диде парторг. − Танма! Тансаң, гаебең зурая гына.

Тынлык.

— Менә дәлилләр! — дип Колатун өстәлгә өч комган чыгарып бастырды. Бик матур нәфис җиз комганнар иде алар. — Менә аның комганнары... Менә сурәтләре... ие...

Колатун сурәтләрне берәм-берәм карарга тотынды, һәр фото саен күзен акайтып: «о-о... и-и... у-у...» авазлары чыгарып озак кына караганнан соң, сурәтләрне бюро әгъзаларына тапшырды, тегеләре өелешеп фотолар өстенә ябырылды. Кемдер хихылдады, кемдер аһылдады.

— Бу комганнар синекеме? − дип кычкырды парторг.

— Менә экспертиза! − диде Колатун: — Комганнарда Шантый белән хатынының бармак эзләре.

— Дөресме шул? − дип кабатлады парторг.

Шантый телгә килде:

— Дөрес, иптәшләр, мин танмыйм, минем комганнар.

— Менә, күрдегезме, иптәшләр, − диде паторг. — Үзе дә танмый. Шаһитләр, дәлилләр белән китереп кыскач, «дөрес» дими кая барасың!

Парторг бюро әгъзаларына иелде, әгъзалар һаман аһылдый-хихылдый сурәтләр карый иде.

— Сездә җинаятьчегә карата сораулар бармы? − диде. Сурәтләрдән аерылмыйча гына барысы да «юк», «юк» дигәнне аңлатып кул изәделәр. — Димәк, Шантый Жумбавызның җинаяте тулысы белән расланды. Бу җинаятьчегә, бу корткычка безнең арада урын юк.

Бюро әгъзалары пышылдашып алдылар, алар хөкем карары белән риза иде. Парторг тантаналы тавыш белән:

— Шулай итеп, иптәшләр, — диде. — Шантый Жумбавызны, кылган җинаяте өчен һәм шундый ярамаган эшкә хатынын, балигъ булмаган балаларын котыртканы өчен ике статья нигезендә каты җәзага тартырга. Аны партиядән чыгарып, комганнарын конфисковать итеп, тәһарәт алырга мөмкинлеге булмаган җиргә, строгий режимлы төрмәгә утыртырга!!!

## Касторка

1935 ел иде бу.

Гөндәрле авылының Мескен Сәхи исемле бәндәсе үзенең сөяр-сөймәс хатыны Гаптия белән этле-мырлы яшәп ята иде. Мескен Сәхинең каралты-курасы юк, өялдысыз салам түбәле мунча кадәр бер йорт. Мал-туары юк, хәерче нәсел. Анын кушаматы да «Мескен» иде. Мескен хәерче булса да,

эчәргә жаен таба үзе тагы. Гаптия ике көннен берендә самавыр янында гел бертөрле тавыш белән иренен канына тоз сала.

— Өйгә игътибарың юк... Йортка кот кунмый... Мунча салам диден, салмадын... Күршеләр яккан мунчага йөрүе оят инде, билләһи... Ичмасам, кара булса да бер мунча салып бир...

Мескен Сәхи аек булса, дәшмичә генә хатынынын колагын бораулаганын тынлап утыра-утыра да, йокларга ята яки каравыл өенә чыгып китә.

Мескен Сәхинен күршесе Шәрхемулла Мораты сөекле хатыны Сәлжия, өч баласы белән тату гына, матур гына яши иде. Морат Сәхидән дә фәкыйрь иде. Алар сыер, сарык асрар дәрәжәдә түгел, әмма Моратнын хатыны Сәлжия бер кәжә алырга күптән хыяллана иде, ләкин заемнар түли-түли акча арттыра алмый йөдиләр иде.

Гөндәрле авылынын мәчет манарасын шул елда кистеләр. Манара кисү модага кереп киткәч, авыл советы рәисе Хөрдун башкалардан алдарак өлгерергә тырышып, Гөндәрле манарасын кисәргә Мескен Сәхи белән Шәрхи Моратын яллады. Хөрдун манара аударучыларга 300 сум вәгъдә иткән.

Мескен Сәхи манараны кисәргә шатланып риза булды. Өенә кайткач ул хатынына кычкырды:

— Карчык! Булыр сина кара мунча! — диде. — Йөз илле сумга ак мунча да салырга була.

Сәлжия исә иренең манара кисәргә ризалык биргәнен ишетеп, өйдә кара буран куптарды:

— Башын икемени синен? Алла йортына кагылырга син кяфер түгел! Ике аягыннын берсен дә атламыйсын! — дип кычкырды.

— Ә кәжәне нинди акчага алабыз? Үзен бит «кәжә алыйк» дип колак итемне ашадын! — диде Морат хатынын шушы сылтау белән жинүенә нык ышанган хәлдә.

Ләкин Сәлжия каты торды:

— Ник чукынып китми кәжәсе! Тефү, әстәгъфирулла! Сөт эчмәбез, ләкин халык алдында йөзебез ак булыр.

Морат нишләргә белми, аптырап калды, ничек итеп Хөрдунга жавап бирерсен? Бу юлы да Сәлжия ана ярдәмгә килде:

— Эчем китә диген! Вәссәлам! Барма мәчет кырына!

Шулай булды да, икенче көнне иртүк Хөрдун Моратлар капкасына кагылды.

— Морат! — дип кычкырды рәис. — Сәхиулла инде күптән мәчет янында балта тотып басып тора, син нишләп ятасын, пычкынны алып, чаптыр, тиз бул! Марш мәчеткә.

Сәлжия иренә пышылдап:

— Бар, тиз бул әбрәкәйгә йөгер, шуннан чыкма! — диде.

Сәлжия мич авызындагы комганны алып, иренә тоттырды:

— Пычтырда шунда! Ынгырашкан бул!

Морат комган тотып, өйдән атылып чыкты да әбрәкәйгә кереп бикләнде. Ул арада Сәлжия капканы ачып, Хөрдунны ишегалдына кертте.

— Кайда ул ниччастный Морат? — дип кычкырды рәис.

— Эче китә! Әнә, әбрәкәйдә! — диде Сәлжия.

Хөрдун әбрәкәйгә якын килеп:

— Ни булды? — дип сорады.

Эчтә комганнан пычтырдап агызылган су тавышы ишетелде, Морат ынгырашып куйды.

— Э-э, үлә-әм...

— Ни эчтен, ни ашадын ул кадәр эч китәрлек итеп? — диде рәис.

Сәлҗия иреннән алда өлгерде:

— Кызыл аракы дип кастурке эчкән, нәләт!

— Син кызыл аракыны бушатып, юри кастурке салгансың! — дип ыңгырашты Морат.

Хөрдун:

— Авызкайларыгызны... — дип мыгырдана-сүгенә чыгып китте.

Манара кисүгә каршы торырлар дип Хөрдун районнан милиция чакырткан иде. Милиционерлар дүртесе дүрт башка басып, халыкны мәчеткә якын җибәрмәделәр. Мескен Сәхи мәчет түбәсенә менеп, кадак суыргычы белән калайларын куптара башлады. Халык Сәхигә каргыш атты.

— Мәлгунь! Имансыз! Тәмуг кисәве! Кулың чересен! — дип туктаусыз кычкырып тордылар.

Манараны Мескен Сәхи берүзе аударып, 300 сумны чикмән чабуын киң итеп ачып, чалбар кесәсенә урнаштырды да күрше урыс авылына китте. Сәхи өч йөз сумның тиенен дә өенә алып кайтмыйча, урыста биш көн эчеп ятты. Алтынчы көнгә киткәч, аны хатыны, балалары өстерәп алып кайтып, лапаска яткырдылар.

Ак мунча да, кара мунча да аракы парлары булып махмырга әверелгән иде. Ике тәүлек аунап ятканнан соң, бераз айнып, Сәхи аягына басты. Бригадир Зөләй аңа эшкә әйтте:

— Сәхи, җитте, күп ял иттең, эшкә чык! Малатилкага көлтә биреп торырга кеше юк! — диде.

Мескен Сәхи айнып-айнымас эригегә төшеп китте. Трактор гөрләп эшләп тора, молотилкага каеш кигезелгән. Тракторчы Расих белән бригадир Зөләй Мескен Сәхине көтә. Сәхи молотилка барабаны янына килеп, җиңнәрен сызганды да, тракторчыга кул изәде, молотика уылдап эшли башлады. Сәхи хатыннар кулыннан билбавы киселгән көлтәләрне алып, молотилкага каптыра, молотилка көлтәләрне умырып алып кереп китә, ике йөк көлтәне суктырып бетерәм дигәндә генә, әллә нәрсә булды: Сәхинең әллә башы әйләнеп китте, әллә аягы тайды, әллә җиңе чишелеп, тешләр арасына чолганды, аның уң кулы көлтә белән бергә молотилка барабанына кереп китте. Сәхинең акырган тавышы ишетелде, молотилка аның кулын иңбашына хәтле капкан да тунапмы туный, халык аһ итте, трактор сүнде. Салам өемен, ашлык көшелен чәрдәкләнгән сөяк, кан каплаган иде. Мескен Сәхи уң кулсыз калды. Аны хастаханәгә тиз алып киттеләр, байтак ятканнан соң чыгардылар. Ләкин тора-бара аның иңбаш сөяге чери башлады, табиблар да, им-том да аны коткара алмады. Авыртуына чыдый алмыйча, шулай акыра-акыра Мескен Сәхи бу дөнья белән бәхилләште.

Халык гөж итте:

— Манара кискәнгә аны Алла сукты! Мескен Сәхигә авыл халкының каргышы төште! — диделәр.

Шәрхи Мораты сау-сәламәт калды. Бер ел да узмагандыр, Морат заемга акча отты, шактый зур сумма иде ул, бераз бурычка кереп, откан акчага кушып, Морат сыер сатып алды. Кәҗә саварга хыялланган Сәлҗия рәхәтләнеп сыер сава башлады.

Хатыны Сәлҗия аркасында Морат «кызыл аракы урынына касторка эчкәненә» куанып бетә алмый иде.

## Нармальны

Йөрисен йөрде, күрәсен күрде, татыйсын татыды инде Кучкар исемле егет. Ул төпләнергә, акыл утыртырга уйлады. Аның күптән таныш бер кызы бар. Филисә исемле. Филисә дә аңа ягымлы карый иде. Сүз каткан булса, Филисә, һичшиксез, аңа кияүгә чыккан була иде. Кучкар аңа егерме бер

яшендә өйләнә иде дә, аның койрыгы гаиләгә катып кала иде. Кызны ошатса да Кучкар ана сүз катмады. Әле кочмаган күпме гүзәлләр аны көтә. Шуңа күрә, ул Филисә өметләнерлек гамәл кылмады. Кучкарның хатыннарны «урып барганын» Филисә күрә, белә иде. Шулай да, Кучкарның бер шактый мактарлык гадәте бар иде: ул йөри торган кызларының берсенә дә «мин сиңа өйләнәм», димәде. Аерылышканда да күңелләрдә юшкын калдырырлык итеп, тупас аерылышмады, дусларча аерылыша иде. Ташлашкан кызлар аңа нәфрәтле, үчлекле булмады, хәтта алар Кучкарга рәхмәтле дә иде. Ошата икән йөрсен, ләкин өйләнер, дип өметләнмәсен.

Ни гаҗәп, Филисә дә кияүгә чыкмады, юкса ул гүзәл, мөлаем кыз.

Кучкар Филисә белән йөри башлады һәм алар озакламый өйләнештеләр. Зәфаф кичендә Кучкар хәйран калды: аның кәләше Филисә гыйффәтле кыз булып чыкты. Кучкар аның кыз булуын шарт итеп куймаган иде дә. Утыздан узган гүзәл бөтен була ала микәнни? Никах укытылды, туйлары матур узды, кияү мунчасы да шәп булды, кияү коймагы да тәмле иде. Тормыш итәр өчен Кучкарның бөтен җире житеш иде. Фатиры, машинасы дигәндәй, Филисә дә йорт яме иде. Филисә Кучкарны чынлап сөя иде. Кучкар башкалардан күпме наз күргән булса да Филисәдәй ягымлы хатынны очратканы булмады.

Ләкин Кучкар Филисәнең гыйффәтле килеш сакланганына аптырый иде. Аның башына бәйләнчек бер уй кереп урнашты. Ни өчен шундый чибәр, ягымлы кызга башка егетләрнең күзе төшмәгән, ни өчен аны кочмаганнар, ни өчен... Бик аптыраткач, Филисә көлемсерәп әйтте:

— Сине көттем! Йөрерсең-йөрерсең дә, барыбер минем янга килерсең дидем.

Матур әйтте. Җавап Кучкарга ошады. Ләкин теге уй һаман кыймылдый: нигә минем хатын гына кыз килеш калырга тиеш?

Кучкар ешрак салгалый башлады. Салган саен ул хатынына бәйләнә:

— Ничек алай булды соң әле бу? Нүжәли син беркем белән дә...

— Тигәнәк! — диде Филисә. — Миңа синнән башка кеше кирәк түгел иде.

Кучкар усал көлде:

— Һа-а, мин Алланың кашка тәкәсе түгел! Башка ирләрдән бер дә артык җирем юк, синең арттан йөргәннәрдән дим... Димәк, синең нинди дә булса сереңбар... Бәлки, син ирләр белән йоклап та бөтен булып кала белә торгансыңдыр, ә?

Моңа кадәр хатын иренең бәйләнүләренә көлеп кенә карый иде, соңгы җөмлә аның күңелен чеметеп узды. Ул әйтергә сүз табалмады.

— Саташкан! — гына диде дә тынып калды.

— Башкалар бит миннән матуррак иде... Ни өчен син мин йөреп туйганны көтеп, миңа кияүгә чыктың?

Филисә сүзсез генә:

— Уф-ф! — дип куйды.

— Ю-ук, син әйт: ни өчен син башка ирләр белән йокламадың, ә?

Хатын сөйләшүне әле һаман шаяруга борырга тырыша иде, бу юлы шактый җитди итеп:

— Сайладым-сайладым да, картая башлагач, кияүсез утырып калмыйм дип сиңа чыктым. Шушы ир уртасы кешегә кияүгә чыгыйм да, яшьрәк егетләр белән типтерим дип чыктым. Миңа әле күз атучылар да-ху-ху...

Үңәченә кылчык калалгандай, Кучкар төртелеп калды, тамак кырды, кирәге булмаса да ютәлләп алды да әйтте:

— Ә-ә, алай булса эш башка! Мин әллә берәр сереңбармы, дип торам. Бу — нармальны! — диде дә Кучкар тынычлап йокыга китте.

## Таккүз

Без, Казан каласыннан Урал якларына сәяхәткә чыккан өч кеше, Белорет каласындагы бер типтәр йортына фатирга төштек. Максатыбыз бу яклардагы риваятьләр, әкиятләр, мажаралы хикәяләр жыйнау иде. Бер уңайдан Урал тауларын да күреп китәргә иде исәп.

— Ямантауга якын бармагыз! — диде хужабикә. — Анда Таккүз яши.

Имеш, Ямантау мәгарәләренең берсендә Таккүз исемле дию яши икән. Таккүз кайчандыр ике күзле, җөп күзле булган, ләкин Урал батыр орышта аның бер күзен чыгарган да, дию бер күзле, так күз булып калган. Сыңаркүз иң олы мәгарәне үзенә сайлап, шунда яши, мәгарәсенә якын килгән кешеләрне кунакка дәшә. Кунаклар мәгарәгә кергәч, дию тау куышын таш белән бастырып куя. Аннан беркем дә чыга алмый. Таккүз гаять зиһенле дию икән, тоткындагы кешеләрне ул яхшы ашата, эчертә, алар белән зыялы әңгәмәләр кора, кешеләр симергәч, ул аларны тотып ашый, ди. Таккүз үзенә катлаулы табышмаклар, мәсьәләләр биргәнне бик тә хуплый. Һәм нинди генә катлаулы сораулар булса да ул аларны бик тиз чишә, әгәр дә куелган сораугa өч тәүлек эчендә җавап табалмаса, аның көче бетә. Тау куышы үзеннән-үзе ачылып китә, кешеләр ирекккә чыга, ди. Ләкин моңа чаклы тау куышыннан чыккан кеше булмаган, ди.

Безнең экспедиция составында өч кеше, дидем. Мин, фәкыйрегез, өйләнә алмыйча йөрүче карт буйдак, өлкән фәнни хезмәткәр Сайраш, гыйльми дәрәҗәсе булмаган, сазаган карт кыз Залидә.

Дәрәҗәләр буенча Сайраш белән без аннан югарырак булсак та, белем ягыннан Залидә бездән күпкә өстен кебек сизәм. Ул тыныч холыклы, кияүсез калганына иялә нгән, кияүгә чыккан кызлардан ул көнләшми дә кебек. Матур гаилә корганнарга карап ул сөенә. Ләкин сизенәм мин, аның яшертен хыялы бар: гаилә кору, балалар үстерү. Ир-егетләр аңа игътибар итми. Әллә бар ул, әллә юк. Фән темасында гына ирләр аның белән сөйләшә. Сайраш, гомумән, аны хатын-кызга да санамый.

Киттек Урал тауларын карарга. Сайраш та, Залидә дә, мин дә: әйдәгез, Ямантауны барып күрик, димәдек. Сүз куешкандай, без Ямантау тарафына юл алдык.

Ямантау дингез өстеннән 1600 метр биеклектә булып, анда менеп җитәр өчен шактый көч сарыф итәргә кирәк булды. Ярый әле, без сәяхәткә ныклап әзерләнгән идек, тау араларында йөрерлек аяк киеме, чатырлар, учак тергезер өчен әсбаплар, ашау-эчү җаен да караган идек. Компасыбыз да бар иде. Ләкин без адаштык. Йөреп арыгач, чатыр корып йокларга яттык. Иртән торып тагын йөреп киттек. Күпме генә йөрсәк тә без Ямантау башына барып чыга алмыйча гаҗиз булдык. Тагын ялга туктадык. Дусларым пошаманга төште, сиздермәскә тырышалар. Шулай йөри торгач, алган ризыкларыбыз да бетте, без ачыга-кибегә башладык. Ике тәүлек ризыксыз, сусыз йөреп, хәлдән тайдык. Безнең уен фаҗигага охшап калды. Сайраш каушаган, шомлана, дәшми, минем дә эчтә курку, Залидә генә тыныч күренә, ул безне юата. Сәяхәтләрдә тәҗрибә туплаган булсак та, без таулар арасында ничек ризык табарга икәнен белми идек. Кайтыр юлны тапмасак, без ачтан үләчәкбез, дигән шом сызылып узды.

Чатыр корырга хәл юк иде, без өчебез өч җиргә биштәрләребезне ташлап ял итәбез.

Шулчак тау куаклары артыннан бер егет килеп чыкты. Өчебез бердән кычкырдык:

— Котылдык! — дидек.

Егетнең бер күзе кара чүпрәк белән бәйләүле иде.

— Югарырак менгәнсез шул! — диде егет.

Ул янга аскан букчасыннан шешәле су чыгарып, Залидәгә сузды. Залидә ике йотты да шешәне миңа бирде, мин дә бер-ике йотканнан соң Сайрашка бирдем.

— Әйдәгез! — диде сәер егет. — Минем куышыма. Анда ризык та бар, жылыда ял итәрсез.

Ул куаклар арасына ташланган ике куян, бер көртлекне алып, алдан китте.

Бераз баргач, без тау куышына килеп життек. Тау куышы алагаем зур түгәрәк таш белән бастырып куелган иде. Без биштәрләребез белән маташкан арада егет нидер кылды, таш капкач күчте, без тау куышына кердек. Без керүгә үк егет тагын нидер кылды, әлеге таш мәгарә авызын каплап куйды. Мәгарәдә якты иде. Монда жәнлек тиреләре белән капланган таш сәкеләр, диварларга кеше сөлдәләре эленгән, уртада учак, казан, алда тагын бер куыш. Егет шул куышка кереп китте дә тиз генә әйләнеп тә чыкты, теге егет урынында сынар күзле алагаем зур гәүдәле дию иде. Безнең гажәпләнгәнне күреп, дию көлде:

— Курыкмагыз, бу мин — Таккүз! — диде. — Ашагыз, эчегез, сез моннан чыга алмаячаксыз. Бары тик мин сез куйган табышмакларга жавап бирә алмасам гына сезгә юл ачылыр. Ләкин әле моннан чыга алган кеше булмады. — Ул кеше сөякләренә ишарә итте. — Әнә, табышмак белмәгәннәрнең сөлдәләре! — диде.

Без телсез калдык.

Сайраш капчыгын ташлап, үкерә башлады:

— Нәжес! Жирәнгеч хайван! Чыгар безне моннан!

Минем дә хәл мөшкел иде, ләкин мин куркуымны күрсәтмәскә тырыштым. Дию ул арада куяннарны тунап, көртлекне пешекләп, казан асты. Учак көлендәге утлы күмер тиз көйрәде, Таккүз учакка утын ташлады да янә үз куышына кереп китте, ул аннан чүлмәк алып чыкты:

— Монысы ширбәт! — диде Таккүз, һәм Залидәгә чүмеч сузды: — Бал кушып ясалган эчемлек. Татып багыгыз!

Сайраш һаман чәбәләнә, Залидә берни булмагандай чүлмәктән ширбәт чумырып алды да эчә башлады.

— Татлы ширбәт! — диде кыз.

Мин дә эчтем, чыннан да эчемлек гаять ләззәтле иде. Анынчы куяннар белән көртлек ите дә өлгерде, без бер гаилә кебек, учак тирәли табын ясап утырдык, Сайраш та канәгатьсез мыгырдап, безгә кушылды.

— Күрәм, сез фән белән шөгыльләнәсез! — диде хужа. — Минем гел бертөрле яшәешемә сез якты нур алып килдегез. Безнең кичәләр гаять кызык узар дип уйлыйм. Сезнең кайсыгыз алдан симерсә, мин шуны ашармын. Анынчы сез миңа табышмаклар, сораулар бирерсез.

Эчтән генә уйлап куйдым, беренче булып Сайраш симерәчәк, чөнки ул инде болай да симез.

Әйе, Таккүз атлы дию мәгарәсендә безнең гел бертөрле тормышыбыз башланды. Сайраш та бар булган табышмакларын әйтеп бетерде, мин дә четерекле сораулар бирдем, Таккүз аларны бик тиз чишеп, сорауларга тиз жавап биреп, безне хәйран калдырды. Чират Залидәгә житте.

— Тыңлагыз! — диде Залидә көннәрдән бер көнне. — Бер падишаһның өч кызы булган. Икесе бик тә уңган, тиктормас, өченчесе үшән, ялкау, йокы чүлмәге булган ди. Бу пошмасына кияү табылмас, уңганнарына кияү тиз табылыр әле дип падиша иң башта төпчек кызын башлы-күзе итәргә хәйлә корган. Падиша халыкны, булачак кияүләрне мәйданга жыйган. Өч бертөрле казан астырган, казаннарга бер үк микъдарда су салынган, һәр казан янына берәр кызын куйган да игълан иткән: барысына да бертигез

шарт, бертигез ризыклар, бертигез утын, кайсы кызымның казаны алдан кайнап, ашы өлгерә, шул кызымны беренче булып кияүгә бирәм, дигән. Иң башта ялкау кызның казаны кайнаган. Һәм ул шаһзадәгә кияүгә чыккан. Ни өчен аның казаны алдан кайнаган?

Таккүз аптыраашта иде.

— Кызык! — диде мәгарә хуҗасы. — Кызык! Мина уйларга вакыт кирәк.

Дию куышына кереп, юк булды. Бер көн узды, икенче көн узып бара. Тоткынлыктан котылдык дип торганда гына дию башваткычның чишелешен әйтте:

— Унган кызлар: казаным кайчан кайнап чыгар икән, дип ашның тозы таманмы, дип казан өстен ара-тирә ачып-ачып караштырганнар, ялкау кыз бер тапкыр да казан өстен ачмаган, казан кырында йоклап утырган, аның казаны тизрәк кайнаган, ашы тизрәк өлгергән.

Дию тантана итә, без сөмсеребез коелган килеш йокларга яттык.

Икенче көнне Залидә тагын табышмак әйтте:

— Әйт, Таккүз! Икедә өч, өчтә ике — нәрсә ул?

Бу юлы да дию аптыраашта иде, җавапны ул тиз генә табалмады. Өченче көнгә киткәндә тагын әйтте:

— «Ике» сүзендә өч аваз, «өч»сүзендә ике генә! — диде.

Тагын йокларга яттык. Залидә төннәр буе йокламый иде, барыбыз да белгәннәребезне Таккүзгә әйтеп бетердек, Залидәнең дә запасы бетте, ул табышмакларны үзе уйлап чыгара иде булса кирәк.

Ул арада Сайраш тәмам симереп өлгерде. Таккүз мине тотып ашар дип төне буе борсаланып чыга.

— Дию Таккүз! — диде Залидә. — Менә бу йон бөртеген турайтырга синең куәтең җитәрме?

Төкне күргәч, Таккүз шаркылдап көлде.

— Мин андый төкне генә түгел, тимер капкаларны, тимер бүрәнәләрне дә турайтам, клиндер ясый мин алардан.

Залидә Таккүзгә йон бөртеген бирде. Дию-егет төкне турайтып карады, төк янә бөгәрләнеп килде. Тарта торгач, йон өзелде, ләкин турайммады.

— Янасын бир! — диде дию.

Залидә кесәсеннән яна төк чыгарып бирде. Дию төкне ике башыннан таш белән бастырып, төнгә куеп та карады, төк турайммады, ташларны алуга ук янә бөгәрләнеп килде.

Залидә челтерәп көлде, Сайраш та елмайды.

Өченче көн бетеп килә иде. Таккүз йонны турайта алмады.

— Юк! Булмый! — диде Таккүз һәм шулчак мәгарә ишеге ачылып китте, тоткыннар иреккә чыкты.

Аерылышыр алдыннан бичара Таккүз Залидә алдына тезләнеп:

— Зинһар, әйт, — диде. — Нинди төк булды ул мин турайта алмаган?

Залидә әйтте:

— Шул нәрсәмнең йонын да турайта алмагач, син нинди дию инде, такбаш! — диде.

Таккүз мәгарәсенең ишеге янында үкереп елап калды, без таудан төшеп, туры юлны табып, кайтып киттек.

Казанга кайтканда мин күземне Залидәдән алалмадым, ул миңа шундый гүзәл булып күренде, мин аңа үлеп гашыйк идем. Казанга кайткач, без өйләнештек.

***

**Нефтькә хак арта:**
**Байлар арта**
**Җир астында нефть барында!**
**Нефть түгел,**
**Тамак фәлсәфәсе**
**Җир өстендә халык зарында...**

**...Нефтькә хак кими:**
**Байлар кими**
**(Шулай булыр кризис үтмичә...) –**
**Эх...**
**Җир өстендә хәерчелек бетмәс,**
**Җир астында нефть бетмичә...**

## «Жигули» автомобиле

**Хурламыйлар да аны,**
**Зурламыйлар да аны...**
**...Урламыйлар да аны!**

***

**Патшаларга күзләр терәп,**
**Сабаклар ала халык...**
**Һәм,**
**Күкләргә өмет баглап,**
**Чиркәүләр төзи халык,**
**Мәчетләр сала халык...**

***

**– Армиягә барудан ник**
**Баш тарталар?..**
**— Кем белсен...**
**Кемнәрнең — әллә кайларда –**
**Кемнәр өчендер сугышып! –**
**Башлар саласы килсен...**

***

**Тирләп–пешеп,**
**«Яңа тормыш»**
**Төзибез: искитәрлек»!**
**....Сталин терелеп кайтса,**
**Аңа да эш җитәрлек!**

***

**Чит илләрдә — яшәү башка!**
**...Башлагач, әйтеп үтәм:**
**Халык кайда да халык ул,**
**Патшалар гына — бүтән...**

**Солтан МОРАТ**



Замандашлар. Уңнан сулга – Әхмәт Ерикәй, Муса Җәлил, Фатих Исхаков. Мәскәү. 30нчы еллар.



Шагыйрь Әхмәт Гадел (1942-2012).



Татар галимнәре Германиядә. Уртада – Миркасыйм Госманов, уңда Искәндәр Гыйләҗев. Гиссен шәһәре. 2003 ел.



*Композиторлар: Заһид Яруллин, Фасил Әхмәтов. 1960 ел.*



*Әдәбият белгече Баян Гыйззәт (1918-1991).*



*Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреатлары. Утырганнар: Илдар Юзеев, Рафаэль Мостафин; басып торалар: Равил Фәйзуллин, актер Юрий Федотов, Туфан Миңнуллин. 1976 ел.*

# 2012 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ**

2012 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында. № 6

«Татарстан Республикасының Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында. № 7

«Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. № 7

**ЯҢА КОНСТИТУЦИЯГӘ 20 ЕЛ**

Шәймиев М. «Вәкаләтләребезгә тыкшыну ышанычны какшата». № 12

Мазһаров Ә. Татарстан Республикасы Конституциясе: тарих һәм бүгенге көн. № 12

***

«Милли асылыбызны җаныбыз белән тойдык, акылыбыз белән аңладык» *(Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең шагыйрь Ленар Шәех белән әңгәмәсе)*. № 6

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НА — 90 ЕЛ**

Татарстан Республикасы Президенты Р. Миңнеханов котлавы. № 5

Фәйзуллин Р. Без булганбыз, бар һәм булачакбыз! № 5

*«Безнең юл»:* Һ. Такташ, М. Җәлил; *«Яңалиф»:* Х. Туфан; *«Атака»:* Ф. Кәрим; *«Совет әдәбияты»:* С. Баттал, Г. Афзал, З. Нури, Н. Арсланов, С. Хәким, Ш. Галиев, Ә. Баян И. Юзеев, С. Сөләйманова; *«Казан утлары»:* Зөлфәт, Роб. Әхмәтҗанов, Рәш. Әхмәтҗан, Р. Харис, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, Р. Вәлиев, Р. Низамиев, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, Г. Морат, Р. Зәйдулла шигырьләре. № 5

Акөтәгава Р. Чытырманлыкта. *Новелла.* № 5

Әхмәтҗанов Ю. Табыннарыбыз турында. № 5

Батулла. «Агу» чыгарган җирдә. № 5

Вафин Т. Мәкруһлар. № 5

Газиз Г. Татар телендәме, рус телендәме? № 5

Гаташ Р. Без «Казан утлары»нда үстек. № 5

Еники Ә. Тигезлек аша татулыкка. № 5

Зәйни Э. Шәһри Болгарга 1966 елгы сәяхәт. № 5

Саттаров М. Ач үлемнән коткарган батырлык. № 5

Камал Ш. Депутат. *Хикәя.* № 5

Туфитуллова Р. Лу-и-за-а. *Бәян.* № 5

Фукс К. Казан татарлары: статистик һәм этнографик җәһәттән. № 5

Котлаулар... № 6

Юбилеебыз тантанасы мизгелләре. № 6

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVII КОРЫЛТАЕ**

Миңнеханов Р. «Төп сыйфат — талант һәм һөнәри осталык». № 7

Фәйзуллин Р. Корылтай ачылышында ясалган чыгыш. № 7

Ибраһимов И. Мәдәни үсешкә йөз тотып. № 7

Мансуров З. Шигърият рухын гамь яшәтә. № 7

Зәйдулла Р. Киләчәккә ышансак кына. № 7

Татарстан язучыларының XVII корылтае резолюциясе. № 7

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Өмет. №1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхмәтгалиева А. Әрем балы. *Хикәя.* № 12

Әдһәм Г. Наласа авылы көе. *Хикәя.* № 7

Булгакова Д. Озын чәч. *Хикәяләр.* № 12

Габделхакова Р. Кояшлы мизгел. *Бәян.* № 6

Галиуллин Т. Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы. *Роман-эссе.* №№ 3 - 5

Зарипов Ә. Галиябану туе. *Кыйсса.* № 4

Зыятдинов Ф. Авылдашның авыр юл башы. *Документаль бәян.* №№ 6 -7

Җамалетдинова Ф. Соңгы карлар яуганда. *Хикәя.* № 4

Имамов В. Утлы дала. *Тарихи роман.* № № 9 - 11

Кәбиров М. Бердәнбер һәм кабатланмас. *Роман.* №№ 1 - 3

Миншин М. Кызыл диплом. *Бәян.* № 6

М и ң н у л л и н  Т. Онытмагыз мине! № 11
М ө х ә м м ә т ш а  Р. Өч хикәя. *(М. Закирның кереш сүзе белән).* № 9
Н ә б и у л л и н а  И. Борылыш. *Хикәя.* № 2
Н у р м ө х ә м м ә т о в  Т. Кабан күле, әй, алкын. *Бәян.* №№ 8,9
Р а х м а н  Р. Сан-зат тыйз-зи. Б ә я н. № 9
Х ә б и б у л л и н а  Р. Мулла килене. *Роман.* №10
Х ә л и м  А. Үрнәк эшелон. *Хикәяләр.* № 1
Ю з е е в  С. Үлгәннәрне бүлдермә. *Роман.* №№ 7, 8
Я х и н  Ф. Умырзая. *Роман.* № 11,12

**ШИГЪРИЯТ**

А р с л а н о в  Н. Азат жанлы булып туганмын мин... *Шигырьләр (Р.Фәйзуллинның кереш сүзе белән).* № 9
Ә х м ә д и е в  Н. Шагыйрь күңеле — шаулы кара урман. *Шигырьләр.* № 6
Ә х м ә т ж а н о в а  С. Татар кызлары. *Тарихи циклдан өзекләр.* № 3
Б у л а т о в а  К. Үткәнемнең тамыр җебен эзлим. *Шигырьләр.* № 4
Б и е к т а у л ы  И. Моңсу мизгелләр. *Шигырьләр.* № 2
В ә л и е в  Р. Җанымны җылыткан уй табам. Ш и г ы р ь л ә р. № 1
Г а б д е р ә х и м  Ф. Үзем өчен бер хакыйкать ачтым. *Шигырьләр.* № 12
Г а д е л  Ә. Җил исә, еллар үтә... *Шигырьләр.* № 2
Г ә р ә е в а  С. Моңнардай ташый күңелем. *Шигырьләр.* № 2
Г ы й л ә ж е в  И. Үлемсез дан җиңел бирелми. *Шигырьләр.* № 1
Д е р ж а в и н  Г. Сәхрәләргә чыга идек без... *(Л. Шагыйрьҗан тәрҗемәләре). Шигырьләр.* № 6
Ж а м а л е т д и н о в а  Ф. Борма юллар безнең гомер сыман. *Шигырьләр.* № 10
И д и я т у л л и н  Р. Заман үзе безне сайлады. *Шигырьләр.* № 11
И с м ә г ы й л е в а  И. Йөрәк аша уза вакыт... *Шигырьләр.* № 6
М а н с у р о в  З. Сабыр холкым ерак каннан килә. *Шигырьләр.* № 9
Н ә з и р о в  М. Күп сынады язмыш ныклыгымны. *Шигырьләр.* № 4
Н и з а м и  Р. Яшәргә дип җиргә яралганбыз... *Шигырьләр.* № 3
Н ә г ы й м у л л и н а  Д. Хакыйкатьне аңлап ярсый күңел... *Шигырьләр.* № 10
М о р а т  Г. Вөҗүдендә дөнья җәйрәп яткан... *Шигырьләр.* № 8
Ш ә р и ф у л л и н а  Э. Очышта да күңел сына икән... *Шигырьләр.* № 6
Р ә х и м  Г. Узасы еллар узган. *Шигырьләр.* № 7
Р ә х м ә т у л л а  С. Без дә кошлар нәселеннән микән? *Шигырьләр.* № 2
С а ф и н а  Н. Сиңа багышланган җырым. *Шигырьләр.* №11
С и т д ы й к о в а  Ә. Мин тормышны өзелеп яратам. *Шигырьләр.* № 8
С ү л т и  Р. Идел-йортым мөлдерәпләр тора күз төбәп. *Шигырьләр.* № 1
Р ә х и м  Г. Узасы еллар узган... *Шигырьләр.* № 7
Ф ә й з у л л и н  Р. Яңа шигырьләр. № 12
Ф ә т х е т д и н о в а  Л. Бу бәхеткә исем кушып булмый. *Шигырьләр.* № 8
Х ә м и д у л л и н а  В. Сагыш моңлы җырын сузар... *Шигырьләр.* № 12
Ш а һ и е в а  Р. Мәңгелегең балкый, асылзат... *Шигырьләр.* № 3
Ш ә м с у а р о в  Т. Синең барлык кирәк дөньяда. *Шигырьләр.* № 7
Ш ә р и п о в  Р. Без дә бит бу дөнья баласы... *Шигырьләр.* № 7
Ш ә е х  Л. Ак болытлар буйлап яшьлек ага. *Шигырьләр.* № 11
Ш ә р и ф у л л и н а  Э. Очышта да күңел сына икән... *Шигырьләр.* № 6
Ю н ы с о в а  А. Иҗат көчен данлар алтын җитмәс. *Шигырьләр.* № 9
Якупова С. Уем — тамчы, моңым — чишмә. *Шигырьләр.* № 7

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

С ә г ъ д и  Р. Галиҗәнап Гатаулла хәзрәт. *Мелодрама-легенда.* № 12

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Р ә х и м  Г. Күзгә хикәя. № 10

**ПУБЛИЦИСТИКА**

М и ң н у л л и н  Т. Үзгәрү. №№ 1 - 3
Ш ә р ә ф и е в  Р. Кем белән берләшик, Рәфикъ Юныс? № 2
Ш ә р и ф у л л и н  Н. Зыялылык җитмәсә... № 3
Ю н ы с  Р. Иң әүвәл икәү берләшик, Адашетдин! № 2

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Ә х м ә д у л л и н  А. Якты иҗат *(Әнәс Хәсәнов иҗаты турында уйланулар).* № 10

Галимуллин Ф. Игелекле эшләр. *(Лирон Хәмидуллинга 80 яшь)* № 10

Галиуллин Т. Күкрәгендә шигъри сагыш *(Рөстәм Мингалимгә 75 яшь)*. № 8

Даутов Г. Уйланыр вакыт җитте. № 3

Закирҗанов Ә. Бергәләп уйланыйк, яисә Г.Даутовка ачык хат. № 3

Закирҗанов Ә. Таләпчән тәнкыйтьче. *(Рифат Сверигинга 80 яшь)*. № 8

Закирҗанов Ә. Яшәү яме — хезмәттә. *(Азат Әхмәдуллинга 80 яшь)* № 10

Заһидуллина Д. Гали Рәхим: милләт өчен яшәү үрнәге (Гали Рәхимнең тууына 120 ел.). № 11

Мөлеков М. Хунвэйбиннар заманы. № 12

Сверигин Р. Хакыйкать эзләп. № 8

Хәсәнова Ф. Флера Гыйззәтуллинаның шигъри дөньясы. № 4

Хәсәнова Ф. Йөрәккә яшерелгән серләр *(Флера Тарханова иҗатында газәл җанры)*. № 6

Хатипов Ф. Әсәрләребезгә ни җитми? № 9

Шәрипов Р. Рәмзиянең «Көмеш туны». № 4

Юсупов Р. Ком сәгате дөрес йөри, сакау күке ялгышмый. № 4

Яхин Ф. «Оча торган кешеләр» яки ак төс тантанасы. № 9

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Абдуллин М. Башлык килгәч. *Хикәя*. № 9

Айбулатов Н. Комиссия. *Шигырь*. № 4

Әхәтов Х. Нигез көче. *Нәсер*. № 9

Бәдигыйзмнар. № 4

Баттал Ф. Җәһәннәмдә дәҗҗал. *Шомлы хикәят*. № 3

Вафин М. Ялгыш кына. *Шигырьләр*. № 4

Вафин М. Габделҗаббарның төше. № 5

Гали Ф. Чәнечкеле робагыйлар. № 1

Гарипов Х. И Казан... *Шигырь*. № 4

Гаффаризмнар. № 1

Диндаров И. Кырый урамда. *Шигырь*. № 4

Кәримизмнар. № 2

Ләбибизмнар. № 3

Морат С. Такмаклар. № 4

Морат С. *Шигырьләр*. № 12

Мәннан Р. Шигырь табу. № 10

Низами Р. Фетнә. *Хикәя*. № 7

Нуриев В. Казан күркәсе. *Хикәя*. № 2

Сәлим М. Ышандырин. *Хикәя*. № 4

Хөснияр З. Авыл малайлары... *Шигырьләр*. № 4

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Кәрим Я. Аллам. Шигырьләр. № 3

**СӘЯСӘТ**

Таһиров И. Федерация — ил язмышы. № 5

**ФӘН**

«Авыр чакта гел Казанга ялганам... *( Рафикъ Юнысның академик Рәшит Сүнәев белән әңгәмәсе)*. № 11

Галиева Э. Мәдрәсәләребез — «татар академияләре». № 2

Ганиева Ф. Әдәби әсәр һәм тәнкыйть логикасы. № 9

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. № № 1 - 12

Гарифуллин Д. Нугайлар тарихыннан сәхифәләр. № 4

**ТАРИХ**

Әхмәтҗанов М. Җамал Вәлидинең тууына 125 ел. № 10

Вәлиди Җ. Тукайның шагыйрьлеге. № 10

Ислаев Ф. Яңа керәшен кантуры. № № 10,12

Нуриева Ф., Петрова М., Сөнгатуллина А. Беренче төрки басма китап. № 12

Сибгатуллина Ә. Имам һәм мөдәррис *(Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең тууына 150 ел)*. № 12

Хәмидуллин Л. Тукайның остазы һәм оста матбагачы. № 6

Шәрәфиев Р. Себер юлы серләре яки тарихи табышлар. № 8

**СӘНГАТЬ**

Бәйрәмова Г. Җырлы-моңлы еллар... *(Татар дәүләт филармониясе оешуга 75 ел)*. № 8

Милли моңнарыбыз илчесе *(Хәмитов А., Гәрәева В., Мостафин Р., Гарипова Р. белән Бәйрәмова Г. әңгәмәсе)*. № 12

Шакиров Ә. Татарның бөек артисты Хәлил Әбҗәлилов. № 2

**ХӘТЕР**

Әмир М. Еллардан юллар. № 5

Әпсәләмова А. Ул утлар беркайчан да сүнмәс! № 1

Гаташ Р Халыкчан хисләр җырчысы *(Газизә Сәмитованың тууына 150 ел)*. № 11

Яруллин Ф. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр*. № № 1,2, 3, 4, 6

Зәйдулла Р. Карурман җанлы кеше. № 9

Нәфиев Ф. Рәшидә апа дәресләре. № 10

Сафин Ф. «Шигырь — минем яшәү рәвешем» *(Кадыйр Сибгатуллинның туууына 70 ел).* № 2
Сәмитова Г. Каләм. *Шигырьләр.* № 11
Сибгатуллин К. Кама ярларыннан эзлим сине. *Шигырьләр.* № 2
Сафиуллин Ф. Бәләкәй чак бәләкәйлек түгел ул. № 8

**ЮБИЛЕЙЛАР**

БЕРЕНЧЕ ТӨРКИ-ТАТАР КИТАБЫ ЧЫГУГА 400 ЕЛ

Мансуров З. Татар китабы. № 10

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Закирҗанов Ә. Милләт каһарманы. № 3

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Заһидуллина Д. Татарның беренче тарих профессоры. № 7

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Закирҗанов Ә. Вакытсыз сүнгән йолдыз. № 9

ЗЫЯ ЯРМӘКИНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ. № 1

ӘХМӘТ ЕРИКӘЙНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ. № 12

ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙПНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 1

МОСТАФА НОГМАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 12

ГАЗИЗ МӨХӘММӘТШИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кәримов К. Ирләр кырыкта сынала. № 12

КОЯШ ТИМБИКОВАНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Бәйрәмова Г. Кояшлы көзге. № 12

ГАЗИЗ КАШАПОВ-ҮЗИЛЕНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ. № 8

**КОТЛЫЙБЫЗ**

МИРГАЗИЯН ЮНЫСКА 85 ЯШЬ

Юныс Р. Татар офыгын киңәйткән әдип. № 6

АЗАТ ВЕРГАЗОВКА 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 3

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 75 ЯШЬ

Закирҗанов Ә. Шигъри җанлы галим. № 4

РАВИЛ ФӘХРЕТДИНОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 3

ДАНИЯ ГЫЙМРАНОВАГА 75 ЯШЬ

Театрны яратучы шәхес. № 10

ИНДУС СИРМАТОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 3

АЛЬБЕРТ ХӘСӘНОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 12

АЙДАР ХӘЛИМГӘ 70 ЯШЬ

Айдар Хәлим: шәхес һәм иҗат *(Фирдәвес Хуҗин белән әңгәмә).* № 1
Әдип турында каләмдәшләре (*Флера Низамова, Рифат Сверигин, Рөстәм Зарипов).* № 1

ГӨЛЗАДӘ ӘХТӘМОВАГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 1

РАУЛЬ МИР-ХӘЙДӘРОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 3

НӘКЫЙП КАШТАНОВКА 70 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Тын дөньялар моңын тыңлаганда. № 1

ДАНИЯ ГАЙНЕТДИНОВАГА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

КАМИЛ СӘГЪДӘТШИНГА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 2

РӨСТӘМ ЗАРИПОВКА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. № 2

ЛӘИС ЗӨЛКАРНӘЙГӘ 50 ЯШЬ

Зәйдулла Р. Кысага сыймас канат. № 4

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛАГА 50 ЯШЬ

Рахман Р. «Бөек мәгънә эзли юкса шагыйрь». № 1

ЙОЛДЫЗ ШӘРАПОВАГА 50 ЯШЬ

Ә хакыйкать һәрчак кирәк бит ул. *Шигырьләр.* № 4

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Бәдретдинов Р. Гасырлар илчесе. № 8
Фәйзуллин Р. Үз заманының каһарманы. № 8

**ЮМОР ПОЧМАГЫ**

Батулла Яна мулла. № 8
Батулла мелла хикәяләре. № 12
Галиев М. Көлү мәрәкә. № 5
Гаффар Ә. Әкиятләр. № 6
Мәннан Р. Бердәмлек. *Шигырьләр.* № 4
Шәфигуллин Ф. Эш вакыты. № 5
Үзеңнеке — үзәктә *(Л.Лерон, М.Закир эпиграммалары, З.Хәйруллин шаржлары).* № 5

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН**

Акбаш А. Тормыш ул нечкә сәнгатьтер. *Шигырьләр.* № 10
Миннуллин Р. Төрки әдәбиятларын дөньяга танытучы. № 10
Әхмәт-Хуҗа Ә. Тормыш тоташ әкияткә охшаш. *Шигырьләр.* № 9
Шукшин В. Ана йөрәге. № 9

**АК ҖИЛКӘН**

Әхмәтшина М. Сары яулык. *Хикәя.* № 9

Гафурова Г. Киләчәк күрсәтер! *Шигырьләр.* № 1

Габдрахманова А. Караш. *Хикәя.* № 1

Исхакова Л. Мин калам көзләрдә... *Шигырьләр.* № 9

Мамадыш районы Югары Сөн урта мәктәбе укучылары иҗаты *(Гыйләҗетдинов С., Габдрахманова Н., Гыйләҗетдинова Г., Йосыпов И.,Сәйфетдинова Л.).* № 3

Нотфуллин И. Елыйсы килә. *Шигырьләр.* № 2

«Хикәя яза аласызмы?» №№ 2, 8

Шакиров К. Тукран да бионикага ярдәм итә. № 1; Күзләрең ачык, колакларың тырпайган булса. № 2; Космосны кем чистартыр. № 3; Юраганнары юш килгән. № 9

**БӘЛӘКӘЙЛӘР**

Әмирханов М. Бәләкәй Марат. № 1

**КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ**

Мансуров З. Иелгән башта таҗ тормас. № 4

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Гайнанова Л. Баш редактор. № 3

Галиев Г. Дога кылып кит. № 1

Мансур З. Барыбер кайттың син... № 7

Юсупова Р. Сәйдәш, Еники һәм... зәңгәр костюм кыйссасы. № 9

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

Миннуллин Т. Фәүзия Бәйрәмова. № 7

**ТАТАР ГАЛӘМЕ**

Апакай С. Сан-Францискода татар җәмгыяте. № 5

Надир И. Финляндия татарлары. № 5

**БЕЗДӘ КУНАКТА — БАШКОРТСТАННЫҢ ЭСТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ**

Туктаров Ф. Эстәрлебаш Казаннан ерак түгел. № 11

Арсланов Г., Байгилдин Р., Басыйрова Г., Гыйззәтуллина Н., Гыйзетдинова З., Зиязетдинов Р., Ибраһимова Ф. Назарова Х., Сабитова Л.,Үләев Г. *шигырьләре.* № 11

Исмәгыйлев Х. Явурай. *Хикәя.* № 11

Кәримов М. Гарип Мәхмүт. *Хикәя.* № 11

Рысаев Р. Тартай теленнән таба. *Хикәя.* № 11

**ОЧРАКЛЫКЛАР ОЧРАКЛЫМЫ?**

Баттал Ф. Әҗәл миңа өч тапкыр янады. № 9

Нуруллин Р. Әҗәл миңа да өч тапкыр бакты. № 10

Хәмзин А. Аккан сулар кире кайтмый. № 12

**ГОМЕР ИТМЕШ, ДӨНЬЯ КӨТМЕШ...**

Мөхәмммәтшин Г. Балачакта калачак. № 7

Кадыйров Ә. Журналыгыз шәп рупор, әмма... № 9

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Баттал Ф. Иптәшләр гаеп итмәсләр. № 12

Гомәр Г. Чыңгыз үләне. Нәкышче Нәккаш. № 7

Гомәр Г. Сөембикә-ханбикә. № 10

Гомәр Г. Багана кыру һөнәре. № 3

**ЯҢАЛЫК**

Иксанова И. Җыелыйк бер түгәрәккә... №1

**КАЙТАВАЗ**

Идиятуллин Р. Кайдан ала алар бу көчне? № 1

Галимуллина Г. Бергәләп гәзит чыгардык. № 1

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№ 1, 2, 4, 7, 8, 9, 10, 12

Укучы сүзе. №№ 7, 9

«Казан утлары» архивыннан. №№ 1-12;

Яңа китаплар. №№ 3, 9, 10

2013 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. № 12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№ 1-12

Хушлашу сүзе (Фәнис Яруллин. №1; Равил Бохараев. № 2; Шамил Закиров. №4; Туфан Миннуллин. № 6; Шәүкәт Биктимеров. № 7; Әхсән Фәтхетдинов. №8; Шамил Маннапов. № 11)

## КИТАП — БӨЕК МИРАСЫБЫЗ

Октябрь аенда Казанда халыкара зур җыен булып узды. Дөньяда беренче төрки-татар китабы нәшер ителүгә 400 ел тулу унаеннан үткәрелде ул. «Дөньякүләм рухи мәдәният мәйданында төрки телле китап» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциягә, төрки-татар китабын олылап, ерак һәм якын чит илләрдән — Төркиядән, Ираннан, Германиядән, Казакъстаннан, Әзербайҗаннан, Кырымнан, Литвадан китап тарихын өйрәнүче белгечләр килде. Алар ТР Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, Татарстан югары уку йортлары укытучылары белән берлектә, 2 көн дәвамында төрки телле китапның тарихы, аның халыклар язмышындагы урыны, үсеш юллары хакында фикер алышты. Конференция ТЮРКСОЙ оешмасы химаясендә үтте.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты конференция алдыннан өч китап нәшер итте. Алар: Иероним Мегизернең яңадан бастырып чыгарган «Төрки тел нигезләре» хезмәте, «Төрки телле китап: гасырлар хәзинәсе» һәм «Татар китабы: тарихи сәхифәләр» җыентыклары. И.Мегизернең хезмәте — төрки телләр грамматикасы буенча беренче басма китап. Ул моннан 400 ел элек Лейпцигта басылып чыккан.

## «ТАТМЕДИА» АГЕНТЛЫГЫ КАБАТ ТОРГЫЗЫЛДЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов «Татмедиа» Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгын бетерү турында» Татарстан Республикасы Президенты Указын үз көчен югалткан дип тану хакында» Указны имзалады.

Указга Татарстан Республикасында матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү максатыннан чыгып кул куелды.

Татарстан Президентының 2012 елның 20 октябрь Указы нигезендә Ирек Җәүдәт улы Миңнәхмәтов «Татмедиа» Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе итеп билгеләнде.

*И.Миңнәхмәтов 1980 елның 25 декабрендә Казанда туган. 2003 елда «икътисад» белгечлеге буенча Казан дәүләт финанс-икътисад институтын, 2008 елда «юриспруденция» белгечлеге буенча Казан дәүләт университетын тәмамлаган.*

*И.Миңнәхмәтов 2000 — 2010 елларда җаваплылыгы чикләнгән «Чыңгызхан» ширкәте генераль директоры булып эшли. 2010 елдан «Татспиртпром» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директорының коммерция буенча урынбасары вазифасын башкара. 2012 елда ул «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры итеп сайланды. 2012 елның 20 октябрендә «Татмедиа» Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе итеп билгеләнде.*

## КАМАЛ ТЕАТРЫ КЫТАЙДА

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына Пекинда уздырылган «Данлыклы Европа» дип аталган традицион халыкара фестивальдә катнашырга һәм аны ачып җибәрергә насыйп булды. Театрның художество җитәкчесе-баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев һәм яңа  билгеләнгән директор Илфир Якупов Кытай милли театры җитәкчелеге белән очрашты. Алар киләчәктә алмаш гастрольләр оештыру мөмкинлекләре турында сөйләштеләр. Бу фестивальгә безнекеләр Кытай җирлеге нигезендә язылган «Турандот» спектакле белән катнашсалар, Ф.Бикчәнтәев фикеренчә, алдагы елларда татар драматургиясе белән ныграк таныштыру өчен милли спектакль алып килү кирәк булачак.

## ТОСНОДА ҖӘЛИЛ КАЛЫКТЫ

Ленинград өлкәсенең Тосно шәһәрендә герой-шагыйрь Муса Җәлилгә бюст куелды. Аның авторы — Санкт-Петербургта яшәүче сынчы, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Венера Абдуллина. М.Җәлил сугыш кырында каты яраланып, әсирлеккә төшкән җирдән ерак түгел урында бюст кую идеясен Санкт-Петербург шәһәренең һәм Ленинград өлкәсенең татар җәмәгатьчелеге тәкъдим иткән иде.

Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин бюстны ачу тантанасында чыгыш ясап, Президент Рөстәм Миннехановның Рәхмәт хатын укып ирештерде. Хатта: «1942 елда каты сугышлар барган, анда шагыйрь дә катнашкан җирдә — Тосно шәһәрендә Ленинград өлкәсе һәм Санкт-Петербург татар җәмәгатьчелегенең Муса Җәлилгә һәйкәл-бюст булдыру һәм урнаштыру буенча башлангычын хуплавы өчен Ленинград өлкәсе хөкүмәтенә һәм Тосно районы хакимиятенә чын күңелдән рәхмәт белдерәм», — дигән сүзләр бар.

## ЯҢА УРАМНАРДА — ЯКЫН ИСЕМНӘР

Казанның яна урамнарына «исем куштылар». Башкаланың бер урамы танылган драматург һәм язучы Туфан Миңнуллин исемен йөртәчәк. Совет районында урнашкан Яңа Сосновка бистәсендәге бер урам — җәмәгать эшлеклесе, укытучы Габдрахман Рәфыйков, берсе — танылган галим Җамал Вәлиди, берсе — ТАССРның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова исеме белән аталган, анда шахмат һәм шашка буенча халыкара чемпион Рәшит Нәҗметдинов исемендәге урам да пәйда булды. Идел буе районының Кояшлы бистәсендә исә урамнар композитор Фасил Әхмәтов, язучы һәм шагыйрь Нәби Дәүли, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Садретдин Максудов, ТАССРның атказанган артисты Габдулла Рәхимкулов исемен йөртәчәк.

## ХАЛЫКАРА КОНГРЕССТА

22-24 ноябрьдә Казакъстан башкаласы Астана шәһәрендә «Төрки дөньясы әдәби журналларының V конгрессы» («V. Türk Dünyasl Edebiyat Dergileri Kongresi») булып узды. Астанага төрле илләрдә төрки телләрдә чыга торган журналларның җитәкчеләре чакырылган иде. Бу мәртәбәле конгресста, Татарстан вәкиле буларак, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин катнашты. Пленар утырышта ясаган чыгышында ул татар әдәбияты классик-мәгърифәтчеләренең соңгы гасырларда гомумтөрки әдәби-мәдәни үсешкә керткән өлеше, «Казан утлары» журналының татар халкы рухи тормышындагы урыны, соңгы дистә елларда төрки телләрдән тәрҗемә ителеп чыккан әсәрләр, һәм гомумән, уртак бәйләнешләр турында сөйләде. Ул шулай ук, Евразия әдәбиятларының уртак журналы саналган «Кардәш каләмнәр»дә, «ТЮРКСОЙ» химаясендә чыга торган башка басмаларда бүгенге татар әдәбияты үрнәкләренең системалы рәвештә даими бирелү тиешлегенә аерым басым ясады.

Монарчы бу халыкара конгресс Төркиядә үткәреп киленде. Үткән җыеннарда бу чараны башка төрки дәүләтләрдә һәм республикаларда да үткәрү кирәклеге турында фикерләр әйтелгән иде. Ниһаять, бу теләк тормышка аша башлады. Быел ул Астанада үткәрелсә, тагын бер елдан соң, ягъни 2014 елда «Төрки дөньясы әдәби журналларының VII конгрессы»н Казанда уздыру планлаштырыла.

## КЫРГЫЗСТАНГА СӘЯХӘТ

Бишкәк каласындагы «Туган тел» татар-башкорт җәмгыяте һәм Кыргызстан парламенты чакыруы буенча Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев октябрь аенда Кыргызстанда булып кайтты.

Тугандаш республикага сәяхәт Ч.Айтматов исемендәге драма театры бинасында Разил Вәлиев иҗатына багышланган кичә белән башланып китте. Анда Кыргызстан президентының хәләл җефете, милләттәшебез Рәисә ханым Атамбаева котлау сүзе белән чыгыш ясады, кичәдә шулай ук Россия илчелеге вәкилләре, Кыргызстанның сәнгать осталары, депутатлар, кыргыз язучылары һәм Татарстанның атказанган артисты Вәис Бәйрәмов катнашты.

Кыргызстан Язучылар берлегендә узган очрашу вакытында каләм әһелләре татар һәм кыргыз әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе, тәрҗемә мәсьәләләре хакында фикер алыштылар, үзара әдәбият-сәнгать көннәре үткәрү кирәклеге әйтелде.

«Туган тел» җәмгыятендә, Кыргызстан парламенты «Җогорку Кенеш»тә һәм Россия илчесе А.А.Крутько белән очрашуда сүз ике республика арасындагы эшлекле элемтәләрне ныгыту, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге бәйләнешләр, биредә яшәүче милләттәшләребезнең рухи ихтыяҗлары хакында барды.

## ШАГЫЙРӘ ИСЕМЕННӘН «ТАТНЕФТЬ» БҮЛӘКЛӘРЕ

Республикада күренекле шагыйрә Сажидә Сөләйманова исемендәге бүләк бирү күркәм гадәткә әйләнде. Ул һәр елны каләм ияләренә аеруча уңышлы дип табылган әсәрләре өчен тапшырыла. Әлеге бүләк Татарстан Язучылар берлеге һәм «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте карары нигезендә бирелә.

Быел бу бүләккә Сәйдә Зыятдинова («Җилел юл авырмы?» дигән китабы өчен), Мөҗәһит Әхмәтҗанов («Зирәк булу кирәк» җыентыгы өчен), Гөлзадә Әхтәмова («Күнел ашкынуы» китабы өчен) лаек булды. Кызыксындыру бүләкләре Рүзәл Мөхәммәтшин («Каралама» җыентыгы өчен), Таһир Шәмсуаров («Моң коесы» китабы өчен) һәм Резидә Шәриповага («Ялкау балыкчы» мәҗмугасы өчен) тапшырылды. Болардан тыш, 10 студент С.Сөләйманова исемендәге стипендия алачак.

Әлмәт Татар дәүләт драма театры бинасында үткән бүләкләү тантанасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, әдәбият галиме һәм язучы Тәлгат Галиуллин катнашты.

## ӨЗЕЛГӘН ҖЫР ДӘВАМ ИТӘ

Уфаның «Нефтьчеләр» мәдәният сараенда Башкортстанда туып-үскән, тарихка 12 нче җәлилче буларак кергән яугир-шагыйрь Рәхим Саттарның тууына 100 ел тулу уңаеннан бер ай дәвамында барган республика фестивален йомгаклауга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. «Өзелгән җыр дәвам итә» дип исемләнгән әлеге

мәдәни чараны «Рамазан» төрки милли-мәгърифәт үзәге оештырды.

Әйе, Башкортстанның бәрәкәтле туфрагында туып-үскән уртак каһарманнарыбыз байтак безнең. Җөмһүриятнең Чишмәле районында дөньяга килгән, Казанда шагыйрь буларак танылган һәм җәлилчеләр белән яшерен оешмада фашизмга каршы көрәшкән, соныннан хәбәрсез югалган Рәхим Саттар да әнә шундый шәхесләребезнең берсе. Шуна күрә кичәдә Башкортстан һәм Татарстан сәнгать осталарының, каләм әһелләренең бергәләп катнашуы да нур өстенә нур булды, аның әчтәлеген тагын да баетты. Зал тутырып килгән тамашачыларны Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, шагыйрь Газинур Морат сәламләде. Ике республиканың танылган җырчылары Фән Вәлиәхмәтов, Нәсимә һәм Азамат Тимеровлар, Венера һәм Марат Шәриповлар, Фәнир Галимов, Георгий Ибушев, Резеда Галимова, Вил Усманов, Регина Вәлиева, Айрат Имашев һәм башкалар башкаруында халкыбызның һәм композиторларыбызның моңлы җырлары яңгырады.

Соныннан Казаннан килгән язучылар Чакмагыш төбәгендә булып, район китапханәчеләре белән очрашты. Кунакларны Башкортстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Марис Нәзиров озатып йөрде.

## РӨСТӘМ МИНГАЛИМНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Мингалимгә 75 яшь тулуга багышланган «Яратам шул бу дөньяны» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

Кичәдә беренчеләрдән булып Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин сүз алды.

— Без — Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Ренат Харис һәм мин 60нчы елларда әдәбият мәйданына бергә килеп кердек һәм менә инде 50 ел дәвамында иҗат итәбез, — дип башлады ул сүзен. — Бишебез дә Татарстанның халык шагыйрьләре, язучылары, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге ияләре булдык. Татар театрына щепкинчылар нинди янарыш алып килгән булса, татар әдәбиятына 60нчы еллар буыны шагыйрьләре зур йогынты ясады. Рөстәм Мингалим драматургиядә дә, балалар әдәбиятында да, шигърият өлкәсендә дә бердәй актив иҗат итте. Иҗатында Җир шары күләмендәге зур, глобаль темалар күтәрде. Тәс-кыяфәте кырыс кебек күренсә дә, бик нечкә, бай күңелле кеше, шәп иҗатчы ул Рөстәм Мингалим.

Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим үзенең котлау сүзендә шагыйрь Р.Мингалим иҗатының дөньяви, тормышчан булуы белән аерылып торганын искәртеп узды.

Кичәдә бәйрәмдарны һәм аның галиләсен мәдәният министрлыгының сәнгать бүлеге мөдире Зөлфирә Салихова, шагыйрьләр Газинур Морат, Ләбиб Лерон, аның шигырьләренә иҗат ителгән җырларны башкарып, җырчылар Мингол Галиев, Клара Хәйретдинова, Рөстәм Маликов, Рамил Миндияр, Асаф Вәлиев, олы кызы Айсылу Мингалимова, Рәсим Низамов һәм Самара өлкәсеннән кичәгә күпләп килгән якташлары тәбрикләде. Шигырьләрен тамашачыларга Инсаф Абдулла, Луара Шакирҗан, Алсу Каюмова, Фәнис Кәлимуллин һ.б. укып ирештерде.

Кичәне Айсылу Лерон һәм Татарстанның атказанган артисты Фәнис Җиһанша алып барды.

## «ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ» БӘЙРӘМГӘ ҖЫЙДЫ

Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда күренекле әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамовның быел Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Татар шагыйрьләре» исемле китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Гаять үзенчәлекле китапның бәйрәме дә бик үзенчәлекле килеп чыкты: анда бу басмадагы иҗат портретларының кайбер геройлары — бүгенге көндә актив әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге белән шөгыльләнүче шагыйрьләр Ренат Харис, Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров та чыгыш ясады, шулай ук әдәбият галиме Фоат Галимуллин да, шагыйрә Флера Тарханова да әлеге китап турында үз фикерләре белән уртаклашты, Казан театр училищесы һәм И.Әүхәдиев исемендәге музыка училищесы студентлары башкаруында кичәдә катнашучы шагыйрьләрнең шигырьләре дә, Тукай шигырьләренә язылган җырлар, татар халык көйләре дә яңгырады. Яна китап бәйрәме тамашачылары өчен Нурмөхәммәт аганың хәләл җефете — күренекле тел галимәсе Фәһимә Хисамованың чыгышы да, аларның игезәк уллары — танылган рәссамнар Айдар һәм Нияз Хисамовларның гитара моңнарына кушылып, әти-әнисенең яраткан җырын башкарулары да бик кызыклы булды.

«Татар шагыйрьләре» китабын тәкъдим итү кичәсен музей директоры, шагыйрь Рәмис Аймәт алып барды.

## ӨЛКӘН ӘДИПНЕ ХӨРМӘТЛӘП

Ноябрь аенда язучы һәм тәрҗемәче Лирон Хәмидуллинга 80 яшь тулды. Ул — ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Л.Хәмидуллин,

шулай ук, татар халкының күренекле шәхесләренең (Дәрдмәнд, М.Фәйзи, Г.Баттал, Ф.Туишев һ.б.) иҗатларына һәм язмышларына багышланган күпсанлы хезмәтләр авторы да.

Әдип юбилеена багышлап берничә очрашу оештырылды. Татарстан фәннәр академиясенең фәнни китапханәсендә язучылар һәм галимнәр катнашында «Әдәби мирасны барлау һәм әдәби арадашлык мәсьәләләре» турында сүз бара. Ул очрашуда ТР ФА президенты Әхмәт Мәзһаров, галимнәрдән Фоат Галимуллин, Ким Миңнуллин, Азат Зыятдинов, Фатих Сибагатуллин, Гомәр Сабирҗанов, әдипләрдән Равил Фәйзуллин, Рабит Батулла, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. ТР милли музееның Әдәби салонында һәм Г.Тукай әдәби музеенда уздырылган очрашуларда каләм әһелләреннән Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, Фоат Галимуллин, Илфак Ибраһимов, Зиннур Мансуров, Роберт Миннуллин, Хатыйп Миңнегулов, Солтан Шәмси, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, танылган скрипкачы Марат Әхмәтов һәм җырчы Георгий Ибушев катнашты.

## МӘҺДИ ЯНӘ ТУГАН ЯГЫНДА

Галим һәм прозаик Тәлгат Галиуллинның Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең тормыш һәм иҗат юлы турында Татарстан китап нәшриятында «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» дигән китабы дөнья күрде. Әлеге вакыйга уңаеннан китап героеның туган ягы — Арча районы Сикертән мәктәбендә әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр катнашында үткән бу бәйрәмгә Казаннан да кунаклар кайткан иде. Алар иң әүвәл М.Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктәге музеенда булды, әдипнең каберен зиярат кылды.

Кичә китапның авторы Тәлгат Галиуллин чыгышы белән башланды. Ул китап язарга замандашы, каләмдәше, фикердәше, дусты турында хәтер яңарту, аның якты истәлеген, иҗат рухын бүгенге яшь һәм киләчәк буыннар күңеленә салып калдыру максатында алынуын әйтте һәм әлеге роман-эссеның язылу тарихын бәян итте. Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин (ул әлеге китапка кереш сүз язган) бу әсәрнең «Казан утлары» журналында басылгач та, укучыларда зур кызыксыну уятуын әйтеп узды. Аның сүзләренчә, бу китапта М.Мәһдиев иҗат иткән чорда татар әдәбиятының үсеш процессын, әлеге үсешнең төп юнәлешен билгеләүче байтак шәхесләрнең җанлы портретларын күреп була. М.Мәһдиевнең кызы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Гәүһәр Хәсәнова үз чыгышында әлеге роман-эссеның татар әдәбиятында яңалык буларак кабул ителергә лаеклы икәнлеген искәртте. Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Надия Мифтахетдинова, «Ак Барс-агро» хуҗалыгының генераль директоры Шәйдулла Сәлахов, Арчадагы «Казан арты» әдәби музей берләшмәсе директоры Ринат Фазлыйәхмәтов якташ әдип белән горурлануларын тагын бер кат белдереп, «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» өчен Тәлгат Галиуллинга ихлас рәхмәтләрен ирештерде.

Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, шагыйрь Газинур Морат, Казан дәүләт медицина университеты профессоры Әфхәт Галиуллин, М.Мәһдиевнең бертуган апасының кызы Җәүһәрия Галимова катнашты һәм чыгыш ясады.

***

2012 елның 13 ноябрендә шагыйрь, прозаик, публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Әхмәт Гадел (Әхмәт Мөхәммәтһади улы Гаязов)** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы иртә.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы, тәрҗемәче **Вера Хәмидуллина**.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 2013 ЕЛДА

Сезгә мәгълүм булганча, быел журналыбызның олуг юбилеен билгеләп үтеп, ел дәвамында әдәбиятыбыз үсешенә өлеш кертерлек байтак әсәрләр чыгара алдык. Нигезебез нык булгач, киләсе елда да укучыларыбызны яхшы әсәрләр белән сөендерербез дип ышанабыз. Шул ният белән, редакция портфеленә кергән кайбер әсәрләр исемлеге белән таныштырып үтәбез.

**Чәчмә әсәрләр**

**Х.Камалов.** Сугыштан кайткан сөю. Кыйсса; **Батулла.** Туган ягым – Зәй төбәге. Автобиографик роман; **А. Хәлим;** Үрнәк эшелон. Хикәя; **М.Әмирхан.** Әкәй икән ир Мамай. Тарихи роман; **Р.Газизов.** Ялгышылган язмышым. Бәян; **Ә.Сафиуллин.** Адәм сөйли, язмыш көйли. Роман; **Х.Мөдәррисова.** Ул еллар... Кыйсса; **Рөстәм Галиуллин.** Хикәяләр.

**Шигърият**

Әйдәп баручы шагыйрьләребезнең яна шигырьләре һәм поэмалары.

**(Ә.Баян, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, М.Кәримов, Р.Гаташ, Г.Рәхим, Р.Вәлиев, З.Мансуров, Р.Миңнуллин, Ф.Гыйззәтуллина, Л.Шагыйрьҗан, К.Булатова, М.Мирза, Ә.Рәшитов, Г.Морат, Р.Зәйдулла, Г.Бәйрәмова; яшьләрдән Л.Шәех, Р.Мөхәммәтшин, Л.Фәтхетдинова, Р.Сәлах, Б.Ибраһимов һ.б.)**

**Публицистика**

**Т.Биктимерова.** Татарстанда 1921 елгы ачлык фаҗигасе; **Х.Исмәгыйлев.** Кырым татарлары фаҗигасе; **Н.Шәрифуллин.** Сез каласыз... (күптән очсызланган кыйммәтләр, беркем ярлыкамас гөнаһлар хакында); **Ф.Хатипов.** Судан электр энергиясе алу хикмәтләре турында.

**Фән, әдәби тәнкыйть һәм сәнгать**

**Д.Исхаков.** Бөек ауразиячеиең бер ялгышы (Л.Гумилев турында); **Рәмзи Вәлиев.** Ватанга багышланган гомер (Г.Шәрәф турында); **А.Зыятдинов.** Буыннар язмышы (академик Әхмәт Мазһаров турында); **Л.Шәех.** Халыкара ПЕН-клуб турында; **А.Хәлим.** Ф.Габдерәхим иҗаты; Мирсәй Гариф. Башкортстанда Тукай эзләре; **Р.Мәрданов.** «Кыз хикәяте» кыйссасы; **Фатих Котлы.** Татар-төрек әдәби багланышлары; **Искәндәр Яркәев.** Фәнгә багышланган гомер. Галимҗан Нигъмәти шәхесе һәм иҗаты; **Ә.Шакиров.** Баштан кичкән хәлләр...

Традиция буенча, дөнья әдәбияты һәм кардәш әдәбиятларыбызның иң яхшы үрнәкләре белән таныштырып барачакбыз.

2011-12 елларда конкурс итеп үткәрелгән «Печән базары» журналда сатирик әсәрләрнең даими сәхифәсе (рубрикасы) булып кала.



Вера Хәмидуллина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)